# Казан утлары

8. 1993



## ХӨРМӘТЛЕ УКУЧЫЛАРЫБЫЗ!

**Вакыт агышын һич тә туктатам димә икән... Хәер, соңгы елларда ул бигрәк тә ашыгып ага башлады. Сәяси мохитта булсын, иҗтимагый тормышта булсын, вакыйгалар, калейдоскоптагы кебек, берсен-берсе алыштырып кына торалар. Сезнең кебек үк без дә,— ягъни редакция хезмәткәрләре дә,— моны ачык тоеп яшибез. Әнә ич, соңгы бер-ике ел эчендә газета-журналларга язылуны да икегә — яртыеллыкларга ваклап-чәрдәкләп оештыра башладылар. Ләкин без, ни генә булмасын, шатбыз: чөнки шушындый авыр вә мәшәкатьле бер вакытта да 1993 елның икенче ярты еллыгына 26 меңгә якын укучы «Казан утлары» журналын алдылар. (Башка күләмле басмалар белән чагыштырганда шактый күп бу!) Димәк, безнең меңләгән дустыбыз, киңәшчебез бар. «Казан утлары»н һаман да кызыксынып укыйлар!**

**РӘХМӘТ СЕЗГӘ, ӘДӘБИЯТ СӨЮЧЕЛӘР!**

**Ләкин, әйткәнебезчә, Вакыт тәгәрмәче бик тиз тәгәри шул. Журналның бу саны Сезнең кулга килеп кергәндә, менә тагын 1994 ел өчен язылу мәшәкатьләре башланып киткән булыр. Без ышанабыз, иң тугрылыклы укучылары журналны ярты юлда ташлап калдырмаслар һәм аны алдыруны алга таба да дәвам итәрләр.**

**Әйдәгез, кадерле туганнар, «Казан утлары» балкуыннан туктамасын! Ә без үз чиратыбызда, татар язучылары, шагыйрьләре, галимнәре, публицистлары һәм, гомумән, татар халкы язмышы өчен янып-көеп яшәгән иҗат әһелләре белән берлектә, моның өчен бөтен көчебезне куеп эшләргә һәм иҗат итәргә тырышырбыз.**

**Кыскасы, «Казан утлары»на языгыз, язылыгыз, бәйләнештә торыгыз!**

**Безнең адрес: 420066. Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 йорт, 10 кат.**

**Журналның индексы — 73210.**

**«Казан утлары» редакциясе.**

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

**ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:**

**ТАТАРСТАН ХӨКҮМӘТЕ, ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ**

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

**8**

**(850)**

**1993**

КАЗАН


## *Бу санда*


ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР ҺӘМ ШИГЪРИЯТ

Ф. ЯХИН. Ахырзаман пәйгамбәре. *Кыйсса* . . . 3
Н. ӘХМӘДИЕВ. Хатирә. *Шигырьләр* . . . . . . 53
Х. ХӘМИДУЛЛА. Тәкъдир каршында. *Повесть* 56
Н. МӘДИЯРОВ. Сүз тәэсире. *Шигырьләр* . . . . 73
Ә. САТТАР. Көздән бер мизгел. *Шигырьләр* . . . 76

ДӨНЬЯ ӘДӘБИЯТЫ ҮРНӘКЛӘРЕННӘН

Я. КӘМАЛ. Болан риваяте . . . . . . . . . . 78

РАВИЛ ФӘЙЗУЛЛИНГА — 50 ЯШЬ

Н. ГАМБӘР. Башны салларга салып... *(Портретка штрихлар)* . . . . . . . . . . . . . . . . . 97
Р. ФӘЙЗУЛЛИН. Авылда кышкы төн. *Шигырьләр* 110, 120
Журнал язмышы — безнең язмыш . . . . . . . 118

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

И. НИЗАМОВ. Уелып калды уйлары . . . . . . 125

ДИСКУССИЯ ДӘВАМ ИТӘ

Ф. БӘШИР. Исә җилләр . . . . . . . . . . . 131

ХАЛКЫБЫЗ ТАРИХЫНА

Д. РАМАЗАНОВА. Урал буе татарлары: тарихы һәм теле . . . . . . . . . . . . . . . . . 141

МӘДӘНИЯТЕБЕЗ ТАРИХЫНА

Ф. БАЯЗИТОВА. Керәшен татарларының туй йолалары һәм җырлары . . . . . . . . . . . . 163

ФӘН ҺӘМ ТОРМЫШ

Т. КАМАЛ. Рух . . . . . . . . . . . . . . 170

МӘСЬӘЛӘГӘ БЕР КАРАШ

А. ТИМЕРГАЛИН. Бер сүз тарихыннан . . . . 174

*Баш мөхәррир*
**Равил Фәйзуллин**

*Редколлегия*
**Гариф Ахунов**
**Гүзәл Вәлиева-Сөләйманова**
**Тәлгат Галиуллин**
**Аяз Гыйләҗев**
**Салих Маннапов**
**Зиннур Мансуров**
**Рөстәм Мингалимов**
**Фәрвәз Миңнуллин**
**Минтаһир Минһаҗев**
**Мөхәммәт Мәһдиев**
**Ринат Мөхәммәдиев**
**Рашат Низамиев**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Индус Таһиров**
**Наис Гамбәров**
*(җаваплы сәркатип)*
**Тәүфикъ Әйди**
*(бүлек мөхәррире)*
**Марсель Әхмәтҗанов**

Безнең адрес: 420066,
Казан, Декабристлар ур., 2.

Телефоннар:
баш мөхәррир — 53-07-60,
баш мөхәррир урынбасары — 53-07-09,
җаваплы сәркатип — 53-36-12,

*бүлекләр:*

шигърият, фән,
хатлар — 53-07-61,
чәчмә әсәрләр, сәнгать,
тәнкыйть — 53-07-63,
корректорлар — 53-07-65.

ЕЛМАЕП-КӨЛЕП КЕНӘ

М. ГАЛИЕВ. Нәни шаярулар . . . . . . . . 178
Р. КӘРАМИ. Куян булу җиңел дисезме . . . . . 179

Фотоларда — заман сурәте . . . . . . . . . . . 182

ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕНДӘ — ТАТАР ШӘХЕСЛӘРЕ

Б. СОЛТАНБӘК. Кәримевләр язмышы . . . . . 184

Безнең календарь . . . . . . . . . . . . . . . 186

Латин әлифбасы нигезендә татарча уку күнекмәләре . . . . . . . . . . . . . . . . . 188
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан . . . . . . 190

## В НАШЕМ НОМЕРЕ

«Проза и поэзия»: повесть-притча Ф. ЯХИНА «Последний пророк конца света», повесть Х. ХАМИДУЛЛЫ «Судьба»; стихи Н. АХМАДИЕВА, Н. МАДЪЯРОВА, А. САТТАРОВА.
«Из страниц мировой литературы»: «Легенда об олени» Я. КАМАЛА.
«К 50-летию Р. Файзуллина»: «Штрихи к портрету» статья Н. ГАМБАРОВА. Стихи и статья Р. ФАЙЗУЛЛИНА.
«Литературная критика»: статья И. НИЗАМОВА о современных проблемах языка.
«Дискуссия: Наша жизнь. Наша литература»: статья Ф. БАШИРОВА «Дуют ветры».
«К истории народа»: статья Д. РАМАЗАНОВОЙ «История и речь татар приуралья».
«К истории культуры»: статья Ф. БАЯЗИТОВОЙ «Свадебные обряды и песни крещенных татар».
«Наука и жизнь»: статья Т. КАМАЛА «Дух».
«Один взгляд на проблему»: статья А. ТИМЕРГАЛИНА «Из истории одного слова».
«Юмор-сатира»: стихи М. ГАЛИЕВА и рассказ Р. КАРАМИЕВА.
Фотографии М. ШАКИРЗЯНОВА.
Статья Б. ЄУЛТАНБЕКОВА «Судьба Каримовых».
Навыки чтения на основе латинской графики.
На наших обложках: «Красная мечеть» — картина уфимского художника И. Бикбулатова; известный писатель Р. Хисматуллин.

*Мөхәррирләр:* Мансур Вәлиев, Рәдиф Гатауллин, Шамил Маннапов, Шаһинур Мостафин, Рәшит Әхмәтҗанов.
*Техник мөхәррир:* Тәслимә Сибгатуллина.
*Корректорлар:* Гөлзада Моратова, Лилия Гатауллина.
*Машинисткалар:* Флера Сабирова, Гөлназ Хөснетдинова.

Производствога бирелде 1.07.93 ел. Басарга кул куелды 4.08.93 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70 × 108 ¹/₁₆. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8).
Тираж 25 787. Заказ Я-400. Бәясе 20 сум.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән. Теркәлү таныклыгы № 7.

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1993 ел.



**Фәрит Яхин**

# АХЫРЗАМАН ПӘЙГАМБӘРЕ

КЫЙССА

## Пәйгамбәрлекнең унынчы елы

Бу елда гомерләрен кяферлектә уздырып, якасына үлем ябышкач кына мәңгелек йортны исенә төшергән вә җәннәткә керергә исәп тоткан бәндәләр өчен бик тә гыйбрәтле вакыйга булды. Ул исә Мөхәммәтнең агасы Әбу-Талип белән бәйләнгән. Китаплар бу хакта болай дип сөйлиләр. Адашкан вә туры юлда булган кешеләрнең барчасына гыйбрәт булсын!

Әбу-Талип үлем түшәгенә егылды. Тәне авырайды, әҗәле якынлашканнан-якынлашты. Корәишләр аның хәлен белергә вә соңгы сүзләрен ишетергә дип, түшәге янына җыелдылар. Шунда Әбу-Талип болай диде:

— Мин инде дөнья белән бәхилләшү минутларын кичерәм. Шуңа күрә сезгә васыять итеп әйтеп калдырыр сүзләрем бар. Белегез, Мөхәммәт чын мәгънәсендә Аллаһы тәгаләнең колы һәм ул үз белдеге белән генә сезне иманга чакырмый, бу — аның Иясенең әмере. Мин аның изге бәндә булуына ышанам. Әмма вакытында диненә керә алмадым. Аңлагыз, барлык гарәп вә күп халыклар исламга килерләр, аның динен кабул итәрләр. Ул барыбер өстен чыгар. Аның юлына аркылы төшмәгез,— дип, калтыранган тавышы белән нәсыйхәтләрен әйтте.

Әмма әйләнә-тирәсендәгеләр бар да Мәккә кяферләре булганлыктан, уртәү кебек бер мескен энине уйларына кертепме, әллә инде сынау ясапмы:

— Мөхәммәт синең энең вә туганың. Җәннәт бакчасыннан сиңа җимешләр вә шәрабләрдән өлеш чыгарыр әле,— дип әйттеләр.

Әбу-Талип боларның сүзләрен үзенчә кабул итте һәм арадан бер кемсәне пәйгамбәр янына йөгертте.

---

Ахыры. Алдагы өлеше журналыбызның 7 санында чыкты.

— И Мөхәммәт, абзаң Әбу-Талип үлем түшәгендә ята, синнән хәер дога өмет итә, аңа җәннәт бакчасыннан бер ашарлык җимеш насыйп ит? — дип, бу бәндә пәйгамбәребезнең каршына килеп баш орды үтенечен бәйнә-бәйнә сөйләде. Әмма Мөхәммәт галәйһис-сәлам бер генә сүз белән дә җавап бирмәде. Күндерелгән кешегә хәбәрсез кайтырга туры килде. Пәйгамбәр җавап бирмәде исә, димәк, имансыз кешегә җәннәт сараеннан бер бөртек җимеш тә вә бер тамчы шәраб дә тәтемәячәк иде.

Мөхәммәт галәйһис-сәламнән кайткан кеше шушу хәлне сөйләп бирде. Барчасы да пәйгамбәр шәфкатеннән вә Аллаһы тәгалә ярлыкавыннан мәхрүм булуларын аңладылар. Әмма...

Бу кемсә сүзен сөйләп бетерүгә, Әбу-Талип йортының тупсасыннан пәйгамбәр үзе атлап керде. Бөтен йорт эчен кяфер корәишләрнең тыгызлап торганын күрде, әмма аларның бер-бер зыян итүеннән куркуны кирәккә санамыйча, түргә узды, Әбу-Талипның янына түшәккә утырды һәм:

— Болар барчасы бераз вакытка икебезне генә калдырсыннар, сөйләшер сүзләрем бар, — дип таләп куйды. Әмма корәишләр:

— Әбу-Талип безнең якыныбыз, аны һич тә калдыра алмыйбыз. Сиңа туган булган кебек ул безгә дә кадерле, — дип киреләнделәр.

Шуннан соң Әбу-Талипка карап, Мөхәммәт:

— И абыем, барлык теләкләрнең вә өметләрнең кабул кылына торган вакыты иде, Хак тәгаләнең бер-бер кәлимәсен әйт, мин аның алдында сиңа ярлыкау теләрмен вә шәфкатен сорармын, — диде.

— Ул нинди кәлимә соң? — дип сорады Әбу-Талип хәлсез тавыш белән.

— Аллаһы тәгалә бердәнбер, аннан башка бүтән илаһи зат юк, — дип, Мөхәммәт галәйһис-сәлам кәлимәне Әбу-Талипка җиткерде. Бәндәләр тынсыз калдылар. Үлем тырнагына каба барган Әбу-Талип үз файдасына вә җәннәт эченә керүе өчен генә дә бу сүзләрне әйтер дип өмет иттеләр. Тынлык хөкеме барчасының җилкәсенә авыр таш булып ятты. Әмма Әбу-Талип:

— Әгәр дә мин сау-сәламәт кеше булсам һәм дә үлем якасында тормасам, шаһитлар каршысында әйтәм ки, һич тә шикләнүсез динеңне кабул итәр идем. Ә хәзер исә үземнең ялгышканымны танудан тыш һичбер нәрсә әйтә алмыйм. Үлем якасында булуы өчен генә, җәннәткә керергә теләп исламны кабул итте, дип әйтмәсеннәр, шуңа күрә үземне... мәхрүм итәм, — дип белдерде дә бер мөнәҗәт әйтте. Бу мөнәҗәтендә Аллаһы тәгаләгә дан җырлавын вә исламны мактавын башында аңы булганнар аңламый калмадылар...

Әбу-Талип вакыйгасыннан соң корәишләр арасында икеләнү хисе хөкем сөрә башлады, йөрәкләре урыннарыннан өзелеп төшкәндәй булды һәм ничек тә иман китерү теләге белән яши башладылар. Исламның юлы киңәйде, иманга килүчеләр арта барды.

Риваятьләрдә шулай сөйләнелә ки, Әбу-Талип соңгы сулышында барыбер иманга килде, әмма аның сүзләрен янындагылар ишетә алмады. Ул сүзләр, гүяки, бу дөньялыктан мәңгелек йортка кереп барганда теленә килде, җирдәге тормышы белән бәхилләшү авазы да һәм бакый тормышны сәламләүләре дә аның тарафыннан шушы сүзләр белән әйтелделәр.

Мөхәммәт пәйгамбәр агасы Әбу-Талипның үлемен бик авыр кичерде. Җеназасы артыннан елап-сыктап барды. Телендә һаман да Аллаһы тәгаләдән мәрхүм рухына мәрхәмәт үтенү сүзләре булды. Рәсүлебез агасын ярлыкауны һәм аны җәннәтле итүне кат-кат сорады. Чөнки Әбу-Талип һашим кабиләсенең җитәкчесе иде, барлык туган-тумача, нәсел-нәсәбе аның әмеренә буйсына, таләбеннән чыкмый, сүзен аяк астына салып таптамый иде. Ул гына да түгел, һәммә корәишләр арасында мөхтәрәм карт саналып, аңа каршы чыгарга һичберәү батырчылык итми һәм хөрмәтеннән Әбу-Талипны мәхрүм калдырмый иде. Шуңа күрә дә Мөхәммәт пәйгамбәргә никадәр җәбер-золым юллаган Мәккә кяферләре

чиктән узып китә алмадылар. Әбу-Талип тәрбиясен күргән вә аның һаман да сөекле туганыннан булган Мөхәммәт шәһәр эчендә яшәп кала алды. Ә агасы вафат булгач, хәлләрнең начар якка үзгәрәчәге көн кебек ачык иде.

Пәйгамбәребезнең дога-үтенечләре Аллаһы тәгаләгә килеп иреште һәм Әбу-Талипның җаны җәннәтле ителде. Абыйсының үлемен бик авыр кичергән пәйгамбәргә Җәбраил галәйһис-сәлам бу хакта хәбәр җиткерде, шуннан соң гына рәсүлебезнең бит очыннан соңгы күз яшьләре киптеләр. Гомеренең ахыргы мизгелендә иманга килеп өлгерүе вә Мөхәммәт галәйһис-сәламнең катлы-катлы үтенеч догалары аркасында гына Әбу-Талипның рухы җәннәт сараеның ишекләрен ачып керә алды.

Әйтерләр ки, иман китерергә бервакытта да соң түгел! Чөнки Әбу-Талип та туксан яшенә кадәр имансыз торды, әмма дөньялыкта яшәгән вакытында яманлыкка караганда яхшылыкны күбрәк кылды вә Мөхәммәт саллаллаһ галәйһис-сәламне тәрбия итүдә үзеннән зур өлеш кертте. Аңлашыла булса кирәк, бары тик шулар аркасында гына Әбу-Талип Аллаһы тәгаләнең мәрхәмәтеннән өлешсез калмады.

Абыйсын җирләп кайтканнан соң, Мөхәммәт галәйһис-сәлам өеннән берничә көннәр буена чыкмады. Әбу-Талип рухына вә Ибраһим пәйгамбәргә, ягъни нәсел бабасына атап догалар чыкты, Ходайга үтенечләрен җиткерде. Барчасы кабул булды. Аңа ияреп, мөселманнар вә хәтта кяферләр дә шушы рәвешчә үз бабаларын вә нәсел-нәсәпләрен исләренә төшерделәр, аларның рухына хәер-догада булдылар.

Әйтерләр ки, җирдәгеләр бәхете — күктәгеләрнең шатлыгы өчен, күктәгеләрнең шатлыгы — җирдәгеләрнең бәхете өчен. Бу сүз хактыр!

Билгеле булсын, кяфер дигәннән, кяферләр дә ике төрле. Бер төрлесен әйтерләр «кяфер инкарь» дип, икенче төрлесен — «кяфер җөхуди», диярләр. Ягъни, беренчесе — «Аллаһы тәгаләне инкарь итүче кяфер» булса, икенчесе — «Аллаһы тәгаләгә ышанып җитмәүче, хәерсез кяфер» була. Беренчеләре исә йөрәкләре вә җан-күңелләре белән Аллаһы тәгаләне танымыйлар, юк дип саныйлар. Аларның телләре Алла исемен әйтүне түбәнлек саный, иманлы кешеләрдән көлү — аларның төп шөгыле була. Алар Аллаһы тәгаләнең ярлыкавыннан мәңгегә мәхрүм. Мондый кешеләр барчасы да Әбу-Җәһил кебек кемсәләр.

«Кяфер җөхүди»ләрнең иманнары янәшәдә генә йөреп, күңелләренә кереп ояламаганлыгы билгеле булсын. Бу кемсәләр җаннары вә йөрәкләре белән Аллаһы тәгаләгә инаналар, аның сыйфатларына вә үзенә тел озайтмыйлар, әмма дә ләкин Аллаһы тәгалә исемен телләре белән әйтеп, аңа дога вә хәер кыла алмыйлар. Җаннары бер төрле уйлап, тәннәре икенче тарафка хәрәкәт итә. Әбу-Талип исә нәкъ шушындый кемсәләрдән иде. Аның җаны вә йөрәге Аллаһы тәгаләнең барлыгына ышанды, шуңа күрә аның уллары беренчеләрдән булып иман китерде, Мөхәммәт пәйгамбәрнең яраннарыннан саналдылар. Бигрәк тә Гали бине Әбу-Талип хәзрәтләре ислам өчен күп батырлыклар кылды. Әмма Әбу-Талип үзе иманга вакытында килә алмады, теле әйләнеп, Хак тәгаләгә бер дога да юлларга хәленнән килмәде. Юкса үзе шагыйрь иде. Имеш, Мөхәммәткә ияреп, ул бервакыт намазга да тезләнгән иде, җаны белән иман да китергән иде, әмма халык алдына чыгып, изге кәлимәне адәм балалары ишетелерлек итеп кабатлый алмады. Шунлыктан кяфер хәлендә калды. Җан вә тәннең үзара дошманлыгы да шушындый затларда күренә. Аларның бер ишесе җәннәтле, икенчеләре тәмуг кисәүләренә әйләнәләр. Барча эш Аллаһы тәгалә әмереннән тора.

Пәйгамбәрлекнең унынчы елы Мөхәммәт галәйһис-сәлам вә әһеле-ислам өчен зур кайгылы ел булды. Югалтулар бер-бер артлы килеп, бәхетсезлек сөремен ислам йөзенә сарылган кебек иттеләр. Авыр, бик авыр иде хәлләре. Шуңа күрә дә ул елны «каты кайгы вә сагыш елы» дип атадылар, икенче төрле әйткәндә, бу 619 ел «матәм елы» буларак хәтерләрдә калды. Әбу-Талип вафат булганнан соң өч көн үтүгә, пәйгам-

бәребезнең хатыны вә чын мәгънәсендә тормыш вә дин иптәше Хәдичә ханым да гүр иясе булды.

Риваятьләрдә шулай хәбәр ителә: Хәдичә ханым авырып түшәккә яткач, пәйгамбәребез һәрвакыт аның янында булды. Әйтте:

— И хатыным Хәдичә, синең урының җәннәттәдер, ислам хатыннарының иң күркәме вә иң акыллысы син булдың, Мәрьям вә Асия һәм дә Хәува синең кыз карендәшләрең вә көндәшләрең икәнлекне үзең дә җәннәттә белерсең, алар синең исемеңне телләрендә йөртәләр, үзеңне күрү өметендә яшиләр,— дип хәбәр итте.

Хәдичә ханым аларның исемнәрен телгә алды, Хак тәгаләгә рәхмәтле булды, сабырлык сорады.

Әйтерләр, Мөхәммәт пәйгамбәр мигъраҗга ашкач, җәннәттә аңа Мәрьям вә Асияне никях иттеләр. Мәрьям исә Гайсә пәйгамбәрнең әнкәсе, Асия исә Мусаныкы иде.

— Минем хатыным Хәдичәгә уртаклык булыр,— дип, Мөхәммәт галәйһис-сәлам никяхтан баш тартты. Әмма шунда Хәдичә ханым күренде һәм:

— Асия белән Мәрьям минем кыз карендәшләрем, шунлыктан алар миңа уртаклыктан була алмый! — дип җавап бирде. Шулай итеп, Мөхәммәткә алар насыйп кылынды.

Вакыйгаларны сөйләүчеләр шундый хәбәр китерә.

— Җәннәтле булгач, әни үлгәч ник еладың? — дип сорады пәйгамбәребезнең кызы Фатыйма.

— Аны сагынып еладым! — дип җавап бирде әтисе.

Хәдичә чын мәгънәсендә сагынырлык зат иде шул. Чөнки ул һәрвакыт иренең кайгы-хәсрәтләрен, уңышларын вә югалтуларын үзенеке кебек кабул итте. Һич тә Мөхәммәтне киңәш-табышсыз калдырмады. Балаларына игелекле ана, иренә тугры хатын булды. Аның белән бергә яшәгән чакларында Мөхәммәт галәйһис-сәлам бер генә тапкыр да башка бер яшь хатынга өйләнү вә гашыйк булу хакында сүз әйтмәде, бу турыда күңеленә уй да салмады. Алар арасындагы мәхәббәт Фәрһад вә Ширин, Таһир илә Зөһрә һ. б. тасвири гыйшык ияләренең бетмәс-төкәнмәс кайнар утларыннан да көчлерәк вә шагыйрәнә бөегрәк иде. Әйтерләр ки, Хәува белән Адәм мәхәббәтеннән кала, дөнья йөзендә Хәдичә белән Мөхәммәтнең гыйшкы иң көчлеләрдән иде. Чөнки аларның бер-берсенә булган сөю хисләреннән тыш күңелләрендә Аллаһы тәгаләгә карата уртак ярату да яшәде, ә бу мәхәббәт исә атаның — балага, баланың анага булган ярату хисе төсле үк чиста вә саф, шул вакытта, үзара ир һәм хатынның да гыйшкын көчәйтә ала торган ут иде ки, ялгышмыйча әйтерләр, аларның бер-берсенә мәхәббәте, Аллаһы тәгаләгә юлланган хисләре белән бергә өртелеп, күкләргә кадәр ашкан һәм гүзәл бер гөл чәчәге төсле балкыр иде.

Хәдичә бай хатын булып, бар табыш-килешен ире Мөхәммәт пәйгамбәрнең дин эшләре өчен салды, мөэминнәрнең тынычлыгы хаҗәтенә сарыф итте. Шуңа да аны «Ислам анасы» дип атадылар. Фараз кылып кына да әйтергә мөмкин, әгәр дә Хәдичә ханым иренә шулкадәр ярдәмнәр күрсәтмәсә, Мөхәммәтнең барлык омтылышлары тагын да зуррак авырлыклар белән генә тормышка ашар иде һәм, бәлки, пәйгамбәр кяфер кабиләләр өстенә вә Мәккәгә бәддога да юллаган булыр иде. Мөхәммәт пәйгамбәр Хәдичә киңәше белән Мәккәдән китмәде, корәишләр алдында ачуланышып сүз башламады. Түземлек вә сабырлык кебек күркәм сыйфатлары Хәдичә ханым аркасында аның йөзендә нур булып балкыды.

Әйтерләр ки, хатыны нинди булса, ире дә шундый! Бу сүзне мәгънә ягыннан тирәнтен төшенгән кемсәләр белә, ирне тәрбия кылган хатыннан да күркәмрәк кешене дөнья йөзендә табып алуы мөмкин түгел. Ул исә бәхет белән бәрабәр бер төшенчәдер.

Китапларда шулай язалар, Хәдичә ханым вафат булганда гомере алтмыш биш яшькә таба бара иде. Мөхәммәт пәйгамбәр аның гәүдәсен

үз кулллары белән гүргә иңдерде, күзләрендә яшь иде. Бары тик Аллаһы тәгалә каршысында эшләргә тиешле эшләре генә аның үзен дә гүр иясе булудан саклап калды. Хәдичә белән аерылышу Мөхәммәт пәйгамбәр өчен бик зур югалту иде.

Әбу-Талипның вә Хәдичәнең вафатыннан соң Мөхәммәт пәйгамбәр бик күп елады, күзләреннән аккан кайнар яшьләрен тыя алмады. Бик озак кайгы-хәсрәт чикте. Ә көннәрдән беркөнне шушындый авыр вакытында аңа корәиштән бер төркем кяферләр очрап, аннан көлә башладылар. Арадан берсе учына туфрак алып, пәйгамбәрнең өстенә сипте, аны мыскыллады. Мөхәммәтне шушы хәлендә кызы Фатыйма күрде, күзләреннән яшь агызып, аның итәкләрен туфрак-тузаннан чистартты.

— Мәккәдә Әбу-Талип агам бар чагында корәишләр миңа кул күтәрергә вә болай мыскылларга кыймый иделәр, хәзер ул да юк. Елама, кызым, Хак тәгалә мине ярдәменнән ташламас һәм тугры юлыннан күндәм баруым өчен тәрбиясеннән аермас,— дип, Мөхәммәт пәйгамбәр кызын юатты.

Әбу-Талип урынына һашимилар нәселенә Әбу-Ләһәп юлбашчы кылынды. Ул кемсә Әбу-Талипның туганы булса да, холкы вә акылы белән аннан бик түбән тора иде. Мөхәммәтнең пәйгамбәрлеген һичбер вакыт өнәмәде, ничек кенә булса да аны үз нәселдәшләреннән аерырга тырышты, таиләгә төшкән барлык бәхетсезлекләрне Мөхәммәтнең пәйгамбәрлегеннән күрде.

Бер көнне исә Мөхәммәт галәйһис-сәламгә Әбу-Җәһил очрады һәм аны бик каты итеп орышты да:

— Моңа кадәр сине Әбу-Талип агаң яклап килде, инде ул да юк, Лат вә Гузза потларым белән ант итеп әйтәмен ки, Мәккә шәһәреннән синең эзеңне корытачакмын! — дип янады.

Бер кемсә корәишләргә килеп әллә юри, әллә үч кайтарып:

— Әбу-Ләһәп иман китергән, Мөхәммәт энесенә кушылган,— дип хәбәр бирде. Бу сүзне ишетүгә Әбу-Җәһил, барча кяферләрен җыйнаштырып, Әбу-Ләһәп тупсасыннан атлап керде һәм:

— Сине исламга кергән дип сөйлиләр, хак сүзме? — дип ачулы йөзен аңарга төбәде.

Бу хәлнең әлегә кадәр булмаганлыгы хакында Әбу-Ләһәпнең сүзләрен ишеткәч кенә тынычландылар болар. Әмма аптыраштан битәр тау кадәр җыелган ачуларын басып бетерә алмадылар, Әбу-Ләһәпне иман китерергә барыбер барыр дип уйладылар.

Әбу-Ләһәп исә иман китерергә бер дә ашыкмый иде. Шулай да Мөхәммәт пәйгамбәр белән сөйләшеп карарга уйлады. Бәлки, Аллаһы тәгаләнең хак юлыннан кире кайтыр вә иске динен тота башлар дип өметләнде, үгет-нәсыйхәт кылырга да исәбе юк түгел иде. Мөхәммәт пәйгамбәргә килде, сорады:

— Туганыбыз Әбу-Талип җәннәтле булдымы? — диде.

Тел төбе яхшы аңлашылды: кяфер була торып та җәннәткә керергә мөмкиндер ич! Әмма Әбу-Ләһәп бик каты ялгышты. Мөхәммәт пәйгамбәр аның тел төбен бик тиз төшенеп алды һәм:

— Кяфер кешегә җәннәтне өмет итү мөмкин эш түгел, кяферләр тәмуг утында мәңге яначаклар,— дип җавап бирде.

Пәйгамбәрдән бу сүзләрне ишетүгә, корәишләрнең ачулары тагын да кабарды. Гүяки, аларның җәннәттән мәхрүм булуларына Мөхәммәт галәйһис-сәлам гаепле иде, гүяки, ул аларны тәмугка мәҗбүри кертә иде. Шунлыктан ачу ташларын ахмаклык утында кыздырдылар һәм Мөхәммәт пәйгамбәргә үчләшә вә каныга башладылар. Төрле яклап аны кысрыкларга вә җәберләргә уйладылар. Хәзер инде, Әбу-Талип вә Хәдичәнең вафатыннан соң, Мөхәммәтне яклаучы вә саклаучы туган-тумачасы калмаган төсле булды. Мөселманнар әлегә барчасы бергә җәбер вә золым диңгезе эчендә калдылар. Әбу-Ләһәп исә һашим гаиләсен Мөхәммәтне якламаска күндерә алды. Әбу-Җәһилнең шатлыгы эченә сыймады,

әмма шулай тоелды гына, чынлыкта исә бу «бәхете» озакка бармаячак иде.

Мәккә шәһәрендә аек акыл иясен очрата алуына шикләнә башлагач, Мөхәммәт галәйһис-сәлам дин карендәше булган Зәйд бине Харис белән каладан читкә таба юл алды. Башта Бәкер бине Ваил кабиләсенә һәм башка бәдәви кабиләләргә төбәп киттеләр. Әмма берсендә дә аларны кабул итмәделәр, сырт йоннарын кабарткан этләр шикелле ырылдап каршыладылар. Хәтта кайберләре аларга ташлар атты. Шундый бер очрашудан соң китеп барганда таш аткан ахмакларның берсе Мөхәммәтнең башына туры китерде. Пәйгамбәр канга буялды.

Бу кадәр дә кадерсез, бу кадәр дә авыр чаклары һичкайчан булмагандай иде.

Алар шушы китүдән Рабига балалары хөкем йөрткән бер уйсулык-оазиска, ягъни бакчага керделәр. Мөхәммәт пәйгамбәрнең өмете тәмам киселгән иде. Бер агач төбенә барып утырды. Аяклары канаган вә уңышсызлык авырлыгыннан бәгыре телгәләнгән чагы, нишләсен, теленә аять вә үтенеч килде һәм ул:

— И Аллаһы тәгалә, бу кадәр җәбер вә кимсенүләрне дә миңа күрсәттең, аяк табаннарым кан булды, әмма кяферләрне иманга китерә алмадым. Сыеныр затым бары син генә. Синнән башка минем яклаучым юк. Син бер нур! Шул нурың белән барча караңгылыкларны яктырт, бәндәләреңнең күзен ач,— диде.

Аның бу сүзләрен Рабига кабиләсенең олугларыннан Гатабә вә Шәйбә ишетеп тордылар, яннарында бер коллары да бар иде. Ул колның исеме Гаддас иде. Дине христиан булганга, аңа Аллаһы тәгалә белән сөйләшкән бу кемсә бик якын тоелды. Теге олугларның да тәннәрендә тын гына йөреп торган каннары кайнарланды, күңелләрендә мәрхәмәт хисе уянды һәм алар, Мөхәммәт пәйгамбәргә күрсәтеп, коллары Гаддаска ризыктан бирәр нәрсә китерергә куштылар.

Бу кол дигәннәре бик тә тыңлаучан вә җиренә җиткерүчен булганлыктан, әмерне тиз үтәде. Пәйгамбәргә ризыкларны сиздермичә генә китереп куйды һәм соңыннан аның белән әңгәмә кылды. Аның пәйгамбәр булуын вә җәбер-золымнар күрүен белеште.

Әйтерләр ки, бу көндә ул кемсәләр иман китерделәр вә исламга керделәр, дип.

Мөхәммәт галәйһис-сәламнең авыр вә кайгылы көннәре булганлыктан, аның мөселман таифәсе дә шушындый ук хис-кичерешләр белән яшәде. Әмма шушы вакытта, риваятьләргә караганда, хикмәтле бер вакыйга булды, кырык мең җен исламга килде, иман китерде. Китаплар бу вакыйганы болай дип язалар.

Көннәрдән беркөнне алты җен заты Мәккә яныннан узып бара иделәр, ишеттеләр, Мөхәммәт галәйһис-сәлам дога укып, Аллаһы тәгаләгә дан вә сәламен җиткерә иде. Тавышы гаять дәрәҗәдә күркәм вә укыганы җанга ятышлы булганлыктан, бу җеннәр барыр җирләрен оныттылар һәм, рәсүл янына килеп, сүзләренә колак салдылар. Сорадылар:

— И адәми зат, бу укыган әйберләрең ни-нәрсә?—диделәр.

— Бу—Аллаһы тәгаләдән иңгән Бөек Коръәннең аяте иде, ишеттегез булса кирәк,— дип җавап бирде пәйгамбәр.

Риваятьләр, бу вакыйганы кичке якта булды, дип сөйлиләр. Берничә кат сүз алмашканнан соң, җеннәр иман китерделәр һәм үз өсләренә башка җеннәрне дә иманга китерү вә исламга дәгъва кылу бурычын алдылар. Шуннан соң барчасы бергә юк та булып, икенче көнне тагын кырык мең җенне алып килделәр.

Мөхәммәт галәйһис-сәлам Габдулла бине Мәсгуд белән бергә утыра иде. Пәйгамбәргә вәхи, иңеп, бу кич җеннәрнең иман китерәчәге хакында хәбәр ирешүе. Мөхәммәт, якын иптәше Габдулла бине Мәсгудне әйләндереп бер әйләнә-даирә сызды һәм аның эченнән чыкмаска боерды. Шуннан соң догага утырды. Ул арада артыннан вә яныннан җеннәр

болыт-болыт булып килделәр вә аңа ияреп аятьләрне укый башладылар. Габдулла бине Мәсгуд курка калды, пәйгамбәргә бер-бер зыян ясамасыннар, дип борчылды. Әмма Мөхәммәт галәйһис-сәламне күрмәде. Ул исә як-ягына өелешкән җен төркеме эчендә иде.

Барчасы бердән иман китерә башладылар. Пәйгамбәрнең нәсыйхәтләрен ишеткәннән соң гына күтәрелделәр вә, төркем-төркем булып, болыт кебек күкләргә оча-оча, юкка чыктылар.

Бу вакыйганы Мөхәммәт галәйһис-сәлам үз дусларына сөйләде. Әмма аларның берсе-бер ышанмады һәм дәлил таләп иттеләр. Шунда каршысында үсеп утырган агачка пәйгамбәр төртеп күрсәтте вә аның шаһит булуын белдерде, сүзе хакмы-ялганмы икәнен сорады.

Рәсүлнең таләпләрен ишетүгә, агач җиргә кадәр иелде һәм телгә килеп:

— Мөхәммәт пәйгамбәр сөйләгән хәлләр дөрес, ул, чын мәгънәсендә, Аллаһы тәгаләнең җирдәге илчесе. Аңа җеннәр дә иман китерделәр,— диде.

Бу вакыйгага кемнәр — ышанды, кемнәр — аптырады, кемнәр исә аны игътибар күзеннән читкә куйды. Әмма ләкин безнең көннәр өчен дә хәбәр булсын диярәк, хәдис вә аятьләрдә бу хакта мәгълүмат калды.

Пәйгамбәрлекнең унынчы елында булган вакыйгалардан тагын да бер хикмәтлесе Тафил бине Гомәр Дәүсинең иманга килүе иде. Ул кемсәнә Дәүси кабиләсенең җитәкчесе булып, арада, хөрмәт вә дан тотудан тыш, батыр һәм күркәм кешеләрнең берсе иде.

Аның Мәккәгә килүен корәишләр күреп алдылар һәм, янына җыелышып, әңгәмә кордылар. Мөхәммммәт пәйгамбәрдән зарландылар, әйттеләр:

— Безнең шәһәребездә дуслык, хөрмәт вә тигезлек кебек күркәм сыйфатлар чәчәк ата иде. Әмма Мөхәммәт үзен Алланың илчесе дип атап, динебездән көлә башлады. Үзенә кешеләрне аударып, аларны безгә каршы котыртты,— дип төрле сүзләр белән рәсүлне яманлый башладылар.— Аны һәлак итмичә безнең шәһәребездә тынычлык вә иминлек булмас,— дип белдерделәр.— Син аның янына барып, сүзләренә колак сала күрмә, юкса башкаларны үз ягына аударган төсле сине дә саташтырыр,— дип нәсыйхәт вә киңәшләрен дә бирделәр.

Тафил аларның сүзләренә колак салды, рәсүл янына бармаска булды, Кәгъбәгә таба юнәлде. Олуг потларга үзенең ягыннан тиешле хөрмәтләрне күрсәтеп чыгарга уйлады. Керде. Анда Мөхәммәт пәйгамбәр дога укып утыра иде. Тафилнең колакларына ирексездән пәйгамбәрнең сүзләре кереп йөрәген кузгаттылар, акылын сафландырдылар. Тафил бине Гомәр:

— Бүген миңа киңәш биргән вә бу кемсәнәне яманлаган ул кешеләр көнчелек вә ачу белән генә шулай эшләгән булсалар кирәк, чынлыкта һәр адәмнең үз башы үзенә. Сүзләре һич тә яманга охшамаган. Аның белән сөйләшеп тә карыйм әле,— дип уйлады, әмма пәйгамбәрнең догасын бүлдермичә, тәмамлаганын көтте.

Мөхәммәт галәйһис-сәлам, намазын укып бетерүгә, үз йортына таба юнәлде. Тафил аның артыннан китте. Күңеле курку вә икеләнүләрне белмәде. Пәйгамбәргә ияреп йортына ук керде.

— Йа рәсүл, мин шәһәрдәге корәишләр белән сөйләштем, алар сине яманладылар, синнән зарландылар, сүзләреңә колак салмаска киңәш иттеләр. Әмма бу көн сүзләреңне ишеттем, алар күңелемә хуш килделәр. Аңладым, бу кемсәнәләр сине үчлек итеп вә көнләшеп яманлыйлар икән. Инде дә үз динең хакында миңа мәгълүматыңны бирсәң иде? — дип үтенде шулчак Тафил.

Пәйгамбәр аңарга шәригатьтән бераз белем бирде, аятьләрдән берничәсен укып күрсәтте.

— Минем моңа кадәр бер генә дә бу сурәттә күркәм сүзләрне ишеткәнем булмаган иде. «Әшһәдү ән лә иләһә илләллаһи вә әшһәдү ән

Мөхәммәдән рәсүлуллаһи»,— дип, Тафил бине Гомәр Дәүси иман китерде һәм,— и пәйгамбәр, мин кабиләмә кайтам, кабиләмнең исеме Дәүси булып, аларны иманга китерергә рөхсәтеңне бир,— дип үтенде.

Шунда Мөхәммәт галәйһис-сәлам аңа иман юлын өйрәтте. Китапларда шулай язылган ки, Тафилның кулында бер янар ут төсле якты нур хасил булды. Аны «иман нуры» дип атадылар. Ул үз кабиләсенә кайтып ирешге. Башта әткәсе янына керде һәм:

— Мин мөселман булдым, ислам дине алдым, без хәзер бер-беребез белән бер юлдан баручылар вә сәламләшүчеләр түгел инде,— дип белдерде.

— И улым, син кайсы диндә булсаң, мин дә шул диндә булыйм,— дип, атасы да иман китерде. Аннан соң әнкәсә вә туганнары да, иман китерделәр. Шуннан Тафил бине Гомәр үзенең Дәүси кабиләсенә чыгып сүз әйтте, аларны иманга чакырганда, кайсы иман китерде, әмма күпчелеге батыйль диннәрендә калдылар. Моңа Тафилнең бик каты ачуы чыкты... Пәйгамбәр янына килеп:

— Минем кавемемнән бик күпләр иман китермәделәр, динеңне кабул итмәделәр, аларга бәддогаңны юлла?— дип үтенде.

Әмма Мөхәммәт галәйһис-сәлам Тафилнең үтенечен кире какты, бары тик:

— Дәүси кабиләсенә, Хак тәгаләм, шәфкать-бәхетләреңне ирештер,— дип сорады.

Тафил бине Гомәр, пәйгамбәрнең бу сүзләреннән соң, Мөхәммәтнең никадәр изге вә шәфкатьле кеше булуын аңлап алды һәм җаны-тәне белән аңа хезмәт итә башлады, барлык гомерен изгелек юлына салды.

Әйтерләр ки, бу Дәүси кабиләсен, үз заманы җиткәч, Әбу-Бәкер хәзрәтләре барып иманга китерде. Шунда Тафил бине Гомәр дин юлында шәһит китте.

Хәдичә ханым вафатыннан соң, Мөхәммәт галәйһис-сәламнең йортында эшләрне карар кеше калмады. Пәйгамбәребез үзе бик тә инсафлы кешеләрдән булганлыктан, өс-башын, чәчен-сакалын үзе карый, киемен үзе юа, тузганын үзе ямый иде. Әмма йорт арасына барыбер хатын-кыз кулы кирәк булганлыктан, өйне җыештырырга Госман бине Мәзгуньнең хатыны Хәүлә-Хәким кызы килеп йөри башлады. Көннәрдән беркөнне җае туры килеп:

— И Мөхәммәт пәйгамбәребез, синдәй олуг кешебезгә ялгыз тору бер дә әйбәт түгел, сиңа бер күркәм хатын вә киңәшче кирәк,— дип белдерде.— Әгәр рөхсәтегез булса, сиңа лаеклы бер хатынны табарбыз.

— И Хәүлә, минем хезмәтемә лаек нинди хатын булыр икән?— диде пәйгамбәр.

— Аның берсе хатын кешедән булыр, икенчесе исә кыз баладан булыр,— диде Хәүлә.

— Алар кемнәр?— дип сорады пәйгамбәр.

— Хатын дигәнем — Сәүдә булыр, кыз дигәнем — Гайшә, Әбу-Бәкер баласы,— диде Хәүлә.

— Ярый, икесен дә эзлә,— диде Мөхәммәт галәйһис-сәлам.

Шушы бурычны өстенә йөкләп, Хәүлә Әбу-Бәкер капкасына килде. Ул вакытта Гайшә әле балигъ булмаган үсмер кыз иде. Үзе бик чибәр иде. Әтисе Әбу-Бәкер исә, Хәүләдән Мөхәммәт пәйгамбәргә кызын никах кылып бирергә мөмкинлек барлыгын ишетүгә, аптырашта калды:

— Карендәшкә карендәшне бирү дөрес булырмы?— дип сорады.

— Дин карендәшенә дин карендәшен никах кылу дөрес булыр, кан карендәшенә кан карендәшен никах дөрес булмас,— дип белдерде Хәүлә. Бу сүзләрне ишетүгә, Әбу-Бәкернең йөзе яктырып китте, бәхет аңа ишелеп килә иде, чөнки пәйгамбәр белән туганлашу зур мәртәбә буларак кабул ителде.

Әмма бу никахка каршылык килеп туды. Электән Гайшә Мотгыйм бине Гуданың малае белән яраштерелеп куелган иде. Әбу-Тали бу хакта Хәүләгә җиткерде, ә ул исә:

— Мотгыйм бүгенге көндә дә кяфер булып кала бирә, мөселман башың белән кяфергә кызыңны бирерсеңме? — дип сорады.

Шушы сөйләшүдән соң Әбу-Бәкер Мотгыймга китте. Аны дингә чакырды, иман китерергә кушты. Әмма Мотгыйм ахмаклык юлыннан чыгарга җыенмады. Шуннан соң Әбу-Бәкер аңа үзенең кызын хатынлыкка бирү мөмкин түгеллекне белдерде, үзара төзелгән килешү туктатылды.

Пәйгамбәр үзен соратуны ишетүгә, Гайшә бик тә сөенде. Әбу-Бәкер йортына бәхет иңде, шатлык тулды. Гайшәне укырга вә язарга өйрәттеләр, пәйгамбәр хатыны булырлык дәрәҗәдә гыйлем бирергә теләделәр, чөнки Гайшә яшь килеш Хәдичә ханым урынына килергә тиеш иде.

Хәүлә шуннан соң Сәүдә янына барды. Билгеле булсын ки, Сәүдә үзе утыз яшьләрдәге тол хатын булып, Мәккәгә кайткан иде. Беренче мөслимәләрдән иде. Ире, риваятьләргә караганда, Сәкрән бине Гомәр иде, Хәбәш иленә күченеп, шунда яшәделәр. Сәкрән анда христиан диненә күчте һәм, озак тормый, вафат булды. Сәүдә исә Мәккәгә кайтып, Хәдичәдән соң пәйгамбәрнең хатыны булырга бик тә теләде. Теләге хакында пәйгамбәргә дә ирештерде. Хәүлә шуңа күрә Мөхәммәт галәйһис-сәламгә аны да хатынлыкка тәкъдим итте, рәсүл әкрам каршы килмәде.

Әмма Мөхәммәт пәйгамбәр Сәүдәне ярата алмады. Яратмыйча никахка керү дөрес булмаганлыктан, пәйгамбәр талак әйтте. Шунда Сәүдәнең күзләре канлы яшь белән тулдылар. Ул үзенең гыйшкы хакында такмаклап-такмаклап сөйләде, аяк астында туфрак булыйм, дип егылды. Мөселман кешенең мөслимәне кимсетүе зур гөнаһлардан иде. Сәүдә:

— Әгәр дә хатының итмәсәң, колың яса, хезмәтләремне күрсәтермен, бар эшеңне үзем башкарырмын. Гайшәгә һичбер вакыт көнчелек күрсәтмәмен, көндәше булмамын, — дип үтенде. Аннан соң Гайшә янына китте, үзе белән бу хакта сөйләшергә теләде.

Китапларда шулай дип белдерелә ки, бу көнне Мөхәммәт пәйгамбәргә Җәбраил фәрештә килде һәм:

— Хак тәгалә әмере белән билгеле булсын, бу Сәүдә Күкләр тарафыннан саклана, аны безнең гарип-ятим балабыз дип белегез. Син аны талак кылдың. Әмма Аллаһы тәгалә әмерен җиткереп әйтәм, син аны үзеңнән аерырга тиеш түгелсең. Ул сиңа гашыйк кылынды. Синең хатының булсын! — дип белдерде. Шуннан соң гына Мөхәммәт галәйһиссәлам Сәүдәне үз йортында калдырды. Гайшә бик яшь булганлыктан, ул балигъ булганчы, Сәүдәгә никахланып торды.

Сәүдә исә хәзерге Гомәр заманына кадәр яшәде һәм вафатыннан соң Мәдинә шәһәренә җирләнде.

Пәйгамбәрлекнең унынчы елы әнә шушы вакыйгалар белән тарихка кереп калды...

## Мәккә кяферләре белән бәхәсләр

Мөхәммәт саллаллаһ галәйһис-сәламнең укымыйча да гыйлем вә һәр әйткәненең адәмнәр күңеленә ирешерлек булуы белән Мәккә кяферләрен хәйран калдырганлыктан, алар пәйгамбәребезне сихерче вә бозучы дип белдерә башладылар. Шул рәвешле, аннан көлү, рәнҗетү һәм мөселманнарны җәберләү кебек эшләрдән чирканмадылар. Бозык җаннары, томаналыклары аркасында, шакшылык сазлыгына кереп батты. Аларны моннан тартып чыгарыр өчен Мөхәммәт галәйһис-

сәлам күпме көч вә тырышлык сарыф итте, алар белән дуслык мөнәсәбәтендә булып карады, шул рәвешле үзләренә ярдәмен бирергә иде исәбе.

Көннәрдән беркөнне Мәккә кяферләреннән олуглары булган Гатабә һәм Шәйбә, Әбу-Сафйан, Надар бине Әл-Харис, Әбу-Бухтури, Әбу-Җәһил, Әсвәд бине Әл-Мотлап Кәгъбә дивары янына җыелышып сөйләштеләр һәм әйттеләр:

— Бу Мөхәммәт һаман да үз динен таратуны дәвам итә, әйткән сүзләребезгә колак салмый, җәбер-золымнарыбызга сөртенеп баш-аяк килми, үзен чакырып алыйк, сөйләшик. Кеше көлкесенә калдырыйк,— дип сүз беркеттеләр һәм, бер кемсәне пәйгамбәр янына күндереп, аны үзләренә чакырттылар.

Мөхәммәт галәйһис-сәлам килде болар янына.

— Ни диеп сөйләшергә исәбегез?— дип сорады рәсүл.

— Син безнең динебездән вә потларыбыз-аллаларыбыздан көлдең, үзебезне наданнар вә ахмаклар, караңгылыкта яшәүче томаналар дип атадың, кабиләләрне таркатып бетердең. Әйт, болай эшләүдән максатың нәрсә? Әгәр дә солтанлык, йә булмаса дан, яки башка бер-бер әйбер эзләр булсаң, таләбеңне күндер, барсын да хасил итәрбез, әмма үз динеңә өндәүдән һәм дә бездән көлүдән тукта,— диделәр.

— Минем максатым, һичбер мал яки солтанлык, йә булмаса башка бер әйбер түгел. Мин, Хак тәгаләнең арагызга күндерелгән пәйгамбәре буларак, сезне тамуг якасыннан коткарырга, барчагызны җәннәтле итәргә генә телим. Кешеләрне ике дөньяда да иман белән яшәп, бәхет иясе булырга өйрәтәм. Мин сезгә Коръән китердем. Әмма сез каршы төштегез. Сабыр итәрмен. Хак тәгалә ни-нәрсә әмер итсә, шуны үтәрмен. Мин бары тик аның әмерен үтәүче вә теләкләрен инсаннарга җиткерүче генә,— дип җавап бирде аларга Мөхәммәт галәйһис-сәлам, сабыр холыклы булуын күрсәтеп.

Мәккә томаналары бу сүзләрне ишетүгә, кабарынып тордылар, кайсы орыша, кайсы кыза башлады. Алар:

— Син үзеңне Аллаһның пәйгамбәре дип атадың. Сүзләреңне Хак тәгаләңнән килә дип белдердең, иманга чакырып, үзеңә хәер-садака теләдең. Әгәр дә син чыннан да шундый пәйгамбәр икәнсең, күрсәт безгә могҗиза! Мәккә янындагы таулар вә ташлар күченсеннәр, бакчалар чәчәккә төренсен, барчасында җимеш вә сайрар кошлар тулып торсын, чиста сулар вә чишмәләр челтерәп аксыннар, Шам шәһәрендәге вә тирә-ягындагы төсле булсын, шатлык-сөенечләр белән гомерләребез үтәр, шул чагында без дә иман китерербез,— дип каты таләпләрен куйдылар.

Аларга каршы Мөхәммәт галәйһис-сәлам:

— Мине аның өчен пәйгамбәр итмәделәр,— дип җавап бирде.

— Әгәр дә боларны булдыра алмыйсың икән, ул вакытта күктән бер фәрештә килсен һәм, безгә күренеп, синең хактан да рәсүл, Аллаң илчесе булуыңны дәлил итсен?— дип томаналар тагын да ачулы тавышлар белән дәштеләр.— Әйдә-әйдә!— дип шаулаштылар. Аларны таләпләреннән туктатырга һич тә мөмкин түгел иде инде.

— Сез әйткән нәрсәләр минем максатыма туры килми, мине моның өчен пәйгамбәр итмәделәр,— дип җавабын кабатлады Мөхәммәт.

— Син бит халыкны алдыйсың,— дип шашынды кяферләр,— синең Аллаң да, фәрештәләрең дә юк. Әгәр бар икәннәр, алар сиңа күркәм вә сихри бакчалар ясап бирсеннәр, үзеңне алтын белән көмсеннәр, зиннәтле сарайлар төзесеннәр. Ул вакытта халык иманга килсә дә, без каршы булмабыз!

Томаналарның шашынулары җиткән иде, менә хәзер аларга бер хикмәтле могҗиза күрсәтсәң, барчасы бердәй егылачаклар иде. Мөхәммәт галәйһис-сәлам моны яхшы аңлады. Һәм ул:

— И корәиш халкы, Хак тәгалә мине сезгә Коръәнне өйрәтергә күндерде, миңа сез таләп куйган эшләрне йөкләмәде һәм сез теләгәннәр-

не таләп вә әмер белән хасил итәргә куймады,— дип үтемле итеп җавап бирде.

— Без сиңа иман китермибез, әгәр Аллаһ бар икән, һич югы безгә газап күндерсен, без шуңа да риза,— дип көлештеләр Мәккә кяферләре.

— Аллаһы тәгалә бөек зат, ул ни теләсә, шул була. Тәүбәгә килегез! — диде рәсүл.

— Болай булгач бел, без сине һәлак итәчәкбез, шулай сөйләштек. Әгәр дә үзеңнең иман таләбеңнән тукталмыйсың икән, син арабызда вә шәһәребездә йөрергә тиешле түгел, син үләргә тиеш! — дип кычкырыштылар ярсыган корәишләр. Аларның дәһшәт дингезе ярларыннан ташып чыкты, телләре өстенә утырып Шайтан биеде, күзләрен утлы очкыннар каплап алды. Мөмкин булса, хәзер үк пәйгамбәрне җиргә салып таптыйсылар иде. Шунда арадан берсе:

— Фәрештәләреңне чакырмыйча, сиңа иман китерү юк. Алланың кызлары — фәрештәләр килсеннәр, үзләрен күрик,— дип көлә башлады. Шунда халык арасыннан пәйгамбәрнең туган тиешлесе Габдулла бине Өмәййәт калкынды һәм:

— Минем сиңа иман китерәсем юк, бар, күккә мен, аннан фәрештәләрне китер яки бер китап китер, алар синең пәйгамбәрлегеңә шаһит булсыннар. Әгәр боларның барчасын да җыеп китермәсәң, мин синең пәйгамбәрлегеңә ышанмыйм, сине Алла илчесе дип танымыйм, иман да китермим. Бар, китер барысын да! — дип кычкырды. Аның бу сүзләреннән соң Мөхәммәт галәйһис-сәлам борчуга төште. Бу томаналарның шул надан хәлләрендә калачакларын вә ахмаклыклары телләрен шулай сөйләткәнен аңлап алды. Йортына кайтып китте. Озак кына вакытлар онытылып утырды. Шулвакыт Җәбраил галәйһис-сәлам вәхи китереп, аны тынычландыру вә Мәккә кяферләренең хәленнән хәбәр бирү, шушындый җаһил халыкның мескенлеген аңлату өчен аять күндерде, алар куйган таләпләрнең барчасы җәннәттә әзер булуын хәбәр итте...

Мөхәммәт галәйһис-сәлам, кяферләрне калдырып, үзенең йортына кайтып киткәч, Әбу-Җәһил аптырап утырган корәишләрнең каршыларына чыгып басты һәм:

— И халык, Мөхәммәтнең бу эшләренә асылда сабырым вә тәкатем калмады. Ул безнең динебезне мәсхәрә кыла, арабызга дошманлык уты сала, талаштыра, безне гөнаһка батыра. Без аны үтермәсәк, ул безне харап итәчәк,— дип кызарып-бүртенеп, ярсып-шашынып сөйли башлады.— Ант итеп әйтәм, бүген ул монда сәҗдәгә килгәч, бер дә куркып тормыйча, башына таш белән орам. Кардәшләре аның канын кайтарыр өчен мине һәлак итсәләр дә, исем китми. Болай яшәп тә, торып та булмый. Мин моңа риза түгел! — диде.

Ул вакытларда Мөхәммәт пәйгамбәр Кодсе (Иерусалим) тарафына карап намаз укый торган иде. Урыны да Кәгъбә уртасында булганлыктан, вакыты җиттеме, һичбер нәрсәгә карамыйча шушында килә иде.

Иртә булды. Гадәтенчә, пәйгамбәр намазга Кәгъбәдәге үз урынына килде, сәҗдә итте. Бу арада кулына ләгыйнь Әбу-Җәһил алдан әзерләп куелган олы бер таш алды һәм арттан Мөхәммәт галәйһис-сәламгә таба килә башлады. Барлык корәиш ни булыр икән дип читтән генә күзәтеп торды. Мөхәммәт пәйгамбәр исә һичбер нәрсә дә сизенмәде, догасын дәвам итте.

Әбу-Җәһил акырын-акырын якын килә бирде. Баш өстенә олы ташны кизәнеп күтәрде һәм катып калды. Кайбер риваятьләрдә әйтелә ки, бу таш аның кулына ябышты, дип. Бер риваятьтә исә, аның куллары корыды, дип язалар.

Әбу-Җәһил сугар җиреннән ташны ыргыта алмады, тораташ булды. Пәйгамбәр исә намазын дәвам итте. Артында басып торган Әбу-Җәһилне бар дип тә белмәде. Корәишләр Әбу-Җәһилнең таш белән пәйгамбәрне менә-менә сытасын күрде. Дөнья тып-тын калды. Менә Мөхәммәт

галәйһис-сәлам нурлы йөзен игелекле куллары белән сыпырды, намазны тәмамлап калыкты. Әмма Әбу-Җәһил һаман да хәрәкәтсез тора бирде.

Китеп барган пәйгамбәрне Мәккә кяферләре туктатып, Әбу-Җәһил ягына төртеп күрсәттеләр. Ул тораташ кебек каткан хәлендә һаман да тора иде.

Килделәр. Кулларының каткан икәнлеген күрделәр һәм Мөхәммәт пәйгамбәрдән ярдәм үтенделәр. Ул тагын догага утырды һәм Әбу-Җәһилнең кулларын язу-савыктыруны Аллаһы тәгаләдән үтенде. Шуннан соң гына кяфернең куллары язылып, ташы төшеп китте вә чак кына үзенең аяк бармакларын изми калды.

Мәккә кяферләре Әбу-Җәһилдән үтенделәр:

— Сөйлә, нигә сүзеңдә тормадың? Нишләп болай катып калдың? — дип.

Әбу-Җәһил үзенең оят күләгәсе артына кереп качардай булды һәм:

— Мин аның янына якынлаштым. Менә-менә таш белән орырмын дигәндә генә каршымда бер аждаһа пәйда булды һәм, авызыннан утлар чәчеп, мине туктатты, чарасыз калдым, кулларым тораташ булдылар. Ул намазын бетергәнче аждаһа мине саклап торды, Мөхәммәт янына адым да атлатмады, — дип озак вә озын сөйләп акланды.

Тарихлар шулай хәбәр итә ки, ул вакытта Җәбраил галәйһис-сәлам Әбу-Җәһилнең эшен күреп алды һәм хәтәр ачуы килде. Бер аждаһа сурәтендә аның каршына барып басты. Авызыннан ут өрде. Мескеннең куллары катып калдылар. Әгәр бу ахмак тагын да бер генә адым атласа иде, ул вакытта бөтенләй тораташ буласы иде.

Шушы вакыйгадан соң Мәккә кяферләре намаз вакытында пәйгамбәр өстенә ташланудан курка башладылар. Шулкадәр өркеделәр ки, әгәр дә шунда бер көчсез генә өн ишетелсә дә, җаннары тәмуг җәфасына олагасы иде. Әмма вакыйгалар үз чиратлары белән бара бирделәр.

Корәишләр арасында бигрәк тә Әбу-Ләһәп җәһәннәм утына ышанмады. Ул боларның барлыгын шундый оста итеп инкарь итә иде ки, хәтта кулларына ут алып, болар минем җанымны тәнемнән аермый, дип әллә нинди сүзләр сөйли башлый иде. Әгәр пәйгамбәр тәмуг хакында хәбәрләрен бирә башласа, теләсә ничек булсын, аннан көләргә вә кире дәлилләр эзләргә тотына һәм:

— Минем тәнемнән җаным һич тә аерыла алмас, — ди торган иде. Аның бу кыланышларыннан соң пәйгамбәр:

— Әбу-Ләһәпнең тәмуг утында иң беренче булып куллары өзелеп төшәр, — дип хәбәрләрен бирде.

Бу сүзләр Әбу-Ләһәпкә килеп иреште. Бу вакытта гаурәт мәсьәләсе дә билгеле булды. Болардан хәбәр алган Әбу-Ләһәп түземлеген югалтты, тәкате калмады. Кулына таш алып, Кәгъбәгә килде һәм Әбу-Бәкер Әс-Сыйддыйк белән пәйгамбәрнең сөйләшеп утырганнарын күреп алды да ташы белән ормакчы гына иде, ике күзе дә Мөхәммәт галәйһис-сәламне күрмәс булды. Әбу-Ләһәп башта аптырап калды, Әбу-Бәкер утыра, әмма пәйгамбәр күренми иде.

— Мөхәммәт кая китте? Таш белән башына тондырмакчы идем, күрми дә калдым, юк булды? — дип Әбу-Бәкердән сорап карады бу ахмак. Әмма Әбу-Бәкер Әс-Сыйддыйк җавап бирмәде. Үзенең янында утырган Мөхәммәт галәйһис-сәламне яхшы күреп тора иде, шунлыктан һичбер исе китмәде.

Әбу-Ләһәп тагын пәйгамбәрне эзләп бакты, әмма күрмәде. Шуннан соң, бу качты бугай дип уйлады да, ташын читкә атып, кабаттан боларга карады. Күрде, Мөхәммәт галәйһис-сәлам һаман да шул урынында утыра иде.

Бу хәлдән соң шушы кяфер курка калды һәм тизрәк үз ишләре янына йөгерде. Аларга вакыйгадан хәбәр биреп, пәйгамбәрне сихер иясе вә бозык кемсә дип атады.

Бу сүзләрне мөселманнар колагына барып житәрлек итеп сөйләделәр ки, алар да курка калдылар. Әмма, куркудан бигрәк аптырадылар. Әгәр дә пәйгамбәр дип йөргән кешеләре сихерче булса, моннан да яманрак ялган, алар фикеренчә, булмаска тиеш иде, чөнки сихерчеләр бары тик Шайтан ләгыйньгә генә хезмәт итәләр, Аллаһы тәгалә әмеренә буйсынмыйлар иде. Шуна күрә барчасы да пәйгамбәр янына җыелдылар. Әбу-Ләһәп вакыйгасын сөйләп биргәннән соң, Мөхәммәт галәйһис-сәлам аларга:

— Ә аның таш күтәреп килүен Хак тәгалә күрми калды дип беләдегезме? Юк. Күрде, әлбәттә. Аның күз нурын алып, миңа күчерде. Шунлыктан ул мине күрә алмады, бары тик Әбу-Бәкерне генә күрде,— дип җавап бирде.

Мәккә кяферләре арасында ни шайтан, ни адәм нәселеннән булган Надар бине Әл-Харис исемле үтә дә ахмак вә оятсыз бер бәндә бар иде. Теләсә кайда торып, төрле җирдә һәм илләрдә йөреп, күп кенә кыйсса вә хикәятләр өйрәнеп, Рөстәм һәм Әсфәндияр турында риваятьләр тыңлап, шулардан тәм табып өлгергән бер мокыт иде. Әгәр кайда булса да Мөхәммәт галәйһис-сәлам Коръән хакында хәбәрне бәян итә башласа, аннан бер-бер аять укыса, халыкка иман хакында өйрәтергә тотынса, хәзер шушы Надар килеп җитә һәм тыкшына-сөйләнә үз ягына халыкны аудара иде. Телен телгә йоктырмыйча, вакыйгаларны тәмләп вә озаклап, уратып-уратып сөйли иде ки, барча адәмнәр авызларын ачкан хәлдә, дөньяларын онытып, аның сөйләгәнен тыңлап утыра иделәр.

Бервакыт Мөхәммәт галәйһис-сәлам Вәлид бине Мөгайрәнең җәмәгате белән Коръән хакында сөйләшеп, Хак тәгалә турында хәбәрләрен бәян итә иде, араларына шушы мөртәт Надар бине Әл-Харис килеп керде һәм пәйгамбәр белән бәхәс кыла башлады. Мөхәммәт галәйһиссәламнең бик каты ачуы килде, аларның тәмугка олагасылары хакында әйтте дә мәҗлесне ташлап чыгып китте. Бу хәлдән соң җәмәгать аптырашта калды, күңелләрен курку биләде. Араларына Габдулла бине Зәбгари килеп керде. Аңа да пәйгамбәр әйткән аятьне кабатлап әйттеләр. Габдулла исә моның чын асыл мәгънәсен аңлый алмады һәм:

— Пәйгамбәр исә Гозәер вә Муса пәйгамбәрләрне тәмугка олаккан дип әйткән, аларның тәмугка керүләреннән хәбәр биргән икән...— дип сөйләнеп алды.

Бу сүзләрдән соң Вәлид бине Мөгайрәгә җыелышкан халык тагын да аптырашта калдылар, мәсьәләне чишәргә үзләренең гыйлемнәре житмәде, Надар мәлгуньнең боларга тәэсире үтми иде. Никадәр гыйлем иясе булып күренгән кемсәләрнең көймәләре комга терәлде, акыллары кайнарланып чыкты, җаннары көйрәде. Аптырашта калган халык тагын да икенче вакыт җәмгыять вә мәҗлес җыеп, Мөхәммәт галәйһис-сәламне чакырттылар. Болар үзләренең наданлык дәрәҗәсен күрсәтеп, аның әйткән сүзләрен аңлатып биргәч, пәйгамбәр:

— Гозәир вә Муса һәм дә Гайсә пәйгамбәрләр хакында монда һич тә сүз бармый, бәлки аларның сурәтләрен ясаган һәм аларга табына башлаган кемсәләр хакында әйтелде,— дип беләдерде.— Аларның сурәтләренә табынуны Аллаһы тәгаләгә сәҗдә кылудан өстен күрә башлаган кешеләр дә шулай ук кяфер булып, тәмугка олагачаклар. Чөнки алар Шайтан коткысына бирелделәр һәм фиргавен ничек потлар ясатып, шуларга табынса, болар да шул рәвешле сурәтләр ясап табына башладылар,— диде.

Шушы хәбәрләрне ишеткәч кенә халык тынычлана алды. Юкса күңелләрен кайнар хәсрәт уты яндырып бетерәчәк иде.

Шушы вакыйгадан соң Мөхәммәт галәйһис-сәламнең чын мәгънәсендә пәйгамбәр вә галим булуы тагын да ныграк ачыкланды, Мәккә кяферләрендә дә аңа карата яшертен бер хөрмәт хисе кузгалды.

Әбә бине Хәләф һәм Гакабә бине Әбә-Могыйт үзара бик дус иделәр. Әмма икесе дә пәйгамбәргә үтә дә дошман булдылар. Беркөнне Гакабә-

нең күңелендә бер нур балкып, ул нур илә тәэсирләнде вә Мөхәммәт галәйһис-сәлам янына килеп, аннан Коръән аятьләрен тыңлады, бик тә күңеле булып, өенә кайтты. Әмма аны Әбә каршы алды һәм:

— Минем янyма киләсе булма, башка мин сине күрмим вә синең белән сөйләшмим! — дип антлар эчте.

— Әйт, ни гөнаһым булды? Ни сәбәптән син мине шулай инкарь итәсең? - диде аңа Гакабә.

— Үзең дә беләсең. Ни өчен син Мөхәммәт янына бардың һәм аның сүзләрен тыңладың? Мин аңа ышанмыйм, ә син ышандың, — дип ачуланды аны Әбә.

Шуннан соң Гакабә кабат пәйгамбәр янына килде һәм аның сүзләрен ялганга чыгарырга маташты, исламга кермәячәген белдереп китеп тә барды.

Шушы вакыйгадан кяферләрнең илаһи сүзне аңламаулары һәм Шайтан юлында йөрүләре ачык булып, пәйгамбәргә күркәм бер аять вә хәдисләр иңде. Томананың күңеле ачылса да, акылы туң булса, һаман да наданлык тоткынында кала бирә икән.

Кяферләр арасында котки таратучыларның берсе булган Вәлид бине Могайрә халыкка шундый бер сүз сөйләп йөри башлады. Имеш, Мәккәдә Мәсгуд бине Гамер, Гамир бине Сафафи кебек күркәм вә бай һәм дәрәҗә иясе кешеләр була торып, нигә Аллаһы тәгалә Мөхәммәт кебек бер ятим, малсыз, дәрәҗәсез кешегә генә хәбәр китерә дә, фәрештәләр арадан нигә аны гына сайлап ала?.. Әмма ул Аллаһы тәгалә каршында барлык кешеләрнең дә бердәй булуын аңлый алмады, кешеләрне дә тышкы сыйфатлары белән сайлап алмавын белмәде. Шуңа күрә аның сүзләре кяферләрне котыртса да, мөселманнарның иманнарын какшата алмады.

Әбә бине Хәләф беркөнне череп беткән бер кеше башының сөяген тапты һәм кулына алып:

— Бу да күпме гомерләр үткәч терелеп, җан алып, мәйданга килерме? — дип көлә-көлә сөйләнде дә пәйгамбәр каршысына китте. Кызык ясап, Мөхәммәтне аптырашта калдыру иде исәбе. Шуңа күрә үзалдына көлемсерәп килде. Баш сөяген пәйгамбәргә күрсәтеп:

— Син, адәмнәрне үлгәннән соң каберләреннән кубарылалар һәм дә үз гөнаһлары өчен җәзаларын алалар, дисең. Ул вакытта бу баш сөяге дә кабереннән торгызылып, аңа җан иңеп, терелеп, үз җәзасын алырмы? — диде дә шул сөякне куллары белән уып ташлады.

— Әйе, бу баш сөягенә дә җан кайтыр. Ә син, кабереңнән кубарылып җәһәннәм коесына олагырсың! — диде аңа Мөхәммәт галәйһиссәлам, һәм дә үз сүзләрен дәлилләп, Коръән һәм дә хәдисләреннән берничәсен бәян итте.

Кяферләр белән Мөхәммәт пәйгамбәр арасында шушындый вакыйгалар бик еш кабатланып торды. Алар ничек тә булса аны рәнҗетергә вә аннан көләргә теләделәр. Яңадан-яңа хәйләләр уйлап чыгардылар, берберсенә сөйләп көлдерергә уйладылар. Әмма дә ләкин Мөхәммәт галәйһис-сәлам аларның ни-нәрсә теләп киләселәрен алдан ук Җәбраил фәрештәдән ишетеп, аларга җавабын әзерләп тора иде. Шунлыктан Мәккә кяферләренең төкрек вә селәгәйләре үз иякләреннән читкә төшмәде, мескеннәр үз ахмаклыкларына үзләре гарык булып, һаман да шулай көлке хәлдә кала иделәр.

Шушы вакыйгалар, әлбәттә, могҗиза иде. Шулай итеп, пәйгамбәрлекнең унберенче елы тарих мәйданына чыкты. Бу елда зур бер истәлекле вакыйга булды. Мәдинә шәһәреннән хаҗ кылып Мәккәгә килгән алты кемсә Мөхәммәт галәйһис-сәлам белән очраштылар һәм иман китерделәр. Алар Хазрәҗ кабиләсенең олуглары иделәр. Исемнәре: Әсгать бине Зурарә, Гавеф бине Харис, Гакабә бине Гамир, Җабир бине Габдулла, Кутабәт бине Гамир бине Хәдид һәм Рафигъ бине Малик. Алар, Мәдинәгә кайтып, халыкны иманга өндәргә булдылар һәм Мөхәммәт

галәйһис-сәламне шәһәрләренә чакырып, ислам дине таралуга бар мөмкинлекләрен вә ярдәмнәрен бирәселәрен әйттеләр.

## Бөек мигъраҗ[1] вакыйгаларыннан хәбәрләр

Мәккәдә булган вакыйгаларның иң зурларыннан берсе, әлбәттә, Мөхәммәт галәйһи вә сәлләмнең мигъраҗы, ягъни Күккә сәяхәте булды. Бу хикмәтле хәбәрләрне китаплар бик тәфсилләп язарга яраталар, ниятем алардан калышмаска иде... Әмма иҗат атын аларның сүз кәрванына тагып йөри торгач, шактый озак вакытлар туры юлдан адашып калдым, аптырадым. Хикәяне каян башларга, ничек итеп сөйләргә белмәдем. Мигъраҗ хакында китаплар никадәр күп булса, буталулар да шулкадәр үк арта барды. Кайбер язучылар мигъраҗ кичәсен Рабигыль-әүвәл аенда пәйгамбәрлекнең уникенче елында булган, дип язсалар, икенчеләре рәҗәп аен күрсәтәләр, өченчеләре Рабигыль-ахыр аеның егерме җидесен хакыйкатькә чыгарып, дүртенчеләре исә Рамазан шәриф аеның җидесенә туры китерәләр, бишенчеләре бөтенләй мигъраҗны Мәдинә шәһәренә һиҗрәт иткәннән, ягъни күченгәннән соң булды диләр. Мин инде, арадан иң дөресе дип Мөхәммәт пәйгамбәр хәдисләреннән вә олуг китаплардан алып, бу вакыйга пәйгамбәрлекнең уникенче елында, ягъни 622 елда, Рабигыль-әүвәл аеның дүшәмбе кичәсендә Өмме-Һани йортында, ястү намазыннан соң Мөхәммәт пәйгамбәр йокыга талгач булды, диеп сөйләүчеләр ягында торам.

Мөхәммәт галәйһис-сәлам ул кичәдә шактый озак вакытлар догада булды, намазын тиз генә өзәсе итмәде. Тәне бик каты арыса да, җаны сау булып, күңеле нindидер үзгә бер нурның тәэсирен тойды. Пәйгамбәр үзенең шактый арыганлыгын төшенде һәм урын өстенә ятты. Тәне тыныч кына изрәп китте, әмма җаны-күңеле һаман да уяу калды.

Шул вакытта Күк капусы ачылып китте һәм Җәбраил галәйһис-сәлам, үзенең канатларын сирпеп, пәйгамбәргә хәбәр салды:

— И Мөхәммәт, бу кичә шундый да бер олуг кичәләрнең берседер, йоклап ята торган вакытмы? Күкнең капуслары ачылыр, бәндәләрнең теләкләре кабул булыр, пәйгамбәрләр вә фәрештәләр саф-саф тезелеп басарлар. Бу көн ятып йоклыйлармы? — диде.

Хәбәрләрдә шулай сөйләнелә ки, Аллаһы тәгалә үзенең фәрештәләренә әмерен җиткерде, җәннәт сарайларын бизәргә вә нурландырырга кушты. Пәйгамбәрләргә саф-саф басып торырга вә арадан олуг бер хикмәтле вакыйга күренәчәгенә өметтә булырга боерды. Әйтерләр ки, пәйгамбәрләрнең җаннары үзләренең бөеклекләрен тойдылар вә фәрештәләр Хак тәгаләнең әмерен җиренә җиткерделәр.

Җәбраил галәйһис-сәлам җәннәт болынына килде. Монда кырык мең бурак йөреп торыр иде. Бурак дигәннәре, хикәяләрдән күренгәнчә, үзе ишәктән калку, аттан тәбәнәк булыр, әмма йөрешләре хикмәт илә бик тиз вә житешерлек кенә түгел икән. Җәбраил галәйһис-сәлам менә шулар янына килде. Барысының муеннарында бер кызыл якут эленгәнен һәм аларда «Лә илаһә илләллаһи, Мөхәммәдүр-рәсүлуллаһи» дип язылган мөһерне укыды. Барчасы да берсеннән-берсе күркәм, берсеннән-берсе ышанычлы иде. Фәрештә алар арасыннан кайсын да булса берсен сайлап алырга тиеш булганлыктан, аптырашта калды. Күрде, читтәрәк бер бурак күзләреннән энҗе яшьләр агызып елап тора иде. Аның янына килде. Сорады:

— Җәннәт болынында бар иптәшләрең дә шатлык вә рәхәтлек диңгезендә яшиләр, ә син арадан бер үзең генә моң-зар белән елап

---

[1] Мигъраҗ — Күккә ашу.

торасың. Күзләрең шулкадәр сагышлы, сине күрүгә күңелем өзелеп китәрдәй булды. Сәбәпләрен бәян кылсаң иде?— диде.

Шунда бурак телгә килеп әйтте:

— И фәрештәләр арасыннан иң хөрмәтлеләреннән булган Җәбраил, белмисеңме минем хәлемне? Хак тәгалә мәңгелек еллар башында ук бер әмер җиткереп, мине үзенең олуг колы Мөхәммәт галәйһис-сәлам пәйгамбәргә насыйп кылган иде. Изге кичәдә мин аны үз өстемдә йөртермен дип уйланылган иде. Әмма чиксез еллар узып та, бу вакыйгалар мәйданга чыкмады. Мин шушы вакыйганы сагынудан сагышлымын вә Мөхәммәт пәйгамбәрнең нурлы йөзен күрергә теләүдән зарлымын,— дип җавап бирде. Ошбу сүзләрдән соң Җәбраил фәрештә арадан шушы буракны сайлап алды һәм аның тугры хезмәттә буласын аңлады.

Риваятьләрдә шулай сөйләнелә ки, Мөхәммәт пәйгамбәрнең янына Җәбраил галәйһис-сәлам килде, Рәсүл йокысыннан айнып китте, торып утырды. Җәбраил фәрештә:

— Бу кичә Аллаһы тәгаләбез сине олугларын вә җәннәт сарайларын күрмәгә урыныңнан кузгатыр вә сиңа бер могҗиза буларак шул хәлләрне күрсәтер,— дип аңлатмалар бирде.

Мөхәммәт пәйгамбәр шушы сүзләрне ишеткәч, урыныннан купты һәм дә ике рәкәгать намаз чыкты. Бер риваятьтә әйтелер ки, тәһарәт алды, дип. Шул эше вакытында Җәбраил галәйһис-сәлам:

— И Мөхәммәт, бу эшеңне калдыр, сиңа Хак тәгалә әмере белән җәннәтнең Кәүсәр чишмәсеннән тәһарәт өчен су китерелде, шуның белән юыну мәслихәт күрелер,— диде.

Шуннан соң пәйгамбәрнең башына нурдан эшләнелгән чалманы кидереп, анда дүрт хатны күрделәр. Аның берсенә: «Мөхәммәт рәсүлуллаһ», икенчесенә: «Мөхәммәт нәбиуллаһ», өченчесенә: «Мөхәммәт хәлилуллаһ», дүртенчесенә: «Мөхәммәт хәбибуллаһ» дип язылган иде. Моннан соң исә пәйгамбәрнең аркасына Җәбраил фәрештә тагын да нурдан ясалган бер кием салды, беленә кызыл якуттан эшләнелгән ярымай, кулына яшел зәмрә камчы бирде. Аягына яшел зәмрәдән башмак кидерделәр.

Тагын да хәбәр бар ки, шуннан соң җәннәттән Микаил фәрештә алтын ләгән алып килде һәм пәйгамбәрнең эчен ачып, дүрт ләгән Кәүсәр суы белән барлык әгъзаларын юдылар һәм Җәбраил аның йөрәген ярып, эченә гыйлем-мәгърифәт энҗеләрен салды. Шуннан соң кулыннан тотып, аны Кәгъбә сараена китерде. Ходайның әмере белән башта җиде йөз фәрештә саф-саф булып янына килделәр, сәламнәр бирделәр һәм дә буракны китерделәр. Йөзе — адәм кебек, колаклары — фил колагы төсле, коерыгы — ат койрыгыдай, муены — дөя муены кебек, күкрәге — ат күкрәгенә охшаш, аяклары — сыерныкын хәтерләтә, тояклары да сыерныкы кебек. Буракның ике канаты булып, аларны тәмам ачып бетерсә, мәгърип вә мәшрикъка җитәр, төшерсә, үзенә бәрабәр. Күкрәге кызыл якут төсендә ялтырап тора, аркасы көмештәй, аяклары яшел зәмрә, койрыгы — кызыл мәрҗәннән, муенына кызыл якуттан ике тезмә төймәләр асылынып тора, уртадагы зур кызыл якутына «Лә иләһә иллаллаһи, Мөхәммәдүр-рәсүлуллаһи» дигән сүзләр язылган иде. Боларны күргәч, Мөхәммәт пәйгамбәр сорады:

— И Җәбраил, мондый да галәмәтләрне күргәннән соң күңелемә өммәтләрем өчен кайгы-хәсрәт уты кабынды. Минем өммәтләрем гөнаһларын күтәреп илле мең еллык юл гарасат мәйданыннан ничек кичәрләр, ничек итеп җәннәткә килеп ирешерләр вә Сират күперенең утыз мең еллык юлын ничек үтеп китәрләр дип сагышландым. Алар ни юл белән кучәрләр?— диде.

Җавап шул булды:

— Өммәтләреңнең һәрберсенә шушы бурак төсле атларны китерермен вә илле мең еллык юллары бер «аһ» чыккан вакыт эчендә үтелер,— диде.

Болардан шул аңлашылыр, адәм балалары хаклык юлында булсалар, иманнарына тугры калып, диннәреннән авышмасалар вә чын мөселман кеше дәрәҗәсен дә исламны нык тотсалар, Кыямәт көнендә Аллаһы тәгаләнең шәфкать-миһербанлыгына лаеклы кылыналар вә мең газаплардан азат ителеп, җәннәт сараена барып ирешәчәкләр. Кяферләр вә бозыклар тамугка олагып, мең газап вә авырлыклар күрәчәкләр. Шулвакыт алар иман үтенерләр һәм үзләре иман китерергә теләрләр, ислам шәригатендә булмаулары өчен үкенеп канлы яшьләр түгәрләр...

Мөхәммәт пәйгамбәргә шушы бурак иярене утырырга боерылды. Әмма мөмкин булмады. Бурак чыгымлый башлады һәм:

— Минем өстемә утырыр кешем Коръән сәхибе корәиш нәселеннән Мөхәммәт бине Габдулла! — дип белдерде. Буйсынмады.

Шуннан соң Җәбраил галәйһис-сәлам:

— Алла хакы өчен, бу кеше Мөхәммәт пәйгамбәрнең үзе була инде, Мөхәммәт пәйгамбәр — бу! — дип белдергәч кенә ул бурак, аякларында тыпырдап, корсагына ятты һәм:

— И Җәбраил галәйһис-сәлам, бер үтенечем бар, Кыямәт көнне башка бураклар теләсәләр дә, Мөхәммәт пәйгамбәр бары минем генә җайдагым булсын,— диде.

Риваятьләрдә шулай сөйләнелә ки, Кыямәт көнендә Мөхәммәт пәйгамбәр шушы буракка утырып җәннәткә керәчәк.

Буракның бу үтенече кабул кылынганнан соң пәйгамбәр аңа менеп утырды һәм алар Кәгъбәдән китеп бардылар. Бер ягына сиксән мең фәрештә кулларына утлар тотып бастылар, икенче ягына шулай ук сиксән мең фәрештә шул хәлдә тезелде. Җәбраил галәйһис-сәлам:

— Әгәр юлда сиңа берәрсе аваз салса, яки эндәшсә, яисә туктатса, аларга игътибар бирмә! — диде.

Кузгалып киттеләр. Җәбраил фәрештә алга чыкты. Шунда берара җир уздылар, пәйгамбәрнең сул ягыннан кемдер эндәште, әмма Мөхәммәт игътибар бирмәде, аннан соң тагын да берара җир кичтеләр, уң яктан аваз ишетелде, пәйгамбәр тагын илтифат итмәде. Шул рәвешле очып барганда буракның каршысына бер күркәм йөзле хатын килеп басты. Йөзе бик тә сокландыргыч иде. Мөхәммәткә эндәште. Бурак туктап калды. Шулвакыт пәйгамбәр Җәбраилның биргән киңәшләрен исенә төшерде һәм камчысы белән буракка орды, туктап калган бурак урыныннан алга тартылды. Бераз ара үттеләр. Җәбраил галәйһис-сәлам пәйда булды. Пәйгамбәр аннан:

— Мине юлда күреп, исемемне әйтеп эндәшүчеләр кемнәр иде? - дип сорады.— Әгәр аларга игътибар итсәм, нинди хикмәткә юлыгыр идем?

— Сиңа эндәшкән кешеләрнең беренчесе яһүди иде,— диде Җәбраил.— Әгәр дә син аңа игътибар иткән булсаң, өммәтләрең яһүдиләр рәтендә булырлар иде. Икенчесе носари, ягъни христиан иде, әгәр дә ул кемсәгә илтифат иткән булсаң, өммәтең тулысынча носари булыр иде. Өченчесе исә потка табынучы булып, әгәр дә шунда туктап калсаң, өммәтең тулысынча потка табынучы гына булып калыр иде,— дип җавап бирде.

Юлларын алга таба дәвам иттеләр. Шунда аларга бер таш очрады. Ул ташның авызы булып, эченнән су чыга иде. Чыга иде дә киредән керергә тырышыр иде, әмма теләге насыйп булмас иде.

— Моның мәгънәсе нәрсә? — дип сорады пәйгамбәр.

— Бу — хикмәт, кешеләрнең сүзләрен аңлата, әгәр бер кеше сүз әйтә, сөйләсә, аны инде кабат җыеп ала алмый,— дип җавап бирде Җәбраил.

Алга таба юлларын дәвам иттеләр. Каршыларына бер карт, бер ир уртасы кеше һәм бер егет очрады. Мөхәммәт пәйгамбәр егеткә игътибар итте, тегеләрен күздән кичермәде. Шуларны узгач, Җәбраил:

— Син дөрес эшләдең, арадан бары тик егеткә генә илтифат бирдең. Синең өммәтең җирдә вә күктә мәңге нигъмәтле вә бәхетле була, синең шәригатең мәңге яшәячәк,— диде.

Яңадан да беркадәр араны уздылар. Шунда пәйгамбәрнең кулына ике савыт тоттырдылар. Берсендә сөт, икенчесендә шәраб иде. Мөхәммәт пәйгамбәр алардан сөтне авыз итте. Шуннан соң Җәбраил пәйгамбәр:

— Савытлардан сөтлесен сайлап алдың, синең өммәтең кыяматкәчә саф шәригатең белән яшәр, аларга җәннәт шәрабе вә ширбәтләре насыйп булыр,— дип хикмәтне аңлатып бирде.

Алга таба киттеләр. Аларның каршына бер кемсә очрады. Ул кое янына су эзләп килә һәм чиләген бәйләп төшерә, әмма су таба алмый газап чигә иде.

— Бу бәндә ялган, икейөзлелек белән эш итә торган кешеләр өчен мисал булып торыр, бар эшләгән эше буш булыр, Кыямәт көнне кулына һичбер нәрсә кермәс,— дип сөйләп бирде аның хакында Җәбраил галәйһис-сәлам.

Алар юлларын дәвам иттеләр.

Бурак Мөхәммәт пәйгамбәрне Бәйтел-Мөкатдәс бинасына китерде. Күк капусы ачылып, фәрештәләр аңа сәлам бирделәр, ахырзаман рәсүле икәнлеген белдерделәр. Ул арада барлык пәйгамбәрләр пәйда булып, һәммәсе дә Мөхәммәт галәйһис-сәлам белән күрешеп, үзләренең дөньялыкта кылган эшләрен бәян иттеләр, Мөхәммәтнең бөеклеге алдында үзләренең баш июләрен таныдылар. Беренче булып Ибраһим пәйгамбәр, аннан соң Муса, Сөләйман, Гайсә пәйгамбәрләр «Инжил» вә «Тәүрат» хакында хәбәрләрен ирештерделәр, Мөхәммәт каршында үзләре кылган могҗизалары хакында сөйләп бирделәр.

Бер риваятьтә әйтелер ки, «Бакара сүрәсе» Мөхәммәт галәйһиссәламгә шушында иңде һәм барча пәйгамбәрләр саф-саф басып, Мөхәммәт галәйһис-сәлам алар өчен имам кылынып, барчасы сәҗдәгә килделәр, намаз укыдылар.

Шуннан соң Җәбраил фәрештә Мөхәммәтне бер сахрага китерде. Анда мигъраҗ юлы ачылды. Күк капуслары күренеп, фәрештәләрнең вә рухларның шушыннан чыгып-кереп йөрүләре беленде. Ул капкаларның берсе — алтыннан, икенчесе — көмештән, кызыл якут белән бизәлгән иде ки, әгәр дә берәр кеше бу капкаларны күрсә, исе-акылы китеп, һушсыз калыр иде.

Мөхәммәт пәйгамбәр Җәбраилнең канатына утырды һәм алар ике йөз еллык юлны тиз арада үттеләр, күк капусыннан эчкә керделәр. Әйтерләр ки, ул күк капусында бер фәрештә Мөхәммәт пәйгамбәргә сәлам бирде һәм үзе белән таныштырды. Бер риваятьтә, пәйгамбәр диңгез янына килде, аның дулкыннарын чылбырлар белән фәрештәләр тотып тора, ә бер башы күккә барып тоташкан иде, дигән хәбәрләр бар. Пәйгамбәр беренче кат күккә ирешеп һәм бик күп гаҗәп хәлләрне күрде, һәртөрле фәрештәләр белән очрашты.

Җәбраил галәйһис-сәлам беренче кат күк капусына Мөхәммәтне китерде. Аның исеме «Хафиз капкасы» иде, гарәпләр «Бабул-Хафиз» диләр. Аның артында Исмәгыйль атлы фәрештә торып, сорады:

— Җәбраил, синең белән кем анда?

— Мөхәммәт! — диде Җәбраил фәрештә.

— Күккә аштымы? — дип сорады ул фәрештә.

— Әйе,— диде Җәбраил.

Шуннан соң Хафиз капкасы ачылып китте, унике мең фәрештә әзер булып килде. Бер ише китаплар аларның җитәкчесе дип Исмәгыйль пәйгамбәрне күрсәтерләр, икенче төрлеләре исә, ул пәйгамбәр түгел, бәлки фәрештә, дип белдерерләр, әмма үзара бәхәс кылмаслар. Бер риваятьләр мигъраҗ юлын зәмрә баскыч иде, дип белдерерләр, икенчеләре исә нурдан кылынган, зәмрә вә якут белән бизәлгән бер юл иде, дип сөйләрләр. Шулай ук болай ике төрле сөйләүдә һичбер каршылык күренмәс, чөнки аны берәүләрнең «баскыч», икенчеләрнең «юк» дип күзаллаудан берни дә үзгәрмәс, аннан күтәрелү җирдәге тизлек белән

хисаплаганда биш йөз еллык юл булып, тади теләк белән генә аның буйлап күккә ирешү мөмкин эш тә түгелдер. Кадир кодрәте билгесе булыр бу!

Исмәгыйль фәрештә карамагында булган күк яшел зәмрәдән кылынган иде. Аның исеме «Ракыйга» дип аталып йөртелә иде. Бу күкнең зурлыгы биш йөз мең еллык юл дәрәҗәсендә булып, эчендә төрле гаҗәеп күренешләр бар иде. Мәләкләр-фәрештәләр һәрчак Аллаһы тәгаләгә сәҗдә итеп торырлар. Һәм дә бу күктә энҗедән ясалган вә нурлар белән балкып торган бер тәхет куелып, анда бер рух утырып тора иде.

— Бу кем була?— дип сорады Җәбраил галәйһис-сәламнән Мөхәммәт пәйгамбәр.

— Бу синең атаң Адәм пәйгамбәр рухы була, үзенең балаларына, ягъни җирдә яшәүче адәм затларына нәсыйхәтләрен юллый, алар өчен кайгыра,— дип җавап бирде Җәбраил.

— Бар, син аңа килеп сәлам бир. Хак тәгалә аңа хәбәр житкереп, үзенең мөэмин улын очратачагын белдергән, Адәм рухы шуның өчен Аллаһы тәгаләбезгә чук рәхмәтләрен юллый,— диде.

Мөхәммәт галәйһис-сәлам Адәм рухына килеп сәлам бирде. Адәм рухы исә сәламен хөрмәт белән алды. Үзенең сөенечен белдерде.

Адәм рухының тәхете уңында бер капка булып, ул ачылыр, аннан хуш ис бөркелеп килер, тагын да сул ягында бер капка бардыр, аның ишеге ачылуга, яман ис килер. Адәм рухы уң ягына багар, ул ишектән килгән искә сөенер, сул ягына багар, күзләренә мөлдерәмә яшь тулып, күңелен сагыш-кайгы биләр.

— Бу нинди ишек-капкалар?— дип сорады Мөхәммәт пәйгамбәр.

— Уң ягында булган капка җәннәткә кертер. Адәм галәйһис-сәлам ул яктан килгән хуш искә сөенер, күңеле хушланыр, ә сул ягындагы ишек исә тәмугка юнәлтер, ул ачылуга, ут ялкыны бөркелер. Гөнаһлы бәндәләр өчен Адәм рухы кайгырыр, күзләреннән яшьләр килер,— дип хәбәр итте Җәбраил фәрештә.

Бу сүзләрдән шул аңлашылыр ки, Адәм атабыз рухы Җирдәге бәндәләр кайгысында булып, алар өчен һаман да җан атып торыр.

Тагын да күкнең шушы катында күренде ки, бер төркем җәмәгать бардыр. Бертөрле бәхет белән күңелләре шат вә кулларында энҗе булыр.

— Болары кемнәр?— дип сорады пәйгамбәр.

— Болары Аллаһы тәгаләнең әмерен тоткан вә садака биргән кешеләр!— диде Җәбраил фәрештә.

Шулай ук бер төркемгә юлыктылар, болар бик арык, какча-сөяк кенә иделәр.

— Болары кемнәр булыр?— дип сорады пәйгамбәр.

— Болары — ятимнәрне кимсеткән вә байлыгыннан тиешле өлешен җәмәгать файдасына бирмәгән кемсәнәләрдер. Аларның урыны тәмугтадыр,— дип җавап бирде фәрештә.

Шулай ук бер төркем күренде. Аларның алларында затлы азык белән янәшә табакта үләксә иде. Алар затлы ризык кабарга теләрләр, әмма кулларына үләксә эләгер.

— Болары кемнәр?— диде пәйгамбәр.

— Болары исә хәрамга күңел салган кешеләрдер, алар җирдәге тормышларында хәләл маллары була торып та хәрам малга ябышкан бәндәләрдер,— диде фәрештә.

Тагын да бер җәмәгать очрады. Болары тәмам ут кебек яна иделәр. Мөхәммәт галәйһис-сәлам:

— Болары тагын кемнәр?— дип сорады.

— Болары исә юл буенда торып, килгән-киткән кешеләрне каш сикертеп үртәүчеләр вә мәсхәрә итүчеләр, рәнҗетеп калучы гайбәтчеләр вә бозыклар,— дип җавап бирде фәрештә.— Аларның урыны тәмугта булыр.

Тагын да бер кеше очрады. Аның аркасында бик зур вә бик авыр йөк өелеп, бу кемсәнә аны күтәреп йөри-йөри хәлдән тайган һәм бер генә дә барыр көче юк исә дә һаман тартылып тырмаша һәм туктарга әмәле иде.

— Бу кемсә иманына тугры калмаган, иманын бозган кеше икән. Әгәр дә тагын шундыйлар бар икән, аларның хәлләре шушы булыр,— дип аңлатып бирде Җәбраил фәрештә моның турында.

Бу рәвешле Мөхәммәт галәйһис-сәлам егерме төрле могҗиза күрде, бозык вә итагатьсез бәндәләрнең җаннары ничек иза чигүенә һәм интегүләренә очрап, алар хәленнән бер-бер хәбәр алды. Алга киттеләр. Анда бер диңгезне күрделәр. Ул дәрьяның суы сөттән ак вә дулкыннары тау-тау иде.

— Бу диңгез — Тормыш дәрьясы,— дип аңлатты Җәбраил галәйһис-сәлам.— Аннан Җиргә яңгыр явар, ул яңгыр кешеләргә рәхәтлек бирер, корыган агачларны терелтер,— диде.

Шулай ук тагын да мәләкләр (фәрештәләр) очрап, алар күк йөзендә болытларны йөртүчеләр булдылар. Болар үзләренең сурәтләре белән адәм балаларын хәтерләтә иделәр.

Җәбраил фәрештә белән Мөхәммәт галәйһис-сәлам тагын да икенче кат күккә аштылар. Каршыларында гаять тә нурлы, күзләр камашырлык, кызыл алтыннан ясалган капкалы икенче кат күкне күрделәр. Аның исеме «Кайдум» дип атала иде. Җәбраил галәйһис-сәлам шуның капкасына килде.

— Син кем? — дип сорадылар.

— Мин — Җәбраил фәрештә булам.

— Ә синең янында кем? — диделәр.

— Мөхәммәт пәйгамбәр! — диде Җәбраил.

— Аны таләп иттеләрме инде? — дип сорадылар тагын да.

— Әйе,— диде Җәбраил фәрештә.

— Әлхәмдел-иллаһ! — дип күкнең капусын ачып җибәрделәр.

Шунда Мөхәммәт пәйгамбәр тагын да бер ишек күрде. Аны «Хафизел-Исрафил» дип әйттеләр. Ул — нур белән чолганган, ак энҗедән ясалган иде. Анда йөз мең мәләк булып, аларның һәрберсенә ике йөз мең мәләк хезмәт итә иделәр.

Икенче кат күктә Мөхәммәт галәйһис-сәлам Гайсә вә Яхъя пәйгамбәрләрнең рухлары белән очрашты. Бер риваятьтә әйтерләр, үзләре белән очрашты, дип, чөнки Гайсә вә Яхъя пәйгамбәрләрнең тәннәрен дә җаннары белән бергә Аллаһы тәгалә күккә ашырды, кяферләрнең дәһшәтеннән саклап калды, диган хәбәрләр бар.

Гайсә вә Яхъя пәйгамбәрләр Мөхәммәт галәйһис-сәламгә үзләренең могҗизалары хакында сөйләделәр, мөселман шәригатенең хакыйкый шәригать булуын белдерделәр.

Алга таба үтеп, рәсүлебез җитмеш башлы бер фәрештәне күрде. Аның һәр башында җитмеш йөзе, һәр йөзендә җитмеш авызы, һәр авызында җитмеш теле булып, һәр теле үзенә аерым бер ләгать белән сөйли иде. Исеме — «Касыйм» иде.

Моннан соң Мөхәммәт пәйгамбәр белән Җәбраил фәрештә өченче кат күккә ирештеләр. Иң элек ак энҗедән төзелгән күк йөзен күрде Мөхәммәт. Аның бер нурлы ишеге булып, бу күкнең исеме «Зәйлүм» атлы иде. Анда бер капкачы һәм аның өч йөз мең ярдәмче фәрештәсе бар иде. Ул фәрештәләр сәҗдәдә иделәр. Шуннан соң һәр намазда ике рәкәгать фарыз булып, һәр рәкәгатьтә ике сәҗдә тиешле булды. Мөхәммәт пәйгамбәр аларга сәлам бирүгә, фәрештәләр кабул итеп алдылар, башларын күтәрделәр һәм кабат сәҗдәгә киттеләр. Шунда Мөхәммәт галәйһис-сәлам Йосыф пәйгамбәрне фәрештәләр арасында күрде. Җәбраил өйрәткәнчә аңа сәлам бирде. Йосыф пәйгамбәр Мөхәммәтнең сәламен кабул итеп алды, аның белән сөйләште. Моннан соң аларга Сөләйман вә Давыт пәйгамбәр очрадылар, сәламнәрен алып, васыятьләрен Мөхәммәт пәйгамбәргә җиткерделәр вә үз тәсбихларыннан хәбәрләр бирделәр.

Алга таба китеп, тагын да бер фәрештәне күрделәр. Ул фәрештәнең житмеш мең башы булып, тагын да житмеш мең канаты бар иде. Һәр канаты, әгәр җәелсә, ике як тарафны да каплап ала иде. Аның янында тагын да мәләкләр хезмәт итеп, бер төркем гөнаһлы бәндәне чукмар белән акыртып кыйный иделәр.

— Бу кешеләр кемнәр?— дип сораугa каршы, Җәбраил:

— Болар синең өммәтләреңә җәбер-җәфа салучылар, алар кыяматкәчә шушылай газап чигәрләр һәм соңыннан тәмугка олагырлар,— дип җавап бирде.— Бу фәрештәнең исә исеме «Суһаил» булыр.

Аннан соң бер диңгезгә килеп чыктылар. Ул дәрья шулкадәр зур иде ки, аны әйләнеп чыгарга да һич мөмкин түгел иде. Җәбраил әйтте:

— Бу диңгезне «Бәхрел-Нукум» дип атарлар. Нух пәйгамбәр вакытындагы туфан шушы дәрьядан чыкты. Аның суы бөтен җирне җиде кат каплап китәргә җитә!

Шуннан соң алар дүртенче кат күккә күтәрелделәр.

Бу күк йөзе саф көмештән вә энҗедән булып, исеме «Әзилүн» дип аталган иде. Аның бер нурлы капкасы күренеп, аңа «Лә иләһи илләллаһи, Мөхәммәдүр рәсүлуллаһи!» дип язылган. Капкасында бер фәрештә сакта тора, аның исеме «Газраил» иде.

Дүртенче кат күктә Мөхәммәт галәйһис-сәлам Муса пәйгамбәр белән очрашты. Җәбраил фәрештә өйрәткәнчә килеп күреште. Муса галәйһис-сәлам аның алдында тез чүгеп, аяк өсте баскач, ике каш арасыннан үпте һәм:

— Дан вә хөрмәтләр булсын, Аллаһы тәгалә мине синең белән күрештерде, нурлы йөзеңне күрергә насыйп итте,— дип сөенечен белдерде.

Шуннан соң Мөхәммәткә үзенең бик күп кирамәтләрен сөйләп бирде дә:

— Сиңа Аллаһы тәгаләнең нурын күрергә насыйп булыр, әмма үзеңнең өммәтләрең хакында онытма, аларны исеңдә тот,— дип киңәшләрен дә житкерде.

Муса пәйгамбәр янынан киттеләр. Әмма ул күзләреннән кайнар яшьләрен агызып елый башлады.

— Нигә елыйсың?— дип сорадылар.

Муса галәйһис-сәлам:

— Миннән соң олуг зат булып Мөхәммәт пәйгамбәр күтәрелде. Минем өммәтләрем үземне олуг дип белә иделәр, сүзләрен һәрчак шулай сөйләрләр, әмма миннән дә олуг булган Мөхәммәт пәйгамбәрне таный алмаслар. Аның дине минекеннән өстенрәк булды вә милләтенә Кыямәт көнендә рәхим-шәфкать килер, ә минем өммәтем алар дәрәҗәсендә вә аларга тиң була алмаслар,— диде.

Бу сүзләрне ишетүгә мәләкләр сәҗдә иттеләр, алар җәннәткә ислам таифәсенең иреШәчәгенә сөенделәр һәм бу фәрештәләрнең тәсбихе адәмнәр тарафыннан намаз ахырында әйтелергә тиешле күрелде.

Шушы күктә очраганнардан берсе — Гайсә пәйгамбәрнең әнкәсе Мәрьям иде. Аның карамагында житмеш мең сарай булып, алар барчасы да ак энҗедән ясалган иделәр. Шулай ук хәзрәте Муса галәйһис-сәламнең әнисе дә шушында иде. Аның карамагында тагын да житмеш мең сарай булып, барчасы зәмрәдән корылган иделәр. Тагын да фиргавеннең хатыны Асия ханым да шушында иде. Аның карамагында да житмеш мең сарай булып, алар барчасы да кызыл якуттан корылган иделәр. Һәм дә тагын житмеш мең сарай күренеп, алар барчасы да кызыл мәрҗәннән иделәр. Мөхәммәт галәйһис-сәламне күрүгә, барчасы да кадер-хөрмәт белдерергә ашыктылар. Йөзләре балкып, күңелләре нурга күмелде.

Бу күктә тагын да бер тәхет күренде. Анда бер олуг фәрештә утыра иде. Һәм ул тәхетнең дүрт сарае булып, аларның һәрберсендә җиде йөз мең багана алтын вә көмештән ясалган иделәр. Бар тарафында да мәләк-фәрештәләр хисапсыз җыелышып, күркәм рухлар да шушында

иде. Аларның яхшылыгы һәм хөрмәтле теләкләре шулкадәр дә көчле булып, йөзләрендә балкыган нурдан күзләр камашыр иде. Аларның киемнәре яшел төстә, сөйләшкән сүзләре шундый да ягымлы иде ки, әгәр дә адәм баласы бер генә сүзләрен ишетсә, күңел төпләрендә яткан яман уе яки кемгә дә булса тоткан үпкәсе кул белән сыпырып алган төсле юкка чыгар һәм ул адәм мәңге шушы ямьле вә нурлы халәттә калачак иде.

Бу тәхетнең сул ягында золмәт мәләкләре җыелышып, сүзләре салкын вә җан өшеткеч, йөзләре караңгы, авызларын ачып сүз әйтә башласалар, утлар чәчелер һәм кулларында гөрзи-чукмарлары булып, алар белән айкарлар, күз салган кешенең котын алырлар иде.

Тәхет өстендә утырган олуг фәрештәнең башыннан аягына кадәр сансыз-хисапсыз күзләре тезелеп, барчасы күк йөзендәге йолдызлар кебек якты вә җитез иделәр ки, кулындагы бер сәхифәгә карап, янындагы тактага багарлар. Уң ягында бер агач булып, аның яфраклары сансыз күп, һәрберсендә бер кешенең исеме язылган иде. Янә дә уң ягында бер ләгән төсле әйбер бар, олуг фәрештә аннан уң кулы белән нидер ала һәм нурлы мәләкләргә тапшыра яки сулында басып торган караңгы йөзле мәләкләргә бирә.

Бу хәлләрне күреп, Мөхәммәт пәйгамбәрнең күңеленә борчу төште. Ни уйларга, нәрсә сорарга белми торды. Бу эшләр Җир йөзендә күрелмәгәнлектән, алар хакында һичкем һичнәрсә белми иде. Бераз карап торганнан соң Мөхәммәт пәйгамбәр:

— Бу тәхет өстендә утырган затны кем дип белергә? — дип Җәбраил галәйһис-сәламнән сорады.

— Бу фәрештә — Газраил галәйһис-сәлам. Аның йөзен күрергә һичкемнең көче җитмәс. Кешеләргә үлем һәм аерылу китерүче зат,— дип җавап бирде Җәбраил фәрештә.

Газраилнең чиксез күп канатлары җәелеп китсә, дөньяны бер тарафтан икенчесенә кадәр каплап алыр иде. Аның белән очрашу һәр адәм баласына котылгысыз булганлыктан, җаныбыз чыгу ачысын да татымый калмаячакбыз. Җәбраил фәрештә Газраил тарафына якынаеп:

— И Газраил, синең каршыңдагы бу кемсә Ахырзаман пәйгамбәре вә Аллаһы тәгаләбезнең яратканы һәм сөйгәне, рахман иясе Мөхәммәт пәйгамбәр,— дип белдерде.

Бу сүзләрне ишетүгә, Газраил йөзен күтәрде вә пәйгамбәребезгә хөрмәтен күрсәтеп:

— Мәрхабә! — диде.— Аллаһы тәгалә синнән дә олуг бер кешене дә яратмады, өммәтең дә Аллаһы тәгалә катында. Барча ислам шулай ук олуглар исәбеннән. Мин дә синең халкыңа рәхимле булырмын,— дип белдерде.

— Минем күңелем бу сүзләреңне ишетеп хушланды, хәтерем сагышгамь утыннан арынды, әмма күңелемдә тагын бер нәрсә калды, синең үзеңне сагышлы вә кайгылы итеп күрәм, сәбәбе нәрсә? — дип сорады аңардан Мөхәммәт пәйгамбәр.

— Йа рәсүлуллаһ,— диде Газраил.— Хак тәгалә мине шушы хезмәткә тәгаен кылды. Синең монда килеп җавап тотуыңа сагышлы вә гамьле булып торамын!

— Ә янындагы бу ләгән төсле әйбер нәрсә? — дип сорады пәйгамбәр.

— Бу — дөньяның үзе. Бер Каф тавыннан икенчесенә кадәр барчасы шушында, нәрсә вә кемне эзләсәм, барчасы шушында күренерләр,— дип белдерде Газраил.

— Ә бу такта нәрсә?

— Халыкның әҗәл дәфтәре шушы була инде,— диде Газраил.

— Ә бу сәхифә нәрсә? — дип сорады Мөхәммәт пәйгамбәр.

— Бу сәхифә — рузнамә,— диде Газраил.

— Ә бу агач ни-нәрсәне аңлата?

— Бу агач яфракларында барча адәмнәрнең исемнәре язылган. Әгәр дә берәү үлем хастасы белән авырып китсә, яфрагы саргаеп шушы агачтан бу тактага төшәр, исеме вә кылган эшләре ачык күренер. Кулымны озайтып, аның җанын алырмын. Кайда гына булса да кодрәтем житәр. Әгәр дә яхшы вә күркәм эшләре белән танылган кемсәнең җаны икән, аны уң ягымдагы мәләкләргә юллыйм, әгәр дә яманлык вә имансызлык иясе булса, сул ягымдагы золмәт мәләкләренә тапшырамын,— диде Газраил.

— Бу мәләкләрнең хисабы күпме булыр? — дип сорады тагын да пәйгамбәр.

— Бу мәләкләрнең санын Аллаһы тәгаләнең үзеннән башка һичкем белмәс,— диде үлем фәрештәсе.— Әмма берәр кешенең җанын тотсам, алты йөз мең фәрештәм әзер тора, кайсы тарафка бирелер — карап алырлар. Кыяматкәчә шушы рәвешле булыр.

— И үлем фәрештәсе, бар кешенең дә җанын син алырсыңмы? — диде пәйгамбәр.

— Бар кылынганнан бирле урыннымнан күчмәдем диярлек. Ләкин житмеш мең мәләк миңа хезмәт итә. Һәрберсенең алдында тагын да житмеш мең мәләк бар. Әгәр берәр кешенең җанын алырга морат итсәм, шушы мәләкләргә әмер бирәм. Барып, ул кешенең рухын бугазына китерәләр. Шуннан, кулымны сузып, ул адәмнең җанын аламын,— дип серләрен ачып бирде Газраил.

— Сиңа гозерем шул: — дип үтенде Мөхәммәт пәйгамбәр,— минем өммәтләрем бик зәгыйфьләр, аларның рухларын бик саклык вә дуслык белән тота күр инде?!

Газраил галәйһис-сәлам әйтте:

— Аллаһы тәгалә сине үзенең хәбибе, яратканы итеп бар кылды, пәйгамбәрләрнең пәйгамбәре итте. Болар барчасы Хак тәгаләнең гыйззәте хакы өчен иде. Кичә көндез ул миңа өммәтләреңә карата рәхимшәфкатьле булырга боерды. Мөхәммәт өммәтенең саклык һәм асатлык белән җанын тот, арадагы олугларын хөрмәт белән кабул итә күр, диде. Мин синең өммәтеңә шәфкатьле булырмын! — дип сүз бирде Газраил. Шуның белән әңгәмә тәмам булды.

Җәбраил фәрештә белән Мөхәммәт пәйгамбәр янә алга таба киттеләр. Каршыларына бер дәрья очрады. Суы кардан да ак иде. Мөхәммәт галәйһис-сәлам:

— Бу нинди дәрья? — дип сорауга Җәбраил:

— Бу диңгезнең исеме «Бәхрес-Сәлес» дип атала,— диде.— Моннан бер генә микъдар кар чыкса да, җир йөзендә барча бәндәләр вә тереклек шул суыктан һәлак булыр иде,— дип җавап бирде.

Юлларын дәвам иттеләр. Бер сарай күренде. Кызыл якуттан төзелгән, ике ишеге бар, икесе дә яшел зәмрәдән ясалган иде. Эчендә кызыл алтыннан эшләнгән яктырткычлар эленеп, барчасы ун мең дип хисап ителде. Алар җәүһәр вә якут белән бизәлеп, күргән кеше сокланмыйча түзә алмас иде. Капкасына бер мөнбәр куелып, үзе алтыннан иде. Көмештән тагын бер манара булып, озынлыгы биш йөз еллык юл бәрабәреңә тора икән. Каршында нурдан бер диңгез дә бар иде. Яратылган көненнән бирле Кыяматкәчә монда мәләкләр килеп, суында госел коеналар, иңнәренә нурдан киемнәрен эләләр һәм шушы бинаны тауваф кылалар. Шуңа да аларга Кыямәт көненәчә нәүбәт килмәс, җаннары бозылмас, күңелләре саф килеш калыр, дип аңлатты Җәбраил фәрештә.

Шулвакыт Җәбраил галәйһис-сәлам Мөхәммәт пәйгамбәрнең кулыннан тотып, шушы мәсчеткә алып килде:

— Син дә бу халыкка катыш,— диде.

Мөхәммәт галәйһис-сәлам ике рәкәгать намаз укыды. Барча мәләкләр-фәрештәләр җиде кат күктән аңа карап тордылар, йөзләре нур тулып балкыды. Җәбраил фәрештә:

— Синең өммәтләрең дә җомга көнне шушы халык төсле бергә җыелып, мәсчеттә намаз укысыннар,— дип белдерде.

Риваятьләрдән билгеле булганча, җомга намазы бу вакыйгадан соң укыла башлады. Иманлы бәндәләр бер генә вакытта та җомга вакытында мәсчетләрен буш калдырмадылар. Чөнки дүртенче кат күктәге шушы мәсчеттә Җәбраил галәйһис-сәлам азан әйтә, Исрафил галәйһис-сәлам андагы мөнбәргә менеп хөтбә укый, Микаил галәйһис-сәлам имамлык итә, барча фәрештәләр җыелалар. Бу исә җомга намазы вакытында була иде. Җомга турында барлык мәсчетләрдән килгән намаз тавышлары бердәй булып Аллаһы тәгалә хозурына күтәрелә вә җирдәге бәндәләренең күңелләре нурга күмелә.

Җәбраил галәйһис-сәлам әйтте:

— И барча фәрештәләр, шаһит булыгыз, мин бу азанның савабын Мөхәммәт өммәтендәге мөәзиннәргә багышладым! — дип. Аның бу сүзләреннән ислам мөәзиннәренең Җәбраил фәрештә шәфкатендә торулары аңлашылыр һәм дә ул мөәзиннәрдән шушы шәфкатькә лаек булулары соралыр.

Исрафил галәйһис-сәлам әйтте:

— Мин бу хөтбәмнең савабын Мөхәммәт өммәтенең хөтбә укучы хатиб муллаларына багышладым! — дип. Аның шушы сүзләреннән бу аңлашылыр ки, хөтбә укучы муллалар Исрафил фәрештәнең шәфкатендә торырлар һәм дә алардан ул шәфкать бөеклегенә лаек булулары соралыр.

Микаил галәйһис-сәлам әйтер:

— Мин дә бу имамлык савабын аның имамнарына багышладым! — дип. Моннан да шул аңлашылыр ки, имамлык кылучы муллалар Микаил фәрештәнең шәфкатенә ия булырлар, шуның өчен дә алардан аның шәфкатенең бөеклегенә лаек дәрәҗәдә булу соралыр.

Бу сүзләрне ишеткәч тә барча мәләкләр:

— Без дә шушы җомганың савабын Мөхәммәтнең өммәтләреннән җомга укыган халкына багышладык,— дип белдерделәр. Аларның савабына вә шәфкатенә лаек булу өчен барча мөселманнар җомга намазына мәсчеткә җыелырга тиеш иделәр.

Шулвакыт Хак тәгаләдән аваз килеп ирешге. Ул:

— Әй, сез миңа һәрвакыт буйсынучылар! Шаһитларым булыгыз, Мөхәммәт өммәтеннән һәммә кеше, кылган гөнаһларыннан тәүбә итсә, мин аларны гафу итәрмен һәм җәһәннәмнән саклап калырмын! — дип белдерде.

Моннан соң пәйгамбәр белән Җәбраил галәйһис-сәлам күкнең бишенче катына күтәрелделәр. Ул күк каты кызыл алтыннан, икенче бер риваятьтә исә кызыл якуттан иде, диелә.

Хәбәрләрдән күренгәнчә, бишенче кат күк белән чагыштырганда, калган дүрт кат бары тик сахра кебек булып күз алдына килә. Бишенче катның күркәмлеген вә гүзәллеген калган дүрт кат барчасы бергә алыштыра алмыйлар икән.

Бишенче катта нурдан ясалган сурәттә бик тә матур бер тәхет өстендә фәрештә утыра иде. Аның исемен китапларда Сактаил дип белдерәләр. Аңа биш йөз мең мәләк хезмәт итә. Мөхәммәт пәйгамбәр сәлам биргә, Сактаил үз ягыннан пәйгамбәргә зур хөрмәтләр күрсәтте һәм бик тә ятышлы вә ягымлы сүзләр әйтте. Моннан соң Җәбраил фәрештә белән Мөхәммәт галәйһис-сәлам алга таба киттеләр.

Бишенче кат күктә Ибраһим, Исмәгыйль, Исхак вә Ягъкуп, вә Лут пәйгамбәрләр тора иделәр. Мөхәммәт галәйһис-сәлам аларга да килеп сәлам бирде. Барчасы бергә җыелышып утырган иделәр. Мөхәммәт пәйгамбәрнең сәламен кабул итеп алдылар, ахырзаман пәйгамбәрен күрү бәхете аларның йөзләрен-күзләрен нурландырды.

Ибраһим пәйгамбәр әйтте:

— Йа Мөхәммәт, сиңа Аллаһы тәгалә тарафыннан бер кичә тәгаен кылынган иде, ул сине күрүенә бик шат вә канәгать булыр. Зинһар өчен

дип әйтәм, үз өммәтеңә жиңеллекләр үтенсәң иде,— дип киңәшләрен бирде, васыятьләрен тапшырды.

Шактый гына сөйләшүдән соң Мөхәммәт пәйгамбәр белән Җәбраил фәрештә алга таба үттеләр. Бер төркем мәләкләрнең сәҗдә иткән вакытларына туры килделәр. Алар Аллаһы тәгалә каршында үз аяк бармакларына таба баш салындырып торырлар, башка бер якка да игътибар бирмәсләр иде.

Мөхәммәт галәйһис-сәлам Җәбраилдан:

— Бу фәрештәләрнең гыйбәдәте шушы рәвешлеме?— дип сорады.

— Әйе!— дигән җавапны алды.

Шуннан соң пәйгамбәребез Аллаһы тәгаләдән өммәтләре өчен дә шушы рәвешле гыйбәдәтне үтенде. Теләге кабул булып, Хак тәгалә мөселманнарга гыйбәдәтне бу сурәттә кылырга әмер бирде. Аңлашылыр ки, башка рәвешле кылынган гыйбадәтләр Хак тәгалә тарафыннан мөселманныкы буларак кабул ителмәс!

Алга таба китеп, Мөхәммәт галәйһис-сәлам тагын да бер төрле фәрештәләрне күрде. Аларның башларында-аякларында алтын киемнәр иде. Үзләре кулларына зур чукмарлар тотканнар, буй-сыннары шактый куәтле күренә. Тагын да яннарында бер төркем адәм балалары, өсләренә утлы күлмәк кигән хәлдә, аякларыннан өскә асылынып куелган иделәр. Мәләкләр боларга чукмарлары белән шундый итеп китереп оралар ки, бәндәләрнең авызларыннан җан ачысы белән сүзләр вә аһлар чыгып, тәннәрендәге итләре уелып төшә иде. Әмма Хак тәгалә әмере белән тагын бөтенәерләр иде.

— Болар кемнәр?— дип сорады пәйгамбәр Җәбраил фәрештәдән.

— Бу адәм балалары барчасы Аллаһы тәгаләгә буйсынмыйча, үзгә бер дин белән утларга вә потларга, вә шуның төсле нәрсәләргә табынучы кемсәнәләр. Шуңа күрә дә алар шушы рәвешле зур газаплар кичерәләр,— дип аңлатып бирде Җәбраил галәйһис-сәлам.

Тагын да алга китеп, Мөхәммәт пәйгамбәр белән Җәбраил фәрештә бер олуг диңгезгә килеп җиттеләр. Ул үзеннән утлар атып тора иде. Янында мәләкләр күренде.

— Бу диңгезнең исеме «Бәхрес-Сагак»,— дип белдерде Җәбраил.— Барлык яшен ташлары шушы диңгездән чыга. Бу диңгезнең гаҗәп хәлләрен Аллаһы тәгаләдән башка һичкем белмәс, аның сере бары тик үзендә генә,— диде.

Алар аннан күтәрелеп киттеләр һәм алтынчы күкнең капуслары ачылды. Бу каттагы олуг фәрештә «Ругаил» атлы иде. Мөхәммәт пәйгамбәр аңа сәлам бирде һәм ул да кабул итеп:

— Бәракәллаһ!— дип бер дога укыды, Мөхәммәт галәйһис-сәлам исә:

— Амин!— диде.

Ругаилның тирәсендә алты йөз мең мәләк хезмәт итеп, аларның да һәрберсенә алты йөз мең фәрештә буйсына иделәр. Үзләренең тәсбихләрен әйтеп, намаз укыдылар.

Моннан киткәннән соң Мөхәммәт пәйгамбәр белән Җәбраил бер капка каршына килеп туктадылар. Капканың башы күкләргә ашкан, галәмәт зур йозагында ачкыч күренеп тора иде. Мөхәммәт пәйгамбәр бу күренешкә бик гаҗәпләнде.

— Җәбраил, безнең каршыбыздагы бу олы йозаклы, ике канатлы капка нинди нәрсә?— дип сорады.

— Бу капканы «Кәбабел-Иман» дип атыйлар,— диде Җәбраил галәйһис-сәлам.

— Нәрсә өчен алай диярләр?— дип сорады пәйгамбәр.

— Хак тәгалә җәһәннәмне бар кылды,— дип җавап бирде Җәбраил.— Төрле газапларны анда хасил итте. Имансызлар шушы капкадан тәмугка олактылар. Җиде кат җир вә җиде кат күктә барча зат Хак тәгаләгә иман китерде. Шуның өчен бу капка «Кәбабел-Иман» дип аталды,— диде.

Шуннан билгеле булыр ки, иманы булмаган һәркем шушы капкадан, ягъни «Иман капкасыннан» җәһәннәмгә олагырлар вә мәңгелек газапларга дучар булырлар, әгәр инде кешедә саф вә ныклы иман бар икән, ул вакытта алар бу капкадан эчкә таба үтеп, тәмугка төшүдән котылырлар.

— И Җәбраил, ул капка артында нәрсә икән? Шуны күрсәм иде?— дип үтенде Мөхәммәт пәйгамбәр.

— Моның артында җәһәннәм бар,— диде Җәбраил.— Аның белән синең һич эшең юк. Ул сиңа кирәк түгел!

— Бары тик күрергә генә телим,— диде Мөхәммәт.

Ул шушы сүзләрен әйтеп бетерүгә, Хак тәгаләдән:

— И хәбибем, бармагың белән ишарә ит, бу ишектәге ачкыч борылыр, ачылып китәр!—дигән аваз ишетелде.

Мөхәммәт галәйһис-сәлам бармагы белән ишарә ясады һәм дә ачкыч борылып, бу биек капка ачылып китте, артыннан утлар вә төтен ургылып чыкты, ниндидер шомлылык белән тетрәндергеч гөрелдәү тавышы ишетелә башлады.

Мөхәммәт пәйгамбәр җәһәннәмгә күз салды. Анда бер мәләк күренде. Тимердән ясалган бер мөнбәрдә утыра иде ул фәрештә. Ә мөнбәренең алты йөз мең аягы бар иде. Бу фәрештә шулкадәр зур иде ки, күкләрнең бер генә катында да Мөхәммәт пәйгамбәр андый мәләкне күрмәде. Ул күктән җиргә кадәр булган башын селкетеп, үзгә бер тәсбих әйтә иде. Аның авызыннан утлар чәчелеп, тау кадәр борыныннан төтен чыга, бер-бер күзләре дөнья кадәр булып, алардан очкыннар бөркелә иде. Пәйгамбәр моны күрүгә, күңеленә хәвеф-курку төште. Әгәр дә Хак тәгаләдән яхшылык вә ярдәм ирешмәсә, Мөхәммәт коты очудан үзенә саклык кыла алмаган да булыр иде.

— И Җәбраил, бу кем? Аны күрүгә, күңелемә курку төште вә башымнан акылым качты,— дип сорады пәйгамбәр.

— Бу бер фәрештә, «Хәзин җәһәннәм» (җәһәннәм сакчысы) шушы була. Хак тәгалә аны бар кылгач, бик сөенде вә шатланды,— дип җавап бирде Җәбраил һәм янына килеп сәлам бирергә кушты.

Мөхәммәт пәйгамбәр аңа барып сәлам бирде, бу фәрештә урыныннан купты, аңа хөрмәтен күрсәтте һәм:

— И Мөхәммәт, Хак тәгалә синең кылган эшләреңнән бик тә риза вә синең өчен борчылып тора. Билгеле булсын, җәһәннәм уты сиңа вә өммәтләреңә, якын яраннарыңа хәрам ителде. Барчасын да тәмуг утыннан саклап калырмын. Хак тәгалә сиңа бик күп могҗизалар хәзер кылды,— дип белдерде бу фәрештә. Шуннан соң Мөхәммәт галәйһиссәламгә үзенең җәһәннәмен күрсәтте.

— Сиңа вә өммәтеңә каршы булган барчалар менә шушы тәмуг утында көячәкләр. Бу җәһәннәм алар өчен әзерләнде,— диде.

Мөхәммәт пәйгамбәр, бу хәлләрне күреп, гаҗәпкә калды. Аннан соң бу урыннан китеп, Идрис вә Нух пәйгамбәрләр янына килде. Алар аны күрүгә, сәламнәрен кабул итеп алдылар һәм кадер-хөрмәт күрсәтеп:

— Аллаһы тәгаләгә барлык мактауларыбыз ирешсен, синең күркәм йөзеңне дә безгә күрсәтте,— диделәр.

Шуннан соң Җәбраил белән Мөхәммәт тагын да ары таба киттеләр. Анда Микаил фәрештәне очраттылар. Ул бер биек тәхет өстендә утыра иде. Бер ягында зур үлчәү-мизаны корылып, бер-бер тәлинкәсе җирләр-күкләр кадәр бар иде, тагын да янында чиксез язу төргәкләре дә өелгән иде. Мөхәммәт пәйгамбәр сәлам биргәч, Микаил галәйһис-сәлам урыныннан купты, сәламен кабул итеп алды, сәҗдә итте һәм дога кылды.

— И Мөхәммәт, Хак тәгалә яраткан адәм балаларыннан син иң бәхетлесе, моңа кадәр сиңа иңгән төсле догалар һичбер кемсәгә ирешмәде. Синең өммәтләрең барчасы бәхетлеләр,— дип Микаил фәрештә бик күп хәбәрләрне аңа җиткерде.

Риваятьләрдән күренгәнчә, Микаил галәйһис-сәламгә җиде йөз мең мәләк хезмәт күрсәтеп, аларның һәрберсе алдында тагын да бер байрак

булып, ул байраклар янында тагын да аерым-аерым җиде йөз мең мәләк тезелеп тора иде. Барчасы Микаил галәйһис-сәламнең әмерен көтеп торалар. Аларның аңлатуыннан шул беленде ки, бу мәләкләрнең тәрбиясе һәрбер кар бөртеге вә яңгыр тамчысы иде. Алар ни-нәрсә теләсәләр, яңгыр вә кар да алар әмеренә буйсынып, таләпләре кабул булды. Кыямәт көненә кадәр алар шушы рәвешле хезмәт куярга тиеш иделәр.

Алга таба китеп, Мөхәммәт пәйгамбәр белән Җәбраил фәрештә бер дәрья янына җиттеләр. Дәрьяның өсте шундый яшел вә нурлы иде ки, текәлеп карасаң, күзең сукыраерга мөмкин иде. Аның ярында бер төркем мәләк хезмәт күрсәтеп торалар.

— Бу нинди диңгез? — дип сорады пәйгамбәр Җәбраилдан.

— Моны «Ахзар диңгезе», ягъни, «Яшел диңгез» дип атарлар,— диде фәрештә,— дөнья йөзендә булган барлык үсемлекләр, агачлар вә башкалар яшеллеге менә шушы дәрьядан килә. Барчасының әҗәле дә шушы дәрьядандыр...

Шушы гаҗәеп нәрсәләрне күргәннән соң, алар җиденче кат күккә күтәрелделәр. Ул исә ак энҗедән, ак көмештән вә ак нурдан ярatылган иде. Бер күк белән икенчесенең арасы биш йөз еллык юл булып, баскычлары да тагын шулай биш йөз еллык юл икән. Җиденче кат күкнең исеме «Сәсхаил» булып, ул барлык күкләрдән дә бөегрәк һәм матуррак иде.

Шулай итеп, мигъраҗ кылучылар җиденче күккә җиттеләр һәм сораган сорауларга һәр катның капка төбендәгечә җавап бирүгә, капка ачылып китте, Мөхәммәт белән Җәбраил галәйһис-сәлам эчкә үттеләр.

Биредә Мөхәммәт пәйгамбәр тагын да бер олуг фәрештәне очратты. Аның җиде йөз мең башы булып, һәр башында шулай ук җиде йөз мең авыз, ул авызның һәрберсендә җиде йөз мең тел, ә телнең һәрберсе җиде йөз мең үзгә бер лөгать (тел) белән сөйли иде. Аңа таба җәннәттән нур килеп тора. Үзе кыяматкәчә Аллаһы тәгаләгә тәсбих укый иде.

Янә дә бер фәрештә күренде. Ул бер тәхет өстендә утыра иде. Аның исә дүрт башы булып, берсе — адәм башы төсле, икенчесе — сыер башы төсле, өченчесе — арыслан башы кебек, дүртенчесе — кош сурәте шикелле иде. Ул башларның һәрберсе үзләренең телләре белән үзенчә тәсбихләрен әйтә иделәр. Тәсбихләрен әйтеп бетергәч, затларына тиешле ризыкны таләп итеп, аларның һәрберсенә лаеклы күрелгән азыкны Хак тәгалә каршыларында бар кыла, алар шуларны ашаганнан соң, яңадан үзгә бер тәсбихләрен әйтә тора иделәр ки, бу хәлләрне күреп гаҗәпләнмичә һич тә мөмкин түгел иде.

Тагын да бер фәрештәгә юлыктылар. Аның башы күк катына кадәр ашып, аяклары җиде кат җирләргә җиткән иде. Аның бер канаты — Көнбатышка, икенчесе Көнчыгышка кадәр бар тарафны каплап тора иде. Аны күрүгә, Мөхәммәт галәйһис-сәлам аптырап калды һәм Җәбраилдан:

— Бу кем була? — диеп сорады.

— Бу — Исрафил галәйһис-сәлам була. Янына барып күреш,— диде Җәбраил.

Мөхәммәт пәйгамбәр Исрафил галәйһис-сәламгә сәлам бирде. Исрафил аның сәламен кабул итеп алды, күп кенә хөрмәтләр күрсәтеп, аңа теләкләрен җиткерде һәм тәсбихен әйтте.

Күкнең җиденче катында күргән могҗизаларның иң олуты, әлбәттә, «Сидрәтел-монтаһа» дип аталган агач булды. Аны һичбер адәм баласы күрмәгән икән. Әмма пәйгамбәргә, шушы Сидрәтел-монтаһа агачына юлыгуы белән, бик күп гаҗәп әйберләргә шаһит булырга туры килгән.

Сидрәтел-монтаһа ботакларының бер ишесе — алтыннан, икенчеләре — көмештән, өченчеләре — зөмрәдән, дүртенчеләре якуттан иделәр. Аның бер-бер яфрагы фил колагы кадәр булып, җитмешләре хәтта үгез башыннан да зуррак иде. Бу агач Хак тәгаләнең нуры тәрбиясендә үсеп, хисапсыз мәләкләр аны яшәр урыннары иткән иделәр. Сидрәтел-монтаһа

алтын нурлар белән ялык-йолык итеп тора. Аңа кунган фәрештәләр дә алтын шәмнәр кебек, күк йөзендәге йолдызлар вә җир йөзендәге ком бөртекләре санынннан да күбрәк иделәр. Алар Мөхәммәт пәйгамбәрнең монда килгәнен белүгә, урыннарыннан куптылар һәм, аның каршысына төшеп, нурлы йөзенә ихластан вә чын күңелдән яратып карадылар.

Ул агачта бер ботак булып, аның озынлыгы йөз мең еллык юл дәрәҗәсендә, ә үзе яшел зөмрәдән бар кылынган иде. Анда тагын да бер яфракның яссылыгы җиде кат җир вә җиде кат күк яссылыгында, имеш. Өстендә — нурдан яратылган михраб. Ул михрабның уңында тәхет куелган. Җәбраил галәйһис-сәлам Мөхәммәт пәйгамбәрне, кулыннан тотып, шул көрси-тәхеткә китереп утыртты. Тагын да аның тирәсендә башка тәхетләр тезелеп китгән иде. Уң ягында энҗедән ясалган ун мең тәхет һәм дә шул тәхетләрнең һәрберсе тирәсендә кырык мең тәхет булып, кайсында мәләкләр «Тәүрат»ны язалар, кайсында «Инҗил»не күчереп утыра иделәр. Ә икенче ягында тагын да ун мең тәхет өстендә фәрештәләр булып, алар «Зәбур» китабын яза, яннарында кырык мең тәхеттәге мәләкләр шул «Зәбур»ны укый иделәр. Барчасының тәхетләре яшел зөбәрҗәттән ясалган. Тагын да бер тарафта ун мең тәхет тора. Алары кызыл якуттан булып, монда мәләкләр «Коръән» яза. Һәрберсенең янында кырык мең тәхет куелып, андагы фәрештәләр «Коръән» укый иделәр. Алар:

— Йа Мөхәммәт рәсүлуллаһ! Бу урында безгә намаз укысаңчы? — дип үтенделәр. Бу сүзләрдән пәйгамбәрнең күңеле янә дә нурланып китте. Шунда ул Кодсе-шәрифтә кылган догасы төсле үк ике рәкәгать намаз чыкты. Барлык мәләк-фәрештәләр аны күреп, артыннан ияделәр. Барчасы нурдай балкып, шатлык вә сөенечләре йөзләренә бәхет очкыннары булып яктырып чыкты.

Сидрәтел-монтаһаның алдында дүрт чишмә ага иде. Җәбраил фәрештә әйтте:

— Бу ерганак-чишмәләрнең икесе, күренмичә ага торганнары, җәннәткә китә һәм дә тагын да икесе, күренеп ага торганнары Җиргә китә,— диде.— Җиргә киткән чишмәнең берсе — Нил елгасының башы, икенчесе исә — Ефрат елгасының чыганагы,— дип, бу гаҗәеп хәлләргә аңлатма бирде.

Мөхәммәт пәйгамбәр янә дә бер чишмәне күрде. Тирәсендә якуттан, энҗедән вә зөбәрҗәттән чатырлар корылган. Ул чишмә янында яшел кошлар очып йөри һәм дә бик моңлы вә сәмави тавышлар белән сайрыйлар. Аларның муеннары дөя муеннарына охшаш иде.

— Бу нинди чишмә? — дип сорады Мөхәммәт пәйгамбәр.

— Бу чишмә,— диде Җәбраил фәрештә,— Кәүсәр чишмәсе. Аны Хак тәгалә сиңа насыйп итте.

Кәүсәр чишмәсенең суы сөттән ак һәм дә бик чиста булып, ул якут вә зәмрә ташлар арасыннан агып чыга иде. Пәйгамбәр аннан уч тутырып су алды, иреннәренә таба китерде һәм туйганчы эчте. Аның тәмлелеген җирдә булган ширбәт вә гасәл (бал) белән генә чагыштыру мөмкин түгел иде. Безләргә авыз итү насыйп булмаганлыктан, теләгебезне киң тотып, тел өсләребездә аның тәмен тоеп торырга язсын иде дип теләргә генә каладыр...

Янә дә бу Сидрәтел-монтаһаның төбеннән бер чишмә агып чыга иде. Аның да күркәмлеге тел җитмәс сурәттә булып, аның янына тезләнгән вә килеп җитә алган бәндәләрдән дә бәхетлерәк һичбәр кемсәнә юктыр.

— Бу чишмәне «Сәлсәбил» дип атарлар, аннан тагын да ике чишмә барлыкка килеп, берсе — Кәүсәр, икенчесе — Бәхрел-Бәхет, ягъни Бәхет диңгезе диеп йөртерләр,— дип аңлатмалар бирде Җәбраил галәйһиссәлам.

Янә дә йөзләре нур белән балкыган бер төркем затларның монда таба килгәне күренде. Алар чишмәдә госел коенсалар, бәхет вә шатлыклары нур булып балкый икән.

— Болар кемнәр? — дип сорады пәйгамбәр.

— Болар барчасы да синең өммәтеңнән көнләшеп йөргәннән соң тәүбәгә килүчеләр, Хак тәгалә аларның гөнаһларын гафу иткән вә тәүбәләрен кабул кылган,— диде Җәбраил галәйһис-сәлам.

Шунда Мөхәммәт пәйгамбәрнең алдында өч төрле савыт китерделәр. Аның берсендә — бал, икенчесендә — хәмер, өченчесендә исә сөт иде. Эчәргә әмер иттеләр вә үтенделәр. Мөхәммәт пәйгамбәр арадан сөт салынган савытны алып эчте. Моны күреп торган Җәбраил галәйһис-сәламнең йөзенә шатлык нуры ягылды. Ул:

— Аллага шөкер, сөтне сайлап алдың. Бу сөт исә ислам диненә ишарәт иде. Синең өммәтең диненне үзенә якын күрер, аны аяк астына салып таптарга юл куймас, мөселманлык юлында булырлар,— диде.— Әгәр дә шунда хәмерне сайлап алган булсаң, динең аз гомерле булып, өммәтең соңыннан исламнан китәр вә кяферләр кул астында калыр иде,— дип аңлатып бирде.

Янә дә Сидрәтел-монтаһада бер фәрештә күренде. Шундый зур иде ки, әгәр буен үлчәсәң, мең еллык юл озынлыгы булыр иде. Аның җитмеш мең башы, ул җитмеш мең башында тагын да җитмеш меңәр йөзе вә ул йөзләрнең һәрберсендә җитмеш мең авызы бар иде. Тагын да җитмеш мең муенында берәр муенса асылынып, аларның һәммәсенә меңәр энҗе тезелеп һәм һәр энҗе эчендә бер мөһер сугылган булып, балкып тора иделәр. Аларга: «Лә иләһә илләллаһи, Мөхәммәдүр рәсүлуллаһи!» дип язылган. Ул фәрештә бер кулын башына, икенчесен аркасына куеп тәсбих әйтә, аның тәсбиханнән күк йөзе хәрәкәткә килә иде.

— Монысы кем була? — дип сорады Мөхәммәт пәйгамбәр.

— Бу фәрештә Адәм яратылганнан ике мең ел әүвәл бар кылынган вә җәннәт эчендә тәхет сакчысы иде. Аның карамагында мең мәләк булып, аннан соң ул шушында күчерелде,— дип сөйләп бирде Җәбраил галәйһис-сәлам.

Мөхәммәт пәйгамбәр бу фәрештә янына килеп сәлам бирде. Әмма ул аның сәламен кабул итеп алмады, тәсбих әйтүен дәвам итте.

Шуннан Җәбраил галәйһис-сәлам ул фәрештә янына килде һәм Мөхәммәт пәйгамбәрнең аңа сәлам биргәнен әйтте. Бу сүзләрне ишеткәч, ул фәрештә тәсбих әйтүеннән туктады һәм Мөхәммәтнең сәламен кабул итеп, аңа башын иде, хөрмәт билгесен белдерде. Урыныннан торып, ике канатын да җәеп җибәрүенә күк йөзен бар тарафтан каплап алды. Мөхәммәт пәйгамбәр янына килеп, аның битеннән үпте вә:

— Мәгълүм булсын, синең вә өммәтләреңнең гөнаһлары шушы бәхетле көн хөрмәтенә гафу кылынды,— дип сөендерде.

Аның янында ике сандык бар иде. Аның йөз мең ачкычы вә йозагы күренеп, барчасы да нурдан хасил ителгәннәр икән. Мөхәммәт пәйгамбәр, алар хакында Җәбраилдән:

— Бу нинди сандыклар икән? — дип сорады.

Җәбраил исә:

— Үзеннән сорасаң, җавабын бирер,— диде.

— Бу нинди сандыклар? — дип кабатлады Мөхәммәт пәйгамбәр шул ук соравын. Бу фәрештә ишетеп торды һәм:

— Бу сандыклар эчендә тәүбәлек язмалары теркәлгән. Анда синең барча өммәтләреңнең җәһәннәмнән азат булуларына ышанычнамә тезелгән, мин шул төргәкләрне саклыйм,- дип җавап бирде. Бу сүзләреннән соң Мөхәммәт пәйгамбәр тагын балкыбрак китте. Ул гүя нур эчендә коенып чыккандай булды.

Тагын да анда бер фәрештә күренде. Үзе әтәчкә охшаган иде. Ак тәхете якут баганада иде. Аның җитмеш мең канаты бар, ул җитмеш мең канатның һәрберсендә җитмеш мең каурый — энҗедән, җитмеш мең каурый — якуттан, җитмеш мең — яшел зәмрәдән, җитмеш мең — гамбәрдән һ. б. асыл ташлардан иде. Канатларына Мөхәммәтнең Хак тәгалә пәйгамбәре булуы язылып куелган. Һәр намаз вакытында башын кал-

кытып, Аллаһы тәгаләне данлап, үзгә бер тәсбихен әйтә вә канатларын бер-берсенә сугып кагына һәм алардан искиткеч нигъмәтләр вә җимешләр коела иде. Ул сыйлар барчасы җәннәт бакчасына төшә, барлык хурилар боларны күреп, гаҗәпкә кала иделәр. Җәннәт бакчасындагы агачларның ботаклары тибрәлеп, бихисап күп гүзәллекләр пәйда була иде. Мөхәммәт пәйгамбәребез өммәте, ягъни мөселманнар намазга калыктылар исә, ул әтәч төсле фәрештә тагын хәрәкәткә килә вә канатларын кагынып, җәннәтне нурландыра иде.

Бу фәрештә каршында Мөхәммәткә Хак тәгалә барча өммәтләрне, ислам халкын җәһәннәмнән азат итүен вә аларга җәннәт насыйп булачагын белдерде.

Моннан соң Җәбраил галәйһис-сәлам Мөхәммәт пәйгамбәрнең кулыннан тотты һәм аны шушы агачның өстенә таба алып китте. Анда килеп җиткәч, үзен генә калдырып китмәкче иде, рәсүл:

— И Җәбраил, шулай итеп мине монда калдырасыңмы инде? Шушында минем гомерем беттеме? Җиргә кабат әйләнеп кайтмаячакмынмы? — дип сорады.

— Сиңа билгеле булсын,— диде Җәбраил фәрештә.— Минем хезмәтем шушы җирдә туктап кала, алга таба миңа барырга ярамый! — дип белдерде.— Анда офык башлана!

— Син бит мине Аллаһы тәгалә катына китерәм дип әйткән идең, ни өчен шушы урында калдырасың? — диде моңа каршы Мөхәммәт, кулын Җәбраилнең учына куйды һәм бер адым артка чигенде. Моннан соң Җәбраил дә:

— Әгәр дә мин офык башланган урыннан алга таба бер генә адым атласам да, Хак тәгаләнең кыяфәт-карашыннан һәлак кылынып, бар булганым белән көеп, көлгә әвереләчәкмен! — диде.— Аллаһы тәгалә янына син ялгызың гына барырсың инде.

Алда күренгән юл илле мең еллык иде. Анда бер төрле мәләкләр каршы очрап:

— Аллаһы әкбәр, аллаһ бөек! — дигән сүзләрне кабатладылар. Тагын да шундый гыйбарәләр белән Аллаһы тәгаләне вә Мөхәммәтне зурладылар. Рәсүлне каршы алып торган фәрештә бу кәлимәләрнең әле бүген генә беренче тапкыр әйтелүен, ә үзләре өчен башка бер тәсбихләре булуын сөйләп бирде. Бу фәрештә аны биш йөз еллык юлдан озата килде. Моннан соң башка бер мәләккә тапшырып, пәйгамбәр тагын да биш йөз еллык юлны аның белән кичте. Шушы рәвешле җитмеш ара булып, һәр арада биш йөз мең еллык юл булды. Мөхәммәт пәйгамбәр янына бурак килде. Рәсүл, аңа утырып, шактый җирләрне узды, аннан соң Микаил да берара җир аны канатына утыртып озата килде. Шунда Мөхәммәтне Исрафил кабул итте. Тагын бер чаршаудан икенчесенә кадәр китерде.

Ул пәрдәләрне бер китапта — челтәр, икенчесендә — тукыма иде дип күрсәтәләр. Һәрхәлдә, ул пәрдә-чаршау дигәннәре Хак тәгаләнең гаять көчле нурыннан галәм вә күкләрне саклап тора, әгәр дә алар күтәрелсә, дөньялар бердәй харап булачак иде.

Микаил фәрештә канатында очканда Мөхәммәт галәйһис-сәлам күпме утлы дәрьяларны күрде. Аларның ялкыннары үрелеп тотардай иделәр. Әмма Микаил галәйһис-сәламгә кодрәтләре җитми иде. Аларны исән-имин кичтеләр. Исрафил фәрештә кабул итеп алгач та, рәсүл бик күп могҗизаларга тап булып, аларның барчасына исе китте. Бер тарафтан икенчесенә кадәр җәелгән, ут диңгезләренең очы-кырыйлары юк иде. Барча чаршаулар үтеп бетелде. Исрафил галәйһис-сәлам каршында «Кодрәт чаршавы» күтәрелде. Аны үттеләр. «Бөеклек чаршавы»на ирештеләр. Әмма Исрафилның көче бетте. Алга таба ул да бара алмый иде. Мөхәммәт пәйгамбәрне шушы Бөеклек чаршавы алдына куйды. Шунда кинәттән Рәфрәф пәйда булды.

Рәфрәф дигәннәре нурдан вә бер данә энҗедән яратылган канатлы келәм-түшәк иде. Мөхәммәт пәйгамбәр аның өстенә аягы белән басты.

Рәфрәф күтәрелеп китте. Күктә төрле гаҗәп күренешләр хасил булды. Җитмеш мең пәрдә — алтыннан, җитмеш мең чаршау — энҗедән, җитмеш мең чаршау — яшел зәмрәдән, җитмеш мең чаршау — кызыл якуттан, җитмеш мең чаршау — нурдан, җитмеш мең чаршау — золмәттән, җитмеш мең чаршау — уттан-ялкыннан, җитмеш мең чаршау судан булып, һәр чаршауны узу мең еллык юл иде. Рәфрәф боларның барчасы аша бик тиз узды һәм каршыда күтәрелгән пәрдә алдында туктап калды.

Ул пәрдәләргә чылбырлар тартылган иде. Ә чылбырлар үзләре берәр фәрештәнең муеннарына асылган һәм берсе-берсе арасы меңәр еллык юл булды. Монда тагын да җитмеш мең чаршау күренеп, һәркайсысы энҗе-якут төсле асылташлардан эшләнелгән, araларында шулай ук меңәр еллык юл иде. Рәфрәф Мөхәммәт пәйгамбәрне бу чаршаулар артына китерде. Бөек күкләр пәйда булды.

Бер риваятьтә әйтелгәнчә, Мөхәммәт пәйгамбәр соңгы Кәбирия чаршавы каршына килде. Шуннан соң Рәхиш пәйда булып,— бу Рәхишне алсу төстәге ат рәвешендә дип күз алдына китердек,— рәсүлне ул чаршау аша алып чыкты. Пәйгамбәр белән Хак тәгалә нуры якынаеп очрашты. Әмма Аллаһы тәгалә үзе күренмәде.

Бер тәхет пәйда булды. Үзе ак энҗедән, аяклары кызыл якуттан иде. Бу тәхет өстенә пәйгамбәрне утырттылар. Бер үзгә тамчы алдына килеп, Мөхәммәт галәйһис-сәлам аны йотып җибәрде. Бу гаҗәеп хәлләрдән акылы киткән, теле сөйләмәс хәлгә җиткән иде.

Шулвакыт вәхи ишетелде:

— Әссәламегаләйкем, пәйгамбәрләрнең олугы вә рәхимлесе вә бәрәкәтлесе! — дип.

— Әссәламегаләйкем, гыйбәдәтләребезнең иясе вә салихыбыз! — диде Мөхәммәт пәйгамбәр моңа каршы.

Сәламнәрне ишетеп торган фәрештәләрнең исләре-акыллары китте һәм алар бу сүзләрне отып калдылар, шунда ук барчасы да аңа иман китерделәр:

— Шаһитлык итәбез, Аллаһы тәгаләдән башка илаһи зат юк, шаһитлык итәбез, Мөхәммәт аның габиде вә рәсүле! — диделәр.

Шуннан соң пәйгамбәрнең Аллаһы тәгалә белән сөйләшүләре башланып китте. Ул хәбәрләрне фәлсәфә вә фән китаплары өчен калдырып, бу урында унбиш хикмәт күренүен, алардан ислам таифәсе, ягъни Мөхәммәт өммәтенә ризык вә сәламәтлек, сафлык вә бөеклек ирешкәнен әйтеп үтүдән артыгын сөйләп чыгу мәгъкуль күрелмәде. Аллаһы тәгалә вә аның пәйгамбәренең сөйләшүләреннән шәригать вә йолаларның нинди булырга тиешлеге аңлашылды, гыйбадәт рәвеше ачык күренде.

Аллаһы тәгалә белән сөекле пәйгамбәре Мөхәммәт саллаллаһ галәйһи вә сәлләм арасында булган хәбәрләшүнең иң тәүгесе иман китерү хакында булды.

— Син ничек иман китерәсең, пәйгамбәрләр иман китерәләрме? — дигән сорау килеп ирешге Мөхәммәт галәйһис-сәламгә.

— Мин, барлык пәйгамбәрләр шикелле үк, Аллаһы тәгаләм, синең бөеклегеңә вә кодрәт иясе булуыңа, юкны бар, барны юк итүеңә, барлык сыйфатларыңның камил булуына ышанып, күңелемнән бөртек тә шик белдермичә иман китерәм һәм дә миңа кадәр булган пәйгамбәрләреңә, фәрештәләреңнең барчасына, синнән иңгән изге китапларның һәммәсе дә камил вә хак булуына ышанып иман китерәм,— дип тезеп китте Мөхәммәт галәйһис-сәлам.

Моннан шул беленде ки, әгәр берәр кем Аллаһы тәгаләнең хак пәйгамбәрләренә иңдерелгән берәр китапны танымый һәм аңа иман китерми калдыра икән, бу кеше, һичшиксез, кяфер була. Ул китап «Инҗил»ме, «Тәүрат»мы, «Зәбур»мы, яки башка китапмы, аларның барчасын да мөселман таифәге хөрмәт белән укырга, аларга кимсетеп карамаска тиешме. Мөселман түгел халыкларның гына китабы ул дип карамыйча, Аллаһы тәгаләдән иңдерелгәнлегенә инану таләп ителә.

Әмма хак мөселман, ул китапларга карап, Мөхәммәт пәйгамбәребез шәригатеннән чигенергә тиешле түгел, чөнки ислам кануннары — дини тәгълиматның иң соңгысы.

Хак тәгаләгә инанган вә иман китергән кешеләр һәрвакыт инсаф иясе булырга тиешлеләр. Дога-намазны үтәү фарыз эшләрдән саналып, бәндәләрнең Аллаһы тәгалә белән үзара мөгамәләдә вә бәйләнештә торуларын ныгытыр. Әмма бер вакытта да Хак тәгаләне фәкыйрь дип әйтергә ярамас. Болай дип әйтүче кешеләргә шул сүзләре белән фәкыйрьлек килер, гомерләре авырлыклар вә борчулар казанына ташланыр. Шулай ук бер генә тапкыр да Аллаһы тәгаләне ишетмәс вә белми калыр дип тә шикләнергә ярамас, чөнки адәм балалары аннан качарга вә бозыклык юлына керергә уйлар, бары аларның бу сүзләренә вә уйларына карап кына Аллаһы тәгаләнең күрү һәм ишетү мөмкинлеге чикләнмәс. Аның күрүе вә ишетүе безнең кебек күз белән вә колак ярдәмендә түгел, бәлки бөтенләй башкачадыр.

Хак тәгаләгә инану мәсьәләсендә сүзләр тәмамланугач, шәригать вә намаз тәртипләре тикшерелде. Намазны үзенә бертөрле йола рәвешендә генә караучылар каты ялгыштылар вә гөнаһка чумдылар. Ул бер дә алар уйлаганча түгел. Намазның төп асылы Аллаһы тәгалә алдында кылган гөнаһларның, (бәләкәйме алар, зурмы — барыбер) гафу вә ярлыкау кылынуын үтенүдер. Тормыш кырын адәм балаларына ялгышсыз һәм гөнаһсыз кичү мөмкин дә түгелдер, моны кабул иткән кешеләр белсеннәр: намаз укыган вә аны калдырмаган бәндәләрнең булган гөнаһлары гафу кылыныр.

Берәүләр сөйләрләр, имеш, әгәр мин гөнаһ эшләсәм, Аллаһы тәгалә ярлыкар, чөнки намаз укыдым, берсен дә калдырмадым, диярләр. Моннан да олуг хата вә зур гөнаһ булырга мөмкинме? Әлбәттә юк!

Намаз уку — гөнаһтан котылу рәвеше дә, чарасы да түгел, бәлки үз-үзеңне Аллаһы тәгалә алдында бурычлы дип санап, гөнаһтан саклану вә ялгышып кылынган гөнаһ авырлыгын җилкәләрдән төшерү чарасы гына.

— Рәхмәтең белән шушылай безнең гөнаһларыбызны гафу иттең,— диде Мөхәммәт пәйгамбәр Аллаһы тәгалә алдында.

— Әгәр дә сезгә рәхмәтем ирешмәгән булса, өммәтең һәлак булыр иде,— дигән җавап килде Хак тәгаләдән.— Минем рәхмәтем вә рәхимем даим вә туктаусыз. И хәбибем, яратканым, синең доган минем рәхмәтемә сәбәп булмас, бәлки минем рәхмәтем синең доганны кирәкле итте. Рәхим-шәфкатем тулысынча тәкъдиреңдә беленер һәм алар синең үзеңнең шәфкатеңнән. Үзең нинди булсаң, сиңа шундый тәкъдирне бүләк итәрмен!

Бу сүзләрдән бик күп мәгънәләр чыгып, гыйлем ияләре аларны сөйләп-аңлатып бирерләр. Монда шуны әйтү белән генә чикләнәбез ки, адәм балалары үзләрен ни рәвешле тотсалар, тәкъдирләре дә шундый булып, яманлык сукмагыннан киткәннәр — тәмугка, яхшылык юлын сайлаучылар җәннәткә килеп керерләр.

Дога кылганнан соң, өммәтләре өчен Мөхәммәт галәйһис-сәлам Аллаһы тәгаләдән биш нәрсә сорады: беренчесе: гөнаһларны гафу итү, икенчесе: ялгышларны ярлыкау, өченчесе: бозыклыкны гафу итү, дүртенчесе: хаталарны гафу итү һәм бишенчесе: рәхим-шәфкатьле вә рәхмәтле булу. Үтенече кабул ителеп, вәгъдә бирелде.

Аллаһы тәгаләнең сүзләрен ишетүгә, Мөхәммәт галәйһис-сәлам башын түбән иеп, сәҗдә кылды.

— Нигә, яратканым, башыңны болай идең? Күтәр башыңны,— диде Аллаһы тәгалә.

— Мин дә синең бәндәң, ялгышлык вә хаталык кылуымнан куркып шулай иттем. Синең ярлыкауларың хакында ишеткәч, намусыма авырлык килде,— дип җавап бирде рәсүлебез.

— Мин ярлыкаудан сезгә җинеллек килмәс, яманлыклардан вә бозыклыклардан саклансагыз, минем бу әмерем өммәтенә Ахырзаман көне килеп, гарасат мәйданында гына алга чыгар,— диеп аңлатты Хак тәгалә.

Моннан шул билгеле булды ки, адәм балалары чиксез гөнаһларга батып, Хак тәгаләдән ярлыкау үтенеп кенә үзләрен сафландыра алмаслар, бәлки намус авырлыгын тоеп яшәүләреннән соң гына Кыямәт көнендә бу йөкләреннән арынырлар. Әмма бер гөнаһ та җәзасыз калмас. Мөхәммәт өммәте шуның белән барча кавемнәрдән өстен булырлар.

Аллаһы тәгалә белән сөйләшүләр вакытында Мөхәммәт пәйгамбәр өммәтенең күрәчәкләреннән вә Кыямәт көнендә ниләр буласыннан бик күп мәгълүмат алды. Ул хәбәрләр аны бик тә сөендерде. Мөселманнарның бар яктан да өстен чыгачаклары һәм Аллаһы тәгаләнең мәрхәмәтенә юлыгачаклары башка диннәр юлыннан киткәннәрнең күңелләрендә көнчелек утын кузгатып, аларны тагын да адаштырачагы билгеле булды. Шуннан соң вәхи килеп:

— Ислам өммәтендә тормаганнар мине күп сурәтләрдә ясадылар, хәтта арадан үземә сыннар да коючылар булды. Алар, шуларга табыну юлы белән китеп, зур гөнаһка баттылар. Моның сәбәбендә диннәре бетүгә таба борылып, гыйбадәтләре дөрес түгелдер,— дип белдерде Хак тәгалә.

Моннан шул билгеле булды ки, Хак тәгаләдән иңдерелгән изге китаплары хөрмәт белән укылырга тиешле исә дә, аларның бозык шәригать юлын сайлаулары вә төрле сын һәм сурәт ясап, шуларга табынулары өммәтләр өчен өлге түгел, шулай ук мөселманнар күңелендә ул нәмәрсәләре хөрмәт белән бәяләнергә дә тиешле булмадылар...

Үзара аңлашу вакытында Мөхәммәт пәйгамбәр сорады:

— И Хак тәгалә, син Җәбраилгә алты йөз мең канат бирдең, ә миңа нәрсә тапшырдың?

— И Мөхәммәт хәбибем, Җәбраилнең алты йөз мең канатыннан синең бер сүзең өстенрәк. Чөнки син бәндәләрне шул сүзләрең белән хак юлга китердең. Аларга Хакыйкатьне өйрәттең. Әгәр дә Җәбраил канатларын җәйсә, бер Каф тавыннан икенче тарафта булган Каф тавына кадәр барча җирләрне каплап алыр. Әмма синең динең шулай ук кодрәткә ия булып, дөньяның бер тарафыннан икенче ягына кадәр барып җитәр. Барчалар синең өммәтең булырлар,— дип җавап бирде Хак тәгалә.— Синең: «Амин»,— дип йөзеңне сыпырган ике кулың Җәбраилнең алты йөз мең канатын җилпенүеннән өстенрәк вә хөрмәтлерәк,— диде.

— Атабыз Адәм пәйгамбәрне хөрмәтле фәрештәләрдән иттең, ә миңа нинди язмыш юлларсың? — дип сорады Мөхәммәт галәйһис-сәлам.

— Адәм пәйгамбәргә бары тик синең йөз нурыңны саклаганы өчен шушындый хөрмәт күрсәтелде,— диде Хак тәгалә.

— Аллаһым, аны җәннәтле иттең,— диде Мөхәммәт.

— Әйе, мин аны җәннәтле иттем, әмма аннан чыгардым. Синең өммәтеңне дә шулай ук җәннәтле итәрмен, әмма кире чыгармамын,— диде Бөек зат.

— Адәм атабызга барлык фәрештәләрне сәҗдә итәргә боердың,— диде пәйгамбәр.

— Әйе,— диде Хак тәгалә.

— Ә миңа нәрсә булыр? — дип сорады Мөхәммәт.

— Адәм пәйгамбәргә барча фәрештәләрне сәҗдә иттердем. Әмма синең исемеңне җиде кат күкләргә язып куйдым. Сират күперендә, җәннәт капкаларында — барчасында синең исемең, җирдәге пәйгамбәрем буларак, барчасы ярατылганнан алда язылып куелды. Исемеңне барча фәрештәләр белеп тордылар. «Лә иләһә иллаллаһи, Мөхәммәдүр рәсүлуллаһи!» кәлимәсе барчасына могҗизадай тәэсир итәр, ябык капкалар ачылыр, куелган ташлар кубарылыр, сакта торучы фәрештәләр юл бирерләр,— диде Аллаһы тәгалә.

— И Раббым, син Идрис пәйгамбәрнең җанын гәүдәсе белән бергә җәннәткә керттең, миңа нәрсә насыйп булыр? — диде Мөхәммәт.

— Мин Идрис пәйгамбәрне җәсәде белән бергә җәннәт бакчасына кертсәм дә, әмма элек аңа Газраилдән җан алыну ачысын татырга мәҗбүр иттем. Ә сиңа исә җан алыну ачысын татырга туры килмәс, тәмуг кисәүләренең зәһәрен күрмичә җәннәткә керерсең,— диде Хак тәгалә аңа җавабында.

— Нух пәйгамбәргә көймә бирдең, ә миңа ни бирерсең? — дип сорады тагын Мөхәммәт галәйһис-сәлам.

— Нух пәйгамбәргә көймә бирдем, шулай итеп аны туфаннан саклап калдым. Ә сиңа канатлы Буракны бирдем. Күз ачып-йомганчы Җирнең бер читеннән икенчесенә ирештең, күкләргә мендең, бөек Галәм хикмәтләрен күрергә насыйп булды,— диде Аллаһы тәгаләбез.— Синең өммәтләреңә күп мәсчетләр өләштем. Алар шул мәсчетләрен күреп сөенерләр. Шул мәсчетләре булу аркасында өсләренә ургылып туфан килмәс, алар олуг хәвефтән имин булырлар,— диде.

— Аллаһым, син Ибраһим пәйгамбәреңә Нәмрудның учагын гөлбакча иттердең, ә минем өчен нәрсә боердың? — дип сорады Мөхәммәт галәйһис-сәлам.

— Мин Ибраһим пәйгамбәргә Нәмрудның учагын гөлбакча итсәм дә, аның динендә булганнарны тәмуг утыннан сакламадым. Аны «Хәлилем»[1] дип атасам да, сине «Хәбибем»[2] дип белдердем. Сине вә өммәтләреңне яраттым, сөеклеләрем иттем. Тәмуг уты сиңа вә өммәтләреңә гөлбакча булыр, алар аннан сау-сәламәт көенчә җәннәткә ирешерләр,— дигән җавабын ирештерде Хак тәгалә. Аның бу сүзләреннән Мөхәммәт галәйһим-сәлам бик тә канәгать калды вә өммәтләренең тәмуг утында гарык булмаячакларын ишетеп, бик тә сөенде, әлегәчә үзенең өммәтләре өчен хәсрәт чишмәсеннән су эчә иде, инде шатлык коесыннан ширбәт эчеп, йөрәк януларын басты.

— Исмәгыйль пәйгамбәреңә Зәмзәм чишмәсен бирдең... — дип янә сүзгә керешә Мөхәммәт галәйһис-сәлам.

— Исмәгыйль пәйгамбәремә Зәмзәм бирсәм, сиңа җәннәтнең Кәүсәр чишмәсен тапшырдым,— диде Хак тәгалә.

— Ә кяферләрне динемә каршы куйдың?..— диде Мөхәммәт.

— Яһүдиләрне вә христиан-носариларны синең динеңә каршы куйдым, әмма синең өммәтеңә файда күндереп, аларны җәһәннәмгә җибәрдем, өммәтеңне коткардым,— диде Хак тәгалә.

— Салих пәйгамбәреңә дөя бирдең, ә миңа нәрсә насыйп икән? — дип сорады Мөхәммәт.

— Салих пәйгамбәргә дөя могҗизасын тапшырдым, ә сиңа Мәдинә шәһәрен бирдем, күп малга ирештердем, милләтеңә карата мәхәббәтеңне бирдем, сине Коръән иясе ясадым, аның белән бөек иттем. Йә, болар Салихның дөясеннән өстенрәк түгелмени?! — диде Хак тәгалә.

— Йа Аллам, Һуд пәйгамбәргә җил бирдең. Ул аның ярдәмендә кяферләрне һәлакәткә китерде, өммәтләрен җәбер-золымнан саклап калды. Миңа ни бирерсең? — диде Мөхәммәт.

— Һуд пәйгамбәремә җил бирдем, әмма өммәтен тәмугтан сакламадым. Ә синең өммәтең Сират күперен кичәргә килгәндә, җил бирдем. Ул җил җәһәннәмнән чыгып исәр, әмма тәмуг ялкынын ислам өстенә китермәс, киресенчә, аны читкә куар, ә өммәтеңне җәннәт бакчасының ишек тупсалары алдына китереп куяр,— диде Хак тәгалә.

— Аллаһы тәгалә, Муса пәйгамбәрне сүзеңне сөйләүче иттең...— дип тагын да сүз башлады Мөхәммәт.

— Аның белән Тур тавында сөйләштем, сиңа үз яныма килергә рөхсәт бирдем, шушы нурым аша сүз алыштабыз,— диде Аллаһы тәгалә.

---

[1] Хәлилем — дустым.
[2] Хәбибем — сөеклем.

— Аллаһым, Муса пәйгамбәреңә «Тәүрат» бирдең?
— Сиңа «Аятел көрси» бирдем,— диде Аллаһ.
— Муса өммәтен дәрьядан кичердең, аннан чыкканда хәтта аякларына тамчы да су тимәде,— диде Мөхәммәт пәйгамбәр.
— Синең өммәтеңне шул рәвешле җәһәннәмнән чыгардым, хәтта аяклары да тәмуг уты өстендә асылынып калмас, очкыны да барып ирешмәс,— диде Хак тәгалә.
— Муса пәйгамбәреңә могҗиза таягы бирдең, аңа күпме могҗизалар кылырга юллар ачтың,— диде Мөхәммәт.
— Синең өммәтләреңә шәфкатемне ирештердем. Кыямәт көнендә ничә мең өммәтләрең шушы шәфкатем аркасында гөнаһларыннан арынырлар,— дип җаваплады Аллаһы тәгалә.
— Муса галәйһис-сәламгә тишекле таш бирдең. Кирәк вакытында шул таштан чишмә чыгардың,— диде Мөхәммәт пәйгамбәр.
— Синең өммәтләреңә Кыямәт көнендә эсселектән тәннәре пешмәсен өчен йолдызлардан сөт, ширбәт вә бал ирештердем. Алар эсселек вә ялкыннан шуның ярдәмендә котылырлар,— диде Хак тәгалә.— Муса чишмәсеннән бу өстенрәктер!
— Давыт пәйгамбәреңә «Зәбур»ны бирдең, кулында тимерне эреттең, җир йөзендә хәлифә иттең,— диде Мөхәммәт.
— Сиңа «Әнгамь» сурәсен бирдем, халыкларның йөрәкләрен шәфкать вә рәхмәтең белән йомшак ясадым, синең өммәтеңә җир йөзендә иң хөрмәтлеләрдән булырга мөмкинлек кылдым,— дип белдерде Хак тәгалә.
— Сөләйман пәйгамбәргә мөлекләреңне тапшырдың, җеннәрне вә диюләрне буйсындырдың,— диде Мөхәммәт.
— Сиңа вә өммәтләреңә җәннәт мөлкен бирдем, никадәр юлларны җиңел генә үтәр өчен буракны ирештердем. Болармы өстен, әллә Сөләйман өчен җирдә бирелгәннәрме? — диде җавабында Аллаһы тәгалә.
— Юныс пәйгамбәрне өч төрле караңгылыктан азат иттең,— дип белдерде Мөхәммәт галәйһис-сәлам.
— Синең өммәтеңне исә гүр караңгылыгыннан, Кыямәт көне карагылыгыннан вә тәмуг караңгылыгыннан азат иттем,— дип белдерде Хак тәгалә.
Болардан Мөхәммәт өммәтенең мең өлеш бәхетлерәк булуы ачыкланды. Әмма моның өчен һич, башларыбызны югары күтәреп, артыгы белән чөелеп, ахмаклык сазлыгына бату ярамас. Киресенчә, күңелләр белән горурлык тоеп һәм исламда тормаган кемсәләрнең язмышларына кызганып карарга тиешле. Шәфкатьлелек иясе булырга кирәк. Хак мөселманлык шушы түгелме?
— Аллаһым, Гайсә пәйгамбәргә нигъмәтләр тулы өстәлеңне бирдең? — диде Мөхәммәт галәйһис-сәлам.
— Аны өммәтеңә Кыямәттә әзерләдем,— диде Хода тәгалә.
— Аллаһы, аңа «Инҗил» бирдең?
— Сиңа «Ихлас» сүрәсе бирдем!
— Аллаһы, Гайсәне күккә күтәрдең?
— Сине барчасының башлыкларыннан ясадым, төнлә вә көндезләрен биш тапкыр «Әшһәдани лә иләһи илләллаһи, Мөхәммәдүр-рәсүлуллаһи» дип әйтерләр! — диде Хак тәгалә.
— Йа Илаһи, бәни-исраилгә күкнең манный боткасын бирдең вә аларга ярдәмнәреңне ирештердең?
— Сиңа вә өммәтеңә дөньялыкта вә күкләрдә сансыз нигъмәтләр хасил иттем, бәни-исраилнең күпләренә кулым белән кагылдым, аю вә маймул ясадым, өммәтеңнең берсенә дә кагылмадым, гәрчә алар кылган кебек гамәлләрне эшләсәләр дә,— диде Хода тәгалә.— Йа Мөхәммәт, сиңа шундый бер сүрә бирдем ки, андый сүрә «Инҗил»дә дә, «Тәүрат»та да юк. Аны «Фатыйха» сүрәсе дип атарлар. Китапның башында торыр. Әгәр дә кем дә булса аны укыса, үзен җәһәннәмгә хәрам итәрмен,

анасыннан вә бабасыннан газапларын алырмын. И Мөхәммәт, синнән дә бөек берәүне җир йөзендә бар кылмадым! — диде.

Шуннан соң Аллаһы тәгалә Мөхәммәт пәйгамбәрнең өммәтләренә бурычлар йөкләде һәм:

— Йә Мөхәммәт, синең өммәтеңә гыйбадәт таләбен ирештердем, кичә вә көндез илле вакыт намаз кылу кирәк булыр, һәр елда алты ай буена ураза тотарсыз,— диде.

Аның бу сүзләрен ишеткәч, Мөхәммәт пәйгамбәр аптырашта калды һәм Аллаһы тәгаләдән бу таләпләрен киметүне, кичә вә көндез егерме биш вакыт намазы һәм уразаны өч айга калдыруны үтенде.

— Тәмам кабул иттеңме? — диде Хак тәгалә.

— Әйе, кабул иттем! — дип фавап бирде Мөхәммәт.

Шуннан соң Мөхәммәт пәйгамбәр Муса галәйһис-сәлам белән сөйләште. Аллаһы тәгаләнең егерме биш вакыт намазы вә өч ай ураза бурычын йөкләвен ишеткәч:

— И Мөхәммәт, синең өммәтләрең болай да барчабызның кавемнәреннән өстен чыктылар, бу кадәр бурычларны алар өстенә йөкләмә зур авырлыклар вә кыенлыклар тудырыр. Аларны үтәү гаҗизлек белән башкарылыр. Минем кавемемә бик аз гыйбадәт тә авыр тоелды. Хак тәгаләдән үтен, намаз вә уразаны кыскартсын,— дип киңәшләрен бирде.

Мөхәммәт пәйгамбәр бу сүзләрне Аллаһы тәгаләгә ирештерде. Китаплар шулай яза, үзенең яраткан пәйгамбәренең үтенечләрен Хода тәгалә кабул итеп алды һәм:

— Синең өммәтләреңә биш вакыт намазы вә бер ай буена ураза тоту илле вакыт намазы вә алты ай уразаның савабына тиң торсын,— дип билгеләде.— Ишеттең, синең вә өммәтләрең өчен Кыямәт көнендә никадәр уңайлыклар вә рәхим-шәфкатьләр әзерләдем. Сиңа биргән кирәмәт вә могҗизаларым да шунда булыр, саннары хисапсыз икәнен күрерсең. Алар бары хак юлдан йөз чөермәсеннәр вә иманнарына тугры калсыннар,— диде.

Шуның белән Хак тәгаләнең һәм Мөхәммәт пәйгамбәрнең сөйләшүләре тәмам булды. Бу кадәр сөенеч вә бәхетләрнең берьюлы Мөхәммәт галәйһис-сәламгә ирешкәннәре юк иде әле. Шуннан соң Хода тәгалә:

— Инде минем яратканым вә сөекле колым Мөхәммәт пәйгамбәргә өммәтләре өчен әзерләнеп куелган җәннәтне илтеп күрсәт! — дип Җәбраил фәрештәгә боерыгын җиткерде,— Рәсүлемнең хәтере икеләнүләрдән азат булсын!

Шулай итеп, Мөхәммәт саллаллаһ галәйһи вә сәлләмнең каршында җәннәт сараеның ишекләре ачылып китте һәм ул анда сәяхәт итте, гаҗәеп хәлләрне күрде.

Пәйгамбәрләребезнең җәннәттә булуын китаплар бу рәвештә сурәтлиләр ки, без алардан берничәсен генә сөйләп үтәбез...

Җәннәт бакчасының капкасы кызыл алтыннан корылып, һәр канатының яссылыгы биш йөз еллык юл бәрабәренә тиң иде. Мөэминнәр каберләреннән кубарылып чыгарылгач, күзләре шушы капкага төшәр. Ул капка исә күктә үз алдына эленгән сарай сыйфатында күренеп торыр һәм аннан фәрештәләр, барчасы җыелышып, мөэминнәрне үзләре янына чакырырлар.

Бу капканың дүрт йөз кадагы булыр, кайсы — энҗедән, кайсы — якуттан, кайсы — зәмрәдән эшләнгән, күзләрне үзләренең сихерле елмаюлары белән чагылдырып торырлар. Уртасында кызыл якуттан бер бөек түгәрәк күренер, ул гаять тә бөек булуы белән хушларны алып, күңелләрне тартып, җаннарга рәхәтлек иңдерер. Җәннәт капкасын ачып керүгә, кырык мең шәһәр нур чәчәр. Ул кырык мең шәһәрнең һәрберсендә кырык мең төшле дивар күтәрелеп торыр. Һәр дивар төше өстендә бер фәрештә утырыр. Кулларында ике табак булып, берсендә — нур, икенчесендә — затлы кием икән. Мөхәммәт галәйһис-сәлам Җәбраил фәрештә белән

җәннәт капкасына килделәр, вә пәйгамбәр бу хәлләрне күреп исе китте һәм алар хакында белешә башлады.

— Болар барчасы да Адәм галәйһис-сәламгә кадәр сиксән мең ел әүвәл бар кылындылар. Кыямәт көнендә синең өммәтеңә бу фәрештәләр шушы табакларны китерерләр. Алар барчасы да хак мөселманнар өчен әзерләнеп куелганнар,— дип аңлатып бирде Җәбраил фәрештә.

Җәннәт капкасын Ризван хәзинәче саклап тора иде. Мөхәммәт пәйгамбәрнең мөбарәк кулыннан тотып, Җәбраил галәйһис-сәлам аны Ризванга китерде.

— Анда кем бар? — дип сорады Ризван, килүчеләрне күреп.

— Җәбраил!

— Синең белән кем бар?

— Мөхәммәт саллаллаһ галәйһи вә сәлләм! — дип җавап бирде шунда Җәбраил.

— Аның пәйгамбәрлек заманы килдеме? — диде Ризван.

— Әйе, килде! — диеп җаваплады Җәбраил.

— Аллага шөкер! — диде Ризван.

Барлык мәләкләр вә фәрештәләр Мөхәммәт пәйгамбәребезнең Коръән сәхибе булуы вә мигъраҗга күтәреләчәге хакында хәбәрдар иделәр, алар өчен шөһрәт казанган бер сәхифә буларак, аны түземсезлек белән көттеләр.

Шунда Ризван җәннәтнең капкасын ачып җибәрде. Тупсалары көмештән, такталары — алтыннан, бизәкләре — ак энҗедән иде. Ризванга Мөхәммәт пәйгамбәр сәлам бирде, үз чиратында җәннәт сакчысы да аңа хөрмәтләрен күрсәтте.

— Бу җәннәт сиңа вә өммәтләреңә әзерләнеп куелган иде, ул синеке вә өммәтләреңнеке! — диде ул.

Шунда Мөхәммәт галәйһис-сәлам Ризванның сигез хәлифәсен вә күпсанлы гаскәрләрен күреп алды. Бу хәлифәләрнең һәрберсе аерым ишеккә куелып, аларның һәркайсына хезмәттә йөз мең фәрештә, тагын да житмеш мең гаскәр башлыгы, житмешәр мең мәләкләрдән торган сугышчылары бар иде. Шуннан соң Ризван үзенең тәсбихын әйтте вә Мөхәммәт пәйгамбәргә җәннәтнең нигъмәтләрен күрсәтте. Әгәр дә бөтен гомерен адәм баласы шундый нигъмәтләр җыярга сарыф итсә дә бу кадәр байлыкларны хасил кыла алмас иде.

Җәннәт сарайларының кирпечләре шундый да камил вә хушны алырлыклар ки, берсе — алтыннан, икенчесе — энҗедән, өченчесе — якуттан, дүртенчесе — зөбәрҗәттән, барчасы да нәкыш белән бизәлгәннәр. Һәрберсенең яссылыгы биш йөз еллык юл иде. Бу диварлар һәммәсе үтә күренмәле булып, эчендәге туфраклары мөшкәт вә гамбәрдән, өсләренә зур тәхетләр куелган вә энҗе-якутлар бар тарафларга сибелеп, күзләрнең алкасында нур уйнатырлар, боларны күргән кеше кабат моннан чыгасы килмәс, барсын да язарга телдә сүз житмәс.

Ул шәһәр диварлары артында тагын да сарайлар вә асылмалы йортлар кылынган иде ки, кайсы — алтыннан, кайсы — көмештән, кайсы — зәмрәдән, кайсы — энҗедән, кайсы — зөбәрҗәттән һ. б. Һәр сарайда житмеш мең зал, һәр залда житмеш мең бүлмә, һәр бүлмәдә алтын вә көмештән тәхет куелган. Һәр тәхет янында бер-берсенә тиң булмаган утыргычлар куелып, тәхет өстендә бер фәрештә башына таҗ кигән хәлендә торып, янындагы житмеш мәләккә әмерләрен житкерә, тавышлары бер илаһи моң төсле ишетелә иде.

Шулай ук Мөхәммәт пәйгамбәр җәннәттә чишмәләргә тап булды. Берсе — сөттән, берсе — судан, берсе — хәмердән, берсе — балдан, һәр сарайга бу чишмәләрдән ермаклар аерылып, шуларга агып керер. Аларның чыккан җирләре алтыннан вә энҗедән ясалып, ташлары җәүһәр вә якуттан, алтыннан, көмештән, ә яннарында мөшкәт һәм гамбәр туфрак, яр читендәге үләннәре зәгъфран вә сөмбел иде.

Тагын да агачлар күренде. Алар шулкадәр биек иделәр ки, очларын күз белән карап та күрү мөмкин түгел. Аларның кәүсәләре — алтыннан, ботаклары — якуттан, энҗедән вә зәбәрҗәттән, яфраклары — ефәктән, парчадан иде. Ә үзләренең зурлыклары бер Каф тавыннан икенчесенә кадәр бөтен җирне каплап тора, җимешләре йодрык кадәр вә аларда җитмеш төрле ләззәт вә тәм бар. Әгәр дә бу агачтан ул җимешне җәннәткә кергән кеше өзәргә теләсә, табактагы нурга таба ул сораган җимеш үзе килер вә табак мөэминнең авызы янына җитешеп, авызга кабарлык булыр. Агачның кайсы гына җирдә, түбәндәме, биектәме, башка урындамы үсүенә карамастан, җимешләре җәннәткә ирешкән кешене шушы рәвештә тукландырыр.

Ул агачларда тагын да кошлар түе иде. Шуннан соң Мөхәммәт пәйгамбәргә сигез җәннәтне күрсәттеләр. Беренчесе — Фирдәвес, икенчесе — Җәннәтел-Мәэвә, ягъни Торак-Җәннәт, өченчесе — Җәннәтел-Гаден, ягъни Җәннәт-Бакча, дүртенчесе — Җәннәтел-Нәгыйм, ягъни Бәхет-Җәннәте, бишенчесе — Дарес-Сәлам, ягъни Тынычлык вә Иминлек Йорты, алтынчысы — Дәрел-Карар, ягъни Карар Йорты, җиденчесе — Дәрел-Җәлал, ягъни Бөеклек Йорты, сигезенчесе — Дәрел-Хулд, ягъни Мәңгелек Йорты. Бу җәннәтләрнең беренче дүртесе гөлбакча вә агачлыклар рәвешендә булып, калган дүртесе бакча вә сарайлар хәлендәдер.

Ул җәннәтләр эчендә олуг вә зиннәтле сарайлар корылган һәм арада иң биегенең иясе Әбу-Бәкер Әс-Сыйддыйкка, тирәсендәге кечерәкләре Гомәр, Госман вә Гали — Мөхәммәт пәйгамбәрнең дүрт ярына багышлап куелган. Алар эчендә олуг тәхетләр корылып, барча урыннар вә җирләр энҗе-якут, алтын-көмеш, зәмрәд вә зәбәрҗәт һ. б. асыл ташлар белән бизәлгән.

Мөхәммәт пәйгамбәр оҗмах сарайларын күреп сөенде, эчләренә үтәргә кыенсынды. Аларда сансыз күп хур кызлары хезмәт итә иделәр. Шулай да Мөхәммәт галәйһис-сәлам Гали сәхабәгә багышлап куелган сарайга кермичә үтә алмады. Анда кияве булган вә хәлифәсе ителәчәк Галинең ясалып куелган сурәтен күрде.

— Галинең бу сурәте фәрештәләргә килеп карар вә соклану өчен монда эленгән,— дип аңлатты Җәбраил галәйһис-сәлам.

Шуннан соң Мөхәммәт пәйгамбәр бакчага үтте дә агачыннан бер җимешне алып капты. Ул арада сарайдан бер хур кызы килеп чыкты. Мөхәммәтнең бу эшен күреп алды да:

— Син кем буласың? — дип сорады.— Бу агачның җимешләре Гали сәхабәгә аталып куелган, башка һичкемнең аңа тияргә хакы юк,— диеп белдерде.

Аның шушы сүзләреннән Мөхәммәт үзен кыен хәлдә күрде. Җәбраил белән бергә сарай эченнән чыктылар һәм җәннәтнең уртасына җиттеләр. Анда оҗмах күгеннән агып килгән бер чишмәгә очрадылар. Моның улагы — зәбәрҗәттән, юлындагы ташлары — җәүһәрдән, балчыгы — гамбәрдән, ярларында үскән үләннәре зәгъфыраннан иделәр. Эченә вә читләренә күз күрмәгән, колак ишетмәгән асылташлар сибелеп, күктәге йолдызлар кебек күз кысышып җемелдиләр. Агып чыккан суы сөттән, хәмердән, судан, балдан булып, бер-берсе белән буталмый вә бер-беренә карышмый иделәр.

— Бу нинди чишмә икән? — дип сорады Мөхәммәт пәйгамбәр Җәбраил фәрештәдән.

— Бу — сиңа дип аталып куелган вә вәгъдә ителгән Кәүсәр чишмәсе була инде! — дип сөендерде аны Җәбраил.— Әгәр дә бер кемсә аннан бер генә йотымны гына эчсә дә, мәңгегә Аллаһы тәгаләнең шәфкатенә вә рәхименә юлыга вә бәхет эчендә нурланып яши,— диде.

Кәүсәр чишмәсенең челтерәп аккан тавышларына кадәр җанга ягымлы вә күңелләрне шатлык-сөенечкә күмә, кырларында үсеп утырган агачлар вә чәчәк-үләннәр хисләрне адаштырырлык хуш исләр тарата һәм ботакларына вә сабакларына басып сайраган кошлар күңелләргә рәхәт-

лек өләшә.Ә җәннәт кошларының муеннары дөянеке төсле озын, матур вә гүзәл иделәр.

Бу бакча төсле урын җәннәттә башка юк иде. Моннан алда күренгән сигезе дә аннан калыша иделәр. Кәүсәрдән бер тармак су бүленеп китә иде.

— Монысы Зәмзәм чишмәсенә коя,— дип белдерде Җәбраил.

Кәүсәр чишмәсенең читләрендә кече сарай вә чатырлар корылган, алар эчендә хур кызлары хезмәт куя иделәр. Һәркайсының йөзләре сөттән ак, бит очлары якуттан кызыл вә нурлы, үзләре җирдән йомшак, айдан якты, чәчләре гаять тә кара вә уралып-үрелеп куелган, һәрберсенә мең хезмәтче бар. Аларны күреп, Мөхәммәт пәйгамбәр:

— Болар уртасында бөтен гомереңне уздырсаң да һич кайгы-хәсрәтең булмас, болар белән бергә булудан да зур бәхет тәтемәс,— дип сөенечен белдерде.

— Бу сарайлар вә бу хур кызлары синең хатыннарың өчен вәгъдәләнгән, алар бәхете өчен әзер кылынган,— дип белдерде аңа Җәбраил фәрештә.— Ул хур кызлары шулай ук синең өммәтең өчен дип тә бар кылынганнар,— диде.

Мөхәммәт пәйгамбәр әлеге дә баягы дүрт чишмә хакында хәтерен яңартты вә Җәбраил фәрештәдән сорады:

— Ул чишмәләр каян килә дә кая китә?

— Кәүсәр чишмәсе Зәмзәмгә төшә, әмма ул чишмәләрнең каян килгәннәрен вә кая киткәннәрен тәгаен генә әйтә алмыйм,— дип җавап бирде Җәбраил.— Әгәр кирәк тапса, Хак тәгалә үзе сиңа белдерер,— диде.

Аның бу сүзләре әйтелеп тә бетмәде, бик зур бер фәрештә пәйда булды. Пәйгамбәрнең аны әлегә күргәне юк иде. Ул, сансыз күп канатларын сирпеп:

— Йа Мөхәммәт, Аллаһы тәгаләбезнең сөеклесе, бер канатыма аякларыңны куй вә мөбарәк күзләреңне йомып тор,— диде.

Мөхәммәт галәйһис-сәлам аның әмерен үтәде. Пәйгамбәрне фәрештә күтәреп алып китте һәм бераздан:

— Инде күзләреңне ач! — диде.

Алар биек вә олуг агач өстенә килеп җиткән иделәр. Каршыда бик зур гөмбәз күренде. Аның зурлыгын вә матурлыгын сөйләп кенә аңлатып бетерерлек түгел иде. Әгәр дә бу гөмбәз янына Җир шарын куйсаң, тау башына кунган кош кадәр генә калыр иде.

Бу гөмбәзнең зөбәрҗәттән бер ишеге булып, алтыннан ясалган ачкычы күренде. Мөхәммәтне монда китергән фәрештә:

— «Бисмиллаһ ир-рахманир-рахим!» дип әйт,— диде.

— Бисмиллаһ ир-рахманир-рахим! — диде Мөхәммәт галәйһис-сәлам һәм кинәт ачкыч үзлегеннән борыла башлады, ишек ачылып китте. Алар шунда үттеләр. Бу гөмбәзнең эче дә тышы кебек үк бик тә гүзәл вә искиткеч иде. Аның бер як диварына: «Бисми» дип, икенче якка: «Аллаһ» — дип, өченче ягына: «Рахман» — дип, дүртенчесенә исә: «Рахим» — дип язылган иде. Шул язулар булган урында чишмәләрнең чыга торган җире, ягъни күзләре бар иде. «Бисми», ягъни «исеме» дип язылган дивардан — су, «Аллаһ» дип язылган дивардан — сөт, «Рахман» дип язылган диварыннан — хәмер, «Рахим» дип язылганыннан — бал чишмәләре агып чыга иделәр. Шуннан билгеле булды ки, җәннәт чишмәләре менә шушы дүрт сүздән барлыкка килә һәм шулардан агып чыга икән!

Шулвакыт Хак тәгаләдән вәхи ирешә:

— Йа Мөхәммәт сөеклем, әгәр дә синең өммәтләрең шушы дүрт сүзне бергә кушып әйтәләр вә телләреннән төшермиләр икән, аларга, җәннәткә кереп, шушы чишмәләрдән авыз итәргә насыйп булыр! — диде.

Бу гаҗәепләргә шаһит булганнан соң, Мөхәммәт пәйгамбәрне теге фәрештә кабат Җәбраил галәйһис-сәлам янына китерде. Җәннәт эченә сәяхәт дәвам итте.

Оҗмахның уртасында тагын да бер сарай бар иде. Әйтерләр ки, ул кызыл якуттан эшләнгән. Капкасын ачып, Мөхәммәт пәйгамбәр белән Җәбраил галәйһис-сәлам эчкә үттеләр. Анда тагын да бер йорт булып, ул ак энҗедән ясалган иде.

Шунда керделәр. Бу йортның уртасында нурдан эшләнелгән бер сандык күренде. Хәтта йозагы да нурлар чагылышы белән балкып тора иде.

— Бу нинди сандык? — дип сорады Мөхәммәт.

— Бу сандык — Хак тәгаләнең сере, үзенең сөекле бәндәсенә күрсәтер өчен әзерләп куйды,— дип җавап бирде Җәбраил.

Шушы сүзләрне ишеткәч, Мөхәммәт галәйһис-сәлам турыдан-туры Хак тәгаләнең үзенә мөрәҗәгать итеп сорады:

— Бу сандыкның эчендә ни бар икән? Күрергә мөмкинме?

Ходай тәгалә аның үтенечен кабул итте. Сандык ачылды. Аның эчендә бер иске палас төрле зиннәтле асылташлар белән төрелеп куелган иде.

— Бу нәрсә? — дип гаҗәпләнде Мөхәммәт.

— Бу — фәкыйрь мәраккагы, ягъни фәкыйрь дәрвишләрнең киеме,— дип җавап бирде Хак тәгалә.

— Бу дәүләтне миңа бир?! — дип үтенде Мөхәммәт.

— Йа Мөхәммәт,— диде Илаһи,— бу фәкыйрь мәраккагын сиңа вә өммәтләреңә ихтыяр иттем. Ул көн моны бар кылдым. Дусларымнан башкаларга бирмәмен. Моннан да газизрәк нәрсә яратканым вә бар кылганым булмады,— дип сүзен бетерде.

Шул билгеле булды ки, үзе фәкыйрь, үзе диндар дәрвиш кемсәләрдән дә изгерәк бәндәләр җир йөзендә юктыр. Аларны үпкәләтү, аларны кимсетү вә рәнҗетү — Хак тәгаләнең үзенә шул яманлыкларны багышлау белән бердер. Әгәр кем дә булса берәр дәрвишне куып җибәрә вә аңа яман сүз әйтә икән, ул кеше имансыз калыр, көне тараер, бәхете бетәр!

Җәннәт эчендә тагын да җиде бакчасарай күренде. Һәрберсе ак энҗедән вә кызыл якуттан коеп куелган иделәр. Хәбәрләрдән шулай килә ки, аларның зурлыклары мәгърибтән мәшрикъкача җитә иде.

— Барабызмы? — диде фәрештә һәм, кулыннан тотып, җиде адым ясады.

— Сөенечемне белдеримме? — дип сорады шунда Мөхәммәт.

— Моннан да сөенечлерәк бөек куанычлар бар,— диде Җәбраил.— Әгәр дә иртә таңда мөэминнәр яткан җирләреннән калкып, җиде тапкыр «Лә иләһи илләллаһи!», ягъни «Алладан башка илаһи зат юк!» дип әйтсәләр, аннан соң тәһарәт алып, намаз укысалар, Аллаһы тәгалә ул кешеләргә җәннәттә бөтен бер җиде дөнья кадәрле мәшрикътан алып мәгърипкә кадәрле барча урыннарны бирер! — дип аңлатты һәм чын куаныч-шатлыкның мәгънәсен төшендерде.

Мөхәммәт пәйгамбәр белән Җәбраил галәйһис-сәлам Ризван — җәннәт сакчысы янына әйләнеп килделәр. Нурлар балкып торган бер тәхет өстендә утыра иде ул. Янында сансыз күп мәләк-фәрештәләр баш иеп торалар. Мөхәммәт пәйгамбәрне күрүгә, аңа хөрмәтләрен белдерделәр. Ризван исә пәйгамбәргә өммәтләре хакында хәбәрләрне бирде һәм:

— Җәннәт үзе өч өлештән торыр,— диеп аңлатты.— Аның ике өлеше синең өммәтләреңә, калган берсе башкалар өчен әзерләнеп куелган. Әгәр дә хак исламнан берәр кеше «Лә иләһи илләллаһи!» дип әйтсә, Хак тәгалә аңа бер бакчасарай әзерләп куя, ачкычын миңа сакларга бирә,— диде.

— Кыямәт көне җитеп, адәм балалары вә синең өммәтләрең каберләреннән кубарылып чыгарлар, шулвакыт мин аларга үзләренең бакчасарайлары ишегеннән ачкычны кулларына тоттырырмын. Шуның белән урыннарына килеп керерләр,— дип сүзен тәмамлады Ризван.

Шул чакта Мөхәммәт пәйгамбәр Идрис галәйһис-сәламне күреп алды, аның белән күрешә һәм:

— Дан булсын, син җан алыну ачысын татыдың вә җәннәткә ирештең,— диде.

— Мин синең дәвердә яшәп, барча өммәтләреңнең җаны алыну ачысын бер үзем күтәрсәм дә, авырга санамас вә синең йөз нурыннан балкыган халкың кебек бәхетле булыр идем,— дип белдерде Идрис пәйгамбәр.

Аның шушы сүзләре Мөхәммәт галәйһис-сәламне аптырашта калдырды һәм ул:

— И карендәшем Идрис, моңа сәбәп нәрсә соң?— дип сорады.

— И Мөхәммәт,— диде Идрис галәйһис-сәлам,— синең өммәтләреңнән дә бәхетлерәк бәндәләр дөнья йөзендә булмас. Мин бу җәннәт эчендә гизгәндә нинди генә бакчасарай яки йорт янына килсәм дә, нинди генә фәрештәләргә вә мәләкләргә очрасам да, алар миңа: «Бу Мөхәммәт өммәте өчен хәзерләнеп куелган!»— дип җавап бирәләр. Мин бер тау күрдем,— диде ул алга таба.— Ул тауны — «Җәбүр-Рәхимәт», ягъни «Рәхимлек тавы» дип атап йөртәләр. Башы күкләргә ашып торыр. Ул тау үзе мөшкәт вә гамбәрдән булып, анда уникe капка тәртипләре белән куелып, барчасы ак көмештән эшләнелгән иде. Бу капканың берсеннән икенчесенә ат белән чаптырып, йөз елда ирешеп булу мөмкин түгел. Аны «Пәйгамбәрнең мәкаме» дип әйтәләр,— диде Идрис галәйһис-сәлам.

— Юк, алай түгел, ялгышма,— дип әмер килде Хак-тәгаләдән.— Алар — Мөхәммәт пәйгамбәр белән бергә намаз укыган яки җәмагать белән бергә җыелышып намазны ике рәкәгать кылган Мөхәммәт өммәтләренең керәге өчен,— дип аңлатып бирде.

— И Хак тәгалә,— диде Мөхәммәт пәйгамбәр.— Мин җәннәтнең барча сарайларын вә бакчаларын, чәчәкләрен, чишмәләрен вә гаҗәеп кылынган урыннарын, Ризванын — барчасын-барчасын күрдем, хакыйкать икәнлегенә ышандым. Хурларыннан күңелем ямьләнде, мондый да рәхәт йорт башка бер җирдә дә булмас, аңладым. Инде дә миңа дошманнарымның торыр җире булган урыннарны күрсәтсәң иде?!— дип үтенде.— Аларның хәлләрен вә урыннарын ачык күреп, өммәтләремә хәбәр бирер идем!

— Инде җәннәтне күреп риза булдыңмы?— диде Ходай тәгалә.

— Риза вә канәгать булдым!— диде Мөхәммәт.

— Ярар,— диде Хак тәгалә һәм Җәбраилгә әмер бирде.— Инде сөеклемә дошманнары торыр урын булган җәһәннәмне күрсәт.

Бу сүзләрен ишетүгә, Җәбраил галәйһис-сәлам Мөхәммәт пәйгамбәрне кулыннан тотты вә тәмугка алып китте. Бу — Аллаһы тәгаләнең утлы хәбесханәсе иде!

Мөхәммәт пәйгамбәр белән Җәбраил галәйһис-сәлам бер фәрештәгә тап булдылар. Аның янына килеп, Җәбраил:

— Мөхәммәт пәйгамбәр җәһәннәмне күрергә килде, тәмугны күрсәтерсеңме?— диде аңарга.

— Йа Мөхәммәт,— диде ул фәрештә.— Аяк астыңа кара, күкләрнең төпләкләре ачылып китәр!

Мөхәммәт пәйгамбәр аяк астына бакты. Күкләрдән иңделәр. Бәйтел-Мөкаддәс күренеп калды. Шунда бер фәрештәгә игътибар итте. Ул шулкадәр зур ки, аның башы әллә кайларга ашып тора, озынлыгы җир белән күк арасын каплый иде. Борын тишекләреннән чәчрәп утлар чыга, очкынлы күзләре утлы тәгәрмәчтәй уйный иде. Мөхәммәт пәйгамбәр белән Җәбраил галәйһис-сәламне каршы алган мәләк бу фәрештәгә:

— Йа Суһаил, синең алдыңа Мөхәммәт галәйһис-сәлам килде. Җәһәннәмнең төплек-тишекләрен ачып, аңарга тәмугны күрсәт!— диде.

— Аяк астына карасын,— диде әлеге фәрештә җавабында.

Беренче кат җирнең төплеге ачылды. Андагы халыклар күренде. Ул да булмады, икенче кат җирнең төплеге ачылды. Андагы тау тезмәләре вә тигезлекләре күренде.

Өченче кат җир төнлеге ачылды. Анда җәһәннәмгә төшәчәк кемсәләргә кидертү өчен әзерләнеп куелган кайнар сумалалы киемнәр күренде. Ул да булмады, дүртенче кат җирнең төнлек-тишеге ачылып китте, анда тау-ташлар күренде. Тагын да бишенче кат җир тишеге ачылды, анда җәһәннәмнең елан вә чаяннары күренде.

Алтынчы кат җәһәннәм тишеге ачылды. Бу катның исеме — «Сәҗин», ягъни «Зиндан» иде. Монда җәһәннәм әһелләренең гамәл дәфтәрләре саклана икән.

Ул да булмады, җиденче кат җирнең төнлек-тишеге ачылып, анда утлар атып торган диңгезләр күренде. Бу катны «Гаҗәп», ягъни «Гаҗәеп» дип атый иделәр.

— Йа Мөхәммәт, җәһәннәмне кереп күрергә тәкатең калдымы? — дип сорады, аларны китергән фәрештә.

— Мөмкин саналган кадәрле булса да ач, — диде Мөхәммәт.

Шуннан соң шушы мәләк җәһәннәм ишеген колагына кадәр генә ачты. Аннан ут вә караңгылык бөркелеп чыкты. Тагын да җиде капка күренеп, аларның барчасына да нинди бәндәләр керәчәге язылып куелган иде. Һәрберсенең алдында бер фәрештә хөкем тартып тора. Беренчесендәгенең исеме — Суһаил булса, икенчесендә торганның аты — Таркаил, өченчесендә — Тарфаил, дүртенчесендә — Тамтаил, бишенчесендә — Сатаил, алтынчысында — Катаил, җиденчесендә — Хатраил дип аталган фәрештәләр иде. Бер капкадан икенчесенә биш йөз еллык юл булып, бу олуг мәләкләр янында җитмешәр мең ярдәмчеләре хәзер тора иделәр.

Газаплардан хәбәрләр табу өчен Мөхәммәт пәйгамбәр барысын да үзе күрергә уйлады. Беренче ишек артында җитмеш мең тау булып, һәр тауда җитмеш мең үзәнлек, аларның һәрберсендә җитмеш мең тармак, үзләрендә җитмеш мең шәһәр, һәр шәһәрдә җитмеш мең газап урыны, аларда исә уттан яратылган җитмеш мең бүлмә, һәр бүлмәдә бер сандык вә ул сандыкның эчендә җитмеш мең газап салынып куелган вә кузгалыр сәгатьләрен көтеп тормакта иделәр. Ул әйберләр барчасы да: шәһәре, тавы, бүлмәсе, сандыгы һ. б., һ. б. лар уттан ясалган вә кайнарлыклары белән бар тарафларны көйдереп, яндырып тора иделәр. Боларны карап бетерүгә, түбәнгә таба җирнең икенче каты ачылып китте, монда да ике сыйныф газап күренде. Мәләкләр вә хезмәтчеләр монда да күп булып чыкты. Өченче кат түбәнгә таба җир ачылып китте, өч катлы газаплар күренделәр. Гаҗәп, бик тә гаҗәп иде.

Дүртенче капканы ачтылар. Монда елгалар күренде. Тирәнлекләре җитмеш еллык юл бәрабәренә тора иде. Хәбәрләрдән шул билгеле, ул елгаларның сулары кайнарланып кайнап тора вә шунда гөнаһ ияләре бәндәләр коендырылып, газап кичерәчәкләр икән.

Бишенче ишек ачылды. Анда таулар арасыннан утлы үзәнлек күренде. Эчендә зәһәр еланнар вә чаяннар мыжгылдап тора иделәр.

— Бу нинди урын? — дип сорады Мөхәммәт пәйгамбәр Җәбраилдән.

— Моны «Вәйл» дип атыйлар, мондагы газап чокырының төбе дә, чиге дә юк, — дип аңлатты ул. — Бу елан-чаяннар зур газаплар кылу өчен әзер торырлар.

Алтынчы капка ачылды. Анда да утлы бер үзәнлек күренде. Пәрдә белән бүленеп алынган иде ул.

— Бу үзәнлек Кыяматкә кадәр шушы хәлендә торыр. Кыямәт көнне кяферләр вә бозыклыкка кергән бәндәләр белән тулар. Аны «Сәҗин», «Ябып тоту урыны» дип атыйлар, — диде Җәбраил галәйһис-сәлам.

Алтынчы ишекне үтеп, җиденче капкага килделәр. Мәләкләр аны ачып җибәрде. Мәрхәмәтсез вә дәһшәтле, тупас вә җәбер итүче фәрештәләр күренде. Аларның исәп-саннары Аллаһы тәгаләдән башка һичкемгә билгеле түгел иде. Монда да шулай ук уттан ясалган табутлар күп иде. Газап фәрештәләренең кулларында кыскыч вә кайчылар булып, барчасы тимердән иделәр. Шул кыскыч-кайчылар белән адәмиләрне бер коедан

эләктереп алырлар вә икенчесенә атып торырлар. Чиксез зур вә әшәке газапларны биреп, бу гөнаһ ияләрен җан ачысы белән чиналалар вә акырталар. Әмма газап мәләкләре аларның бу хәлләренә игътибар итмичә үз эшләрен башкара торалар.

— Болардан да көчлерәк газап кылучылар җәһәннәмдә булырмы? — дип сорады Мөхәммәт пәйгамбәр.

— Болар кылган бу газаплар башкалары белән чагыштырганда җиңелрәк әле,— диде Җәбраил.

Мөхәммәт пәйгамбәр табутларга игътибар итте. Алар кайнар утлар чәчеп торалар вә үзләре утлы йозак белән бикләнеп куелганнар иде.

— Ә болары нәрсәгә? — дип сорады ул.

— Бу табутлар тәкәббер вә борын чөеп йөрүчеләр өчен әзерләнеп куелган. Аларны менә шушы табутларга салып бикләрләр вә утка атарлар. Бу табутларның эчендә шулай ук чиксез чаяннар вә еланнар мыжгып торыр. Алар күрсәткән газапның ачысын тел белән сөйләп, сүз белән аңлатып бетерергә мөмкин түгел,— дип белдерде Җәбраил галәйһиссәлам.

Үзәнлекләр күренде. Аларда ут булып янып торган агачлар бар иде. Аларның хәтта җимешләре дә ут йомгагы иде. Шулай ук бер тегермән күренде. Аның газап өчен әзерләнеп куелганлыгы вә җәһәннәм әһелләренең аңа таба дөяләр кебек килә торулары беленде.

Үзәнлектә шулай ук сыер кадәр кортлар бар, үзләре каралар вә адәмиләрне җәбер кыла иделәр.

— Бу агачлар — «Зәккум агачы» дип аталыр, ягъни «Җәһәннәм агачы» шушы була инде. Бу кортлар янында шулай ук гөнаһ ияләре газап чигәрләр. Чөнки бу кортлар җәһәннәмнең этләре булырлар. Алар китергән газапларны Кыяматкә кадәр сөйләп торсаң да бетмәс...— дип аңлатты тагын да Җәбраил.

Хикәяләр вә риваятьләр аша шул билгеле, җәһәннәмнең җиде каты бар иде. Җиденче каты иң түбәндә булып, аның исемен «Һавия» дип атыйлар. Монда күрсәтелгән газаплар барча катлардан да мәрхәмәтсезрәк вә авыррак иде.

— Һавиягә нинди кешеләр керерләр? — дип сорады Мөхәммәт пәйгамбәр.

— Фиргавен, Карун, Һамман, синең өммәтеңнең вә Гайсә галәйһиссәламнең мәрхәмәтсез дошманнары — барчасы шушында куылырлар,— дип аңлатып бирде аларны озатып йөрүче мәләк.

Алтынчы каты — «Җәхыйм», «Җәһәннәм уты» дип аңлатыла. Бу кат Мөхәммәт пәйгамбәргә каршы булган мөшрикләр өчен бар кылынган булыр, алар газапны шушында татырлар.

Бишенче каты — «Сәкарь», анда ислам диненнән башка бер дингә күчкән, диненнән язган кешеләр газап чигәрләр.

Дүртенче каты — «Ләзан», ягъни «Ялкын», анда Иблис вә аңа иярүчеләр тоткын итеп ябылырлар.

Өченче каты — «Хитмә», ягъни «Ватык кисәкләр», монда яһүдиләр газап кичерерләр вә җәберләрен күрерләр.

Икенче каты — «Сәгыйрь», ягъни «Ут, учак». Монда насари-христианнар өчен бар газаплар әзерләнеп куелган булыр.

Беренче каты — «Җәһәннәм». Монда житмеш мең утлы дәрья кайнап торыр, алар шулкадәр зурлар ки, әгәр дә әйләнеп чыгарга уйласаң, мең ел эчендә дә мөмкин эш түгелдер.

— Бу ут диңгезләре, җәһәннәм дәрьялары кемнәр өчен? — дип сорады Мөхәммәт пәйгамбәр үзләрен озатып йөрүче фәрештәдән. Әмма ул мәләк җавап бирмәде, башын читкә каратып тотты. Мөхәммәт пәйгамбәр тагын сорады. Җавап булмады. Мәләк бөтенләй ишетмәмешкә салышты. Мөхәммәт пәйгамбәр кабатлап сорады. Шунда Җәбраил галәйһис-сәлам түзмәде:

— И, җавап бир, Мөхәммәт пәйгамбәр синнән сорады, ә син нигә ишетмәмешкә салышасың? — диде.
Шуннан соң гына ул мәләк телгә килде һәм:
— И Мөхәммәт, Хак тәгаләнең сөеклесе вә җир-күкләрнең горурлыгы, бу дәрьялар синең өммәтләреңнән булган гөнаһ ияләренә әзерләнеп куелдылар. Аларга нәсыйхәт әйтеп, хәбәрләр бир. Үзләренең җаннарын вә тәннәрен гөнаһ шакшылыгына буямасыннар. Кыямәт көнендә мин монда булырмын. Ни ак сакаллы карт булсын, ни чибәр кыз, ни сабый булсын, әгәр гөнаһ эшләре белән гомерен уздырганнар икән, аларны шушында утлы дәрьяга ташлармын. Җәһәннәмнең зәһәр диңгезләре ул бозык мөэминнәр өчен бар кылынды, — дип белдерде ул.
Аның бу сүзләрен ишетүгә, Мөхәммәт саллаллаһ галәйһис-сәлләм күзләреннән чыккан энҗе яшьләрнең агышын тыя алмады. Аһ орып, үзенең өммәтләре өчен рәхим-шәфкать үтенде, мөселманнарның шулкадәр зәгыйфь вә мондый газапларга түзә алмаячакларын бәян итеп, аларга авыр газапларны багышламауны үтенде. Мөхәммәт пәйгамбәргә кушылып, Җәбраил да елап җибәрде, аның да күзләреннән кайнар яшь диңгезләре бүселеп чыкты. Әмма боларга карап ул мәләк мөселманнарны Аллаһы тәгалә әмереннән башка җәһәннәмнән азат итә алмый иде шул. Аның да күзләреннән яшьләр ургылып чыкты. Шулвакыт Аллаһы тәгаләдән вәхи килеп, Мөхәммәтне морадына җиткерәсен вә шулкадәр гөнаһ иясе өммәтләренә хөкемне пәйгамбәрнең үзенә тапшырачагын әйтте.
Моннан шул беленде ки, Кыямәт көнендә мөселманнар үзләренең бөек пәйгамбәре булган Мөхәммәт саллаллаһ галәйһи вә сәлләмнең рәхим-шәфкатенә өмет белән яшәсеннәр һәм дә шуны теләсеннәр. Зәгыйфь өммәткә тәмуг газапларыннан вә җәһәннәмнең утлы диңгезләреннән исән-имин котылып, җәннәткә ирешерлек булсын! Әмма олуг гөнаһ ияләре вә диннән язган кемсәләргә җәһәннәмнән азат ителү һәм газаптан котылу мөмкин булырмы? Билгесез.
Мөхәммәт галәйһис-сәлам, җәннәткә вә тәмугка сәяхәт кылганнан соң, Аллаһы тәгаләгә мөрәҗәгать итеп:
— Йа Хак тәгалә, мин синең җәннәтеңнең күркәмлекләрен вә рәхәтлекләрен күрдем, җәһәннәм утының ни газаплар китерәсенә шаһит булдым. Һаман да өммәтләрем алдында нәсыйхәтләр кылырмын. Аларны синең хак юлыңнан тайпылмаска өйрәтермен. Без кылган догаларны, өммәтләремнең намазларын кабул итеп, булган гөнаһларын гафу әйләсә идең, — диде. — Әгәр дә җәннәт яман урын булса, Адәм галәйһис-сәлам, җиргә иңдерелгәч, зур газаплар күрмәгән булыр иде. Җәбер-җәфаларыбыз барчасы да дөньялыкта калып, фәкыйрь вә мескен өммәтем җәннәтле булгач, үзенең нинди бәхетле вә хөрмәт иясе икәнлеген бар тулылыгы белән күрер. Син, и Хак тәгаләм, минем өммәтләрем өчен җәһәннәм утын гөлбакча кылармын, дип белдердең. Ибраһим өчен ягылган утның ничек гөлбакчага әверелүен дин халкын күз алдына китерсә, бу җәһәннәм утының да шул рәвешле чәчәк бакчасы булуын хәтеренә китерә алыр. Хөсетлек вә көнчелек галәмәтләре бугазларына таш булып утырган кемсәләр барчасы да җәбер-золымнары өчен үзләренә лаек урынны табарлар. Минем зәгыйфь өммәтем өчен күңелемдә барыбер кайгы-хәсрәт калыр. Шуның өчен аларга хакыйкать юлын өйрәтермен! — дип белдерде.
Хак тәгалә үзенең сөекле пәйгамбәре Мөхәммәт саллаллаһ галәйһис вә сәлләмнең сүзләрен вә үтенечләрен кабул итеп тыңлап торды һәм аңарга үгет-нәсыйхәтләрен җиткерде. Болардан шул аңлашылды ки, Ходай тәгалә үзенең зәгыйфь бәндәләрен бервакытта да ташламас, әмма алар, үз чиратларында, хак юлдан тайпылмый барырга вә көнчелек һәм хөсетлек кебек утларга салып үзләренең күңелләрендәге камил теләкләрен яндырмаска, намаз вә догадан калмаска тиешләр. Моннан тагын да шул мәйданга чыкты: намазны дөрес үтәү тиеш икән!

Мөхәммәт галәйһис-сәлам, Җәбраил фәрештәгә мөрәҗәгать итеп, Хак тәгаләдән намаз дөреслеге, хакыйкатьләре вә таләпләре хакында гыйлем табарга теләге барлыгын шушы урында белдерде. Фәрештә аның таләбен кабул итте һәм аны яңадан Хак тәгалә хозурына куйды.

— Йа Мөхәммәт, җәннәтнең күркәмлеген, җәһәннәмнең авырлыгын ничек дип күрдең? — дип сорады Ходай тәгалә.

— Җәннәтнең нигъмәтләрен кабул кылдым, җәһәннәмнең зәһәрлегеннән курка калдым, — дип җавап бирде Мөхәммәт.

— Әгәр дә һәркем миңа иман китерсә, биргән нәсыйхәтләремне тотса, өйрәткән юлларымнан чыкмаса, гомер юлын лаеклы узса, ул бәндәләремне җәннәтле итәрмен вә нигъмәтләремне биреп сөендерермен, җәһәннәм утыннан саклармын, — дип, Хак тәгалә Мөхәммәт рәсүленә тагын да берничә нәсыйхәтен җиткерде.

Беренчесе:

— Кайчан булса да сиңа сагыш вә газап авырлыгы төшә икән, минем исемемне исеңә ал. Шул вакытта ихласлы вә тугры бәндәмне ярдәмемнән ташламам!

Икенчесе:

Аллаһы тәгалә әйтте: «Әгәр дә берәр мәзлумә кемсә дога кылса вә миңа үтенечен җиткерсә, аны кире какмамын, гәрчә ул кяфер булса да!»

Өченчесе:

— Йа Мөхәммәт, усаллар вә җәбер кылучылар алдында сабыр ит, аларның кызганына карап үзеңне утка салма. Дөньяда башкалар алдында мәгърур вә тәкәббер булма. Вакытыңны буш эшләргә багышлап уздырма. Бу дөнья вакытлы йортыңдыр, бакый гомерләр алда әле! — диде Хак тәгалә. — Дөнья эшләре бер ялган гына, аларга алданып, үзеңне харап итмә!

— Йа Илаһым, — диде Мөхәммәт. — Минем бар таянычым син, башка һичбер затка вә кемгә таяна алмыймын һәм синең ярдәмеңә генә һәрвакыт мохтаҗлыкта яшим. Бары сиңа гына табынам һәм синнән генә куркам, бар өметләрем синдә генә. Син миңа гыйлемеңне вә пәйгамбәрлекне тапшырдың. Дөньялыкның да ризыгы бары тик синнән генә. Бар ышанычым вә миһербаным да син генә!

— И Мөхәммәт, намазыңны вакытында үтә, диннең нигезе шунда булыр! — диде Хак тәгалә.

— Йа Илаһым, мин бу кичәдә бик күп гаҗәеп хәлләрне күрдем. Әмма боларны өммәтләремә сөйләсәм, ышанмаслар. Кем минем сүземнең хакыйкать булуын дәлилләр? — дип сорады Мөхәммәт пәйгамбәр.

— Якын дустың Әбу-Бәкер! — диде Хак тәгалә. — Әбу-Бәкер сиңа ышаныр вә башкалар алдында яклап чыгар!

Шушы сөйләшүдә Хак тәгалә намаз тәртипләрен бәян итеп, аның рәкәгатьләренең кайсы вакытта ничек тиешлеген белдерде. Әйтерләр ки, бишвакыт намазның һәрберсе үзгә бер дәрәҗәдә булып, саваплары да төрлечә күрелде. Шулай ук бу сөйләшүдә бишвакыт намаздан тыш очрый торган догаларның сөннәтләре дә бәян ителде вә пәйгамбәребез аларны кабул итеп алды.

Болардан шул беленде ки, Хак тәгалә үзенең хакыйкый юлында йөргән бәндәләренә һәрвакыт ярдәмен юллар вә аларны газап вә җәбер эчендә ялгызларын гына ташлап калдырмас. Адәм балаларының кылган намазлары үзләре өчен кирәк булып, диннәрен сакларга ярдәм итәр вә аларның күңелләрен нурландырыр.

И зәгыйфь адәм баласы, син бар эшләреңне вә гамәлләреңне үзең өчен генә түгел, башкалар алдында һәм Аллаһы тәгалә каршында башкарасың. Үзең яманда икән, кылган эшең вә гамәлләрең дә ямандыр. Хыялларың иркен вә якты икән, кылган эшләрең вә гамәлләрең дә дөрес булыр. Җәмәгать файдасына дип башкарылган гамәлдән дә саваплырак эш Хак тәгалә алдында юктыр. Чөнки башка гамәлләрне, ягъни Хак

тәгалә өчен багышлап кылынган эшләрне җәмәгатьтән читтә генә, яшереп кенә башкару мөмкин түгел.

Мөхәммәт пәйгамбәр шушы сөйләшүеннән соң Хак тәгалә алдында түбәнчелек белән сәҗдә итте вә Җәбраилнең канатына менеп, күкләр катын куйды вә алар буракны калдырган сахрага килделәр.

— Йа Мөхәммәт, Аллаһы тәгаләбезнең сөеклесе, тәмам тәкатем калмыйча сине көтеп тордым, хәзер инде дөньяның гаҗәеп җирләренә сәяхәтләр кылыйк, дөньялыкны күрик? — дип каршылады аны галәм аты бурак.

## Дөньялыкның гаҗәеп җирләренә сәяхәт

Бурак аларны түземсезлек белән көтеп алды. Мигъраҗчыларга сәяхәтне дәвам итәргә чакыру сүзләрен житкергәч, Мөхәммәт галәйһис-сәлам аңа менеп утырды вә Җәбраил фәрештә белән Җергә Җәбаликә вә Җәбалисә, Йәэҗүҗ вә Мәэҗүҗ һәм башкаларның яшәгән шәһәрләренә, җирләренә таба китеп барды...

Бу урында сөйләнеләчәк вакыйгаларны берәүләр, Җир йөзендә булды, икенчеләр, галәмдә иде, дип баралар. Үзләрен гыйлемгә санаган кемсәләр исә аларны әкияткә чыгаралар. Әмма минем бурыч боларның сүзләренә бәя бирү түгел. Язучы буларак, мин ул вакыйгаларны бәйнәбәйнә сөйләп кенә үтәргә тиешле. Билгеле булсын, шушы сәяхәт вакытында Мөхәммәт пәйгамбәр Йәэҗүҗ-Мәэҗүҗ халыкларына килеп иреште, әмма алар иман китермәделәр вә җәһәннәм әһелләре булдылар. Моннан соң пәйгамбәр ике шәһәргә китерелде. Ул боларның кешеләрен дә дингә өндәргә тиешле иде. Әлеге шәһәрләрнең берсе — мәшрикъта, икенчесе — мәгъриптә, һәрберсенең ике мең капкасы бар иде.

Минем фикеремчә, пәйгамбәрнең ошбу сәяхәте тарихка сәяхәт булды. Үзеннән алда яшәп үткән халыкларны җәһәннәмнән коткарып калу өчен алар янына килергә тиеш иде ул.

Мәшрикъта булган шәһәрнең халкы — Гад кавеме, алар барчасы мөэминнәр рәтеннән иделәр, чөнки үз заманнарында Салих пәйгамбәргә иман китерделәр. Сөрьяни телендә ул шәһәрне Буркыйна дип атый иделәр. Гыйбрани телендә, ягъни иске яһүдиләрчә Җабалика дип йөртеләр.

Икенче шәһәр мәгъриптә булып, аның исеме гыйбрани теленчә Җәбалиса, сөрьянича — Буркыйса дип атала иде. Боларга Кыямәт көненә кадәр пәйгамбәр килеп ирешмәс иде. Мөхәммәт пәйгамбәрне күреп, бу шәһәр халкы капкалардан агылып чыкты. Пәйгамбәр аларны иманга чакырды. Болар үзләренең кыяфәтләре вә киемнәре белән мөэминнәргә тартым булганлыктан, Мөхәммәт аларны бик якын күрде. Алар барчасы да иман китерделәр вә исламга керделәр, мөселманлыкны алдылар.

Моннан соң Мөхәммәтне бурак һәм Җәбраил галәйһис-сәлам Тавил, Марс, Мәнсик халыкларына китерделәр. Пәйгамбәр аларны да иманга өндәде. Әмма бу кяфер халыклар караңгылык базына баткан килеш торуны өстен күрделәр һәм имансыз калдылар. Шулай итеп, үз теләкләре белән җәннәттән баш чөереп, тәмуг утында януны сайлап алдылар.

Алардан аерылгач, Мөхәммәт пәйгамбәр Муса галәйһис-сәлам вакытындагы бәни-исраил халкына китерелде. Үзара сәламнәр бирештеләр. Шуннан соң Җәбраил фәрештә:

— Сезнең алдыгызга килгән кеше — Мөхәммәт пәйгамбәр! — дип белдерде.

Бу кавем үзләренең китапларыннан Ахырзаманда җир йөзенә Мөхәммәт пәйгамбәрнең киләчәге хакында хәбәрдар булганлыктан, Җәбраилнең сүзләрен ишетүгә, урыннарыннан сикерешеп тордылар вә аның алдына җыелыштылар.

— Муса галәйһис-сәлам безгә синең хакта хәбәрләр биргән иде, аның васыяте буенча синең әйткән сүзләреңне өстен күрербез. Әлхәмделиллаһ, бу көннәрне күрү бәхетенә дә ирештек,— дип сөенештеләр.

Ул халыкның базар ишекләре вә мәсчетләре, йортлары ачык иде. Чөнки араларында угрылар булмады. Шулай ук аларда ни бай, ни фәкыйрь дә юк иде. Чөнки бар да бертигез иделәр. Әмма бала туса — елый, кеше үлсә — сөенә иделәр.

— Сез ни өчен болай эшлисез? — дип сорады Мөхәммәт пәйгамбәр.

— Бу дөнья безнең өчен зиндан белән бер, ә мәңгелек йортыбыз — төп торыр җиребез, шуңа күрә арабызда бер бала туса, аның өчен кайгырып җылыйбыз, әгәр дә берәребез үлсә, аның мәңгелек йортка китү бәхетенә ирешүе өчен сөенәбез! — дип җавап бирделәр алар һәм:

— И Мөхәммәт, пәйгамбәребез Муса галәйһис-сәлам безгә синең динеңне вә шәригатеңне алуны васыять итеп калдырган иде. Безне мәхрүм итмә! — дип үтенделәр.

Моннан соң пәйгамбәр аларга шәригатьтән вә исламнан хәбәрләр бирде. Барчасы сөенешеп иман китерделәр. Бу кадәр бәхетле вә бу кадәр куанган халык башка бер җирдә булдымы икән?

Алар яныннан киткәч, Мөхәммәт пәйгамбәргә җеннәр килделәр һәм үзләренең иман китерергә теләкләре бар икәнлекне белдерделәр. Мөхәммәт галәйһис-сәлам аларны кабул итеп алырга ашыкмады.

— И Мөхәммәт,— диде Җәбраил галәйһис-сәлам.— Җен халкына да миһербанлы бул. Алар сиңа вә өммәтләреңә ярдәм итәрләр,— диде.

Бу вакытта Мөхәммәт әле яңа гына калдырып киткән Муса галәйһис-сәламнең халкы турында уйлап бара иде. Алар аннан:

— Безгә Мәккә шәһәренә Кәгъбәтуллага карап намаз укырга, елга бер тапкыр шунда килеп хаҗ кылырга рөхсәт бир, әмма бу хаҗыбызны гади адәм балалары күрмәсен? — дип үтенгән иделәр.

Бәни-исраилнең ошбу теләкләрен пәйгамбәребез кабул итеп дога кылды, алар үзләренең моратларына ирештеләр. Әйтерләр ки, бу халык елга бер тапкыр Мәккәгә килеп хаҗ кыла, әмма өммәт вә дин кардәшләренә күренми иделәр.

Мөхәммәт пәйгамбәр шушы хәлләрне уйлап бара иде. Җәбраил фәрештәнең таләп сүзен ишеткәннән соң гына җеннәргә игътибар итте һәм аларның иманнарын кабул итеп алды. Барчасы, сөенешеп, мөселман булдылар.

— Безгә үз динеңне аңлатсаңчы? — дип үтенде тегеләр.

— Арагыздан берегезне яныма күндерерсез! — дип боерды Мөхәммәт галәйһис-сәлам. Алар риза булдылар. Шуннан соң рәсүлебез Бәйтел-Мөкатдәскә килеп иреште. Аңа кереп, ике рәкәгать намаз укыды вә Хак тәгаләнең нигъмәтләренә шөкер кылды.

Бәйтел-Мөкатдәснең эче пәйгамбәрләрнең сурәтләре белән бизәлгән иде. Җәбраил фәрештә аларны Мөхәммәт галәйһис-сәламгә күрсәтеп йөри башлады.

Пәйгамбәрләрнең сурәтләре арасында Мөхәммәт галәйһис-сәламнең дә рәсеме бар иде. Аның сул ягына Гомәр сәхабә, уң ягына Әбү-Бәкер Әс-Сыйддыйкның сурәтләре ясалган иде.

Сүз уңаенда әйтеп үтик, исламда сурәт мәсьәләсе күтәрелгәч тә, галим-голамә: «Ислам сурәт ясауга каршы!» — дип белдерәләр. Әмма сүзләре зур хаталык, чөнки ислам вә шәригать рәсем ясауга каршы түгел, киресенчә, сурәт ясап, аңа табынуга каршы. Бу мигъраҗ кичәсендә Мөхәммәт пәйгамбәребез үзенең вә яраннарының рәсемнәрен күргән икән, димәк, аларның булуы вә ясалуы Хак тәгалә теләге белән башкарылган. Мөселманнар сурәт ясау вә сурәткә соклану кебек эшләрдән вә күз тәрбиясеннән һич тә шикләнергә вә читләшергә тиеш түгелләр. Моннан шул аңлашылды.

Мөхәммәт пәйгамбәр белән Җәбраил галәйһис-сәлам гыйбадәтханәдән чыктылар. Бурак һаман да бәйләп куелган урынында тора иде.

Җәбраил аңа әмер итүгә, галәм аты Мөхәммәтне үз өстенә атландырды һәм алар яңадан Мәккә шәһәренә таба кузгалдылар.

Мөхәммәт пәйгамбәр кайтып җиткәндә ятак урыны һаман да җылы килеш — суынып бетмәгән хәлендә иде әле. Кайбер хикәяләрдә әйтелә ки, мигъраҗга кузгалганда Җәбраил галәйһис-сәлам саксызлык белән бер комганны ялгыш аударып киткән иде дип, ә кире кайтканда исә ул комганның суы да түгелеп бетмәгән иде әле. Тагын да бериш китапларда артларыннан ишек келәсе селкенеп калган иде диләр. Кире кайтканда ул һаман да тибрәнә, әле туктап җитмәгән иде.

Шунсын әйтеп үтәргә кирәк ки, мигъраҗ вакыты өч сәгать дәвамында булды. Аның шулай бик тиз үтүен күпләр ялгыш вә хыялый хәл дип кенә атадылар. Имеш, Йәмән илендә яшәүче бер яһүди бар иде. Аңа бу хәбәр килеп ирешкәч, ул эчен тотып көлде: «Мөселманнарның пәйгамбәре әкиятләр сөйләргә бик ярата икән»,— диде. Ә көн бик эссе булып, ул кемсә су коенырга уйлады. Бакчасында тирән казаны бар иде. Эче тулы су тотып, вакыт-вакыт анда су керә иде. Бу юлы да хатынына:

— Мин бераз юынып чыгыйм әле! — дип шул казанына чумды. Су галәмәт дәрәҗәдә рәхәтлек белән тәнен юды. Ул ухылдап судап килеп чыкты. Карады: килеп чыккан җире үзенең бакчасы да, сулы казаны да түгел, ә бәлки бер олуг диңгез иде.

Яһүди ярга таба йөзде. Анда бер карт балыкчыны күрде. Чыкты. Сорады:

— Бу нинди җир?

Аңлашуларыннан соң яһүди Йәмән иленә гомере буе барса да кайтып җитмәячәген белде. Чөнки бу илдә Йәмәннең кайсы якта булуын да күз алдына китерүче юк иде. Яһүди кай якка карап та юл тотарга белмәде. Шушы картка хезмәтче булып ялланып, монда торып калды.

Күп сулар акты. Гомерләр узды. Яһүди яңадан бер хатын алып, балалары туып, кайсын өйләндереп, кайсын кияүгә бирде. Сакалы агарды, баш түбәсенең чәче коелып бетте.

Көн саен эссе иде. Аның су коенасы килде. Йортлары диңгездән ерак булмаганга, алар шунда гына юына иделәр. Яһүди суга төште. Чумды. Рәхәт, бик рәхәт иде.

Чумган җиреннән күтәрелеп чыкса, күрде: бар бакчадагы казан эчендә коена икән! Сакалы да кара, чәче дә элеккечә куе иде. Яһүди судан чыкты, киенде. Өенә керде. Хатыны, аны күреп:

— Кая, коенып та чыктыңмыни? — дип аптырап калды.

Яһүдинең һушы китә язды, йөзләре агарды.

— Ни булды, нәрсәдән курыктың? — дип сорады хатыны.

Шуннан соң бу яһүди барысын да сөйләп бирде. Аның сүзләрен тыңлап бетергәч, хатыны:

— Менә, мөселманнарның пәйгамбәре мигъраҗына ышанмаган идең, Хак тәгалә сиңа олуг дәлил китергән, үз башыңнан кичерергә мәҗбүр иттергән,— диде.

Моннан соң яһүди Алладан тәүбә үтенде вә мөселманлыкка күчте, диелә хикәяттә...

Өмме-Һани әле йокыда иде. Мөхәммәт пәйгамбәр аны уятты. Бергә намазга утырды. Иртә намазын кылганнан соң, Мөхәммәт пәйгамбәр:

— И Өмме-Һани, бу кичә шундый да бер кичә булды ки, мин Бәйтел-Мөкатдәскә вә Хак тәгалә янына сәяхәт итеп кайттым,— дип белдерде.

Өмме-Һани, йорт хуҗасы буларак, хәбәргә ышанмады, өендә үзгәрешләрне сизенмәгән иде. Шуңа күрә:

— И Мөхәммәт, син бу сүзләреңне берүк башкаларга сөйли күрмә, ышанмаслар, мөселманнардан көлү өчен файдаланырлар, өммәтебез таркалыр,— диде ул.

— Әмма мин бу хакта сөйләми булдыра алмыйм, бу хәбәрләрне өммәтләремә җиткерергә боерылды,— диде Мөхәммәт.

Шуннан соң алар мәсчедел-Хәрамга килделәр. Шунда нәсыйхәтләр кылып утырганда Мөхәммәт пәйгамбәрнең сул ягыннан Әбу-Җәһил килде һәм:

— Йа Мөхәммәт, сиңа Аллаң бирәр галәмәт вә кирәмәт насыйп итте ме? — дип сорады.

— Әйе,— диде пәйгамбәр.— Мине бу кичә Бәйтел-Мөкатдәскә илттеләр, Хак тәгаләнең күкләрен, җәннәтләрен вә тәмугларын күрдем,— дип белдерде.

Мөхәммәт пәйгамбәр барча хәбәрләрне сөйләп бетергәч, күп кемсәләр аһ итте, беришләре исә кулларын кулларына сугып куйды. Әбу-Җәһил исә аннан көлә башлады. Әбу-Бәкерне эзләп китте. Аны өендә тапты һәм:

— Пәйгамбәрең Мөхәммәт, бу кичәдә Бәйтел-Мөкатдәскә сәяхәт иттем, күкләрне гизеп йөрдем, дип әйтә. Юк-бар сөйли. Инде хәзер дә аңа ышанырсыңмы? — дип сорады.

— Ә ул боларны сөйләдеме соң? — дип, Мөхәммәт пәйгамбәр әйткәннәрне кабатлый башлады Әбу-Бәкер.

— Сөйләде-сөйләде! — дип җөпләде Әбу-Җәһил.

Аның гаҗәпләнүе йөзенә чыккан иде. Хәлбуки, Әбу-Бәкер Мөхәммәт пәйгамбәрнең дөрес сөйләгәнлеген, үзе дә сизмәстән, дәлилләп бирде...

## Мәккәдә соңгы ел

Пәйгамбәрлекнең уникенче елында Ясриптән унике кемсә Мәккә шәһәренә хаҗга килеп, Мөхәммәт галәйһис-сәламгә бәйгыт-килешү китерделәр. Аларның унысы Хазраҗ кабиләсеннән, Әсгать бине Зурарәт барчасына башлык иде. Алар шәригать кануннары белән эш йөртергә вә Мөхәммәт пәйгамбәрне үзләрендә дин таратырга өндәделәр. Иман китереп, барчасы мөселман булдылар.

Мөхәммәт пәйгамбәр алар белән бергә Мисгаб бине Гамирне җибәрде. Ул Ясриптә «Коръән» кануннарын өйрәтергә вә дин таратырга тиеш булды. Китаплардан күренгәнчә, Мисгаб сәхабә үзе яшь кеше иде. Иман китергәннән соң, дин исламга кермәгән әти-әнисеннән бик күп җәбер-золымнар күреп яшәде. Аны һаман да иман китергәне өчен тирги вә җәберли иделәр. Мисгаб сәхабә Әсгать бине Зурарәтнең үзе белән килгән кешеләр ягыннан Мөхәммәткә бәйгыт китергән килешү вакытында катнашты һәм Ясрип (ягъни Мәдинә) шәһәренә вәкил булып килергә ризалыгын белдерде. Алар белән китеп, Әсгать бине Зурарәтнең йортына төште, анда яшәде һәм әнсариларның, ягъни Мәдинә гарәпләренең олугларына килеп, аларга дин тәгълиматыннан хәбәрләр биреп, исламга өнди башлады. Арадан иң башлап Бәни-Габделашһал вә Бәни-Зафир кабиләләре иман китерделәр, аларга бүтәннәр дә кушыла башлады. Мәдинәдә исламга карата артык зур каршылык очрамады.

Хәбәрләрдән шулар билгеле, пәйгамбәрлекнең унөченче елында Мәккәгә хаҗ кылып әнсарилардан тагын да кешеләр килделәр һәм пәйгамбәргә иман китереп, бәйгыт бирделәр. Әмма аларның Мөхәммәт белән аралашуларын һәм рәсүлне үзләренә алып китәргә җыенуларын Мәккә кяферләре белеп алдылар һәм әнсариларны кире кайтармаска тырышып карадылар. Бары тик Мәдинә халкы гына, кяферләр алдында ачылып китеп, серләрен чишмәделәр.

Кяферләрнең мөселманнарга кылган авырлыклары тагын да арта барганлыктан, Әбу-Сәлим Мәккәдән Мәдинәгә һиҗрәт кылырга уйлады. Уңай вакыт сайлап алып, дөя өстенә кызын вә хатынын утыртты да юлга чыкты. Шәһәрдән Мәдинә тарафына китүче юлга төшүләре булды, каршыларына кяферләр килеп чыкты.

— Син кая барырга җыендың болай? — дип Әбу-Сәлимнең кулыннан дөя нуктасын тартып алдылар.— Син үзең нәрсә эшләсәң дә эшләрсең, әмма без кабиләбезнең олугы булган хатыныңны шәһәребездән җибәрмибез,— диделәр дә, кызы белән хатынын Мәккәгә алып кайтып киттеләр. Качмасыннар өчен кызын — бер йортка, әнисен икенче йортка куйдылар. Әбу-Сәлим ялгызы гына Мәдинәгә килеп җитте. Мисхаб сәхабәгә кунарга төште. Әмма хатынын бик нык сагынганга күрә көн-төн кайгыда вә сагышта йөрде. Күзләреннән тамган кайнар яшьләре Мәккә тарафына киткән юл тузанын сугарды.

Хатыны да бик пакизә кемсәнә иде. Әбу-Сәлимне исенә төшереп, ул да кайгыга калды. Беркөнне Мөгайрә кабиләсеннән булган кемсәнәләр аны сахрада кайнар күз яшьләрен агызып утырган вакытында очраттылар. Күңелләре кузгалды, аның хәсрәтеннән күңелләрен борчу басты. Мәккәгә кайтып, Мөгайрә янына килделәр һәм Әбу-Сәлимнең кызы белән хатынын азат итүне үтенделәр.

Кызы белән әнкәсе очрашкан көнне үк яңадан юлга чыктылар вә, дөягә утырып, Мәдинәгә таба киттеләр. Сахрага гына җитүләре булды, аларга Талха бине Габделгази каршы төште.

— Сез кая барасыз болай? — дип сорады.

— Иремне эзләп, Мәдинә шәһәренә барам,— дип белдерде хатын.

Бу вакытта Талха бине Габделгази иман китергән иде инде. Ул аптырап калды:

— Ничек икегез генә юлга чыгарга булдыгыз. Берәр сакчы да алмагансыз. Курыкмыйсызмы? — диде һәм, миһербаны килеп, аларны үзе озатып куйды.

Шушы вакыйгадан соң Мәккәнең мөселманнары азлап-азлап та, төркем-төркем булып та Мәдинә шәһәренә күчәнә башладылар. Моны белеп алган кяферләр, җыелышып, киңәш-табыш кылдылар һәм Әбу-Җәһил:

— Болай булмый, без Мөхәммәтне кылычтан үткәрик! — диде. Мәккә кяферләре сүзнең ахырында аның тәкъдимен кабул иттеләр һәм пәйгамбәрне үтерергә карар биреп таралыштылар. Мөхәммәт галәйһиссәлам өстендә үлем вә дәһшәт болыты кабат куера башлады. Имансыз Мәккә кяферләре, кан таләп итеп, җинаять юлына бастылар, кылычларын айкап, кулларына үлем богавы тоттылар.

Шул минутта Җәбраил галәйһис-сәлам Мөхәммәт салаллаллаһу галәйһи вә сәлләмгә вәхи китерде...

*1990—91 еллар.*

*Беренче китап тәмам.*

## ШИГЪРИЯТ



# Нур Әхмәдиев

### Хатирә

Кызыл таудан сулда —
Ята Ает Кулы.
Шушы Ает Кулы —
Балачагым юлы.

Һәрбер карышына,
Ташы, үләненә
Хәтер булып сеңгән
Минем күргәнем дә:

Атлап үткәннәрем,
Көтү көткәннәрем,
Атлар тарталмаса,
Арба этеннәрем.

Шаһитларым азмы —
Әнә кылган, әрем.
Хәтеремне җуйсам,
Күтәрерме гарем?

Авылдашлар мине
Итмәсләрме үги?
Шушы бер хис һаман
Бәгыремне иги.

---

Нур ӘХМӘДИЕВ (1946) — *шагыйрь, «Аһәң», «Бал яңгыры» һ. б. китаплар авторы. Проза әсәрләре дә яза. Әлмәттә яши.*

Хәтер кузы өтә
Мием күзәнәген.
Туган якны җирсү —
Бетмәс өянәгем:

Кимчелегемме бу,
Әллә горурлыгым?
Таулы сукмаклардан —
Шигырьләргә юлым.

Кызыл таулар — кәгъбәм,
Парнас итеп киләм,
Сәҗдә кылган җирем,
Туфрагыңны үбәм.

Бәхетемнең чиге —
Шушы җиргә басу...
Аеҫ кулларында
Кичке эңгер — алсу.

Соңгы кузы көйри —
Шәфәкъ янып ята...
Җаным тагын бер кат
Киләчәккә кайта.

## Каһирә таңы

Тәрәзәне ачтым — азан керде,
И илаһи аваз! —
Гарешкә
Алып очар кебек хәзер мине,
Иңнәренә алып, фәрештә.

Көчәйткечләр аша килгән өнме,
Әллә күкләр шулай дәшәме?
Затлы ефәк булып, илаһи моң
Төреп алды бөтен шәһәрне.

Хак мөслимин ничек уянмасын,
Җаны барлар тыныч, юк, ятмас...
Каһирә бит!
Әлмәтләргә кайтсам.
Таңда мине азан уятмас.

Этләр өрер,
Азан урынына
Сәрхүшләрнең килер тавышы.
Каферләнә барган туган җирдә
Җинел түгел татар язмышы...

Азан моңын көчәйт, көчәйт, тәкъсир,
Туң бәгырьгә үтсен — тыңласын.
Сикереп торып намаз укыр идем,
Ни үкенеч — белмим догасын...

Нәрсә кирәк,ниләр кирәк икән
Иманыңа кайтыр өченгә?
... Әсәрләнеп тыңлыйм азан моңын,
Гаҗәпләнеп сихри көченә.

Җаным җирдәме соң, гарештәме —
Аңлый алыр хәлдә түгел мин.
Асылыма таба бер адым бу —
Намаз аша кайтам бүген мин...

* * *

Ит изгелек, көт явызлык, диләр,
Нәрсә соң ул, ни ул явызлык?
Гомер буе көрәшеп тә, шуңа
Кидертәлми кеше авызлык.

Ара-тирә җыңгән чаклар була,
Куанычы шундый минутның!
Әшәкелек барыбер онытыла,
Изгелекне исә — онытмыйм!

Ник берәүләр явызлыкка бара —
Изге эшләр өчен яралып?
Намус итеп әләр ап-ак җаны
Дегет кебек бетә каралып.

Андыйларга этлек — стихия,
Тормыш тыныч икән — чирли ул.
Күпме кешеләрне гүргә кертә,
Юк намуска хисап бирми ул.

Оялу ни — төшенә дә керми,
Нәҗес изү — бөтен шөгыле.
Кайсы яктан кайчан пычак тыга,
Бер ходайга гына билгеле.

Изге эшләр өчен ирек бирми
Мин-минлекме, әллә хөсетлек?
Эче тулы агу булганнарда
Кайдан калсын шәфкать, егетлек?

Изгелекне бүтән кылмам дисәң
Һәм бозасың тагын сүзеңне.
Явызлыкка каршы явыз булсаң,
Хөрмәт итмәс идең үзеңне.

Таш атканга ашың белән җавап
Кайтаралу — олы җаннарда.
...Син изгелек кылып йөргән чакта
План кора кемдер алдарга.

Йөз ел элек, йөз мең ел да элек
Явызлыктан иза чиккәннәр.
Ул чакта да кояш көлеп торган,
Агач яшел булган, күк — зәңгәр.

Офыкларым якты, рәхәт миңа
Шатлыгыннан кояш көлгәнгә.
Мин куанып яшим: әле ярый
Үч аласым килми кемнән дә.


Казан утлары
китапханәсе
Хәсән Хәмидулла
Тәкъдир каршында

# Автор һәм аның әсәре турында

Татар мөһаҗирият (эмиграция) әдәбиятының күренекле вәкиле булган Хәсән Хәмидулланың тормыш һәм иҗат юлы турында бүгенге укучылар әлегә бик аз белә. Үз вакытында «Ватаным Татарстан» газетасында *(1992, 31 гыйнвар)* кыска гына белешмә белән мин аның бин шигырен бастырган идем. «Финляндия татарлары» дигән мәкаләмдә *(«К. У.», 2 сан, 1992 ел)* язучы турында бераз киңрәк мәгълүмат бирелде. Х. Хәмидулла хакында профессор Хатип Миңнегулов та язып чыкты *(«Ватаным Татарстан», 21 июнь, 1992)*. Әлегә шул гына. Ә Хәсән Хәмидулланың иҗат мирасы исә гаять бай. Аның унбер җыентыктан торган шигырьләре, алты китапта басылган пьесалары, дистәгә якын хикәяләре, бер повесте һәм бер романы бар. Болардан тыш ул — өч тарихи әсәр, өч сәяхәтнамә, ике фольклор мәҗмугасы, «Шимал очкыннары» дигән журнал һәм күпсанлы дини, дидактик китаплар чыгарган кеше дә. Аның дөнья күргән басмалар саны җәмгысы кырыктан артык. Аларның күбесен миңа заманында автор үзе бүләк иткән иде. Ул истәлекле басмалар китапханәмдә саклана.

Үзе турында Хәсән Хәмидулла «Ник алай?» дигән автобиографик әсәрендә шактый әтрафлы итеп яза. Бу әсәр 1962—1977 еллар дәвамында алты китап рәвешендә дөнья күреп (күләме 15 табак чамасы), анда татар дөньясы өчен гаять кызыклы тарихи, этнографик, мәдәни мәгълүмат тупланган.

«Мин дөньяга килеимен 1900 елның 25 ноябрендә Нижний Новгород губернасының Сергач өязе Яңапар авылында. Бу авылның чын исеме Актук булса да, Яңапар исеме дә һәр тарафка танулыдыр» — дип башлап җибәрә Х. Хәмидулла бу әсәрен. Сабыйлык елларын, мәдрәсәдә укыган чакларын тасвирлагач, ул 1915 елда әтисе Низаметдин чакыруы буенча ничек итеп Финляндиягә баруын һәм гомерлеккә шунда калуын хәбәр итә. Хәсән Хәмидулла Хельсинки шәһәрендә 1988 елның 6 ноябрендә вафат була.

«Минем ике хәзинәм бар: берсе — һөнәрем, икенчесе — күңел байлыгым», — дип яза ул «Ник алай?»ның соңгы — алтынчы китабында *(1977 ел, 16 бит)*. Ул гомер буе сәүдә эше һәм китап язу белән шөгыльләнә. Сәүдәгәрлеге аңа яшәр өчен матди нигез булса, язучылык шөгыле ул милләте өчен зарур мөкатдәс бер хезмәте дип саный.

Баштарак Х. Хәмидулла әтисе белән, аннары үзе генә алыпсатар кәсебенә бирелеп, финнар яшәгән авылларда, шәһәрләрдә төрле тукымалар һәм галантерея әйберләре сатып йөри. Үзлегеннән электр, радио серләрен үзләштерә һәм 1922 елда Кеми дигән шәһәргә төпләнгәч (Хельсинкидән 850 чакрым чамасы ераклыкта), шунда үзенә йорт салып, кибет ачып җибәрә. Аның электр-радио товарлары кибете тора-бара бөтен тирә-якка атаклы кибетләрнең берсе булып танылa.

1950 елда Х. Хәмидулла гаиләсе белән (хатыны, улы, кызы) Хельсинкига күчеп килә, кибетен дә күчерә, хәзерге вакытта анда сату эшләрен улы Гомәр дәвам итә.

Х. Хәмидулла әдәби иҗат белән 15—16 яшьләрендә, Финляндиягә килгәч шөгыльләнә башлый. Беренче шигырьләрен яза, гармун уйнарга өйрәнә. Ул җай чыккан саен татарча, урысча, финча китаплар укый, көндәлек дәфтәр язып бара, шунда каләмен чарлый. Әтисеннән аерылып Кеми шәһәренә килгәч, сәүдәдән бушаган һәр сәгатен иҗатка багышлый, бу шәһәрдә фин телендә чыга торган «Кулен лахти» газетасы белән элемтәгә керен, анда беренче хикәятләрен бастыра. Шунсына игътибар итик, бу газета өчен Х. Хәмидулла әсәрләрен фин теленә үзе тәрҗемә итеп бирә.

Тора-бара ул үз әсәрләрен Кемидә чагында сатып алган шәхси матбага машинасында үзе җыеп, үзе бастыра башлый. Үзе үк мөхәррир дә, корректор да. Үзе үк китап төпләүче дә, аларны таратучы да. Дөрес, аңа бу катлаулы эшендә хатыны Гөлсем ханым да булышкалый. Бер уңайдан Х. Хәмидулланың сәләтле рәссам һәм оста сызымчы булуын да әйтеп китәргә кирәк.

Язучының егермеләп китабы Кемидә яшәгән елларда (1922—1950) языла. Хельсинкига күчеп килгәч тә ул, яңа матбага машинасы алып, әсәрләрен бастырып чыгару эшен дәвам итә. Гарәп хәрефләреннән тыш, латинны да куллана башлый. Кайбер әсәрләренең эчтәлеге турында фин телендә аңлатмалар да биргәли. Кыскасы, сокланырлык тырыш, фидакарь кеше булган ул.

Алда искә алган «Ник алай?» әсәрендә язучының дөньяга һәм әдәбиятка карашларын билгеләгән тормыш сәбәпләре, иҗатына дәрт-куәт биргән хәл-вакыйгалар турында берсеннән-берсе кызыклы һәм мөһим мәгълүматлар бар. Шундыйларның берсе — Х. Хәмидулланың 1926—27 елларда Төркиягә сәяхәте, андагы татар мөһаҗирләре белән арала-

шуы, безнең милләтнең атаклы шәхесләре Абдулла Баттал-Таймас һәм Гаяз Исхакый белән очрашуы. Икенчесе — аерым факт буларак түгел, ә гомер юлының аерым бер дәвере буларак игътибарга лаек. Бу күзлектән караганда «Ник алай»?ның бишенче китабында бирелгән махсус бүлек үзенә тарта. «Дини-милли кайгылар» дип аталган бу бүлектә Х. Хәмидулла Финляндия татарлары өчен милли-мәдәни мөхтәрият мөмкинлекләре ачкан тарихи хәлләрне тәфсилләп һәм шактый сурәтле итеп тасвирлый. Шул исәптән 1925 елда Хельсинкидә «Исламия җәмгыяте», ә 1935 елда «Финляндия төрекләре берлеге» дигән мәдәни җәмгыять оешуы, аларның эшчәнлеген, үз вакытында гарәп графикасы тарафдарлары белән латинга күчүне яклаучылар арасында барган кайнар бәхәсләр турындагы сәхифәләр зур кызыксыну белән укыла. Өченчесе — язучының үз иҗат дөньясын яктыртучы төрле-төрле истәлекләр. Берничә мисал китерү белән чикләник. Хәсән Хәмидулла Скандинавия илләре тарихында «Мәгърифәт» исемле беренче татар газетасын чыгаручы була. Кызганычка күрә, газета 1925 елның башында өч ай чамасы гына чыгып килә дә, тарату кыелыклары аркасында туктап кала. Алай да бу фактның татар матбага тарихы өчен игътибарга лаек булуын әйтергә кирәк. «Шимал очкыннары» дигән журнал (1945—1977), «Бәхетсезләр» (1938), «Хәерелниса» (1943), «Өзелгән өмет» (1960) кебек драма әсәрләренең язылу, басылу тарихына караган мәгълүматлар язучының иҗат үзенчәлекләрен төшенер өчен бер чыганак булып тора.

Хельсинки университеты профессоры Гомәр Таһирның миңа язган бер хатында (1986, 10 март) Хәсән Хәмидулла иҗатына күркәм бәя бирелгән. Хат авторы анда Х. Хәмидулланың Финляндия татарлары мохитендә милли хисләр уятучы, татарлыкны яклаучы, нәфис тойгылар тәрбияләүче, әхлакый мәсьәләләргә даим игътибар итүче олы җанлы, кайнар йөрәкле талант иясе булуын билгеләп үтә. Шул ук хатында ул 1985 елда Хәсән Хәмидулланың Финляндия язучылар берләшмәсенә әгъза итеп алынуын хәбәр итә. Моны, әлбәттә, язучының нәтиҗәле әдәби эшчәнлегенә бирелгән югары бәя дип санарга кирәк.

Кыскасы, аның бай иҗат мирасын җентекләп өйрәнеп, аның чит илләрдәге татарлар барлыкка китергән матур әдәбият тарихында тоткан үзенчәлекле урынын билгелисе, иң әйбәт әсәрләрен туплап Казанда китабын чыгарасы бар. Ул моңа һәр яктан лаек.

Инде журнал укучыларына тәкъдим ителгән «Тәкъдир каршында» дигән әсәрнең язылуы, басылуы турында кыска гына мәгълүмат биреп үтик.

Бу әсәр иң элек «Кулен латхи» дигән фин газетында 1924 елда дөнья күргән. Язучы аның татарчасын Хельсинкигә килгәч, 1950 елда аерым китап итеп бастырган. Журнал өчен әсәр әнә шул китаптан алынды. Язучы аны «озын хикәя» дип атаса да, әдәби кануннарга туры китереп, повесть дип атау дөрес булыр шикелле.

Х. Хәмидулла үзе сугышта булмаган, әмма ул сугышны үз күзе белән күргән, анда катнашкан кешеләр белән якыннан таныш була, аларның сугыш турындагы истәлекләрен тыңлый. «Ник алай?» әсәрендә шундый юллар бар: «Көннәрнең берендә Фәрхеҗиһан апамның ире Мостафа җизнием Австрия сугышында каты яраланып, авылга кайтышлый (сүз Актук авылы турында бара) Финляндиягә керергә була. Без әтием белән аны Терийоки шәһәрендә шатланып каршыладык. Өебезгә кайттык. Җизнием башыннан үткән сугыш вакыйгаларын егълый-егълый сөйләде... Берничә көннән мин аны Петроградка кадәр озата бардым.»

Кыскасы, «Тәкъдир каршында» повесте — мәгънәви тирәнлеге һәм әдәби эшләнеше ягыннан безнең әдәбият тарихында хөрмәтле урын алырга лаеклы әсәр. Аның нигезендә гомумкешелек кыйммәтенә ия гуманлы идея — сугышка нәфрәт идеясе ята. Беренче бөтендөнья сугышының канлы, вәхшәтле кырында бертуган ике татарның көтелмәгән очрашуы Хак Тәгалә иркендәге котылгысыз язмыш билгесе булып кабул ителә. Эш һәм тынычлык сөеп үскән инсафлы вә иманлы Габдулла белән Хөсәен дәһшәтле сугыш гарасатының мәгънәсез корбаннары булып хәтердә кала. Алар, тетрәндергеч вазгыяттә калып, олы фаҗига кичерәләр, энесе абыйсын атып үтерергә мәҗбүр була, ә үзе туп ядрәсе астында туфракка әйләнә.

Дөньяның төрле кыйтгаларында таралып-чәчелеп яткан бай рухи мирасыбыз өлгеләре әкренләп кенә тарихи ватанына һәм анда гомер кичерүче газиз халкыбызга кире кайта.

Финляндиядә яшәгән татар язучысы Хәсән Хәмидулланың «Тәкъдир каршында» повестен әнә шул олы мирасның күркәм бер үрнәге дияргә тулы нигез бар. Шуңа күрә дә әсәрне гарәп графикасыннан күчереп, искәрмәләр биреп әдәбият сөючеләргә тәкъдим итәбез.

# Беренче бөтендөнья сугышы вакыйгаларыннан

ПОВЕСТЬ

## 1

Тышта котырынган буран белән ачы җилнең тәрәзә капкачларын шак-шок ачып ябулары, этләрнең коточкыч тавышлар чыгарып улаулары, урамдагы күзгә төртсәң күренмәс дәһшәтле караңгылыклар — болар һәммәсе дә өй эчендәгеләрнең котларын алган, һәр каюсы да сүлпән шәм яктысында өй почмакларына сыгынып утырганнар вә посынганнар иде.

Бер-берләренә сүз кушарга куркып калган, куркудан чырайлары качкан өй эчендәгеләргә тәрәзә капкачларының шак-шок кыйналуы гүяки кыямәт купкан кеби тоела, ыжгырып җил өрүләре, морҗаның аһылдап сызгыруы гүяки өйне җимерергә торган кеби сизелә, этләрнең ачы тавышлар белән улаулары гүяки ач бүреләрнең ишек төбендә идекләрен аңлата иде.

Кар астына күмелеп калган салам түбәле карсак ызбалар, тәбәнәк пайытлар[1], андагы ач хайваннарның җан булары күңелсез уйлар, өметсез хыяллар тудырса да, өй эчләрендәге җан ияләре шушы тормышта туып-үсеп яшәгән ярлы авыл кешеләре үз язмышларыннан мәмнүн вә үзара йөрешеп-керешеп тату гомер итүчеләр иде.

Бу авыл татар авылы иде. Искедән наданлыкның иң чигендә яшәлеп, күршедәге урыс авылларының төрле-төрле золымнарыннан хөкүмәткә авыр биргеләр[2] түләп изелеп, тапталып беткән булсалар да, хәзер инде шактый гына алга китә башлаган зур гына бер татар авылы иде.

Җәй көннәрендә кыр эшләрен эшләп, кыш айларында шәһәрләргә китеп акчаланып кайтулары аркасында бәгъзе берәүләр такта һәм тимер түбәле өйләр салдыра башлаган һәм авыл төсендә анда-монда үзгәрешләр күренгәләсә дә, халыкның күбесе алай да фәкыйрьлекнең чигендә иде.

Шул фәкыйрьлек аркасында алар муллаларын да яхшы карый алмыйлар, шулай булса да, муллалары юк-бар җыелган сәдака акчалары белән салам түбәле мәктәп вә мәсҗедләр салдырып, халыкны шактый гына агарткан һәм укып язарга өйрәтеп диннәрен аңлатканнар вә биш вакыт намаз укуларына кадәр мәләкәләндергәннәр иде.

Авылның баераклары шәһәрчеләр[3] булганга, муллалар аларның кайтканнарын көтә, алардан мәктәп вә мәсҗедләргә утыннар алдырта. Шулай итеп, мәктәпләре дә , мәсҗедләре дә дәвам итеп килә, авыл көннән-көн ачыла, халыкның тормышы вә хәле дә аз-маз гына яхшылана бара иде.

Әхмәт ага уртача хәлле генә булса да, кыш айларын шәһәрдә үткәргәнгә авыл халкы аны бай дип саный, муллалар каршында да игътибары зур һәм ул да мөмкин кадәр мәктәп-мәсҗедләргә ярдәм итә килә, үз тормышын да яхшы ук рәтләгән, гаиләсе дә җиңеллек белән гомер итә, хатыны Мәрьям инсафлы һәм гаять динле хатын булганга иренә бик итагатьле, муллаларны, галимнәрне ярата, балаларының да мөмкин кадәрле яхшы укуларын тели һәм яхшы тәрбия бирергә тырыша иде.

Биш кыз бала артыннан теләп-кесәп[4] алынган ике ир баласы өчен коты очып тора, аз гына хәстәләнсәләр дә абаулап, егълап йөри, яннарына утырып төннәр чыга иде.

---

[1] Пайыт — абзар *(мишәр диалекты)*

[2] Бирге — салым, налог.

[3] Шәһәрче — Сергач ягындагы мишәр авылларында кышларын берәр шәһәргә китеп, вак сәүдә белән шөгыльләнүчеләрне шулай атап йөрткәннәр.

[4] Кесәп — бик көтеп.

Унике яшьлек олуг угылы Габдулла инде күптән мәктәпкә йөри башлаган, ләкин мәктәп бик ерак булганга анда кунып-төнеп тора, фәкать һәр кече атна көнне кичен өйгә кайта да җомга тәгътиленнән[1] соң атнарас[2] көн янә дәресенә китә иде.

Иртәгесе көн балаларга тәгътил көне булганга, бүген кич Габдулланың мәктәптән кайтуы көтелә, тыштагы буран әллә нинди куркыныч төс алганга күрә, малайның анасы Мәрьям утлы күлмәк эчендә иде. Бер күңеле белән ул, юк, кайтмас, мондый көндә ул ник юлга чыксын, дисә дә, икенче күңеле белән яна, көя, кайгыра, тәрәзә капкачлары шакылдаган саен сискәнеп китә, Габдулла килде, дип уйлый иде. Вакыты белән ул әллә нинди шомлы хыялга чума — әгәр аның угылы адашкан булса, аны кар басып китсә... Әгәр аңар ач бүреләр очрап, алар аңа ябырылса, әгәр ул караңгы кырда кая барырга белмичә туңып үлсә... Ананың җанын әнә шундый шомнар, шикләр телгәли иде. Аннары ул әллә нинди сагышлар белән саташып, янә угылының мондый көндә мәктәптә кунарга калырын уйлап тынычлана төшә һәм дә өметләнә иде.

Тыштагы җилнең ямьсез тавышлар белән ыжгыруы, тәрәзә капкачларын бертуктамый шак-шок кыйнавы өйдәге балаларның котын алып бетерсә дә, алар Габдулланы сагыналар, аны кызганалар, аналары Мәрьямнең борчылганын күреп хафаланалар иде.

Менә кинәттән тәрәзә капкачларының шакылдавы басылып китте. Өй эче тынлыкка калды. Әйтерсең, тыштагы буран тукталган, җил басылган да бөтен дөнья тымызык бер хәлгә килгән кеби тоелды.

Өй эчендәгеләр күзне-күзгә багышып торганда, кемдер ишеккә каккандай булды. Мәрьям йөгереп барып:

— Синме бу угылым? — дип әйтергә дә өлгермәде, ишек төбендә аңгерәнеп яткан Габдулланы күреп, куркудан йөрәге ярыла язды. Нәрсә булганын белмичә аптырап китеп, Габдулланы күтәреп кертте һәм абаулап-абаулап чишендерергә, бөтен җирен кармаларга тотынды вә угылының җавапсыз торуыннан коты очып аягы-кулы хәлсезләнсә дә, аны урынга салып өстенә ауды да сулкылдап егълый башлады.

Бу хәл балаларны да каушатып, бар да абыйлары янына йөгерделәр. Озак та үтмәде, Габдулла күзләрен ачып, үзенең адашып йөрүләрен, туңып үлә язуын, өйгә җиткәч тәрәзә капкачларын яба-яба хәлдән тайганлыгын аңлаткач, анасының һәм туганнарының шатланулары чиксез булды.

— Әй, йөрәк парәм! Үзең һаман йорт яклы бит. Шундый хәлеңдә дә тәрәзә капкачлары ябып изалангансың. Ул капкачлар котыбызны алып бетергән иде. Менә хәзер тышта буран барлыгын сизмибез дә, — дип Габдулланы үбеп алды.

Габдулла да аз гына ашап хәл җыйгач, яткан җирендә туганнарына мәктәп кызыкларын сөйләп аларны көлдерде һәм әткәсеннән килгән хатны укып, әткәсенең акча җибәрүенә шатлануын сөйли-сөйли, әнисе белән туганнарының йөзләренә елмаеп карады.

— Әни! Киләсе кышка әтиєм шәһәргә мине дә алып барсын, мин дә акча эшләп сиңа акча җибәрермен, — диде. Бу сүзләргә сөенечтән әнисенең күзләренә яшьләре тыгылды. Улының кулларын кулына алып ул:

— Юк, син әлдә балам гына, син әлдә артык яшьсең. Менә үскәч шәһәргә китәрсең дә, безгә акчалар җибәрерсең, ә без сиңа дога кылып торырбыз. Алла синең бәхтеңне ачар, син хәзер тырышып кына сабагыңны укысаң, мин бик бәхетле булам, бар дөньям тула. Күп гыйлем алгач, без үлгәннән соң, безне яд та итәрсең, өстебезгә хәтем[3] дә укырсың, — диде.

Габдулла әнисенең битләреннән сыйпап, аңа елмаеп карады.

---

[1] Тәгътил — ял көне.
[2] Атнарас — шимбә.
[3] Хәтем — коръән уку.

— Мин, әни, сезгә акчаны күп итеп җибәрермен, аннары без яңа яшел башлы өй эшләтербез. Безнеке кебек ямьле өй беркайда да булмас. Фатыймага да, Галиягә дә, Галимәгә дә, Зәйтүнәгә дә, Рәхимәгә дә чәч баулары, матур бишмәтләр, уенчыклар җибәрермен, Хөсәенгә мылтык алып кайтырмын, әни, сиңа да әллә ниләр җибәрермен,— дия-дия йокыга китте, чөнки ул чынлап та хәстә, тәнендә эссесе бар иде. Йокы арасында ул әллә нинди куркыныч төшләр күрде, бастырылудан йөдәп бетте.

...Менә ул, имеш, шәһәргә килгән. Урамнарда кая карама, акча аунап ята. Халык шул акчалар өстеннән басып йөри. Габдулла акча белән бөтен кесәләрен тутырган килеш өйләренә кайткан, имеш, өйдәгеләр аны кочаклыйлар, үбәләр, син безне баеттың, менә хәзер без дә яшел түбәле өй салачакбыз,— диләр, имеш.

...Менә аларның мәктәпләре, имеш. Хәлфәләре бармак селкә, дәресләрен әзерләмәгәне өчен Габдулланы ачуланмакчы була. Кулындагы сөлгедән ишкән кушкасы[1] калыная бара. Менә ул пич калынлыгы булды, хәлфәсе Габдулланы сугыйм дигәндә генә кушагы нечкәреп китте, энә кебек хәлгә керде. Аннан ул ачу белән Габдулланың колагыннан тартыйм дигәндә генә бармаклары юкка чыкты. Хәлфә Габдуллага:

«Бармакларымны бир, сиңа бер дә сукмамын,» — дип ялына башлады. Моны күреп шәкертләр дә, Габдулла да шаркылдап көләргә тотындылар. Шулчак ул уянып китте. Каршында әнисенең елап утырганын күреп, аның: «Балам! Ни булды сиңа?» — диюенә дә шаркылдап көлгән кебек булды. Тик сүз әйтергә аның теле әйләнмәде, ул янә авыр йокыга талды.

## 2

Яз башы килде. Габдулла инде хәстәлегеннән терелеп мәктәбенә кайткан, имтиханга әзерләнә иде. Бераздан имтиханнар да артта калды, тирә-якта яз патшалыгы башланды, аның ямьлелеге, елгада уйный-уйный коенулар, җиләккә барулар, качышлы уйнаулар, Габдулланы кәефләндерсә дә, аның күңеле атта иде, атка атланып йөрүдә иде.

Бу вакытларда инде елдагы гадәте буенча атасы Әхмәт шәһәрдән кайтып язлыкта кыр эшләрен эшләр өчен бер ат алган, көн буена кырда булып, өйгә кичен генә кайта торган иде.

Болытлы көннәрдә атасы кырдан иртәрәк кайтканга күрә, Габдулла Алладан болытлы көннәрнең күбрәк булуын сорый, чөнки андый көннәрдә ул ат өстендә йөри, рәхәтләнә, бөтен дөньясы тула иде. Аты да юаш һәм гакыллы булганга Габдулланы ярата, Габдулла теләгәнчә эшли, Габдулла теләгәнчә уйный иде. Башка малайлар Габдулланың атта йөрүен сокланып карыйлар, аның осталыгын мактыйлар иде. Ә ул аларның исен китереп, алаша өстендә басып та төрлечә кыйлана, алаша астыннан йөгереп тә чыга, тагын әллә нинди кызыклар эшли иде.

Менә яз уртасы килде. Август аеның бишенче көне гает көне булганга, халык бар да өйдәләр. Бәйрәм шатлыгы белән дөнья кайный, яшь балаларның кулларында чигелдәк[2], конфет, айбагар, кара кузак вә төрле уенчыклар белән барысы да урамга чыкканнар, бер-берләренә күрсәтешеп мактанышалар иде.

Габдуллага да бу бәйрәмгә атасы уенчык мылтык алып биргәнгә, ул да куанычына чыдый алмый урамга чыккан, малайларга мылтыгын күрсәтә, атып бага, алмаш-тилмәш шартлатып, ду килеп уйныйлар иде.

Мондый сөенечле бәйрәм көненең кичке сәгатьләре һич көтмәгәндә тәэсефле[3] төс алыр дип кем уйлаган? Манарадан моңлы тавыш белән

[1] Кушка — кушак, билбау.
[2] Чигелдәк — вак күмәч.
[3] Тәэсефле — кайгылы.

икенде намазына азан әйткән авазга ялганып, Әхмәт ага абзарыннан яшь балаларның илерешкән-бакырышкан тавышлары яңгырап китте. Бу тавыштан куркынып Әхмәт аганың кулыннан тәһарәт комганы төшеп, ул тиз генә тәрәзәгә йөгерде.

Абзардагы малайларның тавышыннан берни дә аңламыйча ул тышка йөгереп чыгарга өлгермәде, күршеләренең чия кан эчендәге Габдулланы күтәреп кертүләрен күреп һушы китә язды. Ул тыштагы балаларның: «Алаша гаепле түгел, үзе егылды, үзе ат өстенә басты да егылып күзен чыгарды!» — диеп кычкырышуларын да төштәге кебек кенә ишетеп алды.

Бу кызганычлы хәл бөтен авылны тетрәткәне кеби, Әхмәт аганың өендә инде кайнар яшьләргә катнашкан бер матәм көненә охшаш бер көн булды. Шундый бер күңелле көнне, гает бәйрәмендә бу кадәр кайгы килерен Габдулланың кечек энесе Хөсәен берни төшенмичә шашып калып, кешеләрнең: «Алла казасы инде» — дигән сүзләренең нәрсә икәнен аңламыйча, исе китеп аптырап тора һәм үзенең дөньяны белә башлавыннан бирле Алла белән куркыту сүзләрен кат-кат ишеткәнгә, Алладан куркып нәүмиз хәлдә бер читкә поскан да туганы Габдулланы кызганып үксеп-үксеп егълый иде.

Икенче көнне инде Габдулла телгә килеп үз хәлен аңлагач, сул күзенең зарарлануыннан һәм бер күз белән генә калуыннан ачынып егълый һәм ул егълаган саен ата-анасының вә туганнарының йөрәкләре әрнеп, алар да күз яшьләре агызалар иде.

Менә шулай кайгылы август та узып китте, көз килде.

Балаларның мәктәпкә барыр вакытлары җитте.

Габдулланың инде күз әрнүе бетеп ярасы уңалган[1], бер генә күзгә калган иде. Бу көнне инде Хөсәеннең дә яше җиткәнгә, ике туган мәктәпкә китеп, анда бергә тора башладылар. Ләкин мәктәптә балаларның Габдулланы «сукыр», «бәбәксез» диеп ялан саен мыскыллаулары никадәр рәнҗетсә дә, ул аларга берни әйтми, ачуланмый, үзенең ким-хур идекен үзенчә аңлап сабыр итә иде. Кайвакытларда туганы Хөсәен ул малайларга ачуланып алар белән сугыша башласа да, Габдулла аны тыя. «Алла казасы бит, миңа Алла үзе бирде»,— дигәнгә Хөсәен дә тиккә калып янә шул «Алла казасы»ның нәрсә икәнен аңламыйча аптырап кала иде.

Бер мәртәбә хәлфәләре үз колагы белән балаларның Габдулланы:

— Сукыр! Бәбәксез! — дип мыскыллауларын ишетеп, балаларны рәттән яткырып каты сөлгедән ишкән кушка белән кыйнагач, Габдулланың утырган җирендә сулыгып егълаганын күрде. Хәлфә моның сәбәбен сорагач, малай:

— Мин сукыр булмасам, син аларны кыйнамаган булыр идең... Минем гаебем бу,— дип җавап бирде. Габдулланың бу җавабына хәлфәнең исе китеп, аның шөбһәсез бер яхшы адәм булачагын аңлады һәм шуннан аны хөрмәт итәргә, үзенә аерым дәресләр бирергә башлады. Габдулла да, аңлы бала булганлыктан, үзенең зәгыйфь идекен белә, зәгыйфь кешенең фәкать уку аркылы гына көн күрә алуын сизә һәм шуның өчен аның бөтен эше дә укуга бәйле иде.

Көннәр үтә торды. Янә яз башы килде. Әхмәт ага бу кышны да шәһәрдә булдыгыннан, язлыкка авылга кайтырга иртәрәк булса да, Габдулланың уку шөһрәте аңа кадәр ишетелгәнгә, үз колагы белән ишетер өчен дип имтихан тыңларга өйгә кайтты.

Ул кайтканның икенче көне имтихан көне иде. Халык бар да ду килә, имтихан тыңларга мәктәпкә агылалар, хатын-кызлар да бәгъзеләре эчкә — ирләр арасына керергә тартынсалар да, мәктәп тышарсыннан булса да шиыр[2] тыңлар өчен дип, бәйрәм киемнәреннән мәктәпкә таба ашыгалар иде.

---

[1] Уңалган — уңайланган, төзәлгән.

[2] Шиыр — шигырь сүзенең халыкча әйтелеш варианты.

Татар авылларында мәктәп имтиханнары бөек бер бәйрәм төсе алганга, ят авыллардан муллалар һәм мөгаллимнәр чакырыла, алар белән шәкертләр арасында чыккан бәхәсләрне кешеләр кызыксынып тыңлыйлар һәм шактый гына мәгълүмат та алып чыгалар иде.

Муллалар, картлар һәм шәһәрчеләр алдагы сафка утыру гадәт булганга, Әхмәт агага да хатыны белән алындагы урындыктан урын бирделәр. Имтихан башланды. Халык тынга калды. Беренче сыйныфтагы шәкертләр бөтен сыйныфлары белән чыгып, халыкка каршы тезәсләп[1] имтихан бирергә башладылар. Халык рәхмәт укыды.

Менә икенче сыйныфлар... өченчеләр... Нәүбәт зурларга килеп житте. Алар бишәү иде. Унар ел мәктәптә укып, егет диярлек үскән малайлар арасында унөч яшьлек ябык кына сыңар күзле бер баланың чыгып утыруы, зурлар ача башлаган китапларны аның да ача башлавы халыкны һәм муллаларны шаккатырды. Телсез калдылар.

Бу вакыйга арттагыларга кадәр колактан ишетелеп күтәрелеп багылулар, иренеп-иркенеп алга таба чыгулар, «Кем баласы бу, кем баласы?» — диеп бер-берсеннән сораулар ахырда тынычлыкны боза башласа да, мөгаллимнең:

— Сс... Сабыр итегез! — диюен дә инде Әхмәт ага ишетмәде, чөнки ул шатлыктан бөтен дөньясын онытып, дивана кебек катып калган иде. Хатыны Мәрьямнең:

— Әй, йөрәк җимешем! — дигән сүзләреннән дә ул берни дә аңламады кебек.

Дәрес башланды. Муллалар куйган сорауларга шәкертләр биргән җаваплар халыкта төрле кызыксыну уятса да, Габдулланың укытучылар, муллалар белән акыллы итеп бәхәсләшүе, төрле гыйлемнәр буенча чәгәләшә алуы һәммәсенең исен китәрде.

— Афәрин, афәрин! Рәхмәт, балакай, бирешмәдең, җиңелмәдең,— диеп кычкырулар, кул чабулар имтихан бүлмәсен тетрәткәндәй булды.

Гомердә булмаган бу кадәрле кызык имтихан Габдулла һәм аның ата-анасы, туганнары өчен бөек бер бәйрәм булганы кебек, бөтен авыл һәм аның аркылы тирә-якка бер шөһрәтле вакыйга булды. Чөнки бу көнге имтихан тарихта булмаган бер нәрсә — унөч яшьлек Габдуллага коръән хафизлык[2] исемен бирел, анда булган бөтен муллалар коръән хафизының кулын үптеләр.

Имтихан бетте, бөтен халыкның авызында Габдулла гына булды. Икенче көнне Габдулланың хәлфәсе Әхмәт агага килеп, аның улында өмет барлыгын, аны Казанга җибәреп укытырга кирәген һәм шул юлда аңар ярдәм итәргә әзер торуын сөйләде. Әхмәт ага мөгаллимнең бу фикеренә рәхмәтләр укып, үзенең дә шул фикердә икәнлеген, ләкин ул кадәр бай түгеллеген, мондый эшкә күп акча кирәклеген һәм аның аны булдыра алмавын сөйләп маташса да, мөгаллимнең сүзендә нык торуы, син булдыра алмасаң халыктан акча җыярга чыгам, диюе, бай атын күтәргән Әхмәт аганы оялтып, Габдулланы Казанга укырга җибәрергә вәгъдә итте.

## 3

...Габдулланың Казанга килүенә берничә еллар үтеп китте. Ул инде хәзер Казан тормышы белән мәләкәләнгән, бөтенләй башкаланган, ачылган, килгән еллардагы кебек өйдән чыкмыйча укып кына ятмый, уры чыкканда иптәшләре белән йөрергә дә вакыт таба, трахтирларга да керә, театрларга да бара, алай да күбрәк гомерен китапханәләрдә утырып үткәрә иде.

---

[1] Тезәсләп — тезләнеп.
[2] Хафиз — коръәнне күңелдән белүче.

Ул инде хәзер егетлек дәверендә иде. Кыска гына буйлы, артыгына ябык һәм зәгыйфь тәстә күренгәнгә, егетлегенә ул кадәр әһәмият бирми, шуңадыр иптәшләре дә аңар бик игылмыйлар, күбрәк ул ялгыз йөрергә ярата, укып, арып кайткач яткан җирендә төрле-төрле хыялларга чума иде. Бәгъзән төннәрне ул йоклый алмый, йокласа да Чыңгыз ханнар, Аксак Тимерләр белән чуалып бетеп, иртәсен янә шул көйгә мәктәпкә китә иде.

Мәктәпләрдә инде яңача — ысулы җәдит тәртибенчә укулар кызу урын алганга, дәресләр күңелле үтәләр, аны бигрәк тә тарих белән җәгърафия гыйлеме кызыксындыра, өйгә кайткач та ул харитадан борынгы татар ханнарының торган җирләрен эзли, аларның зурлыгын, чиген үлчи, раслыгын билгеләп кызыл кара белән сызып куя иде.

Бәгъзән ул трахтирда утырудан да тәм таба, чөнки ул заманнарда ысулы җәдитчеләр арасында «милләт», «милләт» дигән сүзләр бик модага кергәнгә, трахтирда аракы эчеп утыручыларның милләт өчен җан бирергә әзер торулары карап торыр өчен кызык булганга, иптәшләре аны анда барырга кыстыйлар һәм ул исә аннан кайткач, янә аннардан нәфрәтләнеп йоклый алмыйча саташып бетә иде.

Ул уйлый иде. Менә аның яшьлек дәверләре... ялан аяк йөгереп йөргән кырлар, болыннар, су буйлары... җиләккә барулар, су коенулар... Әллә ничектер күңелгә сырышып калган туган җир һәм аның карсак, салам түбәле булса да мәхәббәтле өйләре... әтисе, әнисе, туганнары, аларга биргән вәгъдәләре... Шулар барсы да аның исенә төшә дә, барын да сагышлый, әтисенең бөтен тапкан табышы аны укытыр өчен генә китеп, өйдәге фәкыйрьлек көчәюгә вә ул фәкыйрьлеккә ялгыз үзе сәбәпче булуына бөтен җаны-тәне көнен-төнен әрни, сыкрый иде.

Шуның өстенә, соңгы вакытларда әтисенең хәлсезләнүе вә шул сәбәпле бөтенләй инде шәһәрдән калуы, өйдән моңар күңелсез вә өметсез хатлар язып, аның укуын селтәп[1] өйгә кайтуын, яхуд бер-бер эшкә бәйләнеп өйгә ярдәм итәргә вакыт җиттеген аңлатулары Габдулланың эчен кыра, бер яктан өйне жәлләсә, дәресләренең дә бетми калуын гакылына һич сыйдыра алмыйча саташып, газапланып чыга иде.

Төрле хыяллар һәм сагышлы уйлар илән изаланып йөри торгач, көннәрнең берендә ул гәзиткә вә журналларга мәкаләләр язып карарга карар бирде. Баштарак язганнары өметләрен бик акламаса да, тора-бара халык яратып укырдай булганга, шактый ук акча да керә башлады. Ул гына да җитмичә, Габдулла төрле-төрле милли эшләргә катнашып, төрле оешмаларда вазыйфалар башкарып, аз-маз булса да мәгашлар[2] алып, бераз гына өйгә ярдәм итәрлек һәм артык кыенлыксыз укырлык бер хәлгә килде.

Көннәрнең берендә ул бер әйбәт танышы ярдәмендә Казанның оста күз докторыннан операция кылдыртып, аз-маз заман эчендә хастаханәдә ятып, күзле булып сәламәтләнү хәленә дә иреште. Вә бу шатлык өйдәгеләрне дә сыңар аяктан биетеп, үзе дә бөтенләй үзгәреп, яшәреп, дөньяга яңа туган кеби рухланып китте. Габдулла хәзер башы-аягы белән эшкә чумды. Аның тоткан юлы фәкать ике генә: өен кайгырту вә укуның очына чыгу иде. Шуның өчен ул вакытны үлчәмичә, көнен-төнен эшли, көнен-төнен бөтен хыялында шул гына иде.

Көндезләрен мәктәпкә йөрү, кичләрен эшләү, төннәрен мәкаләләр язып уяу чыгу, аның ансыз да ябык тәнен ябыгайтканнан-ябыгайта, аның зәгыйфь, чыра кебек йөзен саргайтканнан-саргайта, көчләре кимегәннән-кими бара иде. Бу хәлен күреп дуслары аны тыйсалар да, ул аларга:

— Тагын бер елга чыдасам, киләсе яз башына дәресләрем бетә, җиңеллеккә калам, — дисә дә, күңеленнән бу авырлыкның болай дәвам

[1] Селтәп — ташлап.
[2] Мәгаш — хезмәт өчен алынган акча.

итә алуыннан үзе дә шикләнә, бәгъзан өметләнә һәм шул өметләр белән ата-аналарын да юатып тора иде.

Шундый татлы өметләр белән яшәгән бер вакытта Габдулла өеннән кайгылы телеграмм алды. Анда анасының соңгы сулышта ятуы турында язылган иде. Габдулла шул ук көнне кичке поезд белән авылга ашыкты. Ул кайтканда анасының хәле авыр булса да, Габдулланы кочаклап, соңгы мәртәбә күреп калуыннан гаять шатлануын аңлатыр өчен иреннәрен селкетеп алды һәм ямьле генә елмаеп, күзләреннән бөртек-бөртек яшьләрен агызды. Бу хәлне күреп Габдулланың күңеле нечкәреп китте. Ул анасын кочаклап елъларга башлады. Бу хәсталеккә үзе гаепле бер кеше шикелле өйдәгеләргә куркып, оялып баккан кебек булды. Аның ертык-портык киемле туганнары, картлыктан сазаеп беткән, бөкрәйгән атасының сәләмә өс-башы, өйдәге фәкыйрьлек исе, анасының яткан җирендә гыж-гыж йөткерүләре — болар бар да аның йөзенә терәгән кебек, аңардан нәфрәтләнгән кебек, аның җинаятен бармак белән төрткән кебек күренде.

Ул бу ким-хурлыкларга төшүнең сәбәпчесе үзе идекенә ачына, ничә ел укып та бер-бер эшкә яраклы булып чыга алмавыннан ояла, шул гаепләрен, ничек кенә булса да тизлек белән түли алу бурычлыгын әрнеп-әрнеп уйлый иде. Ул шушы газаплы уйлар белән хәсрәтләнгән арада анасы Мәрьям җан тәслим итеп дөньядан китте. Өй эчен җир күтәрә алмаслык кайгы басты. Ансыз да тормыш хәле читенләшеп киткән Әхмәт ага өенә күңелсезлек вә өметсезлек тулды.

Сазаеп, картаеп беткән Әхмәт ага да яшьлегендә батыр сәүдәгәр булып, бай атын күтәрергә җитәрдәй бер гайрәтле кеше саналса да бу көн гүяки аның өчен дә дөнья беткән, җимерелгән, тормышының тәме, ләззәте мәңгелеккә киткән кебек иде. Аның фикеренчә, бу өметсезлекләрдән котылу Габдулла аркылы гына булачак булганга, ул ап-ак сакаллы йөзен борып елълап шешенеп беткән кып-кызыл күзләре белән моңаеп Габдулла ягына карый һәм шуның белән шәһәрдәге укуларын бетерүен тели иде.

Бөтен бу бәхетсезлекләргә үзен сәбәпче иттереп хыял иткән Габдулланың инде бу куәтләргә каршы торырлык хәле калмыйча, бу җинаятьләрдән пакъланыр өчен, бу бәхетсезлекне үз өстенә алыр өчен бөтен туганнарының моңарга начар күз белән караганнары кебек, карауларыннан котылыр өчен өйдә калырга, өйләнеп янә гаиләне тергезергә, алладан аңар насыйп булмаган гыйлемлекне алудан мәхрүм калырга атасына вәгъдә итте.

## 4

1914 елның җәе иде.

Бөтен авыл халкының эшкә яраклылары урак өстендә, бар да кырдалар иде. Көн кызу. Күктә бер генә болыт әсәре дә юк. Бөтен дөнья янган, көйгән төсле, эленеп алырга ичмаса бер күләгә дә юк... Кайда гына баксаң да кырлар-басулар, гүяки су кебек дулкынланып торган арыш башаклары... Шулар арасында чырмаланып үскән кырмавыклар вә сары чәчәкле алабуталар. Болар бар да манзарага бераз төс биргәне кебек, җир очындагы тар гына чик бразналары да һәм шул бразналарга басылып калган арба тәгәрмәченең эзләре дә гүяки борынгы бабаларыбызның моннан күп гасырлар бу тирәләрдә йөргәнлекләренә тарихтан калган шаһитлар кеби. Еракта күренгән биек тауның каралҗым шәүләсе дә үз башыннан күп вакыйгалар үткәнен үзенә җыйган кеби.

Кырлар өстендә әллә кайлардагы кошлар сайравы ишетелә, әллә кайлардагы чикерткәләр тавышы чыңлый. Вә шуларга ялганып чалгы кайраулар, кыҗырт-кыҗырт киселгән урак тавышлары, арба астыннан ишетелгән яшь оланнар елълавы табигатькә бер тулылык биреп торсалар

да, эсседән күгәреп беткән иреннәрне җебетерлек, юешләтерлек бер тамчы да су булмаганга, урак уручыларның хәлләре авыр, һәммәсе дә арыпйөдәп беткәннәр иде.

Габдулла инде вәгъдәсе буенча өйләнеп өйдә калган, энесе Хөсәен Әхсән байга ялчылыкка кергәнлектән, бөтен йорт эшләрен үзе генә башкара, җитмеш яшендәге карт атасы Әхмәт ага да бернинди эшкә тыгылмыйча йорт сакчысы гына булып калган иде.

Искедә, җирләр ирләргә генә бүленеп, өч душ белән тугыз җанны тәрбия итү бик авырга килгәнгә, кыш көннәрендә мөгаллимлек вазифасын башкару өмете Габдулланың башына кереп, киләчәгеннән ышанган вә шул куанычлар белән кулын беләкләренә кадәр сызганып, хатыны Разия вә кыз туганнары белән бергәләп урак ура иде.

Август аеның бише иде. Моннан берничә еллар элек бу көндә Габдулланың күзе зыяланган, вә бөтен Әхмәт ага гаиләсенә төшкән авыр бер көн — матәм көне иде.

Ләкин үткән эш беткән, онытылган. Адәм баласы шатлыкны да онытканы шикелле, кайгыны да шулай тиз оныта. Дөньяның тарлыгы, авырлыгы вә шушы тартышуларга, авырлыкларга каршы тора белү вә чыныгулар белән җиңеләйгән шикелле, Габдулланың тормышы да яхшы ук яхшырган... Хатыны Разиядән дә бик уңган, вә киләсе тиз заманнарда ата булырга да өмет бар, вә шул өмет белән ул бу көндә җырлап-җырлап урак ура иде.

Дошман гаскәрләре тезелеп үлеп ятканнары шикелле, артта тезелеп калган көлтәләр... Җирнең ары башына кичә генә бастырып куйган чүмәләләр гүяки бу көн үксез шикелле, гүяки әллә нәрсә буласын белгертәләр... вә шуларга ялганып күршедә уручыларның яшь оланнарының берөзлексез илегеп-илегеп егълавы да табигатьнең нинди дер бер кылын чиртеп тынычлыкны боза, күңелләрнең рәхәтен ала иде.

Еракган чабып килгән бер алашачы кырда уручыларны сискәндереп җибәрде. Һәммәсе килүчене күзәтеп ураклярын тоткан хәлдә катып калдылар. Кызу урак өстендә кемнеңдер ат белән чабып йөрү ихтималы булмаганга, бу, әлбәттә, яхшы хәбәр белән килми, авылда йә янгын, йә бер үлем барлыгын гына уйлап була иде.

Озак та үтмәде, алашадагы ирнең авыл старостасы икәнлеге беленде. Ул әүвәл күршедәге уракчылар янына туктап, ниндидер кәгазь укыды да, Габдуллалар янына килде. Якынга килеп атын туктаткач, кесәсеннән кәгазен алып ул Габдуллага:

— Бөек император Николай II патшабыз немецка каршы сугыш ачты. Сез иртәгә сәгать уникедә идарәгә килеп җитәргә тиешсез, аннан соң сугышка озатылачаксыз,— диде.

Һич көтелмәгән бу хәбәр Габдулланы каушатып җибәрде, хатыны вә туганнары аның муенына сарылып егълый, үкси башладылар.

Кыр мәхшәр көне кеби ду итте. Кычкырышлар, бакырышлар, күз яшьләре белән дөнья тулды. Озак та үтмәде, янгыннан ташынган кебек, дрыйн-дрыйн арбалары белән халык кырдан авылга юл тотты.

Бая гына бар дөньяны эссесе белән корыткан уттай кояшның төсе гүяки кызарган кебек, гүяки кан төсле кебек һәм бая гына үзенең шәүкәте белән гайрәтләнеп як-ягына тарих тараткан биек тау да гүяки:

— Менә, күрдегезме? Мин шуларны гомерем буена күрәм!..— дип бармак селеккән кебек булды.

## 5

Карпат тауларының итәкләре ничәмә йөз еллардан бирле кеше канын эчеп туя алмаганга, сугышларның да иң катылары шунда була кебек. Аурупа илләрендәге бөтен ятимнәрнең вә бөтен тол хатыннарның, бөтен карт ата-аналарның вә бөтен балаларның күз яшьләре дә күбрәк шушы тау итәкләренә барып буыла кебек.

Габдулла окоп базыннан чыгып як-ягына каранды. Ул сугышның алгы сафында булса да, менә берничә көн инде һөҗүмнәр булмау сәбәпле, атышулар басылган иде. Сирәк-сирәк кына чебен кеби сызгырып киткән, адашкан пүләләр җелт-мелт кенә тынычлыкны бозгаласалар да, каты сугышларда йөргән кешеләргә бу һич тәэсир итми, алар мондый көнне һавада йөренеп ял итәләр иде.

Габдулланың күзе Карпат тауларына төрелде. Бу мәһаббәт, биек таулар башыннан ниләр генә кичмәгән? Моннан Суворов гаскәреме йөрмәгән, Наполеон гаскәреме үтмәгән, моннан алман гаскәреме кичмәгән, моннан урыс гаскәреме атламаган, моннан төрек гаскәреме узмаган. Бу тауларны Чыңгыз хан гаскәрләре дә таптап йөргәндер...

Әйе! Чыңгыз хан гаскәре... Әнә аларның чатыр корган җирләре, әнә аларның туп эзләре. Менә шунда татар гаскәре бөек һөҗүмнәр кылган... Әйе, менә шунда! Ул үзенең Казанда укыган вакытларындагы тарих китапларын хәтеренә төшереп, кызыл кара белән сызып чыккан харитасын күз алдына китерә дә:

— Менә, менә шунда! — дип куя.

Әйе! Алар бу җирләрне таптаганнар, бу җирләрдә вакыты белән намазлар да укылган, азаннар да әйтелгән... бу җирләрдә татарларның байраклары асылынган, милли маршлары уйналган.

Ул шатлыгыннан көлеп алды да, тагын Карпат тауларының шәрык ягын тикшерергә тотынды... Менә шунда урыс гаскәре чигенгән... әнә кайда йөз меңнәрчә гаскәр кырылган... әнә кая каннар елга булып аккан... бу каннарга татар каны да катышкан. Ничәмә меңләп татар җаны шунда кыелган.

Ләкин ник, ни өчен, кем өчен?

Шулчак ул кайгысыннан иреннәрен тешләп үз-үзенә:

— Мин дә бит шунда кан түгәм! Мин дә бит бер татар гаскәре,— диде.

Татар гаскәре?!

Ул тагын уйга калды. Дөрестән дә ул бер татар гаскәре бит. Утыз өч миллион татарның бәхетен, тынычлыгын, малын, милкен, вә ватанын саклап утка керүче бер татар гаскәре!

Әйе, саклап...

Нинди ватанны? Аның ватаны бармы? Аның тынычлыгын кем боза? Аның малына, милкенә кем тия? Барыннан да элек таланган, налог түли-түли йөдәп беткән ярлы татарның салам түбәле өйләре, карсак пайытларымы австрианнарга, мажарларга йә германнарга кирәк?

Ул башын аска бөкте. Яшенә төелде. Яшен себерер өчен кулъяулыгын эзләде, тапмады, җиң очлары белән себереп куйды. Аның кулы битенә тиде. Озын чәнечкеле сакал! Хатыны сагынмалыкка биргән көзгене кесәсеннән алып йөзенә бакты. Чыннан да, кап-кара зур сакал. Канлы туфраклар белән керләнеп беткән кап-кара бит, керфек ясларына ябышып беткән соры тузаннар. «Бу кыяфәтемдә минс хатыным да туганнарым да танымаслар иде»,— дип уйлап куйды ул һәм тиле кеше кебек көләргә тотынды.

— Әйе, бу да бер татар гаскәре,— диде ул үз-үзенә.

Аның тагын күңеле ташарга тотынды... Яшьлек дәвере каршына басты. Әтисе-әнисе, туганнары, Казанга барып укып йөрүләре... Шунда аның йөрәге жу итеп китте.

— Ах, күземне Казанда ярдырмаган булса идем! Нинди бәхетне кулдан ычкындырдым, нинди бәхет бирелгән булган миңем кулга!

Көзгесен кулына алып күзен бакты. Күңеленә бер фикер төште. «Әллә, юкса... бу туфраклар белән...» Ләкин бу фикереннән ваз кичте. Кулы бармады. Көзгене кулында кат-кат әйләндереп сөекле хатынын искә төшерде... Аның мөлаем күркәле йөзе, матур кара күзләре. Аның зифа буе, сөяге-сыны барысы да гүя көзгенең эчендә баскан кеби күренде. Хатынының көзгедәге сурәте гүя егълаган кебек, күзләре мөлдер-мөлдер

яшь тулы кебек, гүяки аның кайнар яшьләре көзгегә тамып көзгене томанлаткан кебек булды. Аннан Разиясе аңар шул томан астыннан:

— Җаным! Йөрәгем! Бәхетсезем! — дип өзгәләнеп кычкырган кебек булды. Шул кычкыруларга ялганып аның колагына бәбәй тавышы — угылы Галинең егълаганы, илегеп-илегеп бакырганы ишетелде. Аннары бала тавышына кушылып, карт атасының моң-зары ишетелгәндәй булды:

— Углым, карт атаң монда күрмеш эчендә... тормышыбыз бик авыр, кайт инде тизрәк, кайт инде...

Габдулла бу хыялый уйларыннан айнып та өлгерә алмады, мажарларның туп ядрәләре гүләгән тавышлар һөҗүм башланганына ишарә итте. Ул тиз генә базына яшеренде.

## 6

Сугыш башланганга инде ике ел булды. Әхмәт аганың өендә фәкыйрьлек чиктән тыш булуына карамыйча, соңгы улы Хөсәенне дә гаскәргә алганнар, ул да инде елдан артык сугыш эчендә иде. Башта ул төрек фронтында Төркиягә каршы кыйлынган зур һөҗүмнәрдә катнашкаласа да, татарларның төрекләргә каршы күңел биреп сугышмаулары һәм берәм-берәм Төркия ягына качу вә төркем-төркем әсирлеккә бирелүләре сәбәпле, аны Алман фронтына күчергәннәр вә ахырда кайда каты һөҗүмнәр бар, шунда күчерелә килеп, әле инде ул да мажар фронтында иде.

Бала вакытыннан алып ул — нык, таза тәнле, каты буынлы иде. Мәктәпкә йөргән чакта ул көрәшкә дә, сугышка да мәшһүр булганга, аның кыскарак киң җилкәле буе әле дә гайрәтле, йодрыклары тәпәч кебек каты, киң йөзендә көч-куәт сизелеп тора, гүяки ул, чыннан да, Чыңгыз ханның каһарманлы көчле бер гаскәре иде.

Аның бу кыяфәте күргәннәрнең калебен җәлеп итәрлек булганлыктан, аңа күбрәк авыррак нәрсәләрне күтәрергә туры килә вә шул көче аркасында ул офицерлар каршында да шөһрәт алып, аны күп вакыт сугыш кырындагы яралыларны вә үлекләрне җыярга җибәрәләр вә шул сәбәпле аның эше дә бик үк куркынычлы түгел кебек иде. Соңгы вакытларда да аның хезмәте шул иде. Баштарак авыр яралыларны күтәреп ташу, аларның ыңгырашулары, әрнеп егълаулары, тотарлык җирләре булмаганда аларны акыртып-бакыртып күтәреп-күчереп йөртүләр Хөсәеннең йомшак күңеленә артыгы белән тисә дә, бердән аларга ярдәм итү хисе, икенчедән аларның өйләренә хат язып белдерү вазыйфасы аны бу эшкә чыныктырып, үлекләрне ташу-күмү мәшәкатьләре аларның иң соңгы теләгеп үтәү кебек тоела иде.

Урысларның өч көнгә сузылган тоташ каты һөҗүмнәреннән соң, мажарлар Карпат тавы итәгеннән чигенергә мәҗбүр булдылар. Кат-кат кулдан-кулга күчеп йөрегән Раново авылы янә урыслар кулына төште. Санаусыз күп сугышлар кичергән бу авыл урамнарында йөзләгән кешеләрнең каннары акса да, ни гаҗәп, авылның сирәк кенә утырган салам түбәле, балчыктан салган ак өйләре ничектер сәламәт калганнар. Ул гына да түгел, анда-монда куйлар, кәҗәләр, этләр вә тавыклар йөреш-терәләр, хәтта берничә сыгыр да яткан җирләрендә күшәп яталар иде.

Өч көн барган каты сугышлардан соң үлекләрне җыю, күмү тәнәфесе булды. Шул тәнәфес вакытларында гаскәрләрнең беренче эше ияләре качып беткән авыл өйләрен талау, ашачак нәрсәләрен ашау, калган хайван вә кош-кортларын сую иде.

Хөсәеннең бу көнге эше авыл эчендәге яралыларны җыештыру вә андагы үлекләрне ташу булды. Алар күбрәк вакыт икәүләп-өчәүләп йөрсәләр дә, каты һөҗүмнәрдән соң үлекләр күп булу сәбәпле, тиз-тиз генә берәмләп йөрергә мәҗбүрләр, менә бүген дә ул ялгыз гына китәргә тиеш иде.

Башка гаскәрләр кеби аның өйләр талап йөрергә вакыты юкка, ул ашыга-ашыга үз эшенә тотынды. Әнә анда бер мөселман «Алла» диеп кычкырып ята, әнә аның күршесендәрәк бер үлек гәүдәсе... Әнә ерак та түгел берсенең башы каты яраланган, ул да мөселманга ошый, әнә тегендәрәк берәвенең аяклары тетелгән, ә сул якта берәвенең кулы өзелгән... Ул шуларны берәм-берәм җыеп, ташып бетерде дә тынга калды. Аның фикеренчә, үлеге дә, яралысы да бу тирәдә башка юк иде.

Көн гаять матур, җылы. Август аеның янә бишенче көне иде. Ул үзенең тирләрен юар һәм бу авыр, сасы кан исләреннән аз-маз гына булса да котылыр өчен коенырга теләп, су эзләргә китте. Авыл эчендә коенырга яраклы андый-мондый су күренмәгәнгә, ул су эзләп авыл белән бер тоташта утырган урманлыкка кереп китте.

Бер-ике чакрым озынлыктагы бу урманлыкның сугыш дәһшәтен татыганлыгы егылган, сынган агачлардан күренә иде. Бу урманлык шактый гына юеш җирдә утырганга, Хөсәен фикеренчә, анда әлбәттә берәр күл, яхуд кизләү фәлән булырга тиеш иде.

Ерак та китеп өлгермәде, чыннан да, бер инеш янына килеп чыкты. Шатлыгыннан ул тиз генә чишенеп, чумып-чумып юынып алды. Таһарәтләнеп намаз укыганнан соң, мәрхүмнәр рухына хәтем дә багышлады. Хәтем укыганда аның күзләреп яшь басты. Шунда шәфкатьле әнисе исенә төште. Гүяки аның рухы монда бик якын, гүяки ул аны күреп тора.

Менә аның әтисе күзенә күренде, гүяки ул да ап-ак сакалдан, бөкрәйгән, ачлыктан күзләре төпкә баткан. Гүяки ул да бик якын, монда гына кебек тоела.

Ул шуларны уйлап күз яшьләрен сибереп алды, ләкин җиң очларын күзләреннән алып та өлгермәде, әллә кайлардан бер ыңгырашкан кебек тавыш ишетелгән кебек булды. Ул колагын салып янә тыңлап карады һәм ачы тавыш белән кычкырган тавыш янә ыңгырап китеп, ярдәмгә ихтыяҗ барлыгын белгертте.

Хөсәен тиз генә сикереп торды да тавыш ишетелгән якка китте. Озак та үтмәде, шул җиргә якынаеп, тавыш иясенең ыңгырашуын ап-ачык ишетә башлады. Ул инде төрле сугышларда йөри-йөри чыныгып беткәнгә, андый-мондый тозак, хәйлә-фәләннәрдән курыкмый иде. Ерак та бармыйча ул бөек бер фаҗига каршында катып калды. Ике урман арасында кискә кебек кире сунга яткан ике кулсыз, ике аяксыз хәлдә чия кан эчендә бер кеше! Хөсәен тиз генә аның янына йөгереп барып аны күтәрергә уйлады. Ләкин бөтен җире кан вә туфраклар белән болганып беткәнгә, тотар җире юк иде. Шулай ук аның киеменә карап, кайсы як гаскәре идекен дә танып әйтерлек түгел иде.

Хөсәен куллары белән аның яраларын тоткалап бакты да:

— Син маҗармы, алманмы, урысмы? — дип сорады.

— Миндә синең кебек үк урыс гаскәреннән булам. Бүген иртәнге һөҗүмдә туп ядрәсе төшеп, менә шундый хәлгә килдем. Зинһар, мине Алла ризасы өчен тиз генә ат, әрнүемә чыдар хәлем юк, — дип ул абауларга тотынды, газапланып чыраен сытты.

Хөсәен аңар шәфкатьле күзләрен терәп:

— Бездә бит алай эшләргә әмер юк... Менә мин сине яхшы гына күтәреп санитар вагонына кадәр илтәм дә, алар сине хастаханәгә озатачаклар, — диде.

— Юк, юк! Алай эшли күрмә! Мин синнән Алла ризасы өчен сорыймын, ат мине, — диде авыр яралы.

Хөсәен аның урысча авырырак сөйләшеннән, мөселман икәнен төшенде.

— Син мөселман икәнсең! Мин дә бит мөселман. Болай булгач минем кулым сине азарга бөтенләй күтәрелмәс. Мин сине мөмкин кадәр йомшак кул белән күтәреп лазаретка куячакмын. Рөхсәт ит! — диде.

Хөсәен бу сүзләрне татарча әйткәндә аны нигәдер зыр-зыр калтырау басты, күңелендә электән дә шәфкать хисе көчле булганга, аның битләре ут кебек янарга тотынды.

— Мин синнән сорыйм: ат та үтер мине... Без ике мөселман берберебезгә бәхиллек бирешә алабыз. Тик мине бу газаптан гына коткар! Өемә, зинһар, хат яз, үлгәнемне белдер. Менә түшемдә булганнарны да аларга җибәр. Шулай арасында өй адресым да бар,— диде.

Хөсәеннәң бу тартыш каршында көче бетеп, гаҗизлектән зиһене таралгандай булды. Атаргамы моны? Яки акыртып-бакыртып булса да санитар вагонынамы илтергә? Чыннан да бит бу бәхетсезнең хәле йөрәкне өтәрлек авыр. Аяксыз-кулсыз нишләр ул? Гаиләсе, якыннарының моның белән күрмешкә калулары гына түгел, гомер буйларына бу дөньяда яшәүләренең яме-тәме китәчәк. Ул гына да түгел, моның газабы, моның әрнүе бөтен күршеләренең дә йөрәкләренә тиеп, аларның да мәрхәмәт хисләре уянып тормыш ямьнәре югалачак. Бу бичараның үзенең әрнүе дә гомер барышлый җелеген киптереп, шул әрнүләрнең каргышлары, әлбәттә, миңамы тиячәк? Кулымда мылтыгым булган бер вакытта ник мин аны бу җан әрнеткеч бөек бер казадан коткармыйм? Бичараның соңгы өмете, соңгы теләге минем кулымда бит! Ә мин аны бу әрнүләрдән коткарып, аның мөбәрәк тәнен үземнең ару, пакь, тәһарәтле кулым белән соңгы юлына күндерәм дә, аның рухын тынычландырам. Йә аның бөтен гомерен, бөтен якыннарының гомерләрен агулыйм...

Аны каты тир борды.

— Атаргамы, атмаскамы?

Тагын ул уйга батты.

...Ничек иттереп мондый зур казага очраган бер бәхетсез мөселман кардәшне атып үтерергә кирәк? Нинди йөз белән мин аның өенә, угылыгыз сугышта үлде, аны үз кулым белән күмдем, дип хәбәр итим ди? Бу бит бөек ялган булачак! Ник миңа моны үзенең карышуына илтифат итеп тормыйча хастәханәгә озатмаска... Ни өчен ата-анасы, хатыны булса, хатыны аның бу киснә кебек калган гәүдәсен шулай гомер барышлый багып торырга авырсынырлар? Бу бит үз ихтыяры белән болай булган түгел. Тәкъдир язмышы. Бу бит ватанга бер корбан булу!

Ул шул ике бөек мәсьәлә каршында гаҗиз булып торганда яраланган кеше каты аваз белән үкереп-үксеп егъларга тотынды.

— Зинһар, мине тизлек белән ат инде. Чыдамыйм бит бу әрнүгә! Йа раббем, ник үзең алмыйсың тиз генә җанымны... котылдыр илаһи бу газаплардан... ал тиз генә җанымны! — диде.

Ул бу сүзләрне гүяки Хөсәеннән өметен кисеп, гүяки аңар ачуланып әйткән кебек булды. Аның кан катыш туфракка буялган күм-күк йөзе гүяки Хөсәенгә:

— Син кансыз, син вөҗдансыз! — дигән кебек күренде. Иксез-чиксез ике авыр мәсьәлә каршында катып калган Хөсәеннең куллары бәйләнде. Аның бер күңеле «ат!», бер күңеле «атма!» диде. Ул гүяки акыш-макыш иде.

Шул тартышулар белән үзен-үзе югалтып торганда, «ат» дигән бер тавыш ишетелгән кебек булып, ул тавыш Хөсәеннең үз анасының тавышына бик охшаган иде.

Хөсәен куркынып күккә карады. Күк йөзе гүяки саргылтсыман, кояшның нуры да гүяки тотылгандагы кебек сап-сары. Ул күзен урман түбәләренә төбәде. Анда да бар да сары иде. Гүяки урманның яфраклары да сап-сарылар. Әнә якындагы урман алдында үскән ялгызак биек имән агачы да сап-сары кебек.

Аның күзләре янә җиргә төште. Андагы үләннәр дә, аның камышлары да бар да сарылар. Әнә якындагы челт-челт агып торган чырылдакның суы да сап-сары... Аның кырыена гүяки сакчы булып тезелгән сирәк-сирәк ташлар да сарылар, шунда сикеренеп йөргән бакасы да сап-сары...

Хөсәен бу күренешкә шашып калды.

— Миңа соң ни булды? Бу фаҗигаләр бит минем көндәлек вазыйфам. Ни өчен соң мин бу җәфаларны күрәм? Атарга да моны, эшне бетерергә!

Аның бу фикерен куәтләгәндәй, янә күктән тавыш ишетелгәндәй булды, янә:

— Балам, әрнетмә инде аны! Коткар тизрәк бу бәладән! — дигән кебек булды.

Ул тагын күзләрен күккә терәде. Күк йөзе ап-ак киемле, ап-ак канатлы фәрештәләр белән тулган кебек, гүяки алар бу бичараның җанын ашыгып-ашыгып көтәләр кебек тоелды.

Аның күзе янә яндагы имән урманының башына төште, аның түбәсендә нәрсәдер селкенгән кебек, нәрсәдер җилфердәгән кебек күренде. Озак та үтмәде, ул урман өстендә ап-ак күлмәктән кайгылы бер хатын күрде. Аның ябык йөзе, хәрәкәтләре әллә ничек бик таныш күренгәнгә, Хөсәен шашуыннан айнып та өлгерә алмады, ул:

— Ат инде тизрәк! — диде.

Хөсәен бу тавыштан куркынып китеп:

— Әни, син икәнсең, — диде дә, калтырана-калтырана кулына мылтыгын алды.

— Әй, бичара кардәшем, вөҗданым куша сине атарга... Әниемнең мөбарәк рухы да куша сине атарга. Бир бәхиллегеңне газиз дустым, җәннәттә булсын синең урының... Миңа да анда шәфәгать кыл! — диеп, күзен йомып атып җибәрде.

Мылтык тавышыннан урман эче шаулап китте, куркынышып очкан кошлар тавышы да әллә ничектер бөек бер фаҗигагенең булып үткәнлеген, бөек бер вакыйганың дөньяга туганлыгын хәбәр иткәндәй булды.

Мылтык тавышыннан Хөсәен үзе дә сискәнеп китеп күзләрен ачты.

— Мин нишләдем, мин бит кеше үтердем! Мин бит яралы, гөнаһсыз, гаҗиз бер кешене үтердем! Йа Раббем, нинди җинаять кылдым мин! — дип акырып-акырып егъларга тотынды. Аның мылтыгы кулыннан төште, йөгереп үлек янына барды. Куркуыннан аны як-якка селкетеп: — Үлмәдең бит! Үлмә генә инде! Мин бит ихтыярсыз кылдым бу эшне, гафу ит мине, — диде. Ләкин ул бичарадан инде өн чыкмады, ул инде җансыз иде.

Хөсәен бу вакыйга каршында катып калып, яшьләрен себерә-себерә аның кесәсендәге өенә күндереләчәк әманәтләрен алып, моның кем икәнен тикшерергә тотынды.

Иң беренчегә аның кулына кулъяулыгы эченә бәйләгән бер төен эләкте. Ул бу төенне ачуы берлән серле бер вакыйга каршында куркынгандай куркынып китте... Калай рамкалы кечкенә генә бер көзге. Көзге уртасында тутыккан тонык бер җире бар. Бу көзге аңар ничектер таныш кебек күренде. Кайда күрде икән ул аны? Күн капчыгы эченнән Исме әгъзам догалыгын, тузып беткән иман шартын чыгарды. Ник соң болар мондый танышлар, кая күрде икән соң ул аларны? Йә рабби, бик танышлар бит болар!

Аның куллары калтырый башлады. Ул тиз генә авылдан килгән хатларны тикшерергә тотынды.

— Йә Раббем! Язуы да, күк карасы да, кәгазе дә, конвертлары да... бар да таныш бит. Аның йөрәге жу итеп китте. Тиз генә үзенә авылдан килгән хатларны кесәсеннән чыгарды. Ару бер төсле... тәмам шулар! Алла! Ходаем! Әллә... юкса... Зыр-зыр калтырый-калтырый ул моның авыл адресын эзләргә тотынды. Кул-аягы бөтенләй бәйләнгән кебек булса да, адресны эзләп табуга үлек өстенә ап итеп егылды. Чөнки бу — аның үз туганы Габдулла иде.

Ул каты аваз белән уларга тотынды. Үз туганымны үзем үтергән икәнмен, Йа Раббем! Нинди йөз белән өйдәгеләргә күренермен? Ничек итеп карт атам каршына барырмын? Ничек мин аның хатынына күренер-

мен? Ничек мин аның үксез калган бәхетсез баласын йөрәгемә басармын? Йа Раббем! Ал минем дә җанымны, дип, үксеп-үксеп егъларга башлады.

Ул егълый-егълый күккә бакты. Янә шул имән урманы башында шат йөзле анасын күрде. Анасы аңар кулларын җәеп:

— Кил, балам, син дә! Дөнья ул бәхетсезләр йорты бит. Анда кан, анда яшь, анда әрнү... Анда золым... Анда адәм каны гөнаһсызга түгелә... Мин синең алар арасында булуыңны теләмим. Кил, йөрәгемә басыйм! — диде.

Хөсәен әнисен күреп: «Әни!» — дип кычкырып алды. Шул кычкыруларга ялганып ук улап килгән бер туп ядрәсе Хөсәеннең өстенә төште.

Хәзер генә вөҗдан газабы белән мөгаззәб булган Хөсәеннең бөтен гәүдәсе кисәк-кисәк тетелеп күз ачып йомганчы юк булды. Икенче бер туп ядрәсе ялгызак имән агачы өстенә төшеп, аны да төбе белән куптарып бәрде.

Яңа һөҗүмнәрнең башлануына ишарәт иде бу.

Әсәрне матбугатка әзерләү, искәрмәләр һәм кереш сүз **Илбарис НАДИРОВ** тарафыннан башкарылды.



## Нәҗип Мәдияров

### Сүз тәэсире

Килеп кайчак, дөнья ямен боза
Эч пошулы авыр минутлар.
Андый чакта гүя каплап тора
Күңел күген кара болытлар.

Бу афәтне нәрсә китерә соң?
Җан өшеткән мәкер тулы сүз...
Бу афәтне нәрсә бетерә соң?
Җан җылыткан назлы, җылы сүз.

### Малай

... Нидер ясый:
Маңгаена хәтта
Бәреп чыккан
Тир бөртеге...

Малай гынамы соң?
Түгел, ул бит —
Ни әйтсәң дә —
Ир бөртеге!

---

Нәҗип МӘДИЯРОВ (1928) — *шагыйрь, «Чык бөртекләре», «Чәчәк күрдем», «Йөз төрле уй» һ.б. китаплар авторы. Проза әсәрләре дә яза. Чаллыда яши.*

## Ахыр чиктә

Төшә Кояш офык өслегенә,
Көн буенча балкып, нурланып...
Баеганда алтын шарга охшап,
Күренә ул шактый зураеп.

Арабыздан кайчак шәп дус китә,
Моң тудырып. Һәм шул чагында
Кешелеге, олы җанлылыгы
Ачык күренә бит аның да.

## Үткән чор авазы

Чабата, башмак ясаулар беткән бит!..
Урманга да бу хәбәрне илтәләр...
Ул күп агачларга тәэсир итмәде,
Әмма сөенеп туймады юкәләр.

## Яраланган мәхәббәтем белән

Гыйшык уты һөҗүменә бермәл
Баш-аягым белән эләктем.
Һәм мин сөю империясендә
Әсирлеген тойдым йөрәкнең.

Акты гомер. Хәзер ул чордагы
Хәсрәтләрдән качып, шыкланып,
Яраланган мәхәббәтем белән
Гашыйкларга карыйм сокланып.

## Бер дус менә миңа ни сөйләде

Хамелеон күк, йөзен алыштырып
Йөргән икән дошман, дус булып.
Ә гомерлек диеп сайлаганым
Булып чыкты фәкать буш куык.

Шуңа аны мин сугышсыз бирдем,
Мәңгелеккә диеп чигендем.
Юлыксам да язмыш афәтенә,
Хыянәтне җиңеп сөендем.

Бәхетлеме, бәхетсезме алар?
Һич кенә дә анда эшем юк.
Чөнки минем хыянәтчеләрне
Кызганырлык җылы хисем юк.

## Кышкы әкият

Үткәннәрне искә алып,
Киләчәгемне уйлап,
Авылдан китеп барышым,
Карлы кыр юлы буйлап.

Каршыдан исә ачы җил,
Йөземә өрә-өрә.
Ул ахры китмәскә куша,
Кире борыл, ди гүя.

Юк, хәтерем калмый аның
Кисәтү ясавына.
Читкә китеп яшәдем ич,
Аңардан башка гына.

Кыш сулышы — и җилкәем,
Үпкәләвеңне оныт!
Туган як хисле җанымны
Салкының белән җылыт!

## Башың нигә иде икән?

Сандугач сарый, өзләрә,
Меңнәр күңелен яулый.
Ә башы иелгән берәү
Аңа колак та салмый.

И тормыш! Миңа, берүк — ул
Кеше язмышын бирмә;
Сандугач җырын да тыңлый
Алмаслык итә күрмә!

## Үзгәргәнсең

Елмаеп бирдең кулыңны,
Кайткан юлымда очрап.
Бу минем өчен гаҗәп һәм
Сәер тоелды ифрат.

Киткән чакта киресенчә,
Карадың каш җыерып.
... Минем кул һавада ялгыз
Торды бит асылынып.

Уйлагансыңдыр: моның, дип,
Йөргә телгәләнсен...

Яхшыгамы, ямангамы?—
Димәк син үзгәрәсең.

# Әхмәт Саттар



## Күздән бер мизгел

Күзге күксел томаннарда
Кошлар җыена юлга...
Кибәннәр йоклый болында,
Офыкка болыт кунган.

Миләш кызыл алка таккан,
Нарат карыша җилгә...
Яшь усактан — карт яфраклар
Елыша дымлы җиргә.

Күксел күзле көзем яна,
Тынлыкта ялан, урман.
«Язга тикле хуш!»,— дип әнә
Кычкырып үтә торнам...

## Сабан туе

Сабан туе, Сабан туе —
Халык белән мәйдан тулы.
Сабан туе, Сабан туе...
Җырлый урам, сайрый урман.
Бие, җырла — безнең заман!

Сабан туе — көрәш туе,
Көләчлектә ярыш туе.
Шулай булган гомер буе:
Иң батырга сайрый кошлар,
Иң батырны сайлый кызлар!

---

Әхмәт САТТАР (1943) — *җырлар, шигырьләр авторы. Мәскәүдә яши.*

* * *

Тиргәмә син сабый баланы,
Әйткәнеңне отып калмаса:
Савытларга нинди су салсаң,
Эчтәлеге шулдыр ләбаса.

* * *

Чыбык салсаң гына учак яна,
Юмарт өләш син дә җылыңны:
Кешеләргә бүләк итәсе нур
Яктыртачак барыр юлыңны.

* * *

Данлыйсың узган көннәрне,
Яшисең үткәннәр белән.
Сабак ал син бер чишмәдән:
Суы кипкән, җаны үлгән...





Казан утлары
китапханәсе
ЯШӘР КАМАЛ
БОЛАН РИВАЯТЕ

## Яшәр Кәмал

# БОЛАН РИВАЯТЕ

*Яшәр* КӘМАЛ *(1922) — төрек әдәбиятының күренекле әдипләреннән берсе. Аның иҗаты бөек Табигатькә, барлык җан ияләренә, бигрәк тә яклауга мохтаҗларга карата җылы мәрхәмәт, изгелек нуры белән сугарылган. Язучы хыял белән чынбарлыкны, тормыш хакыйкате белән сәнгать дөреслеген оста аралаштыра. Ул Җирне бәркет очкан биеклектән күрә белә, аның үткен карашына һәрбер үләне, һәр куагы, һәр тереклек иясе белән бергә дала киңлекләре, мәгърур таулар сыйган.*

*«Тормыш ул — ярларыннан ташып, алга ыргылучы һәм үз агышын туктаусыз үзгәртеп торучы елга, әнә шушы тормыш агымының бер генә үзгәрешен дә күздән ычкындырмау — язучы өчен фарыз...» — ди Яшәр Кәмал үзе.*

*Бүген журнал укучыларыбызга тәкъдим итела торган әсәре Яшәр Кәмал иҗаты белән генә түгел, төрек әдәбиятындагы матур бер агым белән танышырга да ярдәм итәр дип уйлыйбыз.*

Хәлил, атына атлану белән, карт әнкәсе тезгененә килеп ябыша:

— Йөрмәсәнә, балакаем, шул сунарыңа! Газаплама, зинһар, җанымны! Атаң шул ауга йөреп кенә хараплар булды, син дә шулай булмагаең. Алла тотар, балакаем, нәселебез корыр, бетәр, — ди.

Хәлилнең күңелен икеләнү биләгәнне күреп, ана кеше тагын да ныграк үгетләргә керешә:

— Ниемә кирәк инде сиңа шулчаклы болан? Аларның тиреләрен кая куеп бетермәкче буласың? Болай да үзеңне, атаң шикелле үк, өнәп бетермиләр, көнләшәләр. Болан башына житү — юньлегә илтми, дигән борынгылар. Бәлагә тарырсың, балакаем, күңелем сизенә.

Егет, икеләнү хисеннән арынырга тырышып, ерактагы тауларга, ак болытларга, югарыда тулганучы кошларга кызыгып карап тора. Әнкәсе тезгенне һәмишә җибәрми дә җибәрми. Аптырагач-йөдәгәч, Хәлил ат өстеннән иелә дә, әнкәсенең чәчен сыйпап:

— Җибәр инде тезгенне, югыйсә соңга калам. Дусларым көтә булыр, — ди.

— Бирәү дә көтми сине, белеп торамын. Бик барасың килә икән инде — бар соң. Мәгәр ишетсен колагың: ана боланнарның үзләренә дә, аларның сабыйларына да тия күрмә. Югыйсә афәт китерерсең өебезгә, ялгызак итәрсең сөйгән ярыңны.

Әнкәсе тезгенне җибәрүгә, Хәлил чаптырып китеп тә бара.

Тарыс тауларында өйләр берән-сәрән генә урнашкан. Хәлилнең ярәшкәне Зәйнәпләр өе — Гөкдәр авылының түбән очында. Капка төпләрен-

---

Журнал өчен бераз кыскартып тәржемә ителде.

дә үк карт чинар үсеп утыра. Ат тоягы тавышын ерактан ук ишетеп, чибәркәй сөенә-сөенә каршысына йөгерә, чинар ышыгыннан килеп чыга да сөйгәненең кочагына атыла торган иде. Бу юлы да нәкъ шулай каршылый. Тик менә аерылган чагында бигрәкләр инде өздереп карый. Моңарчы болай караганы булмаганга, егет хафага кала.

— Ни булды, сөеклем?— ди дә сылукайны кысып кочаклый.

Гәрчә күзен алмаса да, сөеклесе бераз көттереп кенә телгә килә:

— Хәлил бәгырем, бармасаңчы шул сунарыңа. Картлар әйтәләр бит, юньле кеше болан атамыни, диләр. Боланга кул күтәргән кешенең җаны рәхәт күрми, диләр.— Шуннан кызның бугазына нидер бөялә, әмма ул үз-үзен кулга ала.— Ниемә кирәктер инде ауга йөрүең? Әйтерсең лә ансыз яшәп булмый инде?

Хәлил көлемсери генә. Менә хикмәт, әнкәсе дә, сөйгән яры да ай буена ауга җибәрмәскә маташалар. Кеше сүзенә карап, ауга бармаскамыни инде?

Сөеклесе тәмам боегып кала:

— Мине яратмавың шушыдыр инде, Хәлил. Ауны артыграк күрәсең ич,— ди.

Сөйкемле күзләрендә яшь бөртекләре җемелди. Егете янә дә көлемсерәп куя. Ауга йөрүне шулай ук сөйгән ярыннан артыграк күрә микәнни? Моңарчы андый уйның башына килгәне булмады, ул фәкать үзенең ауга йөрми-нитми генә яши алмаганын яхшы белә.

— Хәлил бәгырем, бигрәкләр начар төш күрдем бит әле...

Кыз ике учы белән йөзен каплый да, хәлсезләнеп, җиргә сыгылып төшә. Хәлил аны күтәреп торгыза, ипләп кенә чинар төбенә утырта да атына сикереп менеп атлана.

... Көннәрдән бер көнне Гөкдәр буйлап күрше Сарыҗалы авылының бае Караҗали узып бара. Хәлилнең ярәшкән кызы Зәйнәп шул чагында чишмәдән су алып тора икән. Шундый чибәр кызны бер күрүдә гашыйк була бай. Кыздан ул су эчертүен үтенә. Эчертә кыз. Бай эчә дә:

— Суың тәмле икән, үзең әле тагын да татлыраксыңдыр,— дип теленә салына.

Өенә кайту белән, әлеге кызның кем икәнен белергә кеше җибәрә. Йомышчы ул кызның өч абыйсы барын да, Хәлилгә ярәшкәннәрен дә белеп кайта. Моны ишеткәч, Караҗалинең җен ачулары чыга. Абыйлары кулыннан тартып алуы авыр булмас иде, тик менә Хәлилдән ничек котылырга?

Шул очрашудан соң Али бай Гөкдәргә көн саен бара да анда кызның чишмәгә килгәнен көтеп ала, эчәренә су сорый. Зәйнәп хафага төшә.

— Синең кем икәнеңне белмимен, тик миңа бәйләнмәвең хәерле булыр. Өч абыем, вәгъдәләшкән егетем бераүдән дә рәнҗеттермәсләр,— дип белдерә.

Эчәренә су да бирми. Али бай чүмеч тоткан килеш ымсынып кала. Яман зәһәрләнеп:

— Мин моны болай гына калдырмыйм әле. Ярәшкән егетеңнән сугып ала алмасам, исемем Али бай булмасын!— дип лаф ора.

Өенә кайту белән, аттан төшүгә:

— Хәзер үк Дүрмешне табып китерегез!— дип әмер бирә. Үзе таш кебек атылып өй түрендәге зур агач күләгәсенә барып утыра. Зәһәренә чыдый алмыйча, нишләргә дә белмичә, эскәмиядә шактый утыра.

Ул арада Дүрмеш ага да килеп җитә. Баена сүз кушып карый — теге ишетми. Кабат-кабат әйтә торгач кына, башын күтәрә.

— Ә-ә-ә, килдеңме?— ди.

— Нигә кирәгем булды икән, дип торам әле.

— Булды шул. Четерекле бер эш чыгып тора бит әле, Дүрмеш ага. Син Гөкдәрдәге Хәсән мәрхүмнең улын беләсеңдер инде? Ничек булса да котыласы иде шуңардан. Берәр җаен тапсаңчы, Дүрмеш ага.

Картлач уйланып тора-тора да:

— Бик ансат ич аның жае,— дип куя.

— Ничегрәк итик икән соң?

— Ул егет кече яшьтән сунарчылык белән һәвәсләнеп киткән. Кенен-төнен урманда болан атып йөри. Айлар буена кайтмыйча шунда ята. Сагалап торуы бик ансат. Урманга күмәсең икән, кем үтергәнен гомердә дә белмәячәкләр.

Каражалиның йөзенә елмаю куна.

— Рәхмәт яусын, Дүрмеш ага. Киңәшеңне тотып карыйм әле. Кайларда нишләп йөргәнен күзәтергә берәрсен җибәрермен дә, нишләргә икәнен ахырдан карарбыз.

...Хәлил, гадәттә, дус-ишләре белән бергә тауга менә икән дә атын иреккә җибәрә икән. Гарәп тулпары уңга-сулга борылмыйча, өенә кайта да китә икән.

Ул заманнарда Тарыс тауларында болан хәтсез күп йөри. Гәрчә болан ату зур гөнаһка саналса да, болан итеннән берәү дә йөз чөерми, киресенчә әле, сарык яисә кәҗә итеннән артыграк күрә. Берәр егетауга чыгып, буш кул белән кайтса, аның начар даны бөтен тирә-якка тарала, аңа кыз бирүче дә булмый.

Ауга күп кеше йөри, тик инде берәве дә Хәлилдән уздыра алмый. Ул бүтән бер генә шөгыльне дә бар дип тә белми. Әнкәсе, ярәшкән кызы, барча авылдашлары аның өчен ут йотып торалар...

Көннәрдән бер көнне Али байның йомышчысы кайтып төшә.

— Каракош кыясына Хәлил бүген ялгыз башы китеп барды. Хурҗинын дыңгычлап тутырган, озаклап ауда йөрергәдер исәбе. Аның бит өчәр-дүртәр атна йөргән чаклары да була. Каракош кыясы төбендә сагалап торыйк та эшен бетерик.

Али байның шатлыгы эченә сыймый.

— Ни әйттең иде дә бит...

Атларга атланалар да юлга чыгалар. Ике көн дигәндә Каракош кыясына барып җитәләр. Манара кебек текә биек кыялар күккә ашкан, аста куе урман җәелеп киткән, анда болан көтүләре утлап йөри. Кызгылт таш кыяларның арасында аланнар яшәреп күренә. Ак болытларга якын бөркетләр күкне гизә. Алар ояны да иң биек кыяларга коралар икән.

Али бай үз иярченнәренең берсеннән:

— Гомәр, теге мөртәт бүтән юлдан китмәс микән соң?— дип сорап куя.

— Башка җирдән аңа юл юк.

— Дүрмеш ага, син ничегрәк уйлыйсың?

— Бүтән юл юк. Мин бит бу якларда утыз ел ауга йөрдем, аяк басмаган ташым калмагандыр. Шушыннан узачак ул, шушыннан.

Көн дә көтәләр моны, төн дә көтәләр. Хәлил күренми дә күренми. Али бай сабырсызлана башлый:

— Кая китеп олакты икән инде? Юкка вакыт уздырмагаек,— дип сөйләнә.

Дүрмеш ага аны:

— Кайгырма юкка. Сунарчылар бит алар болан эзеннән озаклап йөрүчән. Теге хәчтерүш тә шушы тирәдә йөридер әле,— дип юата.

Хәлил исә үзенә нинди афәт янаганын белми-абайламый. Савырына шапылдатып суккач, аты өйгә элдертә. Егет хурҗины белән мылтыгын кедр ботагына элә дә ылыс исләрен, бөтнек исләрен күкрәк тутырып сулый, бераз башы әйләнеп киткәндәй була. Шуннан ул агач төбенә, коры җиргә сузылып ята да өстенә болан тиресен ябына. Йокысын туйдырмыйча ул ауга тотынуны хупламый.

Хәлилнең әле әнкәсенә биргән вәгъдәне моңарчы бозганы юк: нәнием иярткән боланны күргәндә мылтыгын иңеннән алмый.

Таң беленеп килгәндә ул уянып китә, мылтыгы белән пистолетын барлап куя. Андагыдай мылтык бу якларда беркемдә юк. Шуны иненә

сала да Каракош ягына табан юллана. Хәвеф-хәтәрне уйламый да, күңелендә — фәкать боланнар да сөйгән Зәйнәбе. Җырламас җиреңнән җырларсың.

Аның җырын ишетеп, Али бай:

— Шым булыгыз! Хәзер килеп чыга,— дип пышылдый.

Байның яраннары кайсы кая поса, бай үзе җиргә сеңәргә җитешә. Беравыктан ул:

— Нишләптер күренми әле,— дип куя.

— Бездән ерак әле ул. Тавышы куәтле, шуңа якында булып ишетелә. Әйләнеч юлдан килә шикелле.

Иңгә-иң дигәндәй, тезелешеп яталар, һәркайсы чакманы тартырга әзер. Хәлилгә берсенең дә үче юк югын, тик менә байга ярарга тырышып, аның башына җитәргә тиешләр. Уйлап карасаң, хәтәр эш инде, хәтәр...

Җыр якынайганнан-якыная бара, йә таш кыяларга бәрелә, йә җир өстенә җәелә. Күпме куаныч бит бу җырда — Кояш, таулар, җир-су, үлән-чәчәк белән кавышу куанычы. Шик-шөбһәнең эзе дә юк бу җырда. Тау елгасыдай иркен, агыла да агыла...

— Ачу китереп җырлаган була бит әле! Бик озак җырлый алмассың...

Берзаман Али бай үзенең иярченнәренә:

— Башы күренде!— дип пышылдый.— Әйбәтрәк күренгәч, һәммәгез дә атыгыз, йөрәгенә төзәгез. Әнә генә ич, күрәсезме? Кәкре агачны узгач та...

Тау сукмагы уртасында үсеп утырган, иләмсез дәү еланга охшап кәкрәеп беткән олы, карт агачны әйләнеп узуга, тугыз-ун адым ясауга, Хәлилнең гомере өзеләчәк — йөрәгенә әллә ничә ядрә кадалачак.

Нәкъ әнә шул мизгелдә Хәлилнең аяк астына югарыдан бер таш килеп төшә. Егет башын күтәреп караса — биек кыя өстендә текә мөгезле болан икән лабаса!

Егет шул якка тайпыла, боланга әйләнгән сыман, тавыш-тынсыз гына, кызу-кызу таш кыяга менә башлый. Ә үзе мәһабәт гәүдәле боланнан күзен дә алмый. Тегенең качарга исәбе дә юк сыман, аучыны якын ук җибәрә. Менә гаҗәп! Янына килеп җитәргә дә күп калмый лабаса!

Али бай исә, көтә-көтә көт булып, җирдән калкына.

— Нәрсә, безне күрде микәнни?

Али байның яраннары арасында дөнья күргән, бу тауларны яхшы белгән, хәтәр-шикле Мустан чавуш атлы бер бәндә дә була. Шул:

— Монда нидер бар, ага. Үлемнән бер-ике адым коткарып калды үзен. Әҗәле җитмәгәндер. Язмышка каршы бару ярамас,— дигән фикер әйтә.

Али бай:

— Шаштың мәллә? Нинди язмыш ул тагын? Менә бу дивана, бүтән юл юк, дип башымны катырмаса, тегендәрәк сагалаган булыр идем. Чәнчелеп кенә китсен инде!— дип гайрәт чәчә.

Дүрмеш карт:

— Ачуланма инде, ага. Монда чынлап та башка юл юк. Кем белгән бит аның сукмактан читкә каерасын?— дип акланып маташа.

Али бай:

— Торыгыз! Артына төшәбез,— дип әмер бирә.

...Ул арада Хәлил боланга якын ук килә дә, мылтыгын иңеннән алып, төзи дә башлый. Чакмага басам гына дигәндә, болан түбәнгә томырыла. Аның яшен тизлеге белән күздән югалуына Хәлил аптырап кала.

— Бигрәк сәер инде бу болан!— дип үзалдына сөйләнә.

Болан артыннан аучы да аска томырыла. Ул арада теге мөгезбай икенче кыяның башына менеп өлгергән булып чыга... Аучыны шулай кызыктырып, юри ияртеп барган кебек, мөгезбай әллә кайларга ияртеп алып китә...

Үз чиратында Хәлил дә бит, яраннары белән бергә, Али байны әллә кайларга ияртеп алып китә. Боларның тәмам котлары алына. Малай-шалай артыннан чабу сиңа бер дә килешми, кызны яучылап алудан да яхшысы булмас дип, байны кайтырга күндерәләр.

Гәрчә бөтен авыл каршы торса, каһәрләсә дә, абыйлары Зәйнәпне байга бирү ягын каералар. Али бай әллә кайлардан киндерен, ефәген, бизәнү әйберләрен кайтартып, кызга бүләкләр җибәрә. Ярәшеп тә куялар.

Ул арада Хәлилнең әнкәсе белән сеңелесе, елый-елый күзләре шешенеп беткән Зәйнәп егетне түземсезлек белән көтәләр. Хәлилнең киткәненә ике атнадан артык вакыт узды, ә ул кайтмый да кайтмый. Шуннан авылның ун егете аны эзли чыгалар. Тау араларында сөрән салып ике көн йөриләр. Фәкать өченче көнне генә аучыны табалар. Ерак-еракта бер мәгарәнең эченә болан түшкәләре тутырган, дивар буена чөйләр кагып, шунда тиреләрен кибәргә элгән.

Дусларын күргәч, Хәлил:

— Килеп яхшы иттегез бит әле, югыйсә боларны ялгызым ничек алып кайтыр идем,— ди.

— Киткәнеңә байтак вакыт узды лабаса. Артык озаклагач, эзли чыктык менә. Ике тәүлек эзләдек үзеңне. Бу чаклы ерак китәрсең дип уйламаган идек.

Хәлил:

— Мине бер болан алып килде бит,— дип, теге сәер хәлне сөйләп бирә.— Сихерләнгәндәй, үземне болан көтүлекләренә ияртеп алып килде лабаса. Аучы аягы басмаган бу якларга! Боланнар кача да белмиләр. Теләсәң иллене, теләсәң йөзне атып ал.

Хәлилнең ваемсызлыгына дуслары шаккаталар. Башларында кайгылы уй: ярәшкән кызын ятлар сугып ала, инде ни хәл итәргә?

Хәлил үзләренә:

— Нишләп чырайларыгыз бик төксе әле? Берәр яман хәл-мазар булмагандыр бит? Минем табышка да куанмадыгыз. Әйдә, күтәрегез дә икешәрне, киттек авылга. Болай күп атып кайта алганнары юк иде әле берсенең дә. Нигә куанмадыгыз әле? Нигә эзләдегез әле?— дип бәйләнә.

Егетләрнең берсе:

— Анаң бик борчылды, артык озаклагач. Картлар әйткәч, килмичә булдыра алмадык,— дип җавап бирә.

Хәлил көлә генә:

— Килеп яхшы иттегез әле. Ялгызым һич алып кайта алмаган булыр идем,— ди.

Егетләр җилкәләренә икешәр-өчәр түшкә салалар да кайтыр юлга чыгалар. Алай да алып бетерә алмыйлар әле. Киек җанварлар тимәгәе дип, мәгарәнең авызына таш өяләр.

Кайтып җиткәнче юньләп сөйләшмиләр. Нәрсә генә әйтсеннәр соң Хәлилгә? Өйгә кайтып җиткәч, нәрсә генә эшләр инде? Дусларының күңелләрен күтәрергә теләп, Хәлил генә юл буе сайрап кайта, күңелле җырлар җырлый. Аның берни белмәве, кәефенең күтәренке булуы тегеләрне тагын да ныграк төшенкелеккә дучар итә.

Авыл сунарчыны шомлы тынлык белән каршы ала. Хәлилнең коты алына. Аның кайтуына беркем сөенми, очраган бере тизрәк өенә кереп яшеренү ягын карый. Элекләре һәммә кеше сөенер иде, мәйданда аның хөрмәтенә бәйрәм итәрләр иде.

Коты алынган, тәмам чыгырыннан чыккан егет мәйданга юнәлә. Анда бер генә җан иясе дә күренмәгәч, җилкәсендәге йөген чирәмгә ыргыта да өенә йөгерә. Әнкәсе ишек төбендә була, аны күргәч тә, өйгә кереп китә.

— Нәрсә булды, әнкәй? Мин югында авылыбызга нинди афәт ябырылды?

Карт ана идәнгә сыгылып төшә, үксеп-үксеп еларга тотына. Хәлил аңардан берни әйттерә алмый. Шуннан соң сөеклесе янына ашыга. Зәйнәпнең агалары аны дәшми-тынмый гына каршылыйлар. Илгә нинди афәт килгәнен алардан да белә алмый. Иң якын дусты Дуран булып, ул да авыз ачып бер сүз әйтми. Өйлә вакытлары җиткәнче егет өйдән-өйгә атылып керә, әле берсеннән, әле икенчесеннән сорашып белмәк була. Нишләгәннәр икән соң аның авылдашлары? Әнкәсе дә, Зәйнәп тә, дуслары да ник берни әйтмиләр?

Мәет чыккандагыдай, авыл тынып кала: ни сабыйларның елаганы, ни олыларның сөйләшкәне, ни кошларның сайраганы ишетелми. Шомлы тынлыкны бозарга фәкать картаеп, тәмам бөкшәеп беткән Солтанкәрә исемле карчык кына җөрьәт итә. Егетне үзе эзләп таба да:

— Нәрсә, тилекәем, ниләр булганын миннән гайре сөйләп бирүче дә юкмыни үзеңә? Син тау араларында йөргән чакта монда синең Зәйнәбеңне кодалап өлгерделәр ләбаса. Күрше авылның Али бай дигән хәсисе, имештер, бер күрүдә гашыйк булган да яучылар җибәргән. Шуңа ярәштеләр инде менә...— дип тезеп китә.

Хәлилнең авыз ачып бирәр сүз әйтерлеге дә калмый. Кортка сөйләвен белә:

— Мәргән, әллә инде тораташ булып катып калдың? Аптырама, бирәр җаен табарбыз әле. Теге хәсис Зәйнәбеңне алып китмәгән бит әле. Син тот та дусларыңны монда алып кил. Әйтәсе сүзем бар үзләренә,— ди.

Хәлилнең буйсынмый хәле юк. Озакламыйча авыл егетләре кортканың өенә җыелалар. Аның әмере белән өйдә учак тергезеп, болан ите кыздыралар. Әмма өстәл янына утырышкач, ник берсе ризыкка үрелсен. Солтанкәрә үзләренә:

— Егетләр, әллә инде Хәлил атып алып кайткан боланнар итеннән авыз итәсегез дә килмиме? Ояттыр шул. Ичмасам атларыгызга атланыр идегез дә Зәйнәпләргә барып, агаларының йөзләренә төкерер идегез, Али бай китергән бүләкләрне, аның балдагын алыр идегез дә үзенә Сарыҗалыга илтеп, мөртәтнең аягы астына ташлар идегез,— ди. Хәлилнең җан дусты Дуранга карап:— Нәрсә, Дуран, куркып калырсыңмыни?— ди.

Егет ни әйтерен тапмый.

— Алайса, Хәлил мәргән, әлеге эшне үзеңә башкарып чыгарга туры килә. Үзең тәвәккәл икәнсең, кыю икәнсең — бүтәннәр дә иярер. Шүрләп калсаң — яклаучы таба алмассың. Күреп торасың бит, Дуран булып Дуран да куркып калды. Яклаучың юк икән, ул чагында балдакны үзең илтеп, Караҗалының танавына ыргытудан башка чара калмый. Шушы юлда җаныңны фида кылуың да ихтимал. Әдәм мәсхәрәсенә калганчы — үлгәнең артык. Ул сантыйның кем икәнен йөзенә бәреп әйткәнең хәерле булыр.

Солтанкәрәнең әйткән сүзләре Хәлилне дәртләндереп җибәрә. Шуннан ул тәвәккәл-нык басып өенә табан юллана. Аның артыннан тасраеп карап калган Дуран да урыныннан кузгала. Аңа ияреп бүтәннәр дә өйләренә ашыгалар. Икәве-өчәве генә урыннарыннан кузгалмый. Кортка аларга мәсхәрәле карашын ташлап:

— Батыр егетләрем нишләптер ашыкмый бугай?— дип куя.

Шуннан соң болары да кузгалышырга мәҗбүр булалар.

Озакламыйча авыл мәйданы җайдаклар белән тула. Егетләр генә түгел, яше-карты, малай-шалай һәммәсе атка атлана.

Мәргән ярәшкән кызының өенә табан юл тота. Зәйнәпнең абыйлары караңгы чырай белән чинар күләгәсендә утыралар икән. Алар Хәлилнең юлына аркылы төшмиләр. Зәйнәп үзе котлары алынып, күз яше түгеп өй эчендә утыра икән. Егет аның кулын учына ала. Кызның кулында никах балдагы, муенында муенса-мазар күренми. Егет кырыс кына:

— Караҗалының бүләкләре кайда?— дип сорап куя.

Кыз шыпырт кына:

— Тартмада,— дип җавап кайтара.

Хәлил тартмадагы алтын-көмеш бизәнү әйберләрен алып, кесәсенә шудыра.

Бу вакытны Солтанкәрә дә килеп җитә, чинар күләгәсендә боегышып утырган өч туганга юлыгып:

— Нәрсә бик җәелеп утырасыз әле? Ир-ат халкы барысы да атка атланды — Караҗалига никах балдагын илтә баралар. Сез ни көтәсез монда? Куркак хатыннар кебек утырмагыз, атларыгызга атланыгыз!— дип җелекләренә үтә.

Туганнар бер-беренә карашып алалар да арандагы атларын чыгаралар.

Җайдаклар авылны чыкканчы карт-коры аларны хуплап:

— Йөрәкле икәнсез, егетләр!

— Хатаны төзәтеп була әле, була!

— Нык торыгыз!— дип озатып кала.

Иң алдан Хәлил бара. Авылны чыгу белән, ул, атын ныграк куып, шактый алга китеп өлгерә. Аты җилдәй оча. Башкалар көчкә җитешәләр. Сарыҗалы авылына да Хәлил чаптырып барып керә: дошманы янына ялгыз башы якынаерга ярамаганын да уйлап тормый. Тузан туздырып килүче дуслары еракта кала. Мәргән йортка җитеп атын туктата да:

— Али ага, монда чык әле!— дип тавыш бирә.

Шылт иткәннәре дә ишетелми.

— Али ага! Али ага!

Караҗали иренеп кенә:

— Кем бар анда? Кирәгем булса, өйгә кер, өйдә сөйләшербез,— дип җавап кайтара.

— Юк, син үзең чык! Син безгә монда кирәк!

Бу чаклы әрсезлеккә исе китеп, хуҗа болдырга чыгып баса. Хәлил аның бүләкләре төрелгән төенчекне аягы астына ыргыта.

— Али ага, бу чүп-чарың үзенә булсын! Аңарга мохтаҗ кеше юк. Син илтеп биргән кешеләр, безгә синең бүләкләрең кирәкми, дип әйтергә куштылар.

Хуҗа сабыр гына төенчекне алып чишсә, анда ниләр ятканын күреп, чырае кара янып чыга, төенчектәге нәрсәләре болдырга коела. Никах балдагы зыңлап идәнгә төшә дә почмакка тәгәрәп китә. Шунда гына хуҗа, сантыйланып, аның каршысына килүченең Хәлил мәргән икәнен абайлап ала. Күз ачып йомган арада мылтыгын да алып чыга. Мондый хәлнең булу ихтималын алдан ук сизенгән егет исә атыннан сикереп төшә дә өй почмагына яшеренә.

— Ага, син мәкерле эшкә тотындың. Үз өенең бусагасы төбендә бәдбәхетләр генә кан коя. Куркып качуым түгел, кем икәнеңне әйтеп бетерим, дип яшерендем. Бәдбәхет икәнсең ләбаса! Хәзер инде атсаң да ярый,— дип, егет яшеренгән җиреннән ялт кына чыга да атына сикереп менеп атлана.

Хуҗа аптырашта кала. Акылын җыеп, атып җибәргәндә, Хәлил инде еракта була, аңа ядрә тими кала.

Караҗали ачуыннан шартларга җитешеп өенә керә дә кәнәфигә йөзтүбән капланa. Шактый вакыт кыймылдамый да ятканнан соң:

— Мустан чавуш белән Дүрмешне, аннары тагын Гомәр Диванаиы китерегез,— дигән әмере ишетелә.

Чакыргач, килми хәлләре юк, киләләр. Утырулары була, Мустан чавуш:

— Әңгәмәгә Сөләйман аганы да чакырттырасы иде,— дигән теләк белдерә.

Али бай каршы килми, картны алып килергә кеше җибәрә. Хаҗины дәшми-тынмый гына көтәләр. Әле ул килгәч тә, сүз алай тиз генә

ялганып китми. Бер-беренә кырын карашып, төксе чырай белән утыра бирәләр. Сүзне хуҗа кеше үзе башлап җибәрә:

— Сөләйман хаҗи, менә күрдеңме инде минем нинди хурлыкка төшкәнемне? Синең аркада шул көнгә калдым,— ди.

Картлач моңа каршы:

— Анда минем ни гаебем булсын? Хәлдән килгәннең һәммәсен эшләдем. Синең әмереңне үтәп, кызны вәгъдәләшеп кайттым. Инде хәзер, бөтен авыллары белән сиңа каршы күтәрелгәч, мине гаепләмәкче буласың. Алай ярамый бит,— ди.

Каражали зәһәр чәчүен белә:

— Мустан чавуш, синең киңәшне тотып, шушы көнгә төштем. Бөтенебезне хур итеп киттеләр ләбаса. Хәзер безнең авыл халкы нишләргә тиеш инде? Йә, әйтеп күрсәт, мөхтәрәм Мустан чавуш. Ник дәшмисең? Теге мәми авызны юлдан алып ташлыйсыбыз калган шул менә,— ди.

Мустан чавушның уйланырлыгы бар шул: бу авылда килмешәк ләбаса; байның ачуын китерсәң, куып җибәрергә дә күп сорамас. Шуларны уйлагач, ул:

— Хәлилне үтерүдән башка юл калмый икән шул. Анысын булдырабыз аның. Хәзер инде, намуссыз эш эшләдегез, дип бәйләнә дә алмаслар. Аллаһы тәгалә каршында да без гөнаһсыз. Теге юлы бит алай түгел иде әле. Гөнаһы безнең өскә төшәсе иде,— дип тезеп китә.

Хуҗа аның сүзен тыңлап бетерми:

— Теге юлы җебеп калмасак, бүген бу хурлыкка төшмидер идек. Кыз да безнеке буладыр иде. Хәзер инде, Хәлилне үтерсәң, кем эше икәне билгеле була. Гөкдәргә нинди генә каза килсә дә, бездән күрәчәкләр. Ярар соң! Язганы булыр. Каражалигә кыз бирмәүнең казасын күтәрсеннәр әле менә!— дип, яраннарына текәлә.— Моннан соң Гөкдәрнең бер генә кешесе дә, мал-туары да безнең җиргә аяк басарга тиеш түгел. Инеш аркылы чыгып, ярыбызга аяк басу белән, атыгыз да үтерегез! Эш зурга китсә, Гомәр паша алдында җавабын үзем бирермен.

Яраннары теләр-теләмәс кенә:

— Баш өсте,— диләр.

Фәкать Сөләйман хаҗи гына каршы әйтергә батырчылык итә:

— Ага, бу эшең дөрес булып бетмәс. Кан койган өчен җәзасыз кала торган заманалар узды бит инде. Мондый карар кабул иткән өчен үзеңнең башыңа җитмәгәйләре, хөрмәтлем. Әллә син алар авылында груша җыючылар яши дип белдеңме? Алар бездән остарак аталар. Тагын шунысын да онытма: вәгъдәләшкән кызга син үзең кул суздың лабаса... Миңа калса, хөрмәтлем, ул кызга нәфесеңне сузмау хәерлерәк булыр. Ике авыл кешеләре ул кыз өчен бер-берен үтерә башлавы дөрес булырмы, шуны уйлап кара әле.

Али бай ярсып урыныннан сикереп тора да картлачны инсәсеннән эләктерә.

— Күземә күренмә! Андый эшне белә торган затмыни син? Хәзер инде кыз мәсьәләсе хәл ителми, минем намусым хәл ителә. Әгәр дә мәгәр сүземнән кайтам икән, Гөкдәрнең ыштансыз малайлары да көләчәк бит үземнән.

Каражали, ярсып-гасабиланып, хаҗины бәргәләп чыгарып җибәрә.

Айлы төн. Чишмә өстенә үзенең канатларын җәйгән карт чинардан караңгы күләгә төшә. Күләгәле җирдә су карасы күренә, бераз арырак киткәч, ай яктысына эләгә дә көмештәй ялтырап куя.

Хәлил башын сөйгәненең күкрәгенә салган. Кыз оялчан гына:

— И-и, көттем дә инде үзеңне. Солтанкәрә әбкәй коткармаса, упкыннарга ташланасы идем бит. Көттем дә инде...— дип пышылдый.— Теләсәләр нишләсеннәр, дим, ярәшсәләр — ярәшсеннәр, дим, тик бүтән берәүгә дә яр булмыйм, дим. Күңелем сизгән иде кабат кавышасыбызны. Ярый әле, безнең авыл егетләрен бәреп егарлык, дөнья бәясе торырлык

Солтанкәрә әбкәй бар. Һәй, шул ауга йөрүләрең белән мине ялгыз калдырмасаң! Колак сал, зинһар, бәгырькәем, тилмертмә син мине, вәйран итмә корып яткан оябызны! Ут йотып яшим ләбаса. Бер мин генә түгел, әниең дә, Солтанкәрә әбкәй дә, бүтәннәр дә дер калтырап яшиләр. Тауга аяк та басмамын, дип, ант ит хәзер үк.

Хәлил ишетелерлек-ишетелмәслек итеп кенә:

— Ант әгәр, китмим,— дип куя.

Зәйнәп исә, тәмам гасабиланып:

— Белмәсәм иде мин сине,— дип сөйләвендә була.— Ауга йөрмим, дигән вәгъдәң бер атнадан артыкка бармый шул, сүзеңдә тора алмыйсың шул... Болан кычкырган тавышны ишетүгә, тәмам шашасың.

Гыйшкына Хәлил:

— Бу юлы ант иттем ләбаса. Әйттем — бетте! Моннан ары ауга аяк та басасым юк,— дип җавап кайтара.

Ә бер көнне Хәлил иртә таңнан бусагасы төбендә, баглам кылларын чиртеп, җырлап утыра. Чаттан Солтанкәрә әбинең килеп чыкканын күреп ала да җырлаудан туктап кала.

Карчык аңа кырыс кына:

— Җырлавыңны бел,— дип әмер итә.

Хәлил елмая да:

— Өйгә керер идең, әбкәй,— ди.

— Кереп тормыйм инде, газизем. Нигә туктап калдың әле? Җырлар идең, дивана. Ауга чыкмавыңа нибарысы ике көн үтте, син инде боланнарыңны сагынып җырлый да башладың. Кортканың сүзенә колак салып, ташласана шул ауга йөрүләреңне! Югыйсә көт тә тор бәлагә таруыңны. Әллә ниләр күрерсең әле менә. Хәвеф-хафалы шул кыланышыңнан арынмый торып, җан тынычлыгы юк бит сиңа, дивана.

Хәлил:

«Нишләп миңа бәйләнә торгандыр инде?» — дип гарьләнә. Карчыкның күздән югалуы була, янадан багламын кулына ала. Сунарчылар җыры агыла да агыла. Башка көйгә, күпме генә тырышмасын, күчә генә алмый да алмый.

Кояш инде югары күтәрелә, таш кыялардан, агачлардан күләгәләр сузыла. Хәлил, багламын янына куеп, күзен йома да уйланып утыра. Аның күңел күзенә урман-чытырманны ера-ера чабып барган болан көтүләре күренә. Мангай күзен көч-хәл белән генә ачып, теләр-теләмәс кенә аягына торып баса да өйләре утырган калкулыктан ашыкмыйча гына үзәнгә төшә башлый. Аның артыннан әнкәсе:

— Хәлил! Күңелең бер дә урынында түгел бит, балакаем. Атаң да шулай, мәрхүм, гомере буе тынгы белмәде. Тагын тауларга таярга чамалап торасыңдыр әле. Дошманнарың дөнья тулы икәнен оныткансыңдыр шул. Зинһар, ауга китмә, безне ятим итмә. Кайтып, ичмасам, агачтан миңа кувшин белән киле-сап ясап бирер идең, төрле-төрле бизәкләр төшерер идең. Туең булмый торып, зинһар, ташлама атаң йортын. Югыйсә фатихамны да ала алмассың! — дип сөйләнеп кала.

Хәлил боегып кына аның сүзләрен тыңлап тора-тора да авыл мәйданы ягына кузгалып китә. Бөтен күңеле үзен тауларга тарта, ә колак төбеннән әнкәсе белән Зәйнәпнең аһ-зары, ялварулы тавышлары китми.

Авыл урамнарында очраган бозаулар аның күзенә болан бозаулары булып күренә, сөрмә тарткандай зур күзле җәйраннар булып күренә. Борынына тау исләре килеп бәрелә. Күкрәге тулы моң да сагыш. Иң сәере менә нидә: әлеге сагыш дигәнең өстенә ишелеп төшәргә торган куаныч-шатлык белән аралаша. Әле бер генә айлык, сыртлары елкылдап торган бозаулар бу чаклы охшаса да охшарлар икән җәйраннарга... Тауда бит анда мәһабәт мөгезле, елгыр боланнар да утлап йөри...

Хәлил өенә әйләнеп кайта. Сеңелесенең ихатада болан тиреләре киптереп маташуын күреп, шул тиреләрнең берсенә иңләп кенә утыра да

нарат бүкәненнән кувшин уярга тотына. Мондый эшне инде әллә кайчаннан бирле эшләгәне юк. Кояш баеганчы шулай да кувшинның эшен бетереп, үзенең күңелендәге бөтен изге хисләрен бизәк итеп төшереп, әнкәсенә тапшыра. Карт ананың куанычтан түбәсе күккә тия.

Икенче көнне Хәлил чинар агачыннан киле ясап, аны Солтанкәрәгә илтеп бирә — аны да сөендерә. Хәлилнең үзенә яңа шөгыль табуын күреп, авылдашлары куаналар. Хәзер инде егет көннәрен агач юнып-уеп уздыра торган булып китә. Сөйгәненә ул береннән-бере җиңелрәк кувшиннар да береннән-бере зифарак килеләр ясап китерә. Агачны ул, балчык кебек, әллә нишләтеп бетерә, искитәрлек бизәкләр төшерә. Аның эшләгән эшләрен күреп һәммә кеше дә соклана.

Шуннан инде Хәлилнең мәргән дигән данына агачтан гаҗәеп матур вә камил иттереп төрле нәрсәләр ясый белүче даны да өстәлә. (...)

Көннәрдән бер көнне, тәмам түземе төкәнеп, таң беленә башлау белән, Хәлил атына менеп атлана. Гадәтенчә, иң әүвәл Зәйнәпләр өенә юл ала. Тояк тавышы ишетеп, сөйгәне өйдән атылып чыга.

— Бәгырькәем, антыңны шулай ук бозасыңмыни? Солтанкәрәне үпкәләтәсең киләдер инде,— дип тә карый.

Хәлил көлә генә:

— Үпкәләвенә исең китмәсен. Бәлагә тарыр, дип аның коты алына. Ауга бер тапкыр барып кайтканнан дөнья җимерелмәс,— дип җавап бирә.

Зәйнәп, күз яшенә буылып:

— Барма инде, барма инде,— дип пышылдавын белә, өзеп сала.

Егет аның чәчләрен назлап сыйпый. Аннары, сөеклесенең елаудан туктамаганын күреп, бетмәс моның балавыз сыгуы, дип, тәмам гайрәте чигә. Ул атын чаптырып китеп тә бара...

Хәлилнең ауга чыгып киткәнен күреп, берәү Сарыҗалыга ашыга. Каражали йортына барып җиткәч, атыннан сикереп төшә дә болдырга чыгып баскан хуҗага:

— Сөенче бирәсез, ага! Сөенечле хәбәр китердем. Хәлил яңарак кына тауларга олакты. Артына төшү чүп тә тормый,— дип сайрарга тотына.

Али бай:

— Хәзер үк атлар иярләнгән булсын! Мустан чавушны да, башкаларны да чакырыгыз!— дип җикерепме-җикерә.

Ул арада Зәйнәп, сөеклесенең аттан төшеп, җәяүләп кенә китә торган җиренә ничек итеп аның үзеннән элегрәк барып җитеп булыр икән, дип баш вата. Сукмактан да барып була булуын. Тик инде турырак юлны да сайлап була. Ул чагында боланнар да әйләнеп уза торган үзе текә, үзе шома таш кыяларга юлыгасың. Ошбу юлның хәтәрлеген белә торып, Хәлилдән элегрәк житешү нияте белән, Зәйнәп әнә шушы юлны сайлый.

Текәнең дә текәсе тау-таш өстеннән ул үрмәли дә үрмәли. Ара-тирә хәл алырга туктагандай була да яңадан алга ыргыла. Ничек тә элегрәк, һич югы сөеклесе белән бер үк вакытта барып җитәргә кирәк бит. Күңелкәе сизеп тора: сөеклесен бу юлы авылга алып кайта алмаса, ул аны югалта — һәлакәткә дучар буласы көн кебек ачык. Ансыз яшәүдән ни мәгънә?!

Таштан ташка үрмәли торгач, Зәйнәп бер мәлне, хәле бетеп, таш кыядан егылып та төшә. Әрнүдән һушын җуя. Һушына килеп, күзен ачып җибәрсә — моның янында үк мәһабәт кенә болан баласы. Аның дымлы зур күзләрендә гаҗәпсенү чагыла. «Хәлилем янына бармаенча, монда изрәп ятуыма сәерсенә булыр»,— дип уйлый да, бөтен әрнүләрен җиңеп, аягына торып баса. «Әнә теге кыяга менеп җитсәм, аннары инде түбәнгә төшүе рәхәт кенә була»,— дип үз-үзен юата.

Шул чагында тау сулары аккан гөрләвекне күреп ала да, барлык көч-куәтен бергә җыеп, шунда ыргыла. Сусыз калган таш басмалар

буйлап барса, тизрәк житешер сыман тоела. Тырыша торгач, таш кыяның түбәсенә үк менеп житә. Хәле бетеп, исерек кешедәй чайкалса да, ял итеп алырга вакыт тими: аңа ашыкмыйча һич ярамый.

Менә Зәйнәп куе урман эченә килеп керә. Гомере буе урманнан коты алынып яшәгән кыз балага житә кала. Куркуын басарга тырышып, ара-тирә:

— Хәлил! Хәлил!— диеп тавыш бирә.

Сөеклесенең ишетмәгәнен дә белә инде югыйсә, әмма кычкырудан туктамый. Куаклар кулын-аягын тырный, агач ботаклары күлмәген ерта. Өстәвенә үзенең адашканын да абайлап ала. Бу урманга бит ул Хозыр Ильяс көнендә[1] генә килгән иде. Бүген исә урманны танырлык та түгел: әйләнә-тирәдә карт агачлар утыра, аларның ботаклары бер-бере белән чәбәләнеп беткән, аралап үтәрлек тә түгел. Хәер, дөрес бара бугай ич әле! Тик менә Хәлил үзенең атын кайтарып җибәрә торган урынны ничек итеп табасы икән?

Зәйнәп урман буйлап тәмам аптыраган килеш йөри дә йөри. Шулчак баягы болан бозавы кабат күзенә чалына. «Әллә артымнан йөри инде?»— дип уйлап, аның ягына йөгерә. Бозау исә, түмгәктән түмгәккә сикерә-сикерә, Зәйнәпне тирән озын чокыр янына ияртеп алып килә.

Һич көтмәгәндә мылтык аткан тавышлар ишетеп, кыз чырыйлап:

— Хәлил! Хәлил!— дип кычкырып җибәрә.

Шуннан сөеклесен күреп тә ала. Нәкъ шул чагында егет кыя ышыгына атылып кереп поса. Аны күбәүләп уратып алырга маташалар икән. Берсе артына төшкән, мыштым гына якынлашып бара. Ядрә Хәлилнең башы турысыннан очып уза. Артына посканы мылтыгын күтәрә. Янында ук лабаса, тидерми калмаячак. Зәйнәп илереп кычкырып җибәрә, икесенең арасына ташлана. Пуля кызның беләгенә туры килә. Шунда гына Хәлил аның тавышын ялгыш ишетмәвенә төшенә. Югыйсә бит үз колагына үзе ышанмый азаплана. Шулай икән ич, сөеклесе җәйрәп ята икән ич. Беләгеннән кан саркый.

Кызны Каражали да күреп ала, аңарга аткан кешене:

— Нишләттең инде, мөртәт? Әллә күзең чыкканмы?— дип, эт итеп сүгеп ташлый.

Хәлил сөйгәне янына атыла, аны җәһәт кенә күтәреп ала да таш кыяга ышыклана. Кыз аңына килгәч тә:

— Хәлилем, ничек тә үзең котылу ягын кара. Беләгем авыртмый да. Мылтыгыңны ал тизрәк, югыйсә башыңа житүләре бар,— ди.

Чыннан да шулай лабаса: Али байның яраннары, аптыраудан арынгач та, яңадан атарга тотыналар — табышны ычкындырасылары килми. Зәйнәпне тереме-үлеме хәлендә кулга төшерергә исәпләре. Каян килеп чыккандыр, диген дә, Хәлилгә җибәргән ядрә ничек итеп аңа тигәндер, диген?

Хәлилнең алар белән атышып торырга уенда да юк. Зәйнәпнең күлмәк җиңен ярып җибәрә дә, җәрәхәттән ургылып кан акканны күргәч, тизрәк өстендәге күлмәген сыдырып сала да сөйгәненең беләген кысып кына бәйләп куя. Ул арада тегеләр якын ук киләләр.

Зәйнәп ыңгырашып:

— Бар, кач инде. Башыңа житмәгәйләре,— дип үзенекен тукый.

Хәлил исә:

— Җәрәхәтең тирәнгә үткән үтүен, мәгәр хәвефле түгел. Ничек тә каныңны туктатасы иде,— ди.

— Кач тизрәк, бәгырькәем. Килеп житәләр бит инде. Миңа берни булмас, үзең качып котыл.

Хәлил аның сүзенә колак та салмый. Гайрәтләнеп, мылтыгына ябыша. Төн урталарына чаклы атышалар.

---

[1] Хозыр-Ильяс көне — җәйнең беренче көне, 6 майга туры килә.

Зәйнәп ыңгыраша да ыңгыраша, аның тавышы тауларга бәрелеп кайтаваз булып яңгырый. Егет, аңа табан иелеп:

— Сөеклем, ничек булса да ыңгырашмаска тырыш әле. Югыйсә алар бит безне күреп атмыйлар, тавышка аталар. Чак кына тынып торсаң, китеп котылабыз,— дип ялвара.

Зәйнәп, тешен кысып:

— Тырышып карыйм соң. Хәзер торам да, китәбез алайса. Кабат ыңгырашсам, яулык белән авызымны томала,— ди.

Гашыйклар посып яткан җирләреннән китеп баралар, дошманны ансат кына алдыйлар. Тегеләр әле шактый озак шунда ук атып яталар.

Мәргән кызны аркасына салып бара. Зәйнәп тынын да чыгармаска тырыша, иреннәрен канатып бетерә. Мылтык тавышлары ераклашкач, Хәлил:

— Котылдык болай булгач. Хәзер инде кычкырсаң да, берни эшләтә алмыйлар. Анда бит безнең барыр урыныбыз юк иде. Ә монда — килеп кенә карасыннар, берәм-берәм чүкеп кенә алам үзләрен,— ди.

Гашыйклар авылга табан юллаunion. Караҗали тау-таш арасында куа баруның ни белән бетәсен чамалый, артларыннан бармаска акылы җитә. Зәйнәптән колак какмагаем, дип кенә хафалана. Хәер, үлмәгән булса, җәрәхәте ничек тә төзәлер. Аннары инде бу үҗәт мәргәннән ничек тә үзен чәлеп киту хәстәренә керешер.

Кояш чыкканда гашыйклар инде бөтенләй тыныч урынга кайтып җитәләр. Саф һавага ул арада чабыр исләре таралып өлгерә. Һава зыңлап тора. Ипсезрәк кыймылдасаң яки ялгыш кычкырып җибәрсәң, һава тау бәллүредәй вак-вак кисәкләргә уалып китәрдер сыман тоела.

Мәргән әледән-әле:

— Бераз җиңеләймәдеме хәлең?— дип сораштыргалый тора.

— Шулайрак бугай.

— Минем арттан нигә дип барган идең соң?

Зәйнәп елмая гына, дәшми. Хәлил аңардан:

— Кайсы юлны сайларбыз икән?— дип сораган була.

— Мин килгән юлдан кайтыйк соң, коры шарлавык юлыннан.

Ул күрсәткән якка күз салсалар — бозавын иярткән болан йөри икән ләбаса. Мәргән җәһәт кенә мылтыгын күтәрә дә төзәми-нитми атып та җибәрә. Сөеклесе авыз ачарга да өлгерми кала.

— Хәлил, атма!— дигәндә, ана болан чабып китеп бара, сабые гәрселдәп җиргә егыла.

Аучы йөгереп кенә барып аны алып килә дә рәхәтләнеп көлә-көлә:

— Күрче, сөеклем, Алидан да котылдык, табышлы да булдык,— ди.

Сөеклесе елап җибәрә:

— Хәлил бәгърем, тагы ниләр күрербез икән инде? Болары гына җитмәгән, яңа бәла эзлисең бугай,— ди.

Егетнең гамендә дә юк, көлә генә. Бер беләгенә атып алган болан бозавын салган килеш, икенчесе белән Зәйнәпне күтәреп ала да шарлавык буйлап төшә башлый. Аның шул чаклы да куәтле һәм житез булуына кыз сокланып туя алмый.

Көн үзәгендә авылларына кайтып җитә язалар. Хәлил сөйгәненнән:

— Бик әрнидер, ә?— дип сораша.

— Сулык-сулык килә.

— Беләсеңме, нишлибез? Әйдә кичне көтик. Бу хәлебездә кайтып керүе оят. Гайбәтебез чыкмаска әйбәт булыр. Кичкә хәтле түзәрсеңдер бит? Ә мин үзеңне болан итеннән шашлык куырып сыйлармын.

Кыз каршы сүз әйтми.

Гашыйклар кояш баегач кына авыл юлына чыга. Алар кайтып җиткәндә, караңгы төшкән була. Мыштым гына Зәйнәпләргә юллана-лар. Әмма анда алар кайтканны бөтен авыл халкы җыелып көтә булып чыга. Ярәшкән егет белән кыз халыкны аралап узарга мәҗбүр була.

Шулчагында Солтанкәрә:

— Баһадирыбыз да кайтты бугай!— дип мәсхәрәле тавыш белән әйтеп куя.— Аның кыюлыгын мактамый буламы соң! Тик бу юлы мәргәнебез болан урынына Зәйнәпне аткан бугай! Кыю да соң! Хәчтерүш! Эттән туган нәрсә! Моннан арыауга йөрмим, дип үземә вәгъдә бирдең түгелме соң? Җитмәсә бит әле кыз баланы да ияртеп алып киткән. Һай дивана, вай дивана!

Ә инде аучы кулында болан бозавын күргәч, кортка бөтенләй чыгырыннан чыга:

— Йа раббем, бар икән күрәселәребез! Бу дивана сабый боланны аткан лабаса!— дип илереп җибәрә.

Хәлил бертөрле дә җавап кайтармый. Кортка исә, бер дулап алганнан соң, тынычлана төшеп, Зәйнәп янына килә.

— Ни булды сиңа? Чыраең качкан лабаса.

— Беләгемне җәрәхәтләделәр.

— Кемнәр?

— Теге кяферләр.

— Нәрсә дип бардың соң анда?

— Хәлилне үгетләү иде исәбем.

— Бик әрнидер инде?

— Бик.

Зәйнәпне өйгә кертеп яткызалар. Каткан чүпрәкне көч-хәл белән кубарып, җәрәхәтен әйбәтләп карыйлар. Шунда Солтанкәрә:

— Сөбханалла! Бичаракайның сөяге чәрдәкләнгән икән ләбаса! Ишетсен колагың, Хәлил дивана!— дип күтәрелеп бәрелә.— Хәзер үк су жылытыгыз. Ярасын көйдереп алабыз. Кулы күгәргәнче, шифалы үләннәр ябарбыз. Югыйсә бизгәк тота башлар да, аннары инде коткара да алмабыз. Ишетсен колагың, барысы да синең аркада бит, ишәк!

Бичаракайны коткару нияте белән ниләр генә кылындырмыйлар, тик файдасы гына тими дә тими: кызның хәле көннән-көн начарлана бара. Шуннан тауның теге ягында бер табиб яшәгәне исләренә төшә. Аны алырга берәрсен җибәрмәкче булалар.

Староста:

— Хәлил барсын,— дип әмер дә биреп өлгерә.

Егет шундук атына менеп тә атлана. Солтанкәрә кортка гына:

— Әллә акылыңнан яздыңмы? Әллә табибны алып кайтырга авылда кеше беткәнме?— дип кенә тыеп кала.

— Үзем барырга тиешмен!

— Беркая да бармыйсың. Авылдан чыгарга ярамый сиңа.

Хәлил атыннан төшәргә мәҗбүр була. Кортка ул арада Зәйнәпнең олы абыйсына:

— Хәзер үк атка атлан да оч тизрәк. Табиб килеп җитмәсә, үлеп китә бичарабыз. Ашыгырга тырыш!— диган әмерен бирә.

Тарыс таулары итәкләрендәге авылларда яшәп килгән гадәт буенча, ярәшкән егет белән кыз бүтәннәр алдында сөйләшә алмыйлар. Очрашуын-күрешүен дә төнлә белән, кеше күрмәгәндә генә чамалыйлар.

Кызның өенә керергә базмыйча, Хәлил төн уртасына чаклы ихатада йөренә. Вәгъдәсен бозып, ауга олакканы өчен үзенә әйтмәгән сүзне калдырмый. Каражалины да каргый, сөйгәнен саклый алмаганы өчен үзен дә тирги.

Шуннан ул, сәю көченә артык каршы тора алмыйча, өйгә керә. Өй эчендә Солтанкәрә белән өч-дүрт карчык утыра икән. Егет:

— Әбкәй, Зәйнәпнең хәле ничегрәк соң?— дип сораша.

— Күрмисеңмени? Һушсыз ята, бичарам, көч-хәл белән сулу ала.

— Хәле бер дә әйбәт түгел инде, алай булгач...

Мәргән сөеклесенең аяк очына барып утыра, аның агарынган чыраеннан күзен дә ала алмый. Карчыклар аны-моны әйтмиләр. Мичтә утынның чытырдап янганы аермачык ишетелә.

Кортка, егетне бераз тынычландыру нияте белән:

— Улым, син үзең дә кайтып, бераз черем итеп алыр идең. Зәйнәп әлегә йоклый, бернинди хәвеф-хәтәр юк сыман. Өйлә тирәләренә табиб та килеп төшәрдер. Аның кулы хәйран да шифалы, диләр бит. Син бар, ятып бераз ял итеп ал,— дигән киңәшен бирә.

Егет карышмый.

Күк гөмбәзендә йолдызлар җемелдәшә. Мәргән таңнар атканчы авыл урамнарын таптый. Колагына болан тавышлары ишетелгәндәй була. Нишләгәнен абайлап та җиткермичә, якындагы тау башына менә, тик үзе шундук борылып кайта. Гәрчә ауга йөрмичә яши алмаса да, моның нилектән шулай икәнен уйлап баш ватканы юк. Хәер, ул берни уйламый булса кирәк.

Таң атканда Хәлил үз өенә кайтып, капка төбендәге эскәмиягә чүмәшә. Гадәттә, ул монда кувшин юнып ясаганда яисә баглам кылларын чиерткәндә утыргалый иде. Әнә урам буйлап әнисе дә кайтып килә.

— Әнкәй, Зәйнәпнең хәле ничегрәк икән?

— Исенә килде шикелле. Синең диваналыгың аркасында бичара кыз бала дөньядан китә язды лабаса. Юк та инде үзеңдә акыл, юк та инде!

Зәйнәпнең хәле җиңеләйгәнне ишеткәч, Хәлил түбәнгә йөгерә. Анда ул Солтанкәрәне күреп сораштыра:

— Әбкәй, ничегрәк, бераз әйбәтләнә төшмәдеме хәле?— ди.

Кортка:

— Шулайрак сыман тоела. Әмма хәвеф-хәтәрдән тәмам арына алганы юк әлегә. Өйлә тирәләренә табиб килеп җитмәсә, хәле тагын начарланмагае. Өметләнеп көтәбез инде,— дип төшендереп бирә.

Хәлил өйгә керә. Аны күрүгә, сөйгәненең йөзенә елмаю куна.

— Хәзер менә абыең табибны алып кайтыр да, шуннан тернәкләнеп китәрсең...— ди егет.

Көн үзәгендә Зәйнәпләрнең капка төпләренә ике җайдак килеп туктый. Аларның берсе авыруның абыйсы булса, икенчесе — карт табиб. Аркасына аскан биштәренә авыруны сихәтләндерердәй төрле шифалы майлар салынган. Кызның җәрәхәтен җентекләп тикшерә дә хафага кала табиб:

— Ансат кына дәвалап булмас, азынган ярасы. Кулын кисәргә туры килмәгәе әле,— ди.

Хәлил алга чыга:

— Мөхтәрәм картым! Кодрәтеңнән килгәнне эшли күрсәнче. Зәйнәпкә ул-бу булса, миңа да яшәүнең мәгънәсе бетә. Аны үлемнән коткаруың белән син бит икебезне дә коткарып каласың,— ди.

Картның исемен дә, яшен дә сораган кеше юк, әмма үзенең шифалый алу кодрәтенә, аллага ышанган кебек, ышаналар.

Ул инде үз гомерендә моның кебек җәрәхәтләрне генә күргәләгән, нәрсә эшләргә икәнен яхшы чамалый.

— Хәлдән килгәнне эшләрмен, көчемне кызганып тормам,— дип вәгъдә итә.— Хәвефләнер чакны инде узгансыз,— ди. Аннары ул елмаеп:— Ишетүемә караганда, син мәргән икәнсең. Улым, сөйгән ярыңны дәвалап аякка бастырган өчен син миңа болан атып алып кайтырсың. Килештекме?— дип тә өсти.

— Килештек!— дип җавап бирә Хәлил.

Карт табиб Гөкдәр авылында унбиш көн яши. Моңарчы аның әле бу чаклы озак дәвалаганы булмый — нинди генә чирдән дә ике-өч көндә дәвалап кеше итә икән. Әмма үзе дәвалавының серен бирәүгә дә чишми, кулының шифасы нидә икәнен беркемгә дә сөйләми, диләр.

Карт монда чакны ук Хәлил болан атып алып кайтырга күпме генә омтылмасын, Солтанкәрә аны беркая җибәрми. Андый чакта мәргән:

«Сиздермичә генә китсәм, берне генә атмыйм инде анысы, бөтен авылга житәрлек алып кайтам. Хәзергә антны бозарга ярамавы гына аяк-кулны бәйли»,— дип үз-үзен юата.

Август ахырына чаклы, Зәйнәп савыга-тернәкләнә башлаганчы, Хәлил төннәрен боланнарның чакыру авазларын ишетеп азаплана. Бигрәк якында ишетелә инде, авылга житәргә, ахры, исәпләре. Күр инде ул оятсызларны! Егетләр ауга барудан туктагач, өй борынча йөрергә, ахры, исәпләре.

Боланнар кычкырмыйдыр, дип уйларга егетнең зиһене житми. Хәлил болай үзе болан тавышын кеше кычкырганнан аера алыр иде; тик менә кычкыручысы Мустан чавуш булыр дип, Каражали әмерен үтәп, үзен, Хәлилне, ауга чакырып, буйвол мөгезен авызына кабып, шушылай оста кычкырыр дип, аның башына да килми.

Якындагы таулардан таныш тавышларны ишетүе мәргәнгә жиңел булмый. Ара-тирә күңеленә шик тә төшә төшүен, мәгәр: «Болан булып нинди аучы болай бер урында кычкырып йөрсен икән?»— дип, шиген куып жибәрергә тырыша.

Туйга хәтле авылдан чыкмыйм, дип туган-тумачасына, Солтанкәрә әбкәйгә биргән антын бозмавы аңарга, чыннан да, авырга килә. Житмәсә бит әле табибнє дә, дус-ишне дә Зәйнәп савыккач болан ите белән сыйларга вәгъдә иткән иде. Аны шактый газаплаганнан соң, берзаман боланнар кычкырудан туктый, таулар тынып кала.

Сентябрьгә керү белән, туйга әзерләнә башлыйлар. Хәлилнең әнисе белән сеңлесе, туган-тумачасы, Солтанкәрә һәм Дуран туй хәстәрләренә керешәләр. Кунакларны, ягъни дус-ишләрен алып карт табибнең килгәнен көтәләр. Бу төбәктә галәмәт зур туй булачагын белмәгән кеше калмый. Шуңа әллә кайлардан әллә нинди ашуглар, музыкантлар, жыр һәм бию осталары килеп төшә. Һәммәсенең дә шатлыклы тантанада катнашасы килә.

Туй мәжлесе дүрт-биш көнгә сузыла. Жырлыйлар да, биләр дә. Туйда иң күңеллесе, иң нык дәртләнеп биючесе Хәлил үзе була. Туйның ахыргы көнендә ат ярышлары уза, атышлар уза.

Туй барганда Хәлил бер генә мәртәбә дә болан кычкырганны ишетми. Каражали хәйлә кора: туй мәжлесе үткәнче сабыр итеп, туйдан соң мәргәнне боланга кызыктырып тозакка төшермәкче була.

Менә Хәлилнең кыз янына керү минутлары житә. Кияү егетләре аны ишеккә хәтле озаталар да, аркасына шаяртып кына төрткәләп, кыз янына кертеп жибәрәләр. Зәйнәп аны зарыгып көтә. Кияү кавышырга дип кәләше янына килгән бер мизгелдә таулар ягыннан таныш чакыру авазын ишетеп ала. Кияү кисәк кенә туктап кала. Боланнар аны чакыра. Тавышлары колак төбендә чыңлап тора, һичбер төрле тынгы бирми. Хәлилнең тәки түземе төкәнә.

— Зәйнәп, озак йөрмәм,— дип кенә әйтә дә атылып чыгып китә.

Мәргән тау башына югарырак менгән саен болан тавышлары тагын ераклаша бара. Авылдан чыкканына әле күпме генә, менә бераз өскәрәк менде исә, боланны атып алачак.

Болан тавышлары кисәктән өзелә. Шомлы тынлык урнаша. Аннары гөрселдәтеп мылтык аталар.

Хәлил белегән нидер көйдереп алганын тоя, бер кырыйга сикерә, таш араларындагы ярыкка сыена.

Бер сәгать тә көтә кәләш, ике дә. Кияү күренми дә күренми. Шунда инде Зәйнәп Хәлилнең үзен ташлап ауга киткәнен аңлап ала. Чолandагы мылтыкның да юклыгын күреп, моңа тәгаен инана. Шул чагында Зәйнәп гарьлегеннән, кияү түшәгенә утырган килеш, үкерепләр елап жибәрә. Күпме генә өметләнсә дә, кияү күренми дә күренми.

Хәлил тавыш-тынын чыгармаска була. Таң атуга, дошманнары корган тозактан качып котылмакчы була. Сызылып таң беленә башлауга, елан җитезлеге белән таштан-ташка үрмәли.

Беравыктан мәргән дошманнарының артларына төшә. Төзәп торып атып җибәрүе була — кайсыныңдыр ачыргаланып кычкырганы ишетелә. Мәргән янә ата. Бу юлы да ачы тавыш кабатлана.

Шуннан инде урман тынып кала.

Ул арада таң да ата. Кияү кайтмый да кайтмый. Кәләше ни дияр икән инде халыкка? Мине ташлап, ауга китте, димәссең ич инде. Гомерендә дә алай димәс Зәйнәп.

Гореф-гадәт кушуынча, кияү егетләре ишек төбендә таңны каршылый; таң атуга, кияү алар янына чыгып, кәләшнең гыйффәтле булуын хәбәр итәргә тиеш.

Тик менә ишек ачылмый да ачылмый. Кияү егетләренең берсе:

— Бу Хәлилгә ни булды икән? Чыкмый да чыкмый бит,— дип куя.

— Ул-бу булмагандыр лабаса?

— Кереп карамыйбызмы соң?

— Килешми бит. Йоклыйлардыр әле. Бимазаламыйк инде.

Кояш югары күтәрелгәч, Хәлил качып яткан җиреннән шыпырт кына чыгып, тавышлар ишетелгән якка табан атлый. Таш кыяга сыенып кына күз салса — тегендә моның дошманнары боегышып ике мәет янында басып торалар, имеш. Мәргән бер мәетнең Каражали икәнен танып ала да, сагаеп-нитеп тормаенча, тегеләр янына чыга, нәфрәт белән, мәсхәрәле көлемсерәп өсләрен карап тора да үз юлына китеп бара.

Гөкдәренә җитә дигәндә Хәлил һич көтмәгәндә әле үзе күптән түгел бозавын атып үтергән боланны күреп ала. Егетне чыгырыннан чыгарырга әнә шул хәл җитә кала. «Синең аркада бәла-каза күрәммени әле?!»— дип, мылтыгын кулына ала. Атып тигезү өчен бераз якынрак барырга ниятли. Ана болан таш кыяның кырыенда ук кымшанмыйча басып тора бирә. Мәргән, бу хәйләкәр боланның таштан ташка сикерү гадәтен белгәнгә күрә, бу юлы аңа качып китәргә ирек бирми.

Болан гөрселдәп кыя кырыена барып төшә, бөтен гәүдәсе тартыша башлый.

Кояш күтәрелгәнгә дә байтак инде. Солтанкәрә, хафаланып, кияүләрнең ишеген шакырга тотына:

— Хәлил, дим! Торыгыз инде! Бу вакытка хәтле йоклап ятмагыз!— ди.

Эчтән тавыш бирүче булмый.

— Хәлил, дим! Ник дәшмисең? Зәйнәп, димен, кызым!

Зәйнәптән дә җавап ала алмагач, кортка ишекне бәреп ача да эчкә керә, шунда ук шаклар катып кала: кияү түшәге кичтән җәелгән көе тора; аның бер читенә туй киеме кигән кәләш чүмәшкән; кияү үзе күренми.

— Сезгә ни булды?

— Берни булмады.

— Хәлил кайда соң?

— Белмим.

— Синнән, кияү кайда, дип сорыйлар түгелме соң?

— Китте ул...

— Кая китте? Нигә китте?

— Мылтыгын алды да китте.

— Ишек төбендә утыручы кияү егетләренә ник әйтмәдең?

— Хәлил бит, озакламам, дигән иде.

Солтанкәрә үкереп елап җибәрә.

Мәргән әҗәл белән тартышып яткан болан янына ашыкмыйча гына килә дә бер аягын аның дерелдәгән сыртына куя, бугазын кисәргә дип пычак чыгара. Кулына пычак тотып корбаны өстенә иелгән бер мизгелдә болан, актык көчен бергә туплап, аны тибеп очыра. Хәлил таш кыяның кырыена ук барып төшә. Ул аңына килергә өлгергәләгәнче, болан тоягы белән тагын өсти. Шуннан инде мәргәнебез таш кыядан түбәнгә тәгәри, шактый ук төшкәч, бәләкәй генә бер киртләчкә эләгеп, һуштан яза.

Ике-өч сәгатьтән генә ул аңына килә. Бөтен тәне җәрәхәтләнгән була, әрнүгә түзә алмыйча, Хәлил үкереп елый-елый, ташка тырмашып та карый, фәкать үзендә гәүдәсен кыймылдатырлык та көч таба алмый. Таш кыя буйлап алсу кан юлы сузыла.

Гөкдәргә атын чаптырып җайдак алып килгән: «Хәлил Караҗали белән аның Гомәр дигән кешесен үтергән»,— дигән хәбәр бөтен авыл халкын тетрәндерә. Аннары хәбәрнең яңасы килә. «Караҗалиның башына җиткәннән соң Хәлил упкынга ташланган»,— дигән хәбәрне ят бер көтүче алып килә.

Солтанкәрә авыл халкын тауга алып китә. Анда алар иң әүвәл Караҗали гәүдәсенә юлыгалар. Аннары таш кыяның кырыенда ук болан ятканын күреп алалар. Шунда ук ниндидер ыңгырашкан тавышка колак салалар. Хәлилне көч-хәл белән генә күреп алалар.

Авылдан озын аркан алып килеп, аның очын түбән төшерәләр, Хәлилгә:

— Биленә бәйлә арканны, тартып чыгарабыз!— дип кычкыралар.

Тик инде мәргәннең арканга сузылырлык та дәрманы калмаган була. Бары тик:

— Чыгарып маташмагыз, барыгыз, кайтып китегез,— диеп кенә әйтә ала.

Таш кыядан түбәнгә төшәрдәй тәвәккәл егет табылмый. Шуннан инде авыр тынлыкны ярып Хәлилнең:

— Зәйнәпкә әйтегез, бәхетле булсын,— дигән актыккы сүзләре яңгырап ишетелә.

Сөйгәненең һәлакәткә дучар ителгәненә тәмам инанганнан соң Зәйнәп, авыз ачып бер генә сүз дә әйтмичә, упкынга ташлана.

Шул заманнан бирле бу якларда таң алдыннан таш кыялар арасында моң-зар агыла:

Истән чыгарып вәгъдә-антларым,
Тау юлларына — ауга ашкындым.
Атылган болан, синме каргадың?—
Калам, туганнар, кыя-тауларда.

Кайнар канымнан эри ак карлар,
Мине җәлләпме елый кыялар?
Ерактан карап уза боланнар...—
Калам, туганнар, кыя-тауларда.

Ак келәтендә ять-яшь хатыным
Көтәдер мине өзелеп сагынып.
Язгандыр аңа калу тол булып,—
Калам, туганнар, кыя-тауларда.

Килеп, сорнайда уйнарсыз әле,
Рухымны моңга уарсыз әле,
Мине исән дип уйларсыз әле,
Калды, диярсез, кыя-тауларда...[1]

Гашыйклар һәлакәткә дучар ителгән җирдә елның-елында, нәкъ шушы көндә, ике гөл бергә чәчкә ата. Берсе аның булса җете-кызыл, икенчесе булыр ачык-зәңгәр. Кояшның иртәнге нурлары назлап туялмый әлеге чәчкәләрне. Бер-берсенә башларын иеп, ике чәчкә мәңә-мәңә кавышалар сыман тоела. Мәгәр нәкъ шул мизгелдә каяндыр мөгезбай-болан атылып килеп чыга да әлеге чәчкәләрне таптап-изеп бетерә.

Елның-елында кабатлана шушы хәл.

**Кыям МИҢЛЕБАЕВ** ***тәрҗемәсе.***

---

[1] Шигырь Шамил Маннап тәрҗемәсендә бирелә.

# РАВИЛ ФӘЙЗУЛЛИНГА — 50 ЯШЬ



*Равил Габдрахман улы Фәйзуллин 1943 елның 4 августында Татарстан Республикасының Балык Бистәсе районы Балтач (Юлсубино) авылында туа.*

*Котлы Бөкәш авылы урта мәктәбен, 1965 елда Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетын тәмамлый; Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында аспирантурада укый.*

*Р. Фәйзуллин — 1966 елдан Язучылар берлеге әгъзасы.*

*1968—1972 елларда Р. Фәйзуллин — Татарстан язучыларының Әлмәт оешмасы җитәкчесе. 1973 елдан 1977 елга чаклы — Татарстан Язучылар берлеге идарәсенең җаваплы сәркатибе.*

*Р. Фәйзуллин — яшь шагыйрьләрнең Мәскәүдә ВЛКСМ ҮК оештырган Бөтенсоюз фестивале премиясе (1966), «Дружба народов» журналы премиясе (1973), «Мәрмәр» исемле китабы өчен Татарстан комсомолының М. Җәлил исемендәге премиясе (1970) һәм, ниһаять, «Шигырьләр һәм поэмалар» китабы өчен Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты.*

*Р. Фәйзуллинның аерым әсәрләре рус, башкорт, кыргыз, әзәрбайҗан, чуаш, литва, эстон, грузин һ. б. тугандаш халыклар телләрендә һәм шулай ук итальян, немец, поляк, француз, гарәп кебек чит ил телләрендә дә дөнья күрде.*

*1989 елдан «Казан утлары» журналының баш мөхәррире.*

*Татарстан халык депутаты.*

# БАШНЫ САЛЛАРГА САЛЫП...

ПОРТРЕТКА ШТРИХЛАР

Шигъри дөньялар эзлим!..

Моннан байтак еллар элек, шигъриятнең асылы турында уйлана башлаган гына бер чорда, беренче (һәм әлегә соңгы) мәртәбә Шигырь турында сүз әйтү өчен Тукай клубындагы трибуна артына чыгып баскач, яшьлеккә хас кайнарлык белән әнә шулай дип әйтеп ташлаган идем. Аз да түгел, күп тә түгел: дөньялар эзлим... Ә эзләгән кеше таба инде ул, кем әйтмешли; һич югы табарга тиеш. Мин дә үземнең рухани эзләнүләрем, күңел җегәрем мөмкинлек биргәнчә яңа кыйтгалар ачканмындыр, ачканмындыр да гомер юлымда кайберләрен инде югалтырга да өлгергәнмендер (тапканны гына, бар булганны гына югалтып була лабаса); әмма кай тарафка китеп баш орсаң да, Шигърият дингезенең чиксез киңлекләрендә серле дөнья булып балкып торган, юлыңның азимутын дөрес билгеләргә ярдәм итә алган Казык йолдызлары бар ул, бар.

Ни гаҗәп: мине беренче тапкыр тетрәндергән шагыйрь Тукай, Дәрдемәндләр дә, Пушкин, Лермонтовлар да түгел (күрәсең, безгә — күзе ачылып кына килгән сала малайларына — Шигърият серләре, иң беренче булып, китаптан битәр Табигать аша ачылган булгандыр) Хәсән ага Туфан булды кебек. Сәбәбе? Сәбәбе шуннан гыйбарәт иде: минем беренче рухи уянуым, егетлеккә атлаган көннәрем, әйләнә-тирәдәге олы дөньяга гыйшкый күзләр белән карый башлавым Хәсән аганың-көндәлек мәшәкатьләрне бар нәрсәдән дә өстен күреп, өстән җибәрелгән җәзалардан тәмам гаҗиз булып яшәп яткан татар мохитына кабаттан әйләнеп кайткан көннәренә туры килде. Хәтерлим: яз, апрель һәм мин — заманның һәрбер җиленә киереп ачылучан күңдәм, шыгырдавык авыл капкасыннан соң да дөнья барлыгын аңлый башлаган иләсрәк күңелле үсмер — төз лапас түбәсенә өелгән сары арыш саламына күмелә идем дә, монарчы исеме дә таныш булмаган шагыйрьнең уй дөньясы белән хозурланып, каршылыклы да, газаплы да хыялларга чума идем. Аның һәр сүзе минем өчен яңача: серле дә, моңлы да, хәсрәтле дә иде. «Тыштa яз, һавада кошлар өне» генә әле, югыйсә, табигатьтә дә, күңелдә дә тормыш-яшәү уянып кына килә ләбаса, ә ул инде — китапның титул битеннән җаныңа керердәй булып текәлеп карап торган чал чәчле, какчарак сөякле шагыйрь агай: «Тагын бер яз саубуллашып үтте, ядкяр итеп чәчәкләр биреп» — дип җаныңны сискәндереп куя.

Икенче тапкыр чын-чынлап шигырь алдында югалып калуым Равил Фәйзуллин исеме белән бәйле.

Менә шундый сәгадәтле моң, билгесез ашкынулар белән тилереп яшәгән гомер иртәсендә язмыш дигән хакыйкать иясе безне — Уразмәт урта мәктәбе укучыларын, шул исәптән мин фәкыйрегезне дә, һич уйламаганда, чын шагыйрьләрнең берсе белән дә таныштырды: әдәбият дәресләрен Рәдиф Гаташ алып бара башлады. Дәреслекне тамырга кирәк: авылдашым Дәүфит Раянов әйтмешли, «Үдәрмәт малайлары» Шигырь турында беренче олуг сүзне нәкъ менә аның авызыннан ишеттеләр, яңа исем-атаулар белән аның аша таныштылар. Ул беренче көннәреннән үк, һәр дәрес саен социалистик реализм кануннарын өйрәнүгә багышланган ун-унбиш минутлык мәҗбүрияттән соң «ирекле» темага күчә торган иде һәм бу ирекле темага үткәрелгән дәресләр еш кына өй эше итеп тә бирелә иде. Кыскасы, без дөнья әдәбияты үрнәкләре белән тәүге тапкыр аның ярдәме аша авыз иттек. Казанның үсеп килүче яшь шагыйрьләре иҗаты белән дә безне нәкъ менә ул — Рәдиф Гаташ таныштырды.

Шәхсән минем үземне, Равил Фәйзуллинның иҗат дөньясына Рәдиф Гаташ җитәкләп алып керде. Бу хәл болайрак булды.

1965 елның җәе иде, безне — Уразмәт урта мәктәбенең шигъри күңелле алты малаен (алар арасында Зөлфәт белән Фәрит Гыйльми дә бар иде) — хәлфәбез Рәдиф Гаташ республика туристлар слетына (асылда, уйла, шәһри Казанның әдәби мохите белән таныштырырга) җыеп алып килгән иде. Пароходтан төшү белән ул безне шәриктәше Равил Фәйзуллин хозурына иартеп алып китте. Әмәт тавы итәгендә алма бакчасына төренеп утырган җыйнак кына бер йорт. Тәрәзәсе урамга караган тар гына бүлмә. Күп булса без анда ике-өч сәгать сөйләшеп утыргансыздыр, әмма ничек иркенәеп чыгып киттек без аннан. Ике «яшь аван-

тюрист» илләр, шәхесләр хакында гәп корып утыралар, бер селтәнүдә авторитетларны тетеп аталар, юкка чыгаралар, йә буласа гавәмгә бөтенләй билгеле булмаган яшел авызларны күккә чөеп мактыйлар, ә без — математика дәфтәренең арткы битенә кешеләрдән яшереп кенә шигырь сырлаучылар — журнал-газеталар актарып утырабыз. Ә аларда — шигырьләр, шигырьләр... Әллә нинди, беркемнекенә дә охшамаган, көч-акыл ташып торган, неоннар балкышы, кыйтгаларны тоташтырырлык фәлсәфә, гамәли уй-гамь белән сугарылган Равил Фәйзуллин шигырьләре...

Ләкин, барыннан да бигрәк, гадәти булмаган сүз-гыйбарәләрнең, фикер-төшенчәләрнең һич уйламаганда шигырь тукымасына кереп китүе, саллы-салмак музыканың кинәт зеңләп өзелүе, метафора-образларның «ажагандай» ялтырап-ялтырап алуы — кыскасы, яңача шигъри сөйләм, яңа дөнья (!) әсир дә иткән, бераз аптыраштa да калдырган иде бугай безне ул чакта. Билгеле, әдәби терминнар телгә соңрак килеп кергәндер, гомумән, шагыйрь үзе дә, аның турындагы карашларым да тулаем соңрак формалашкандыр, әмма әлеге очрашудан соң мин Равил Фәйзуллинны урылмаган кишәрлек башында аякларын киң итеп басып торучы Җир хуҗасына, ягъни атасы нигезеннән «башка» чыккан яшь йорт хуҗасына охшатып калган идем. Әйе, беренче карашка ул, бәлкем, бераз һавалырактадыр, исәп-хисаплыдыр, тик ул — кодрәтле, ул — зирәк акыллы, ул — үз көченә ышанучан.

Гаҗәп тә түгел: аннан соңгы иҗат юлында шагыйрь моны исбатлады да. «Нюанслар иле» матбугатта басылып чыккан көннәрдә — әдәби җәмәгатьчелек умарта күче кебек гөжләгән бер мәлдә — булган әлеге очрашу вакытында Равил Фәйзуллин тамагын каты гына кырып куеп: ***«Юк, мин барыбер үземнең хаклы икәнлегемне исбат итәчәкмен. Татар шигъриятендә такмаклардан тыш башка төрле шигърият тә яшәргә тиеш!» — дигән иде.***

Пәйгамбәрләр —
ничек кирәк таба —
шулай иңдерәләр вәхине!
...Җирдәгеләр, әйдә, теләсәләр,
хорга басып, хорей белән
кабул итеп,
дога кылсыннар.

Һәм, әйтергә кирәк, вакыты-вакыты белән аңа нинди генә уклар яудырылмасын, аны нинди генә гөнаһларда (кичерешләр шагыйрен — салкынлыкта; ирекле киңлекләргә ашкынуын — формализм чире белән авыруда) гаепләмәсеннәр, ул беренче адымнарыннан ук үзенең кем булып тууын, алдында нинди максат торуын аңлап эшкә кереште; аның җиңе һәрвакыт сызганулы, биле буулы булды. Беренче эшен ул максатка ярашлы «эш кораллары» булдырудан — сүз белән осталарча эш йөртергә өйрәнүдән, яңача ритмика, рифма, образлар системасы тудырудан — башлады (җир казыйм дисәң — көрәге, өй салыйм дисәң — балтасы кирәк ләбаса): беразга, ориентирлар тәмам ачыкланганчы, тормыш тәҗрибәсе тупланганчыга кадәр, фикерне хисләренә башлык итеп куйды да, акыл «миназләгечләре» ярдәмендә дөнья агышын күзәтергә керешге. Иҗатының башлангыч чорындагы сәер шигырьләре — кыйтгалар һәм халыклар язмышын «телефон аша» гына хәл итү, кеше күңелен онытып торып, глобаль галәми уй белән артык мавыгып алу менә шулай дөньяга килде бугай инде. Ләкин болар, безнеңчә, вакытлы күренеш, һәр талантлы яшь кешегә хас булганча берникадәр салулап алу булырак кына, һәм шул чор контекстында, «яңа» әдәбият туу процессында кабул ителергә тиеш иде. Хәер, яшьлек авыруы ул тиз үтүчән була һәм шулай булды да. «Кеше җаны, Кеше күңеле — үзе бер галәм, Шигъриятнең төп вазыйфасы шул галәмне өйрәнү» дигән төшенчәне тирәнрәк аңлый барган саен, Равил Фәйзуллинның иҗаты да яңадан-яңа төсмерләр алып байый төште, тирәнәйде, ягъни «суы аска китте», ялган пафослар, билгесез көрәшкә чакыру урынына Кешелеклелек, Туган җир, халык язмышы турында уйлану мотивлары алгы планга чыкты. Миңа калса, 70 еллар азагы, 80 еллар башында шагыйрь чын мәгънәсендә гуманистик идеяләр белән сугарылган фәлсәфи-лирик әсәрләр тудыру осталыгына ирешге, нәкъ менә шушы чорда ул макро-дөнья белән микро-дөньяны бердәй күкрәгенә сыйдыра алырлык, аларның гармоник уртаклыгын тоеп яшәрлек шәхес булып өлгерде. Ул — утыз яшәр ир-егет иде...

* * *

Хәер, алгарак киттем бугай, «уй йомгагын» киредән сүтә башлыйм әле. Мин бит сүземне «шигъри дөньялар әзлим» дип башлаган идем ләбаса.

Бу дөньяда һәрбер адәм баласына рухи терәк кирәк, һәрбер адәми затның бу тормышта үз кыйбласы булырга тиеш. Кемдер аны Ходайга сыгынудан, кемдер сөю-сөелүдән, кемдер мал җыюдан, кемдер башка бер нәрсәдән табадыр. Кемдер... шигъриятгән! Шөкер, бездәй «юләрләргә» хәзергә хәтле Шигърият гел терәк була килде. Дөнья бит бу: гомер узган саен әшъяларның җете төсе уңа төшүе дә бик табигый, «башны салларга салып» агып китәсе килгән көннәр дә булмый калмагандыр, әмма хәяттә тормыш юлының иң текә үткелләрен, хәтәр борылмаларын кичкән чагында да сине һәлакәттән йолып кала алырлык, сүнәм-сүнәм дигәндә дә күкрәгеңне утлы күмер кебек яндырып-өтеп торырлык бер Бөек көч барлыгын тоеп-аңлап яшәү үзе бер чиксез бәхет икән лә ул! Шуңа да гомеремдә җан азыгы булырлык бер генә кәлимә сүз әйтә алган һәркем каршында башымны иярга дә әзермен — төчелек булып аңлашылмасын тагын. Бу нәүбәттән, Равил Фәйзуллин шигърияте минем өчен җанга ныклык, иманга нур өсти торган шигърият булды дип әйтер идем.

Ләкин бу урында шунысын да искәртеп үтү артык булмас, ахры: Шигырь — изге җан ул! Шулай булгач, аны аңлату миңа кайчак бер-бер гөнаһлы эштер сыман тоела башлый. Бәлки аны аңларга гына омтылырга кирәктер. Алланы аңларга тырышкан кебек.

Әгәр дә мин фәкыйрегез Шигырь турында, чорыбызның күренекле шагыйрьләреннән берсе булган Равил Фәйзуллин турында сөйләргә дип кулына каләм алырга җөрьәт иткән икәнмен, моны «аңлатырга омтылу» дип түгел, «аңларга тырышу» дип кабул итәргә кирәктер.

Мәгълүм ки, олуг шигърият шагыйрьнең чынбарлыкка үз мөнәсәбәтен белдерү җирлегендә генә туа ала, һәрбер олуг иҗат — ул шагыйрь җанының, аның уй-кичерешләренең, яшәү рәвешенең, фәлсәфи һәм рухи эзләнүләренең ак кәгазьгә күчкән моделе, сүз-образлар ярдәмендә ясалган ихлас сурәте. Ләкин чын шигърият реаль чынбарлыкны да, җанга үзгәреп күчкән, хыялый тирәнлекләрдә



Шигырь сөючеләр белән очрашулар — шагыйрь иҗатының аерылгысыз өлеше ул. Сулдан уңга — танылган балкар шагыйре Кайсын Кулиев, татар шагыйре Хәсән Туфан, урыс шагыйре Сергей Орлов. Равил Фәйзуллин чыгыш ясый.

*1976*

яшәүче чынбарлыкны да чагылдырырга тиеш. Н. Гумилев сүзләре белән әйтсәк, реаль чынбарлык ул — Күк, ә шагыйрь күңеле шул Күкне чагылдыручы Күл өсте. Бу чагылышның соңгы нәтиҗәсе,— ягъни Шигърият,— бер үк вакытта күктәге сурәтләрнең байлыгына да (анда нинди кошлар оча, аның болытлары нинди төстә, яр өстеннән нindirәк агачлар карап тора), Күлнең күзе нindirәк билгеләргә (суы чистамы аның, тирәнлеге, су өстендәге дулкыннар ничегрәк һ. б.) ия булуга да бәйле. Йә, без тормыш бизәкләрен төрлебез төрлечә күрмибез дә, аларга һәркайсыбыз үзенчә бәя бирмибезмени?

Шушыңа нисбәтән рәвештә, шагыйрьләрне шартлы рәвештә ике төркемгә — «шигъри дөнья»ларын тудыра алганнарга һәм, киресенчә, тудыра алмаганнарга бүлеп карарга мөмкин булыр иде. Була шундый шагыйрьләр — аларның иҗатында чынбарлык ничек бар шулай чагылыш таба, андый шигырьләр сине сискәндерми дә, сихерләми дә һәм, табигый буларак, андый иҗат тора-бара, мае бетә башлаган шәм кебек, әкренләп сүнә, тоныклана бара. Заман-чор төсмерләрен тоюдан мәхрүм ителгән «күрә караучы», ягъни күз алдындагы проблемаларны да абайлый алмаучы шагыйрьләр шушындый җирлектә туа. Шагыйрь өчен, «дальтоник» булуга караганда, «күрә карау» чире белән авыру хәтәррәк, безнеңчә.

Була икенче төрле шагыйрьләр — алар чынбарлыкны бөтенләй башкача, үзләренчә, әмма бөтен тулылыгында, каршылыклар бердәмлегендә кабул итәләр; андыйларның һәр әсәре, үзенчәлекле аһәңгә ия булу өстенә, тегеләйме-болаймы, алдагы иҗат үрнәкләре белән органик тоташалар, төп-идея-мотивларны үстерә төшәләр, аңа яңа төсмерләр өстиләр. Шул рәвешле, һәр шигырь аерым ояда гомер кичерсә дә, ахыр чиктә композицион яктан гомуми бер кәрәзгә берләшә һәм шушы нигездә, безнеңчә, шагыйрьнең Шигъри дөньясы барлыкка килә.

Болай дигәндә, танылган литва шагыйре Эдуардас Межелайтисның мәгълүм сүзләре хәтергә килә. ***«Әдип үз дөньясын тудырырга тиеш,***— дигән иде ул.— ***Бу бер дә реаль чынбарлыктан качу дигән сүз түгел. Киресенчә, анда башкалар күрмәгәнне күрә белү һәм чагылдыра алу дигән сүз. Шагыйрь өчен үз иҗат омтылышларының дөреслегенә фанатикларча ышанудан да әһәмиятлерәк нәрсә юк. Алай булмаса, берни дә барып чыкмаячак. Үз идеяләренә инанмаган яки үз идеяләре бөтенләй дә булмаган әһле шагыйрьләр кеше таптап, изеп бетергән урам ташларына охшап калалар».***

Равил Фәйзуллин исә, нәкъ менә шагыйрь әйткәнчә, «үз иҗат омтылышларының дөреслегенә фанатикларча ышанып» яшәде. Әйе, ул — татар шигъриятендә беркемнекенә дә охшамаган үз дөньясын тудырган, тудыра алган бәхетле шагыйрь. Бу дөньяның Күге — биек, тирән; Күленең суы — чиста, тоник; төсләр спектры — бизәкле, бай; нигез ташлары — ныклы, тотрыклы.

Хәзер без моны Олы Иҗат биеклегеннән карап, утызбиш еллык иҗади үткәннәргә бәя биреп әйтәбез һәм аны табигый бер нәрсә, тормыш тарафыннан расланган, алдан ук тәкъдир тактасына язып куелган билгеле язмыш итеп кабул итәбез. Хәлбуки, берәүнең дә гомер юлы энҗе-асылташтан гына түшәлмәгәнен аңлаган хәлдә, шуны да икърар итик: безне болай уйларга озак еллар буена шагыйрь үзе күнектереп килде түгелме соң? Яшәү рәвеше, әдәбиятта яулаган биеклекләре, иҗаттагы һәм көндәлек тормыштагы тынгысызлыгы, яши белүе һәм яшәүне ярата белүе белән күнеКтерде бугай ул безне моңа. Хәзерге исән шагыйрьләрдән, һәрхәлдә, илле бусагасына аяк баскан иҗат әһелләреннән үзен-үзе кабаттан тудыру, формалаштыру, үстерү өчен,— ягъни, ахыр чиктә, олуг максатына ирешү, шагыйрьлеген һәрдаим һәм һәркайда исбатлап торў, исем-имиджының сафлыгын саклау һәм аклау өчен Равил Фәйзуллиннан да газаплырак рухи эзләнүләр алып барган, ихтыяри һәм физик җегәр сарыф иткән, шул ук вакытта өлгерлек һәм зирәклек күрсәткән башка берәүне хәтерләмим мин. Әйе, әйе, ул хәтәр борылмаларны зирәкләрчә, үз вакытында әйләнеп үтә белде, кайчак гел кирәкмәгән урында компромисска да баргалады бугай, эндәшергә-чаң сугарга кирәк чагында юл читендә калган чаклары да булмады түгел, әмма ул хәрам уеннарда катнашмады, кеше язмышы белән уйнамады. **Кыскасы, ул үз эшен белде — әдәбиятка җинүче булып килеп керде, тикшеренүче-эзләнүче булып, иманын раслап яшәде һәм яши.** Гомумән, ул актив тормыш алып бара торган, һәр яңалыкка һәвәс, мавыгучан шәхес. Бәлки, шуңадыр ул, текә генә басып йөрүче, үтә дә сак кайбер агайлардан аермалы буларак, вакыты-вакыты белән (тегеләр күзлегеннән караганда, әлбәттә) малайчарак адымнар да ясап куйгалый. Әнә ул бервакыт ерак араларга йөзү белән мавыгып китте, хәтта берме-икеме тапкыр, мөмкинлекләрен сынап карау өчен, «Компрессорный» күпереннән Киров дамбасына кадәр, ун чакрымлап арага үзенә-үзе йөзү ярышы да оештырды. Билгеле,

тамашачысыз нинди ярыш инде ул — һәм билдән югары суга керергә дә чирканып торган шагыйрьләр, әдәбият-сәнгать әһелләре, аны, көймәләргә төялеп, һау-һаулап финишка кадәр озата бардылар. Шулай, җәй житсә Равил Фәйзуллин, бер генә сәгать буш вакыты булса да, су буена төшеп китә, теннис уйный, кышын исә ачы буранда да чангы юлыннан кайтып керми. Әйе, ул «Вакыт эчендәге вакытны» таба белә.

Яшәү — кыска. Ажагандай!
Үтә гомер пейтнотта!

Бөтен өмет, бөтен ышаныч —
Үзем өчен үзем генә белгән
Вакыт эчендәге Вакытта!

Дөрес, читтән караганда, Равил Фәйзуллин су өстендәге күбектәй тормышта җай гына тирбәлеп яшәде кебек, ләкин аның «су төбенә» китеп торган чаклары да булмады түгел (озын сәфәргә бергә чыккан дусларны югалтулар, сөйгәнең белән ара салкынаюлар, «җаваплы эштән» үз теләгең белән китеп торып, хөрлеккә омтылулар — азмы алар канына тоз салып торырдай хатирәләр кеше күңелендә!). Ләкин:

Суыр көн дә коллыгынны!
Җаныңнан чыгар чөйләп!
Ирегең тоеп суласаң,
исемең — Кеше димәк.

Менә шулай, үзенең «кысң» хәлен дә шагыйрь файдага әйләндерә белде — асылда ул гавәм күзеннән югалып торып акыл туплап ятты, йомшак кәнәфидән сикереп төште дә, «диңгез төбе гаувасляры» арасына чумып, энҗе-мәрҗән эзләде һәм эшләде дә эшләде...

Сәясәттән ераклашкан саен —
Табигатькә ныграк елышам.

...Тәгәрәде кызыл кыргый алма
Елан үтеп киткән юл аша.

Дөрес, мондый адымнар ясау шагыйрьдән күпмедер күләмдә егетлек һәм фидакарьлек тә таләп иткәндер. Шулай икән, бу инде аз түгел. Шагыйрьнең ике томлыгы басылып чыгу моның ачык дәлиле булса кирәк. (Җәяләр эчендә генә әйтеп үтик, үзе исән чагында ике томлык шигырьләр җыентыгын Сибгат ага Хәким генә чыгара алган иде.) «Эш агачы юмарт җимеш китерер» дигәндәй, икенче томның корректурасын укып тапшыргач, ул: «Ярый әле үз вакытында бераз эшләнеп калынган», — дигән иде рухи бер канәгатьләнү белән. Тирәнтен ышанып әйтергә мөмкин, ***Равил Фәйзуллин яшәеш-тормышның бик тә гади, әмма бик тә авыр бер канунын үзләштергән шәхес булырга тиеш: Кеше булу — ул, барыннан да элек, Кеше булып калу өчен туктаусыз көрәш алып бару дигән сүз. Бу — табигый халәт түгел, шуңа да шәхес булу — ул өзлексез эзләнү, үсештә генә иҗат итәлә ала һәм, алда әйткәнемчә, бик күп көч сарыф итүне таләп итә.***

Кызык, Равил Фәйзуллин яшь иҗат әһелләре, сәләхиятле егетләр белән аралашып-дуслашып яши. Бу, бер яктан, яшьлектә калырга тырышу кебек табигый бер халәт булып аңлашылса, икенче яктан, яңа буыннарның уй-теләкләрен, идеал-омтылышларын тоеп-күзәтеп яшәү дип бәяләнергә тиештер, мөгаен. Ә, бәлкем, шигъри балачактан, шигъриятнең мәңге дә яшь, мәңге дә яшел, хәрәмсез иленнән аерылырга теләмәүдер бу? Ни генә булмасын:

Бүтәннәр юри уйныйлар,
Мин, юләр, чынлап уйныйм.
Ихлас ышанып уйныйм.

Барсын беләсе килә.
Кайчак көләсе килә.
Уендашлар шаркылдыйлар,
Миңа күз яше килә.

Шушы хакыйкатьне истә тотып микән, Равил Фәйзуллин, гадәттә, үзеннән яшьрәкләр белән күрешкәндә, күзгә карап:

— Исәнме, егет? — дип эндәшергә ярата.

Бу сүзләргә ул, миңа калса, гадәти исәнлек-саулык сорашудан бигрәк, фәлсәфи-этик мәгънә төсмере сала кебек: «Ир-егетме син, янәсе».

Чынлап та, ир-егетме син? Ир-егетләрме без?

Моңа һәркем намусы каршында үзенчә җавап бирер, әлбәттә, ләкин «ир-егет»лек көннән-көн ныграк девальвацияләнә барган бер мәлдә, ил-халык язмышы турында уйланып кына калмыйча, гамәли эш күрсәтү аеруча актуаль зарурият булып күз алдына килеп баскан бер чорда, бу гыйбарә һәркем өчен риторик сорау булудан битәр, иман-кыйблага юл күрсәтүче маяк хезмәтен үтәргә тиештер.

Равил Фәйзуллинга килсәк, аның алдында мондый дилемма тормады кебек. Уй — шәхси омтылышларында гына түгел, социаль яктан да үтә дә актив шәхес; әйе, үзен дә онытмаган хәлдә, ул шигырьләре белән һәрдаим туган халкына хезмәт итеп килде, иманына тугры булып калды. Аның көче дә, бәхете дә шунда, шушы ике башлангычны — ике өйрәтелмәгән тайны — бер мичәүгә җигә алуында. Шигырьләре һәм иҗтимагый эшчәнлеге — моның ачык мисалы. Ә шагыйрьнең эчке җанын аңламый торып, иҗатын аңлау мөмкин түгел.

* * *

Равил Фәйзуллин — шагыйрь буларак та, кеше буларак та иртә җитлеккән шәхес. Тормышта балалык, иҗатында өйрәнчеклек чоры булды микән аның? Шикләнәм. Чөнки ул егерме яшендә хәзерге илле яшьлек Фәйзуллиннан җитдирәк, хәтта прагматиграк булып тоела миңа. **Ул — үргә каршы аккан агымсу кебек; кешеләр, гадәттә, үткәннәрдән киләчәккә — яшьлектән картлыкка таба үтеп баралар, ә ул, киресенчә, киләчәктән үткәннәргә — картлыктан яшьлеккә таба хәрәкәт итә сыман.** Аңлата алдым микән, һәрхәлдә, илле яшендә ул, тыштан караганда, егерме яшендәгедән яшьрәк, хыялыйрак, җилбәзәгрәк сыман.

Алай үтелгән Вакыт...
Болай үтелгән Вакыт...

Яшәп үтелгән Вакыт,
Яшьнәп үтелгән Вакыт —

Бүтәннәр бәхете өчен
сарыф ителгән Вакыт!

Гайре табигый түгелмени: унбиш яшьлек малай шагыйрь, ата-ана оясыннан чыгып борын асты кибәргә дә өлгермәгән үсмер, үткән гомерләр турында уйлана!? Юк, гайре табигый түгел! Чөнки бу «үткән гомер». Үткәнгә түгел, ә бәлки, программ идея-максат сыйфатында, Киләчәккә төбәлгән... Искә төшерик әле: йә, кайсыбыз соң көннәрдән бер көнне, үсмер чакларда, һичбер сәбәпсез моңсу гына ерак кырлар түренә күз текәп, киләчәкнең гүзәл сарайатауларын күңелебездә торгызмады икән дә, яшәүнең асыл мәгънәсе турында уйланып бер генә мизгелгә олыгаеп алмады икән? Равил Фәйзуллин кебек уйланучан һәм күзәтүчән сизгер күңелле җан ияләрендә бу тойгы, мөгаен, аеруча иртә уяна торгандыр... Уяна торгандыр да, мәңге сүнмәслек гамь-учакка әвереләдер! Чөнки:

«Сөям» дип сөйрәлә сөйрәлчек,
«Килдем» дип кинәнә килмешәк.
Тапмаслык таралган туганнар.

Үзәккә үткәзеп бар үтен
Үтә Вакыт...

Аның иҗатында Вакыт төшенчәсенең тоташ бер агым булып кабатланып килүен, шагыйрьнең әледән-әле Яшәү турында гасабилы тойгы-кичерешләргә бирелеп алуын шуның белән генә аңлатырга мөмкин. Әйе, «кошлар оча-оча югала» шул:

Менгән саен, күтәрелгән саен
ачыла һаман — офык-киңлекләр!..

Ә күзләрне
әкренләп
томан сара.
Кими бара —
жетелекләр,
үткенлекләр,
мөмкинлекләр...

Ә күзәтүчән дигәннән, Гете мең мәртәбә хаклы: ***«Хәят шулкадәрле киң һәм бай, тормыш шулкадәрле күп бизәкле ки, шуңа да шигърият бервакытта да сюжетка кытлык кичермәячәк. Әйдә, шигърият чынбарлыкны өйрәнергә тиеш түгел дип юкка сафсата сатмасыннар; шагыйрьнең таланты гап-гади күренешнең нинди дә булса кызыклы ягын тасвирлый белүендә ачыла да инде».***

Равил Фәйзуллин исә, беренче иҗат тәҗрибәләреннән үк, үзен нәкъ менә чынбарлыкның бер кеше күзенә дә ташланмаган якларын (Айның «караңгы» ягын) күрә алучы шагыйрь-рәссам итеп танытты, аның шигърияте шуның белән кызыклы да инде. Менә аның унҗиде яшендә язган бер шигыре:

Кара карга оясы —
ап-ак кар бүрке.

Яшел чыршы ышыгында
кызыл төлке.

Беренче карашка биредә ис китәрлек бернәрсә дә юк кебек: нәрсә, гадәти бер кышкы урман күренеше тасвирланган инде, диярга дә мөмкин булыр иде, ләкин соңгы юлны укуга барысы да үз урынына баса — төсләр антитезасына корылган сурәт (яшел чыршы ышыгында уттай кызыл төлкенең чагылып китүе) изрәп яткан урманны кинәт гөлт итеп кабызып җибәрә дә күңелләрне сагаерга мәҗбүр итә: чү, бөтен очракта да идиллиягә ышанып бетәргә ярый микән соң әле?

Дөрес, шагыйрьнең кош теле хәтле генә бу шигырендә гомумиләштерүләр, анализ, нәтиҗә чыгару кебек шигъри атрибутлар да юк (алары киләчәктә булыр), ләкин иҗатының башлангыч чорында ук ул бер деталь, образ ассоциациясе аша да гомумкешелек алдында торган проблемалар кинлегенә чыгарга сәләтле сүз остасы икәнлеген сиздереп куйды. 1962 елда иҗат ителгән «Кадак» шигыре аның шушы юнәлештә эзләнүләренең беренче өлгесе булды дисәк тә хата булмастыр, мөгаен. Әйе, дөнья бер кадактан тора, ул югалдымы, тормышның рәте-чираты китә: әнә, тимерчелектә кадак булмау сәбәпле дага төшеп калган, дагасыз атның аягы сынган; ат баралмагач, командир яраланган; командир үлгәч, солдатлар качкан; солдатлар качкач, халкы кырылган... Дөрес, бу образ, композицион алым аңа инглиз халык иҗатыннан күчкән, әмма Равил Фәйзуллин дөньяны танып белүгә сусаган, тынгысыз җанлы шагыйрь буларак, бер тапкан ачкычны югалтмый инде, аны кирәк булган саен, яңадан-яңа конструкцияләрдә куллана килә. Бу яктан «Яңгыр» шигыре аеруча гыйбрәтле.

Дөньяга хәвеф килгән: коргаксыган Җир яңгыр көтеп ята, гөлләр көтә, Кеше көтә аны... һәм төннәр чымырдап китә — хәтта кырда чалкан яткан тырма да, тимер бармакларын сузып, зарыгып яңгыр көтә икән бит. Ләкин «яңгыр» һәркемгә дә тигез ямьмый ул: «болыт күл өстенә килеп койды орып, койды оеп... Кырда эсселектән кызган тимер тырма күккә табынып кулларын сузып калды...» Житәр: «яңгырсызлык» афәтен — бәлки, рухи яңгырсызлыктыр ул! — моннан да үтемләрәк итеп әйтеп бирү мөмкин түгелдер, тырма тешләре бәгырьләргә үтеп керде ләбаса.

Деталь аша — гомумиләштерүгә! Житмешенче еллар башында шагыйрь, тормышның кайсы гына почмагына күз салса да, шушы девизга тугрылыклы булып кала. Ул татар шигъриятенә моңарчы әдәби кулланылышта булмаган, хәтта, әйтергә мөмкин, башка да сыймаслык башбаштаклык булып тоелган бик күп сүз-гыйбарәләр һәм деталь-образларны алып керде, башкалар күзе күрмәгән тормыш күренешләрен шигъриятнең өйрәнү объектына әвереллерде. Ләкин хыял канатларында, тормышны чиксез ярату җирлегендә туган мондый лирик детальнең фотографик, натуралистик, «тормышчан» деталь белән берниндн дә уртаклыгы юк иде, чөнки сискәндергеч өлге табу шагыйрь өчен үзмаксат түгел, ә бәлки һәрдаим үзгәреп торучан чынбарлыкны өйрәнү чарасы иде. Бу нәүбәттән «Метаморфоза» (1963) шигыре аеруча характерлы. Шагыйрь биредә бер деталь, бер кинаяле образ аша тулы бер халык язмышын, ул кичергән трагизмны сурәтли алган. Сарайда аунап яткан иске, тутыккан колун балта образы — ул («түтәсе

иңгән — күп сугудан, йөзе тонган — тутыгудан») кулда көч-власть бар вакытта ярты дөньяны тетрәтеп торган («бар де колунның ялтыраган чагы,— йөзәр яшьлек имәннәрнең калтыраган чагы»), хәзер инде картайгач, хакыйкать каршында җавап бирер вакыт җиткәч, үлеме белән тартышып ятучы теге еллар (һәм бүгенге көннәр!) героеның — димәк, тулы бер эпоханың — фаҗигале күләгәсе. Ләкин нинди күләгә ул? Тулаем татар халкының фаҗигале язмышымы, әллә Сталин хакимияте җимешеме, йә булмаса бүгенге Рәсәй чынбарлыгымы? Уйла, нәтиҗә яса...

Инкяр итмим, бу төр шигырьләр, бәлки, шагыйрьнең киң колачлы иҗат дөньясында үзәк урынны да алып тормыйлардыр, ләкин нәкъ менә шушы чорда ук (минемчә, шагыйрьнең эволюцион үсешенең беренче этабы 1958—1966 елларга туры килә), **шушындый кискен антитезага, контраст буяуларга, образ-метафораларга бай, гуманистик идеяләр белән сугарылган әсәрләрендә шагыйрьнең һәм рухи кыйбласы, һәм форма-өслүб өлкәсендәге эзләнүләре, һәм фәлсәфи-этик инанулары, һәм фикри-хиссеми ориентирлары һәм, гомумән, ПОЭТИКА турындагы карашлары ачык төсмерләнде кебек.**

Схема рәвешендә генә әйтсәк, ул түбәндәгеләрдән гыйбарәт булыр иде. **Равил Фәйзуллинның бер төр шигырьләрендә еш кына хисләр фикерне түгел, ә бәлки фикер хисләрне тудыра һәм бу фикер аның җанын шулкадәрле биләп ала ки, алар, ахыр чиктә, аңны яктыртып җибәрерлек хискә әвереләләр.** Шагыйрь әледән-әле, тасвирлаудан битәр, сөйләү алымына күчеп куйса да (бу бигрәк тә «Күмәч пешерүчеләр», «Гадиләргә гимн», «Көрәшчеләр» кебек күләмле әсәрләрдә сиземләнә), афористик фикер, көтелмәгән әйләнмәләр укучыны ахырга кадәр киеренкелектә тотарга ярдәм итә. Планетар идеяләр нигез булып яткан бераз салкынчарак әсәрләр белән бергә («Шагыйрь өчен тиран нәрсә ул», «Кояшка атылган ядрәгә», «Парикмахерскаяда», «Төштә»), үтә дә кешелекле, халыкчанярача, садә аһәңле «Кер чайкыйлар кызлар», «Ажаган», «Җилфердәүче керләр җыры», «Башны салларга салып...» кебек әсәрләре дә шушы чорда иҗат ителә. Моның белән без шуны әйтергә телибез: санап киткән әлеге әсәрләрендә шагыйрь, ниһаять, Шигъриятнең алтын баганасы булган образ һәм ул тудырган хис бердәмлегенә — гармоник ассоциациягә ирешә. Мәгълүм ич, әсәрдә Образның үзеннән бигрәк, ул тудырган хис-эмоция зуррак әһәмияткә ия. Әгәр хисэмоция чынлап та илаһи кыйммәткә ия икән, образ да шул ук югарылыкка күтәреләчәк. Шушы берлектә генә хисләр поэтик яктан камил, чиста була ала, чөнки алар имитация, чагыштырулардан аермалы буларак, күңелнең иң тирән чоңгылларында бөреләнәләр.

Башны салларга салып,
Китәсе иде агып.

Дәшәрләр иде әле дулкыннар
бер шагыйрь җанны танып...

Күренә ки, биредә көтелмәгән чагыштырулар да, ис китәрерлек метафора-эпитетлар да юк, ә шигырь тәэсир итә. Аның көче нәрсәдә соң? Образ-сурәт тудырган хисләрнең тасвирый ассоциациясендә: шагыйрь турыдан-туры берни әйтмәсә дә, киная белән генә, кеше гомеренең, аның җанының тулы бер сурәтен, фаҗигасен, кичерешләр гаммасын җанландырып бирә алган лабаса. Бу яктан караганда, Равил Фәйзуллинның кыска формаларга бик теләп мөрәҗәгать итүе, алай гына да түгел, аны билгеле бер иҗат принцибына әверелдерүе аеруча тәкъдир ителергә хаклы. Бу төр шигырьләрендә ул үзен чын мәгънәсендә сурәтләр остасы итеп танытты, татар шигъриятенең афористик фикерләү чикләрең киңәйтте. Шул рәвешле шигырь-афоризмнар, шигырь-метафоралар дөньяга килде.

Җил бик тиз актарды әкият китабын.

*(«Балачак»)*

яки:

Кыны тулы кан.
Тышында чәчәк сурәте.

*(«Тарих»)*

яки:

Торналар китеп бара.
Кош канатлары орыңгач,
Болытларның күңеле тулды,—
*(«Көзге яңгыр»)*

—дигән бер, ике, өч юллык шигырьләрне, кем әйтмешли, шәрехләп торуның кирәге юк, һәркем үзенең фантазиясе мөмкинлек биргәнчә фикер йөртсен, нәтиҗә чыгарсын—шагыйрь укучыларын Капу мәйданына чыгарып куя, калган юлларын алар үзләренчә, мөстәкыйль рәвештә дәвам итәргә тиешләр.

Кызык кына килеп чыга түгелме соң: **бер яктан, Равил Фәйзуллин (һәрхәлдә, иҗатының башлангыч чорында) сөйләм-санау алымыннан да бөтенләй баш тартмый, икенче яктан, кыскалыкка, «сүзләргә кысан булса да, фикерләр иркенлегенә» омтыла.** Ләкин бередә бернинди дә каршылык юк. Бу метаморфозаның нигезендә гади генә бер закончалык ята: Равил Фәйзуллин—катлаулы, «күп сыйдырышлы» Шәхес; аның җанында кулга өйрәтелмәгән кыргый аю да, гөл күзенә кунган нәзберек күбәләк тә янәшә яши, ә киң колачлы, беркемнекенә дә охшамаган бай иҗатны шундый затлар гына тудыра ала.

«Ташларны барлар вакыт!»—Равил Фәйзуллинның иҗаттагы төп мәсләге менә шушыннан гыйбарәт иде. Кайбер шагыйрьләребез юл өстендәге шомарып беткән, сайландыктан калган ташларны җыеп йөргән арада, ул шигърияттә киң колачлы, иркен сулышлы, күп төсле мозаик панносын тудыру өчен, тормышның җил-давылына карамыйча, киртләч-киртләч үткелле мәрмәр кыялар иленә сәфәргә кузгалды.

Җилме, син?
Бәр! Бәр!
Бозмы, син?
Бәр! Бәр!
Без—Мәрмәр!

Җилкәбездә тоеп, юк, барлык вөҗүдебез белән аңлап яшибез ләса, тиңдәшсез көрәштә арып егылмау өчен, рухи һәм гамәли дошманы каршында тез чүкмәү өчен татар халкыннан, аның шагыйрьләреннән икеләтә ныклык сорала. Ә мәрмәр, беләбез, ныклык, чыдамлылык билгесе ул! Шушы мәгънәдә Равил Фәйзуллин гади генә төшенчәләрне (мәрмәр образы йөздән бере генә) заманның төп билгеләрен тасвирлый алырлык биеклеккә күтәрде... Һәм алар белән бергә үзе дә күтәрелде.

* * *

Һәр олы шагыйрьнең иҗатында алтын хәзинәгә тиң бер дәвер була. Равил Фәйзуллин да кичерде андый дәверне. 1969—1972 еллар арасында, аеруча 1971 елда үтә дә рухланып, яшәү шатлыгыннан исереп дигәндәй иҗат итте ул һәм эволюцион үсешендә текә борылыш ясады. Шагыйрьнең үз сүзләре белән әйтсәк, монарчы аның иҗатында әлегә нинди дер үсемлек чаткылары сизелә иде: буй җитүгә дә карамастан, «терсәкләр» тырпаебрак торалар, «җилкә-күкрәкләр» дә ир-егетләрнекечә тыгыз, камил мускулга төренеп өлгермәгәннәр. Җитмешенче еллар ахырында исә тулышу чоры төгәлләнде, һәкъ менә шушы чорда аның шигъриятенә тагын бер көчле вә дәртле агым—мәхәббәт лирикасы килеп кушылды. Дөрес, шагыйрь Мәхәббәт турында һәм, гомумән, лирик шигырьләрне элек тә язмады түгел, язды, ләкин алар шул дәвер иҗатының кыйбласын билгеләрлек дәрәҗәдә үзәк урынны алып тормыйлар иде. Ә инде бераздан, «кеше күңеленең монарчы җырланмаган» бизәкләрен табарга омтыла башлау белән, Равил Фәйзуллин шигырьләрендә лирик башлангыч та көчәя төште. Бу нәүбәттән аның «мәхәббәт эволюциясен» күзәтү шактый гыйбрәтле.

Мәхәббәт дигән изге хис, әлбәттә, билгесез өметләрдән, икеләнүле-ашкынулардан башлана инде ул.

Бәлки, син минем җырланмас
иң гүзәл җырымдыр?
Бәлки, син — минем чыгалмас
иң данлы юлымдыр.

Күренә ки, бу әле хиснең үзе түгел, ул якында гына, шагыйрь шул хакта уйлана.

Бу сөю — бөек мәгънә —
бәхетнең үзе икән.
Аңа таба онытылып
гел чап, оч һәм йөз икән.

Ләкин Равил Фәйзуллин салон шагыйре түгел, ул мәхәббәт турында җырлаганда да үзенең шагыйрь, димәк фикер иясе икәнлеген онытмый, яшәү аның бөтен күкрәге аша тулып ага. Бу төр шигырьләрнең үзәгендә — Кеше! Ул — сөя, сөелә; ул — көя, көенә; аның өчен сөю — илаһи сәгадәт.

Янарга да, батарга да риза
эштә, өйдә, идеалларда...
Барыбер килә,
күзләр аша килә олыгаю,
күзләр аша,— авыр аларга...

...Бер бөтерелеп без дә яшәп алдык!
Героинялар көтте урамда.
Онытылып сөйдек, сөелдек бер!
Йә, тагын соң ни бар дөньяда?..

Тора-бара гомуми мотивлар конкретлаша төшә, шуңа бәрабәр рәвештә лирик геройның хыялый сурәте дә ачыклана башлый. Мәхәббәтнең татлы агуын эчкән һәр кешегә хас булганча, ул — шатлана, борчыла, газаплана, шаша, ләкин горурлыгын, кешелеклелеген югалтмый, хисләре каршында алдаша белми, «дөресен» сөйли. «Мәхәббәт күзсез була ди...», «Беренче дә, иң соңгы да түгел...», «Бар күк булган сабырлыгымны...», «Көнләшү ирләр эшеме?..», «Җавап», «Көндезен — кеше күзендә...», «Син — теләп алган сагышым...», «Яшьлегеңне, гомереңне...» һ. б. шундый бик күп шигырьләрдә сөенечле дә, газаплы да мәхәббәткә дан җырлана; аларда кичерешләр реаль эчтәлекле, конкрет сурәтле.

Мәхәббәт күзсез була ди,
ярату сүзсез була.
...Безнең мең күзле булды,
гайбәтле-сүзле булды.

Тагын бер нәрсәне искәртеп үтик: Равил Фәйзуллинның мәхәббәт лирикасында кичерешләр палитрасы шулкадәр бай ки, аларда баш болытка тигәнче ашкынулар да, өзгәләнү-үпкәләшүләр дә — барсы да, барсы да житәрлек, ләкин үкенү, гаеп ташлау кебек хөсетле уйлар аның өчен бөтенләй ят нәрсә. Бу — сәгадәтле, рәхмәтле, ихтирамлы сөю. Чөнки:

Син — теләп алган сагышым,
Син — теләп алган ярам.

Гомумән, лирик шигырьләрендә шагыйрьнең хисләре ачык, сагышлы, фаҗигале; ритмик яктан алар ярсулы, тыгыз тәнле, камил, аһәңле. Бәлки «Аккошлар», «Сагыш», «Элегия», «Тимим күңелемә» кебек шигырьләрнең көйгә салынуы, «миниатюрадагы лирик симфония» булып китүе шуның белән аңлатыладыр да. Ләкин вакытлар узу белән төсләр уңа, чәчәкләр шиңә, «сәгатьләр» югала... мәхәббәт тә уала. Мәхәббәткә рәхмәтле булып калган хәлдә, утыз яшьлек ир-егет «көн уртасында» башкачарак уй-хисләр белән дә яна:

Хәзер эшкә!
Онытылып!
Бар ләззәтен тоеп хезмәтнең!
Әйтер
Вакыт — асылың турында.

...Җиңел түгел үзеңә лаек булу
Кояш астындагы урыныңда.

* * *

Җәмгыятьтә шагыйрьнең урыны кайда булырга тиеш? Бу сорауга һәр заман, һәр халык үзенчә җавап бирә, һәр шагыйрь үзенчә җавап эзли һәм аңа иң кыска туры юлны табарга омтыла. Берәүләрнең, әйтик, шагыйрьләрне гел яу кырында, көрәшнең алгы сафында, баррикадаларда, митинг-трибуналарда күрәсе килә. Икенче төрле караш та бар (бу очракта Зөлфәт белән килешми мөмкин түгел). «Орышка керер алдыннан бер бөек хан мондый фәрман бирә торган булган:

— Шагыйрьләрне һәм ишәкләрне уртада калдырыгыз! Алар сугыштан соң кирәк булачак!» *(«Татарстан», № 10)*.

Яшьрәк чагында, планетар идеяләрне байрак итеп күтәреп, риторик чаралар ярдәмендә Гуманизм өчен көрәш алып барган дәверендә Равил Фәйзуллин да беренче караштарак торды бугай:

Бөтен
планета
буйлап
вакансия!
Көрәшчеләр кирәк!
Көрәшчеләр!

Әйе, шагыйрь әле яшь иде, уй-хыялларында — максималист, хис-кичерешләрендә — ярсу-самими иде. Җитмәсә, дөньяда яңарыш бара — тираннар бәреп төшерелә, колонияләр иркен сулыш ала, империяләр җимерелә. Мондый эволюцион үзгәрешләр поэзиягә дә йогынты ясамый калмый, әлбәттә. Яшьләрнең яңа кыйтгалар ачкан вакыты бу.

Аңлашылса кирәк, Равил Фәйзуллинның — яшь буын татар шагыйрьләре лидерының — үз урынын мәйданнарда күрүе, яшәүнең асыл мәгънәсен, Җәмгыять һәм Шәхес арасындагы мөнәсәбәтләрне тасвирый чаралар ярдәмендә бөтен катлаулылыгында сурәтлисе урынга, бер кавым оран салу, чакыру-өндәү, үзе язганча, «гимн җырлау» белән мавыгып алуы бер дә гаҗәп түгел иде. Аннары, «президент булырлык ат карауччыларга, философ каравылчыларга, полководец күмәч пешерүчеләргә, мәгърифәтче кер юучыларга» «авазлардан үлмәс һәйкәл, таштан — җыр» кую, никадәрле генә гуманистик акт булып яңгырамасын, «иң кешелекле» тоталитар режимның, күзгә төтен җибәреп, аңнарны томалаган чагында ук шагыйранә сүзгә үтә дә сизгер һәм таләпчән укучылар тарафыннан (шагыйрьнең новаторлыгын һәм осталыгын һич тә инкяр итмәгән хәлдә!) «изге теләк», бер мавыгу буларак кына кабул ителделәр. Шул ук вакытта шагыйрь иҗатында кешелекле, сәламәт рухлы, тирән, көчле агымны күрми калу мөмкин түгел иде. Чын шагыйрь дилетанттан шул ягы белән аерыла да инде: ул тормышны төрле ноктадан торып күзәтә, ул бер генә халәттә яши алмый, аңа «тоннель комплексы» хас түгел. «Дөнья буйлап киләм. Байлыгым, тәҗрибәм юк, риям, мәкрем юк, тик гаҗәпләнә беләм!» (1966) — дигән шагыйрь икенче бер урында, язучылык миссиясе турында уйланып, менә болайрак фикер йөртә (1968):

Үлеп күрсәттеләр безнекеләр!
Гомерләре булды, һай, кыска,
Ә бит үлеп үлемсезлек яулау —
Бердәнбер юл түгел тормышта...

Дөрес, бердәнбер юл түгел! Шагыйрьнең үлемсезлеге — шигырьләрендә. Шигырьләрендә «үлә алса» гына, аңа бөтен җанын бирә алса гына шагыйрьнең иҗаты ышандыра, тылсымлый һәм үзе артыннан гавәмне ияртеп барырлык көчкә әйләнә. Равил Фәйзуллин белән дә шулайрак булды. Күп кенә шагыйрьләрдән озак еллар буена аның йогынтысыннан котыла алмыйча азаплануы хакында ишеткәнем бар. Бер шагыйрь хәтта болайрак дип тә шаярткан иде: «Безне чытырманлыкка алып кереп адаштырды да, үзе аннан тиз генә чыгып качты». Монда, күрәсең, бер нәрсәне искәртеп үтәргә кирәктер: **Шигърият — Равил Фәйзуллин өчен сүз уйнату яки акыл сату чарасы гына түгел, ул шигырьләрендә үзенең эчке рухи халәтен аңларга һәм аның тышкы дөнья белән бәйләнешләрен ачыкларга омтылып газаплана, шушы әлеккез бурычу аны дөньяны эзә күзеннән дә, телескоп аша да өйрәнергә этәрә.** Әгәр, чынлап та, шигырьләрендә үлеп терелә алган кеше генә шагыйрь икән, димәк, Туудан Соңгы чиккә кадәр сузылган мистик юлын

алдашмыйча сөйләп бирә алу гына — ПОЭЗИЯ. Поль Элюар сүзләре белән әйтсәк, «без беләбез, поэтик даһи шагыйрь алдашмаган очракта гына туарга мөмкин. Ә алдашмау ул — менә бүген хәрәкәт итү дигән сүз. Шигърият йогынты ясау чарасы, алга хәрәкәт итү чарасы булырга тиеш, чөнки ул бөтен ачык тәрәзәләр аша һәм һәр дүрт тарафка таратып хакыйкатькә мәдхия укый, вөҗданга дан җырлый, ялганга нәгърә ора».

Бу нәүбәттән Равил Фәйзуллин иҗаты аерым өйрәнүгә лаек: аның шигырьләре шулхәтле автобиографик ки, шагыйрь белән бөтенләй таныш түгел кеше дә, аларны укып, авторның холык-фигылен, дөньяга карашын, кичерешләр гаммасын тәгаен ачыклый алган булыр иде. Равил Фәйзуллинның лирик герое — каршылыклы, күп кырлы, катлаулы характерга ия; ләкин ул нинди генә шартларда да — горур, ихлас уйчан, борчулы, эзләнүчән һәм «зәмһәрир кыш уртасында яланаяк басып торам» дигән «сабый» да. Ә бит, әйткәнебезчә, шунысы мәгълүм: катлаулы шәхесләр генә катлаулы, димәк, сәнгатьчә камил әсәрләр тудырырга сәләтлеләр. Дин — гавәмгә, шигырь — шәхескә төбәлгән, диләр. Әгәр шулай икән, бу тулысынча Равил Фәйзуллин иҗатына да карый: шагыйрь, аеруча җитмешенче еллар ахырыннан башлап, иң гавәми дип аталырлык шигырьләрендә дә ул барыбер нинди дә булса шәхесне күз алдында тота; аның «тыңлаучысы»... шагыйрь үзе дә булырга мөмкин. Темадан темага, бер алымнан икенчесенә шагыйрь иркен күчә, ләкин һәр әсәрнең диярлек үзәгендә гамьле шәхес тора.



**Рәсемдә: утырганнар** *(сулдан-уңга)*: **Сара Садыйкова һәм Сибгат Хәким; басканнар — Гариф Ахунов, Вәфирә Гыйззәтуллина һәм Равил Фәйзуллин.**

*1981*

Менә болар барысы бергә, Шагыйрьнең һәм Шигырьнең миссиясе бозылып аңлатылган һәм бозылып аңлашылган «ябык ишекләр» дәверендә Равил Фәйзуллинны күп кенә бәлаләрдән коткарып калды да инде. Шигырьләре аша ул икейөзлелеккә, битарафлыкка, манкортлыкка каршы көрәш уты ачты.

Күз алдында булды ич, шигъриятькә бөтенләй ят функцияләр йөкләнде, ул идеологик сугыш коралына әверелде. Шигырьләр имгәтелде, шагыйрьләр гарипләтелде. Мондый хирургик операциянең нәтиҗәсе дә озак көттермәде: ничә гасырлар дәвамында зинданга ябылып тотылган мәхбүс хәлендә яшәгәндә дә исән калган татар шигърияте соңгы җитмеш биш ел эчендә нинди генә хурлыклар кичермәде, еш кына шагыйрьләр башка тавыш белән җырларга мәҗбүр ителделәр, көнлекчеләр исә идеология ялчысына әйләнделәр.

Җырчы шагыйрьләр аз яши.
Тираннар — озак.

Шулай итеп, әдәбият сәхнәсенә асылда үсешне тоткарлый торган «граждан-лык», «солдат», «эшче» поэзиясе дигән төшенчәләр күтәрелде. Билгеле, монда терминнарның бер гаебе дә юк, ләкин хикмәт шунда — күз буяучылар, һөнәрчеләр шушы терминнарны калкан итеп, Шигърият дигән асыл затның канын суырып яттылар; идеологик басым көчәйгән саен, ясалма рәвештә үстерелгән әрекмән астында черек мәшкәләр дә күбәйделәр.

Хәзер язучылар арасында: «Мин теге елларда Ленин турында, партия турында язмадым», — дигән сүзләрне ишетергә туры килгәли. Бу нәрсә, тагын икейөзләнү, кылган эшләреннән, кичәге көненнән куркакларча ваз кичүме? Андый акланучыларга Равил Фәйзуллинның моннан чирек гасыр әйткән сүзләрен исләренә төшерәсем килә, бәлки сабак булыр.

Җаныңның ваклыгын
Сылтама заманга.
Куркырга, өркергә
Җай бар ул һаман да.

Асылыңны яшереп
Кыланма ни генә, —
Буыннар хәтерендә
Бары да чигелә.

Фикеребезне дәвам итик. Бервакыт татар әдәбиятында «нефть» темасы белән мавыгып алу, хәтта, әйтергә мөмкин, мактанышу модага кергән иде: без нинди бай, бездә фәлән хәтле «кара алтын» чыга, янәсе. Дөрес, бу темага Равил Фәйзуллин да язды, ләкин ничек язды!

Артык данлыйсың түгелме
Илнең гади каласын?
Төнендә ул як җирләрнең
Кырык меңләп ярасы.

Менә шулай, шагыйрь очсызлы коткыларга бирелмәскә, узгынчы темалардан, идеологик хорафатлардан өстен торырга тиеш. Вакытны узып, алдан күрә белү, мәсьәлә-проблеманың асылына төшенү — аның изге миссиясе! Равил Фәйзуллинның бу яктан хафаланырлыгы юк: аның намусы чиста, күңеле пакь. Вакланмауның үз өстенлеге бар шул, соңыннан акланып торасы булмый...

Бүген илдә сәяси атмосфера башкачарак. Халык, бер таңда уянып, урам-мәйданнарга чыкты, аның теле чишелде. Шушы шартларда шигырь лозунг вазыйфаларын үтәүдән азат ителеп, үз ярларына кайтып төшәргә тиеш иде кебек. Чөнки шигырь эстетик категорияләр белән эш итә, шуңа күрә дә ул, сөнге яки ук очына манылган зәһәр агу булудан битәр, агукайтаргыч булып тора. Һәрхәлдә, шулай булырга тиеш.

Кем ничектер, кайбер шигъри митинглардан мин икеләнүле хисләр белән кайтып китәм. Андый җирләрдә, гадәттә, сөнгесе агуга манылган яңгыравык-купшы, ярым әдәби, ярым сәяси шигырьләр укыла. Юк, шигъриятнең милли аңны тәрбияләүдәге, үстерүдәге ролен һич тә киметергә теләмим мин, киресенчә, шигърият ул халыкның рухи көзгесе булырга тиеш. Ләкин әдәбият хәзинәләрен кысрыклап, терсәк белән төрткәләп алгы рәтләргә, трибуналарга һөнәрче-кәсепчеләр үрмәләвен күрә торып дәшми калыргамы? Һәм моңа каршы ничек көрәшергә? Утка каршы ут ягыпмы? «Борынгылар тын гына эшләп-язып яткан шагыйрьләрне бала табарга җыенган Ананы саклаган кебек саклаганнар... Ниһаять, бала тудыргандагы газаплар белән шигырь дөньяга килә. Әгәр шагыйрь шигырь туганда сәнгатьнең табигатенә хас булмаган уй-ниятләр коткысына бирелмәсә, мең рәхмәтләр яусын аңа». Ә бездә киресенчә: кемнең тавышы калынрак, шул яд ителә.

Аһ, тау юклыклар!
Кыя юклыклар!
Күз тегәмә кая —
үзән, калкулыклар.

Заман җилләре исеп, тарих комнары күчә барган саен кемнең чынлап та «тау», кемнең «калкулык» икәнлеге тәгаен ачыкланыр, шөт. «Калкулыкларны»

ком күмеп китәр, «тауларның» исә нигезләре ачыла барыр һәм алар тарих тирәнлегеннән тагын да биегрәк булып калкып чыгарлар.

Ышанам, Равил Фәйзуллинны бөркетләр оялаган таулар язмышы көтә булыр...

**Р. S. Хәер, ул таулар дөньясын бер генә мәкаләдә иңләп тә, колачлап та бетерү мөмкин булмас иде. Шуңа күрә, әйдәгез, сүзне шигырьләрнең үзләренә бирик әле. «Һәр китаптан бер шигырь!» — шагыйрьнең үсеш юлын күзаллау өчен шулай отышлырак булыр сыман; шул рәвешле алда сөйләгән сүзләргә ачыклык кертелер, яңа төсмерләр өстәлер, чөнки алар — беренчел ич.**

**Наис ГАМБӘР.**
1993, май-июнь.

# Равил Фәйзуллин




**Кульязма китап. 1954—1958.**

## Авылда кышкы төн

Балкый тышта — баганада
электрик фонарь.
Корт кучедәй, шул яктыда
бөтерелә карлар.

Нәни ут — Ай-йолдызларның
барын алыштырган.
Бар дөнья яктысын гүя
бер үзенә җыйган!

...Җилләр — чыбыкларны сарган
бәсне коеп тора.
Күгәрченнәр кыекларда
посып, оеп тора.

## Чикләвек

Өлгермәгән җәен
кызынып калырга.
Күз житкәч уйлаган
киемен салырга.

Ялангач көенә
сикергән дә җиргә,
Яңгырда чыланып:
— Туңам,— дип тилмерә.

Төньяктан җил өрә,
кыш аяк киенә.
Ярый ла чикләвек
очраса тиенгә.




**Казан. ТКН. 1965.**

## Минем әти

Философ булмаган әти.
Ә минем кирәкне белеп,
өйләнгән минем әти.

Галим дә булмаган әти.
Ә миңа җылы кирәккәч,
мичләр салуның рәтен
өйрәнгән минем әти.

Җырчы да булмаган әти.
Ә миңа бишек силәсен
зыңлап торганын ясарга
өйрәнгән минем әти,

Рәссам да булмаган әти.
Ә миңа салават күперен
чыкта да күрә белергә
өйрәтте мине әти.

Шагыйрь дә булмаган әти.
Ә мине көйгә кертергә
бер-ике йомры сүзне
өйрәнгән минем әти!

Герой да булмаган әти.
Ә сугышта алган җөен
хәтта миңа күрсәтмәскә
өйрәнгән минем әти!

Син Алла да түгел, әти,
фәрештә дә түгел, әти.
Син бары әти, әти!



Казан. ТКН. 1966.

* * *

Кыз бала йөгереп үткән.
Тезенә бәрелгәч, башактан
орлыклар чәчрәп киткән...

Инде күптән җәй икән!
Кай арада яз үткән?
Кайчандыр учымда йөрткән
кыз үсеп буйга җиткән.

Инде күптән җәй икән!
Җанда моң әллә ниткән...
Өлгергән бодай кырыннан
кыз бала йөгереп үткән,—
йомрыланган тезләреннән
орлыклар чәчрәп киткән...



Казан. ТКН. 1967.



Казан. ТКН. 1969.

* * *

Ул көннәрне инде даулап булмый,
сагынып кына була.
Сөю ни икәнен белми гомерең узса,
каплан да бер ела.

Сүнгән еллар исәбенчә тезеп
кара шәмнәр кабыз.
Ку кешеләрне! Хет тынлыкта кал,—
син, барыбер ялгыз...

Ул елларны инде даулап булмый,
сагынып кына була.
Үткән бөеклеккә кайтып булмый,—
табынып кына була...

* * *

*Ишетәсеңме,*
*әллә җил бу?*
*«Янсаң хөрлек*
*көрәшендә,*
*я кылычтай*
*калсаң сынып,—*
*офтанма бер дә!*
*Заманалар*
*Үзе килер*
*юксынып...»*

Җаныңның ваклыгын
сылтама заманга.
Куркырга, өркергә
җай бар ул һаман да.

Ә бит бар кешеләр —
шәхесен ватмаган,
хаклыкны сатмаган,
вөҗданны саклаган.
Әйткәннәр: тарихтан
түгелсәм түгеләм,
изелсәм изеләм,—
әмма дә бөгелмәм!
Үзләре сеңсә дә,
рухлары калыккан.
Әнә шулар үлеме
җан өрә халыкка.

Асылыңны яшереп
кыланма ни генә,—
буыннар хәтерендә
бары да чигелә!

Җаныңның ваклыгын
сылтама заманга...



Казан. ТКН. 1971.




Казан. ТКН. 1973.

* * *

Бер бөтерелеп без дә яшәп алдык!
Героинялар көтте урамда...
Шундый тансык бөек тилерүләр
кануннардан каткан дөньяда!

Бәрәкәтсез гомер, аһ, сүтелә!
Вакыт белән дуэль. Ни чара?
Бу таңнарны күбрәк күргән саен
күңелне ник моң һәм шом сара?

Янарга да, батарга да риза
эштә, өйдә, идеалларда...
Барыбер килә,
күзләр аша килә олыгаю,
күзләр аша, авыр аларга...

...Бер бөтерелеп без дә яшәп алдык!
Героинялар көтте урамда.
Онытылып сөйдек, сөелдек бер!
Йә, тагын соң ни бар дөньяда?..

## Идел ага

Идел ага. Пароходтан
акчарлаклар, таллар кала,
чиркәүле авыллар кала,
карлыгачлы ярлар кала.

Идел ага. Күпме аккан
ул Ра булып, Әтил булып,
Волга булып... Зур дәрьяга
халыклардан вәкил булып.

Идел ага. Кешеләр буса,
җөелеп ага, тулып ага.
Дулкын булып кына түгел,
җыр-дастаннар булып ага.

Идел ага. Исе китми
дәверләргә, ялганнарга.
Гамь кирәкме каберләре
су төбендә калганнарга.

Идел ага. Ил барыбер
Идел-йортын онытмады.
Ярларында яши бирә
Идегәйнең оныклары.

Идел ага. Без агабыз.
Арттa маяк, саллар кала.
Култыкларда пристаньнар,
яулык болгап ярлар кала.




Казан. ТКН. 1976.

Идел ага. Ул — мәңгелек.
Кай елгалар кибеп кала...
Иделең белән акканда
җанда барыбер өмет кала.

## Күмәч пешерүчеләр җыры



Казан. ТКН. 1977.

Сез кем дип сорыйсызмы?
Күмәч пешерүчеләр без!
Кешеләрнең йөзләренә
шатлык төшерүчеләр без!
Күмәч пешерүчеләр без!
Күмәч кебек йомшак түгел,
каты безнең кулыбыз:
изә, баса, туглыйбыз;
йоп-йомшак камырны
кайнар мичкә юллыйбыз.
Күмәчләрнең йөзе килсә,
бөркелеп хуш исе килсә,
нечкәрә күңелебез:
сөенәбез, көләбез —
бик сабый күңелле без.
Күмәч пешерүчеләр без!
Пешерәбез йөземлесен,
мәклесен һәм мәксезен,
түгәрәген, сырлысын...
Табыныбыз мул булсын!
Әйдә, кайчак он кунсын,
куллар камырда булсын!
Тик эшебез уңганнарның
хезмәте чаклы булсын,
күзләрдә чаткы булсын,
йөзебез якты булсын!
Сез кем дип сорыйсызмы?
Күмәч пешерүчеләр без!
Без күп телләр белмибез,
күп илләрне гизмибез,
алтын белән диварларда
язылмый исемебез,
икмәк кебек гап-гади
күмәч пешерүчеләр без!

Эшебез, ай-яй, тыгын,
сөйләшмибез артыгын,
кабарт, из, бас тизрәк,
әвәлә, сал тизрәк!
Күмәч кирәк! Күмәч кирәк!
Эшчегә, язучыга да,
саллар агызучыга да,
очкыч җибәрүчегә дә,
пыяла өрүчегә дә,
терлек караучыга да,
полярник, аучыга да,
речьләр сөйләүчегә дә,

чалгы көйләүчегә дә,
БМО башлыгына да —
барысына да, барысына да
күмәч кирәк, күмәч кирәк!
Кабарт, из, бас тизрәк,
әвәлә, сал тизрәк!
Күп кешеле зур чатлар,
светофор-маяклар,
машина-самокатлар
авырсынмый юл бирсен!
Әбиләргә, бабайларга,
әтиләргә, әниләргә,
сеңелләргә, энеләргә,
абыйларга, сабыйларга
чәйгә күмәч өлгерсен!
Иртән дә күмәч булсын,
көндез дә күмәч булсын,
кичен дә күмәч булсын,
урта бер җирдә
табынның
кояшы булып торсын!

Сез кем дип сорыйсызмы?
Күмәч пешерүчеләр без!
Кешеләрнең йөзләренә
шатлык төшерүчеләр без!
Сез кем дип сорыйсызмы?
Тәнгә, кул-аякларга
көч-егәр бирүчеләр без!
Сез кем дип сорыйсызмы?
Тереклеккә гел яшәргә
куәт бирүчеләр без —
күмәч пешерүчеләр без!
Ә соң сез
үзегез
кем?

## Яңгыр

Толымланып салынып төште Күк сагышы.

## Искәртү

Каршы төшсә дус-дуска:
«Тел — озын, гомер — кыска!»


## Көзге яңгыр

Торналар китеп бара.

Кош канатлары орынгач,
болытларның күңеле тулды.

## Картлар сүзе

Ике хәзинә бар дөньяда: саклагыз!
Каберстан аның берсе. Гел гөлдә булсын!
Китапханә икенчесе. Күңелдә булсын!
Базар болай да калыр...




Казан. ТКН. 1978.

## Биеклектә

Кыя — текә. Җилләр — йолка.
Кузгала таш... Кая басыйм?
Колакта өн: менгәнсеңме —
егылам дип,
ярдәм сорап кычкырма син!

## Үзем кадәр

Мин зур түгел. Мин —
Үзем кадәр генә.
Тезләнмә!

Бәләкәй түгел мин. Мин —
Үзем кадәр әле.
Кизәнмә!

## Хыял

Җир өстендә ниләр бар?
Әтиләр, әниләр бар.
Шәһәрләр бар, илләр бар.
Урманнар бар, чүлләр бар...

Җир асты да хикмәтле!
Анда хәзинәләр бар.
Алтыннар, көмешләр бар.
Диңгезләр, инешләр бар...

Күк катында ни юк дисез!
Йолдызлар бар, айлар бар,
яшеннәр бар, карлар бар...

Ә Булатның күңелендә
беләсезме, ниләр бар?
Бар аның зур хыялы!
Бәлки андый зур хыялның
юктыр да әле булганы!
Аны Җир дә белми әле,




Казан. ТКН. 1980.

аны Күк тә белми әле,
аны беркем белми әле!..

Беркөн килер, үсеп житәр —
хыялын ул чынлык итәр!
Ул хыялны Җир дә белер,
эшкә ашуын Күк тә күрер!

Әлегә ул серен саклап,
нәни генә малай булып,
чирәмлектә уйнап йөри.




Казан. ТКН. 1981.

## Тагын килде язлар...

*Үткән гомерләрне еллап түгел,*
*гашыйк язлар белән исәплим.*

Сау кеше өчен тагын язлар килде —
бар назлары, дәртләре белән.
Кемнең анда шатлык яше чыккан
ак каенның күкрәкләреннән?

Кемнәр өчен икән тел апкайткан
очар кошлар озын юл узып.
Учларында гөлләр шытар кебек,
ләйсәннәрдә торсаң кул сузып.

Кем күзләре бүген зәңгәр күктә?
Гөрләвекләр кемгә ашыга?
...Кичен кәрәз карда нур үткәреп,
чигү чигәр өчен ай чыгар.

Кемнәр быел сөю ялкынында
жаны белән жанга бәйләнер?
Ә кемнәрнең жуйган сөйгәннәре
рәшәләргә кереп тибрәнер...

...Зәңгәрәйде күкләр. Ачыклана төште
төсләр, югалтулар, табулар...
Тургай хыял булып өскә әйдәсә,
үткән еллар тарта чабудан...

Тик шулай да язын бүтән кәеф:
сулау — жиңел, йөреш — жиңел, тән...
Шәфәкъларга баккан чактагыдан
язгы таңны күргән күз бүтән!

Һәр иртәдә әле туа тора
куанырлык мең-мең сәбәпләр.
Күңелдә әле, яз басымын тоеп,
бар өзгәләнә алыр күзәнәкләр!

Җан түрендә әле урыннар бар
яңа шатлык, яңа газапка.
Тик, алдашмый, жырларыңда кара —
гел кешеле якка, яз якка!

...Сау кеше өчен тагын язлар килде —
бар гамьнәре, дәртләре белән.
Кемнең анда сагыш яше чыккан
ак каенның күкрәкләреннән?..

* * *

Чишмәләр саркып чыга да,
дәрман-көч җыя-җыя,
инешкә килеп коя...
шунда исемен җуя.

Инешләр чаба-чаба да,
агымын тыя-тыя,
елгага килеп коя...
шунда исемен җуя.

Елгалар ага-ага да,
чоңгыллар уя-уя,
диңгезгә килеп коя...
шунда исемен җуя.

...Кешеләр яши-яши дә,
саулыгын җуя-җуя,
киләчәге өчен Иленең
җиренә башын куя...
Бөек эш калдырганнарга
Ил соңрак һәйкәл коя.



Казан. ТКН. 1983.

# ЖУРНАЛ ЯЗМЫШЫ — БЕЗНЕҢ ЯЗМЫШ




Казан. ТКН. 1984.

Һәр басма китап минем өчен үзе бер җанлы җисем, үзе бер тере организм кебек. Ул гүя синең якын бер әңгәмәдәшең. Ул сиңа кычкырмый-нитми; каршы сүз әйтми генә нәрсәдер аңлата, ниндидер гыйбрәтле хәлләр сөйли, нәрсәгәдер өнди... Син дөньяның матурлыгын һәм катлаулылыгын ныграк төшенә башлыйсың, кешелек тарихының мәңгелек категорияләре — Яхшылыкка һәм Яманлыкка, Мәхәббәткә һәм Нәфрәткә, Хаклыкка һәм Ялганга, Тугрылыкка һәм Хыянәткә, Тынычлыкка һәм Сугышка, Гүзәллеккә һәм Ямьсезлеккә... үзеңчә гадел мөнәсәбәтеңне ачыклый төшәсең. «Ташка» басылган һәр чын иҗат әсәре — мәңгелекнең дә, мизгелнең дә кабатланмас бер чагылышы бит. Исеме журнал дип аталса да, үзендә дистәләрчә әсәрләрне бергә җыеп, ай саен даими чыгып килә торган «Казан утлары» дигән китап та нәкъ шундый олы миссияне үтәүче басмаларның берсе. Шуңа күрә дә ул йөз меңләгән укучыларның якын дусты, ышанычлы фикердәше булып әверелде дә.

Минем китапханәмдә «Казан утлары»ның («Безнең юл», «Совет әдәбияты» исемендә чыкканнарын да исәпләп) биш йөзгә якын саны саклана. Төпләмәләре

---

Журналның 60 еллык уңае белән язылган мәкаләдән өзек

күзләрне иркәләрлек ямьле булмаса да, миңа алар үзем өчен зур байлык булып күренә. Әдәбиятыбызның, гомум мәдәниятыбызның, юк, алай гына түгел, бөтен халкыбызның соңгы кырык-илле ел эчендәге тарихы бит аларда! Аерым фәннәр һәм сәнгать төрләре буенча махсус басмалар булмагач, киң мәгънәдәге рухи культурабызның хроникаль елъязмасын шушы журналдан укымыйча, бүтән нинди чыганактан беләсең?!

Үзенең туган нигезе яки әти-әнисе турында уйлаганда, һәркем үткәненә үз күнел тәрәзәсе аша карап, үзе генә белгән газиз хатирәләрне исенә төшергән кебек, мин дә «Казан утлары»ның бәләкәй генә иҗат дөньямда зур һәм якты эз калдыра башлаган вакытны үземнең саф һәм хыялый яшьлек елларым белән бәйләп хәтерлим. 1965 еллар. Журналның баш редакторы булып Рафаэль Мостафин эшләгән чак. Бүлекләрдә — Н. Арсланов, В. Нуруллин, Я. Халитов, М. Хәмитовлар. Университетны бетерер-бетермәс чагым. Вакытлыча киткән кеше урынына мине дә бүлек мөдире итеп эшкә алдылар. Нәкъ шул айларны журналның исеме «Совет әдәбияты»ннан «Казан утлары»на әйләнде. Журналның исеме алышынуы турында укучыларга, бигрәк тә Татарстаннан читтә яшәүчеләргә мөмкин кадәр тизрәк җиткерергә кирәк иде. Юкса, нәкъ журналга язылу вакыты, буталышлар килеп чыгасын көт тә тор. Җитмәсә, «Совет әдәбияты» дигән исемдә тагын бер журнал — төрекмән язучылары журналы да чыгып килә. Баш редактор, бүлекнең төп эшләреннән бераз бушатып, мине шушы журнал тарату эшенә утыртты. Чит республикаларда һәм өлкәләрдә чыга торган газеталар өчен «сез яши торган өлкәдә фәлән мең татар яши, яңа исемдә чыгачак журналны сездә фәлән мең данә таратырга мөмкинлек бар» дигән мәгънәдәге ике йөздән артык хат җибәрелде. Ул мәкалә-хатларда, шулай ук журнал турында — тарихы, бүгенгесе, актив язучылары, басылачак әсәрләре турында да шактый тәфсилле мәгълүмат бар иде. Баш редактор имзасы белән җибәрелгән ул мәкаләләрнең бик күбесе басылып чыкты. Һәм әйтергә кирәк, нәтиҗә дә шактый матур булды. Тираж бер ел эчендә 20 меңгә артты. Бу күркәм нәтиҗәне без җибәргән хатлар гына китерде дип әйтеп булмый, әлбәттә. Ул елларда тиражларны арттыруга бик нык игътибар бирелә иде, шуңа күрә байтак язучылар һәм әдәбият сөючеләр матбугат таратуда җиң сызганып эшләделәр дә. Бу эшкә бөтен күңелен салган кешеләрнең берсе аеруча хәтердә калган: ул — Тәүфикъ Әйдельдинов. Велосипедка утырып, биштәренә өндәмә материаллар асып, ул үз теләге белән берүзе берничә өлкәне урап чыгып, подписчиклар җыеп йөрде. Ул елларда арткан тиражның берничә мене, һичшиксез, Тәүфикъның тырышлыгы аркасында булды. Китап киштәсендә минем дә ул чаклардан калган бер истәлек саклана. Ул — кечкенә генә портатив фотоаппарат. Кырыена исем-фамилия уелган һәм «Казан утлары» журналын актив тараткан өчен» дип әйтелгән. Практик эш өчен әллә ни җайлы булмаса да, корпусы сузылып ачыла торган бу миниатюр аппарат күрер күзгә шактый матур һәм шул сагындырып искә төшә торган елларның кадерле бер истәлеге булып саклана.

Журналда кеше күзенә күренерлек басыла башлау да нәкъ шул елларга туры килә. Дөрес, анарчы да аз-маз басылгаладым. Әмма берәгәйле басылуым шул 1965 елны булды. 11 нче санда тулы тугыз биткә сузылып «Нюанслар иле» дип исемләнгән кыска шигырьләр циклы чыкты. Баш редактор, үз өстенә шактый җаваплылык алып, шулай күләмле итеп бирергә тәвәккәлләгәндә, минем журнал тарату эшендәге беркадәр хезмәтемне дә искә алды булса кирәк. Әлегрәк мин: шигырьләрем яхшы булганга шулай басылып чыктым, дип кенә уйлый идем, ә хәзерге исәп буенча бүтәнчәрәк уйлыйм. Ни булса да булды, «Нюанслар» чыгып калды. Бу цикл үз вакытында шактый зур шау-шу куптарды. Берәүләр — яңача, новаторлык, фәлән-төгән дип мактадылар, икенче берәүләрнең бик нык йонлары кабарды... Шуннан бирле журналда шактый язышып киләм. Ел саен диярлек, күп кенә каләмдәшләремнеке шикелле, шигырьләрем бәйләме чыга. Егерме елга якын дәвер эчендә басылган барлык шигырьләрне бергә җыйсаң, үзе бер биш-алты табаклык китап булыр иде. Моңа өстәп, журнал битләрендә төрле елларда, төрле рухта һәм күләмдә униап әдәби-публицистик мәкаләм чыкты. Арада — моннан өч-дүрт ел элек профессор И. Нуруллин белән икәү әңгәмә рәвешендә язган күләмле мәкалә аеруча хәтердә. Ул — бүгенге поэзиянең үсеш тенденцияләре турында шактый ук кызыклы дискуссия кузгатырга сәбәп булды. Шуңа өстәп, журналда китапларыма карата тәнкыйтьчеләрнең, шагыйрьләрнең, гади укучыларның фикерләре әледән-әле күренеп тора. Әлбәттә, төрле кешенең төрле фикерен төрлечәрәк кабул итәсең, һәм шул ук вакытта, мондый хәлнең бик тә

табигый икәнен аңлап, канәгатьләнеп куясың. Журнал белән шулай язышып һәм аңлашып яшәү — күпчелек язучыларыбызның типик язмышы дип беләм мин. Кайчак уйлап куясың: әгәр дөньябызда мондый журнал булмаса? Дөресен әйткәндә, бу хакта уйларга да куркыныч. Әгәр шулай булса, күп кенә язучыларыбыз һәм әсәрләребез бөтенләй үк булмас иде...

## Яшьлегендә чибәр булган бер чал әби сүзләре

**«Кем беләнаралдың — шуның белән агар!»**

*(Әнисенең әйткән сүзе)*

— Башта ни карадың?

— Күзенә карадым!
Зәп-зәңгәр күзенә!..
Күзендә чагылган
үземә карадым!
Аннан соң... изерәп,
җәйге төн күгенең
йөзенә карадым...

Әрләмә, каргама,
хәлемә кер, әни!
Мин теләп алдым бит
бәхетле ярамны!
Ышанасыңдыр бит —
мин фәкать агардым!
Күңелем агарды!
Уйларым агарды!
Сөюдән кешеләр
чистара бит бары!
Тик аннан соң гына
ятларның сүзеннән
йөзләрем каралды...




Казан. ТКН. 1985.

---

Әнием, рәнҗемә!
Мин тагын агардым.
Йөзләрем агарды.
Чәчләрем агарды...
Кабере генә аның
(син белгән егетнең!)
тора әле каралып...
Бураннар керүгә
ул да, әни, агарыр,
агарыр...




Казан. ТКН. 1987.

## Туган халкым

Бу дөньяда һәркем лаек ихтирамга,
раслый алса яшәвенең олылыгын.
Туган халкым! Тарихларның давылында
югалмыйча кала алуың — горурлыгым!

Матурлыкка, гаделлеккә, тынычлыкка
хезмәт итсәң — намусың пакь, иҗатың чын.
Туган халкым! Сынауларда сабыр булып,
җиңүләрдә ныгаюың — таянычым!

Йолдызларга менгән кеше ялгышып та
таптап китмәс шушы Җирнең бер чәчәген.
Туган халкым! Илен-телен саклый алган
игелекле балаларың — киләчәгең!

## Җилнең сурәте нинди?

— Җилнең мөгезләре бармы?
— Бардыр. Бардыр...
Юкса тамырлары белән
агачлар аумас иде...

— Тырнаклары?
— Бардыр. Бардыр...
Юкса түбә калайларын
куптара алмас иде!

— Томшыгы да бардыр әле!
— Бардыр. Бардыр...
Юкса камышлар эченә
кереп тула алмас иде.

— Канатлары?
— Бардыр. Бардыр...
Юкса күктә болытларны
җилпеп куа алмас иде!

— ...Ә рәсемгә төшерә калсаң,
кыяфәте нинди соң?
Кошмы? Берәр җанвармы?
Әллә берәр җенме соң?

— Белмим. Белмим.
Үзе әнә форточкадан
миңа карап ыслап тора,
нидер әйтеп выжлап тора...
Тик телен төшенә алмыйм!
Шуңа күрә әйткәннәрен
кәгазьгә төшерә алмыйм...



Казан. ТКН. 1989.

## Эпилог

*«Сәйдәш» поэмасыннан*

Җан күбәләк булып кайта, диләр.
Үтермәгез күбәләкләрне!
Күңелләрдән шәфәкъләргә кадәр
югалтулардан соң, җан әрни...
Күпме бездә эзсез югалганнар!
Карт хәтергә булмый ышанып.
Таш торгызу кирәк. Байтак тиеш
һәйкәлләрнең урыны буш әле.
Безнең әле байтак бөекләргә
күңелләрдә генә музейлар.
Битарафлык, яман чир шикелле,
чыгар ул бер, узгач күп еллар...
Табигатьтә бушлык булмас, диләр.
Берәү килә, берәү югала...
Халкы эше өчен янган гына
мәңге яшәр булып кала ала.
Һәлакәткә әзер талантлыда —
үз халкының рухи җегәре!
Аның җаны аша күреп була
үткәнне һәм килер көннәрне.
Талантлар китсә, әй ишәя
конъюнктура сандугачлары!
Аларның шәп эшли унисонга
ашказаны белән башлары!
Рухи дөньяга килеп төрсә
кайтышлар һәм сәләтсезрәкләр,
юклыкларын тоеп даһиларның,
илләр буйлап әрнер йөрәкләр...
һәрбер әрсез көчле булмаган күк,
һәр мескенлек түгел тыйнаклык.
Килер көннәр әйтер — кемнәрдә
фидакярлек, ныклык, йөз аклык!

. . . . . . . . . . . . . .

Йомшаклык белән генә булмый.
Көчле һәм нык булыгыз, талантлар!
Тарихыбыз шундый, заманасы...
Иманыңны бүтән кем саклар!

...Ялгышларны — була, мәнсезлекне...
тууларны булмый кабатлап!
Җырчыларны булмый кабатлап!
Даһиларны булмый кабатлап!

Сәйдәш язмышы —
гыйбрәт тә,
горурлык та,
алыр сабак та!
Нечкә җаннар —
талантлар белән
«Сак булыгыз» дигән набат та!




Казан. ТКН. 1990.

## Тимим күңелемә




Казан. ТКН. 1992—1993.

Тимим күңелемә,—
өзгәләнсен, янсын!
Кеше кайчак үзен
кичерә дә алсын.
Хисләрем ярсысын,
уйларым ташсын,
зиһенем чуалсын,
җан изрәп талсын...
Тимим күңелемә,—
үзгәләнсен, янсын!
...Ә безнең мәхәббәт,
сагышлы мәхәббәт,
каргышлы мәхәббәт
җыр булып калсын.

Яңа таңнар атсын,
яңа гөлләр үссен.
Бу татлы газаплар
бүтәннәргә күчсен.
Яшь йөрәкләр янсын,
яшь җаннар юансын.
Сөю алар белән
киләчәккә барсын!
Тимим күңелемә,—
өзгәләнсен, янсын...
...Ә безнең мәхәббәт,
тыңдәшсез мәхәббәт,
күз яшьле мәхәббәт
җыр булып калсын!

## Бу җырлар...

Бал җыйган кортлар күк
Кояшның нурында
коенган җырлар бу!
Язмышлар кырыннан
җыелган җырлар бу!
Сый итеп, алдыңа
куелган җырлар бу!

Шатлык гөлләре дә,
кайгы гөлләре дә
какты йөрәгемә
язган көннәремдә.
Булдым мин кай көндә
былбыл кош тоткан күк.
Көйдем мин кай төндә
сумала йоткан күк...

Бу җырлар — бәгырьнең
кылына тиюем.
Бу җырлар — гомерем,
нәфрәтем, сөюем.
Тормышны мин шулай
аңлыймын диюем.

Менә күр, аларны
куйдым күз алдыңа.
Хуш күрсәң — рәхим ит!
Чит итсәң — кагылма...
Теләсәң, җаныңны
үлчәп бак җаныма.

Күңелдә, мөһер күк,
уелган җырлар бу!
Рәхмәтле җаннарга
сыенган җырлар бу!
Язмышлар кырыннан
җыелган җырлар бу!



Илдар Низамов

# УЕЛЫП КАЛДЫ УЙЛАРЫ

*(Хәсән Сарьян киңәшләре)*

## Кем ул тел белгече?

Хәсән Сарьян чын-чыннан тел белгече иде. «Тел белгече» дигәндә, без башлыча ике төшенчәне күз алдына китерергә күнеккәнбез. Беренчесе: үз әсәрләрен үткәзерлек, тәэсирләндерерлек, җинел укырлык тел белән язган әдип. Хәсән Сарьян нәкъ шундый язучы иде — балта остасы үз коралларын, галәмгә юл тоткан космонавт үз аппаратларын ничек яратып, төпле белсә, ул да туган телен шулай яраткан, үзләштергән, үтемле куллана белгән оста иде. Аның бу иҗади таланты, сәләте һәм тәҗрибәсе аерым өйрәнелергә хаклы киң бер мәйдандыр.

Икенчесе: «тел белгече» дигәндә, без янә лингвистика галимен, ягъни телнең төзелешен, тарихи һәм бүгенге хәлен өйрәнүче белгечне күзалларга күнеккәнбез. Хәсән Сарьян бер үк вакытта шундый оста да иде. Ул фикерләү чарасы, аралашу коралы, әдәби образлар тудыру чыганагы булган телне фәнни ачыклаган гыйльми белгеч иде. Бу өлкәдәге тикшеренү-уйлануларын, белемен, тәҗрибәсен ул үзендә йомып яткырмады, университетта студентларга бирде, тел гыйлеменә кагылган хезмәтләрендә халыкка җиткерде.

Ниһаять, Хәсән Сарьян иҗаты аркылы без «тел белгече» төшенчәсенең өченче бер мәгънәсен ачыклый алабыз. Сүз сөйләм турында бара. Кызганыч ки, «сөйләм» төшенчәсен — асылы белән гаҗәеп катлаулы күренешне — без үтә дә гадиләштереп, әйтү, сөйләшү мәгънәсендәге көнкүреш төшенчәсе дип кенә күз алдына китерергә күнеккәнбез. Безнең галимнәргә телнең асылын, төзелешен аңлатып кына канәгатьләнмичә, аны, фикерләү һәм аралашу коралы буларак, ничек-ничек куллану, ягъни сөйләм оештыру закончалыкларын да ачып, аңлатып бирергә, димәк; сөйләмият фәнен үстереп җибәрергә күптән вакыт та бит... Әнә урысларда, башка милләтләрдә дә речеведение, психолингвистика, социолингвистика кебек фәннәр үсеп ята, бездә генә мәктәптә дә, университетта да һаман шул тел төзелешен өйрәтү. Моңа борчылып күпме чаң сугылды, күпме язылды инде. Ләкин туңны эретү бик кыен.

Әле менә бүген дә җан ыңгырашуын ишетәм. Мөхәммәт Мәһдиев интервью бирә: «...Бездә бит укыту системасы формаль методикага корылган. Менә безгә гомер буе татар һәм рус теле дәресләрендә иянең астына бер сызык, хәбәрнең астына ике сызык, ә аергыч астына дулкынлы сызык сызарга өйрәттеләр. Гомер буе безгә суффикс, приставканы өйрәттеләр. Ә практик яктан сөйләшергә, аралашырга өйрәтмәделәр...» *(«Мәгърифәт», 1993, 13 февраль)*.

Ә бит бу фәнгә нигез салырга күптән җирлек бар. Г. Ибраһимов, Г. Бәширов, Х. Курбатов, В. Хаков, Ф. Сафиуллина, И. Бәширова һ. б. хезмәтләре белән бергә, Хәсән Сарьяннныкылар да анда саллы-саллы кирпечләр булып тезелә алыр иде.

Сөйләмият дигән фән, иң башта сөйләм белән тел мөнәсәбәтен тәмам ачыклар иде. Сөйләм ул — аралашу-аңлашу максатында фикерне оештыру, бел-

дерү һәм кабул итүнең бөтен бер системасы. Аның асылын аралашуның (коммуникациянең) мотивлары: сөйләм иясе, адресаты, нияте һәм сөйләм оештыруның шартлары, шулай ук аралашуның чаралары: тел һәм телдән башка чаралар (ым, ишарә, тавыш, сурәт, шрифт һ. б.) тәшкил итә. Сөйләмдә мотивларга карап тел чаралары тәгаенләнә дә. Димәк, фәнни күзаллау өчен дә, аралашу максатында өйрәнү-үзләштерү өчен дә, сөйләмне үзенә бер, телне үзенә бер чагыштырмача мөстәкыйль, әмма мәңге аерылгысыз төшенчәләр итеп карау хәерле.

Хәсән Сарьян моны болайрак төшендерә: «Татарча «тел бозу» дип сөйләнсә дә, татар теле дигән гомуми телебезгә бу һич тә кагылмый. Чөнки гомуми телне «бозып» булмый. Чыннан да, менә мин, менә әле, шушы тел белән сөйлим икән, мин аның матур да, камил дә, бай да икәнлегенә сокланып, күңелдәге уйның, хисләремнең һәммәсен әйтә алуыма горурланып сөйлим. Ул телне мин ясамаган. Мин аны боза да алмыйм!» *(73 б.)* (Хәсән Сарьян. *«Уеңны уйдырып сал». Тел, әдәби осталык турында мәкаләләр.— Казан: Тат. кит. нәшр., 1977. Алга таба да цитатадан соң күрсәтелгән битләр шушы чыганактан).*

Фикерне куәтләп, без дә өстик: бүген дә аерым кешеләр урысчалап-татарчалап сөйлиләр икән, хәтта матбугат басмалары да, иске сүзләрне кайтарабыз дип, аңлашыр-аңлашылмас сөйләм оештыруны хуплыйлар яисә үзләре дә, тел кагыйдәләрен бозып, наданлык күрсәтәләр икән, моңардан татар теле «бозылу» түгел, селкенми дә. Чөнки аның һәр сүзе үз урынында кала бирә. Чөнки алар — зур туган телебезнең һич бозылмас энҗеләре. «Халык ни гомер яшәсә — теле дә шул гомер яшәячәк» *(73 б.)*,— ди Х. Сарьян.

## Фикер — сөйләм — тел

Тел һәм сөйләмне менә шушылай якынча мөстәкыйль итеп күзаллау белән беррәттән, Хәсән Сарьян бу ике төшенчәнең бер-берсеннән аерылгысыз икәнен дә буйдан-буйга басым ясап әйтеп килә. Мәсәлән, телнең барлыкка килүен, үсешен, камилләнүен дә нәкъ менә сөйләм белән туры бәйләнештә аңлата ул. Аның телгә бәяләмәсен карыйк: «Телне без иң камил бер а ң л а ш у коралы, кешелек дөньясын алга ә й д ә ү ч е бер прогресс чарасы, дибез. Тел ул б у ы н н а н - б у ы н г а а н а с ө т е б е л ә н к ү ч ә к и л г ә н һ ә м к ү ч ә ч ә к иң мөкатдәс бер мирас булып, телен җуймаган милләтләрнең өстә ярылып яткан бердәнбер сыйфаты, билгеседер. Тел ниһаять — туган ил, туган җир ул» *(109 б.)*.

Төрле яклы, колачлы билгеләмә бу. Телнең күп функцияләре искә алынган монда. Шулай да беренче нәүбәттә аның сөйләм өчен хезмәт итүе ярылып ята. Без астына сызган берәмлекләргә игътибар итегез: алар шушы фикерне раслый. Аннары, бер телнең үз кысасындагы бурычына гына түгел, ә бүтән телләр белән мөнәсәбәтенә дә караш бар: «Бик борын заманнардан бирле халыклар бер-берсе белән аралашып яшәгән: сәүдә итешкән, сугышкан, бер-берсеннән дин, гыйлем, һөнәр алган һәм сүз алган. Чөнки бер халыкның үзендә булмаган әйбер, төшенчә, идеяләр икенче халыктан сүзе белән үк кергәннәр» *(75 б.)*.

Һәрхәлдә, Сарьян «тел тел өчен» чиреннән азат. Аның бер генә күзәтүе, фәнни нәтиҗәсе дә тел гыйлеменең тар кысаларында гына йомылып калмый, ә бәлки сөйләм кыйбласына карап хәл ителә. Менә берничә дәлил. Телгә теге яки бу яңа сүзне алыргамы-юкмы, теге яки бу архаизмны, тарихи сүзне кайтарыргамы-юкмы, дип элек тә бәхәсләшкәннәр, бүген, исә бу чын-чыннан чәкәшләр төененә әйләнде. Әмма мондый очракның күпчелегендә хисси дуамаллык өстенлек итә, фәнни нигезләүләргә урын калмый. Ә Сарьян булса, менә болайрак фикер йөртер иде: «...телгә сүз алу-алмау мәсьәләсен заман үзе хәл иткән — калдырасын калдырган, калдырмасын агызган. Әйтик, хәзер бер язучы дә индустрия, промышленность урынына с а н а г а т сүзен кире кайтарыйк дип дәгъва сөрми (*Сөрә шул, Сарьян абый, кадерлем, хәзер әллә нәрсәләр дә «сөрәләр»* — И. Н.). Әмма ләкин сүзнең аһәңе, эчке ритмы хакына бер язучы, мәсәлән, мин, менә бер, анда да сүз сөрешеннән аңларлык итеп, санагат сүзен кыстырып җибәрәм икән; яки әгәр тәрбиясендә гарәбчәлек һич булмаган яшь буын шагыйрь Ренат Харис: «Синең аша үткән җилләр силгә әйләнсен шатлык тулып» дип, «ташкын» урынына сил сүзен куллана икән, аңардан гына татар әдәби теленең бер чите дә кителеп төшмәячәк» *(112 б.)*.

Сөйләм оештыруның үз канун-кагыйдәләре булса да, алар тел законнары белән тыгыз үрелеп бара. Монда шәхси башбаштаклыкка да, өстән әмер бирү —

волюнтаризмга да урын юк. «Казан дәүләт медицина институты» дигән атаманы «Казани дәуләти медикаль институт» дип тәкъдим иткән бер иптәшкә Хәсән Сарьян болай аңлата: «Сез тәкъдим иткән мисаллар да, сүзләр бәйләнеше дә, татарча булмау сәбәпле, һич безнеңчә түгел». «Безнеңчә түгел», ягъни тел законына туры килмәүнең ни нәрсә икәнен ул менә ничегрәк төшендерә: «Казани дәуләти медикаль институт» дип язар өчен Союзда яшәгән алты миллион татарның һич югы Казан арты дигән бәләкәй генә бер төбәге сөйләшү кирәк...» *(99 б.)*.

Хәтта исем кушканда да, кеше исемен тел һәм сөйләм берәмлеге дип карап, аның бүтәннәргә (ягъни сөйләм адресатына) ничек-ничек тәэсир итәчәген күз уңыннан төшермәскә кирәклеген кисәтә Сарьян. Чыннан да, Инфекция кебекләрне әйткән дә юк (бер апа кызына шундый исем куша), Гүзәл, Сылу шикелле исем кушар алдыннан да уйланырга иде, күрәләтә ямьсез бер кызга гүзәл дип әйтергә кыенсына башлыйсың — мыскыл иткән кебегрәк килеп чыга *(107 б.)*.

Тел белгече буларак, Хәсән Сарьян телне, әлбәттә инде, тоташ бер нәрсә дип, аморф хәлдә дип күз алдына китерми. Ул аны, фәндә каралганча, категорияләрдән тора дип белә. Иң әһәмиятлесе шунда ки, урта мәктәп тәмамлап, үзен белемле дип санап йөргән күпчелегебез, хәтта галимнәребез, ул әлеге категорияләргә катып калган бер төшенчә яисә форма дип түгел, ә бәлки сөйләм хаҗәтен канәгатьләндерү өчен кирәкле нәрсә дип карый. Әйтик, синоним күренешен Сарьян болайрак аңлата: биек белән югары — синоним сүзләр. Һәркайсы аерым торганда бернинди мәгънә аермалары юк кебек: икесе дә берәр әйбернең, берәр билгенең җирдән өстен булуын белдерә. Әмма сүзләр бәйләнешендә (*ассызык безнеке* — И. Н.) алар берсен-берсе алмаштыра алмый. Мәсәлән, биек йорт бер, югары урын — икенче.

Кызык бит: Сарьян сүзтезмә дими, бу — тел гыйлеме берәмлеге, ә сүзләр бәйләнеше, ди. Сөйләмияттә бәлки сүзбәйләнеш дигән термин кереп китәр?

Яисә аның тавтология дигән тел күренеше турындагы уй-фикере: ул бездә форма тавтологиясе (чәчү чәчү, чигү чигү, тегү тегү h. б.), тамыр тавтологиясе (эш эшләү, буа буу, урам урау h. б.) барлыгын искә төшерә дә, хәзер бу мөмкинлекләрдән аз файдалануыбызга офтана: «...Ике кабат кабатлаудан курыккан булып, икенче өлешен икенче сүз белән алмаштыра башладык. Шуның берсе — башкару дигән сүз. Мәсәлән, көтү көтә генә түгел, ә ... көтүче хезмәтен башкара...» *(125 б.)*. Нишләмәк кирәк, хөрмәтле язучыбыз борчылып, кисәтеп язган эш башкарыла (эш эшләү урынына), җыр башкарыла (җыр җырлый урынына) һәм башка шундыйлар әле бүген дә күңелне тырнап, әйтелеп тә, язылып та тора.

Хәсән Сарьянның сөйләмият белгече булуы аның орфоэпия мәсьәләләре белән дә шөгыльләнүендә, бүгенге көндә тәмам диярлек онытылып беткән бу фәннең язмышы белән кызыксынуында да чагылды. Аның әлеге күзәтүләре, мәсәлән, язу һәм әйтүдә тартык авазлар ассимиляциясенең бозылу күренеше (дибәйтәм урынына дипәйтәм h. б.) бүген дә актуаль.

Фикеребезнең бу өлешен түгәрәкләп әйтсәк, иҗат кешесе буларак, Хәсән Сарьян фикер — сөйләм — тел берлеген нечкә тоя, моны ул үз әсәрләрен язганда файдаланып кына калмый, башкаларга да төшендерергә омтыла. Бу хакта аның менә нинди тәэсирле гыйбарәләре игътибарга лаек.

«... Идея һәм тел — бер кешенең ике күзе, ике кулы, ике аягы; ниһаять ул — бер кешенең сөяге белән каны, йөрәге белән акылы! Чын идея чын тел белән язганда гына халык күңеленә төшеп сеңә» *(140 б.)*. «...Тел — безнең бердәнбер эш коралы да. Ул бер, ә без мең! Шуңа күрә без инде аны менебез мең яктан бозмыйк. Киресенчә, менебез мең яктан үстерик, баетыйк... Халыктан тел җәүһәрләрен алганбыз, ә кайтарганыбыз — канәгать итәрлек түгел» *(139 б.)*.

Менә шушы инде ул сөйләмне Сарьянча аңлау.

## Табып әйткән сүз — гәүһәр

Сөйләм ничек оеша? Әйе, тел бар, әйе, сүзләр күп. Ләкин кайсы соң иң кирәклесе, аралашу өчен нәкъ шушысы? Әнә бит халык та, табып әйткән сүз генә гәүһәр, ягъни нәкъ үтемлесе, тәэсирлесе, ди. Табу дигәне нидән гыйбарәт? Күрәсең, ул без бая әйткән сөйләм системасы. Ә ул мәгълүм закончалыкларга нигезләнә, мәгълүм бер механизм белән хәрәкәткә китерелә. Хәрәкәт чарыклары ул — мотивлар: сөйләм иясе, адресаты, нияте һәм шарты.

Сөйләмият фәне нигезенә Хәсән Сарьян хезмәтләре кирпеч-кирпеч ятарга хаклы дигәндә, без сөйләм белгеченең менә шушы механизмны ачык тоемлаган булуын истә тотабыз. Аның фикер агышын әлеге система белән анализлап карыйк әле.

Иң әүвәл шулдыр: Хәсән Сарьян, әлбәттә инде, сөйләмне кем оештыруга карап, телнең үзенчәлекле кулланылуына игътибар итми калмаган. Әйе, аныңча да, сөйләм иясе — мөһим компонентларның берсе, тел чараларының сайлануы шуңа бәйле. Менә дәлилләр чылбыры: — «...татар әдәби теле җегәрләнеп, дөньядагы алдынгы телләрдән һич калышмас дәрәҗәгә басты. Чыннан да, әгәр кешесенә эләксә, җәүһәр-алмазлар уйната ул безнең тел!» *(109 б.)*.

«Өстәл артында утыра», «руль артында утыра» кебек тәгъбирләр дә берзаман бик еш күренә башлаган иде, без аларны хәзер шактый киметтек. Шулай да кайвакыт татарча белмәүчеләр яисә татарча уйлап җиткермәүчеләр телендә бүген дә күренгәләп китә» *(135 б.)*.

«Телнең грамматик нигезен кем кимерә соң? Бер ишесе, мәсәлән, телне тумыштан ук белми, аны инде үгетләп түгел, дегетләсәң дә берни чыкмас; кайберсенең тел тою хисе атрофияләнеп, үлек җыелган — ул хәзер кайсы дөрес, кайсы ялгыш икәнлеген дә аермый, «алай да була» дип, телебезнең төзек һәм мөкәмәл бинасына үзе сыярлык кына тишек тишеп, шуннан йөри башлаган; өченчесе просто үз телен өйрәнер-өйрәнмәстән Европа йә Азиянең модалы бер агымына ияргән була да, телне мескен бакага әйләндереп, мәктәп баласыдай тәҗрибә ясый; тагын бер ишесе бар: болары исә «мин беләм инде!» дигән җирдә туктаган да, бүтән бер адым алга атламас. Әмма көлләсенең дә кәсафәте бер: телне бозалар!» (*117 б. Ассызыклар алга таба да безнеке* — И. Н.).

Шәхси сөйләм иясе буларак, тел куллануда шагыйрь хикәячедән, тәрҗемәче драматургтан, очеркист фельетончыдан аерыла. Сарьян да шулай уйлый. Ул, мәсәлән, шагыйрьгә нинди таләп куя? «... Туган җиренең туфрак, үз халкының күкрәк җылысын йөрәк ите белән тоймаган шагыйрь минем йөрәгемә керә алмый, аңа шулай ук башка халыклар күңеленә дә юллар ябык була. Үзеннең туган җиреннең, үз халкының син булмаганда кыен булачак бер күзәнәге булганда гына, син юлны башкаларга да киң ярасың...» *(69 б.)*.

Ә тәрҗемәченең тел куллану үзенчәлеге ничек күзаллана? Ул да сөйләм булдыручы, ул бер телдә әйтелгән фикерне икенче телдә бирә. Кайберәүләр өчен тәрҗемә ул — бер сүзне икенче сүзгә каплап бару гына кебек, әмма юк икән, монда да иҗади үзенчәлек таләп ителә икән. «Кыям Миңлебаев — үзенә аерым зәвыклы, үзенә генә хас куллы тәрҗемәчеләребезнең берсе»,— ди дә менә шушы үзенә хас «кулын» болай төшендереп бирә. «Ул тәрҗемә өчен һәм лексик, һәм грамматик, һәм философик яктан үтә авыр әсәрләрне сайлап ала: күңеленә шулар якын аның... Әгәр бер кеше берүк язучының (А. Толстой әсәре) башта бер әсәрен, аннары икенче, өченче әсәрен тәрҗемә итә башлаган икән, монда инде «очраклы» дигәннең эзе дә калмый. Димәк, Миңлебаев Алексей Толстой иҗатын йөрәгенә уйлары, хисләре аша үзенеке итеп кабул иткән» *(58—59 б.)*.

Әле китерелгән мисаллардан тел чараларын сайлауда янә бер компонентның, ягъни сөйләм оештыруда ниятнең (максатның, теләкнең) дә әһәмиятле урын тотуы ярылып ята. Чыннан да, шулай бит: фикереңне нинди нияттән җиткерергә теләвеңә карап (үгетләпме, көлдерепме, образ белән ме, әллә фактка нигезләнепме яисә нинди хис-тойгы белдерергә теләвеңә карап) тел чараларын сайларга мәҗбүрсең. Хәсән Сарьянның бу хакта да фәнни фикерләүләре барлыгына бер генә мисал китереп китик: аптырау, гаҗәпләнү тойгысын белдерү өчен язучы, телнең башка чаралары белән бергә, ничек сүзенә дә игътибар итә. «Ничек» сүзе, гамәлнең рәвешеннән тыш, төрле дәрәҗә аптырау, гаҗәпләнүне аңлата. Янә дә үрнәге Тукайда бар: «Ничек соң без табындык потка дип хәйранга калганнар» *(127 б.)*.

Чыннан да, әйтергә теләгән ниятеңә муафыйк берәмлек табуы, ай-һай, җиңел түгел. Күпме сүз-синоним арасыннан нәкъ шушысын табып куярга кирәк. Күп очракта азапланмыйча, кул селтәп китәбез бит. Остазларны нәкъ шул мизгелдә искә төшерергә иде. Мәсәлән, тискәре фикерле нәтиҗә ясыйсың ди, ә нәтиҗә сүзенең асылында уңай төсмер өстенлек итә, шуңа күрә дә начар эш нәтиҗәсе яки ялкаулык нәтиҗәсе дию ниятеңә нәкъ тәңгәл булмый. Шуңадыр да, күрәсең, телгә результат сүзе кереп бара иде, анда тискәрелек төсмере көчлерәк шикелле. Әмма ул «килмешәк»кә дә кул бармый. Нәкъ менә шундый азаплы эзләнү минутында остазның кәсафәт сүзе искә төште дә. Без

ул мисалны бая китердек инде: «Әмма көлләсенең дә к ә с а ф ә т л е бер: телне бозалар!» Күптән түгел бу сүзне публицист, шагыйрь Айдар Хәлим мәкаләсендә дә күреп сөендем, остазлар үрнәгендә эзләнсәң, чыннан да, «гәүһәрләр»гә юлыкмый калмыйсын!

Сөйләм оештыруның янә дә бер мәҗбүри «кабыргасы» ул — с ө й л ә м а д р е с а т ы. Бу компонентны күз алдында тоту ихтыяҗына һәм мөмкинлекләренә Хәсән Сарьян ничек карый?

«VI—VII классдар өчен өстәмә әдәбият» китабын *(Казан, 1973)* рецензиялəгəндə, андагы Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов әсәрләрендәге кайбер иске сүзләргә бит ахырында аңлатма бирелмәвен кисәтеп, ул болай ди: «...Текстны укып чыккач, андагы байтак сүзне б ү г е н г е у к у ч ы н ы ң аңламаячагын беләсең. Мәсәлән, «Китап» шигырендә: «Җиңелләнәм, мәгъсумланам мин ул шул чакта», — дигән җөмлә бар. Нәрсә ул мәгъсумланам? Билгеле, V I — V I I к л а с с б а л а с ы моны аңламый. Яки нәрсә ул таифә, гаурәт, шәһвәт... һ. б.? Ярый ла укучы үзе сорап, укытучы үзе аңлатып бирә алса? Ә укучы сорамаса яки сорап та укытучы белмәсә? Автор әйткән мәгънәгә төшенмәү өстенә, укытучының да кыен хәлгә төшүе бар бит...»

Төрле рәсми документларда, элемнә атамаларда туган телнең бозылуын яисә бөтенләй татарча язылмавын аңлатканда да, Сарьян сөйләм мәнфәгатен истә тота: «Өр-яңа культура йорты салганнар да, маңгаена «Дом культуры» дип язып куйганнар. Авыл — гел татар. Яки өр-яңа кибет салып куйганнар да «Товары массового потребления» дип язып куйганнар. А в ы л — г е л т а т а р» *(96 б.)*.

Һәйкәлләрдәге язуларга да ул шундый күзлектән карый: «...һәйкәлләргә дә үзебезнең тел белән: Мәңгелек дан! дип язып куйган булсак, ү з е б е з н е ң х а л ы к к а, үзебезгә хөрмәт булмас иде микәнни!... Аннары, авыл саен шушы һәйкәлләргә карап йөргәндә, бу авылдан ничә кеше үлде икән дип, исем-фамилияләрен укып, санап торганда, безнең янга берәрсенең ә т и с е яки ә н и с е дә килеп баса. Алар без юкта да киләләрдер. Әгәр шунда бер ана, төштә генә күргәндәй булып калган газиз улының исемен табып: «Дзяппаров Мутахкар» дип укыса — күңеле нишли икән аның? «И балам, үзең һәлак булу җитмәгән, инде исемеңне дә бозып бетергәннәр бит!» дип әрни торгандыр дип уйлыйм» *(97 б.)*.

Тәрҗемәнең сыйфатына бәя биргәндә дә, Х. Сарьян аны менә нинди сүзләр белән билгели: «...мәгънәсез һәм аңлаешсыз җөмләләр... Төрле кульязмадан төрле йөз күрәсең: берсе куәтле, берсе куәтсез, берсе ояңчан, берсе әрсез...» Болар да иң әүвәле укучыны — сөйләм адресатын күз алдында тоткан критерийлар. Кульязмага кеше сыйфатлары биреп, ул нәкъ менә текстның аралашу, аңлашу өчен әзерләнгән булуын искәртә. Югыйсә, күпчелек тәнкыйтьчеләр текстка ул яктан бәя бирмиләр, бирсәләр дә «матур», «яхшы», «тәэсирле», «ошый» кебек гомуми бәяләр белән чикләнәләр. «Сүз мәңге хәрәкәттә, — ди Сарьян, — өстәвенә телдә дә тагын җәмгыятькә тиң хезмәт бүленеше бар». Шунда ук Кави Нәҗми сүзләрен дә китерә: «Барлык татар халкының яше, карты бер тигез белгән сүзләрне генә әдәбиятка кертү принцибы белән эш итсәк, телебезне ярлыландырудан башка нәтиҗә чыкмаячак» *(111 б.)*.

Шунысы аеруча әһәмиятле һәм кадерле: сөйләм белгече үзенең фәнни хезмәтләрендәге мондый «күрсәтмәләренә» әдәби һәм публицистик әсәрләрендә дә тугъры кала. Әйтик, әгәр гарәп-фарсы сүзе нәкъ иң кирәкле сүз икән, бүтән сүз белән алыштырып булмый икән, әмма ул шушы текстта адресатка аңлашылып бетмәс дип шикләнелә икән, ул аны аңлатып китәр. Татарча йә русча термин белән, йә бүтән чара белән: «Аннары тагын, әйткәнемчә, тел кагыйдәләребез бик нык унификацияләү сәбәпле, бездә бернинди мөстәсна (исключение) юк» *(133 б.)*.

## Үз йөзе, үз «кулы»

Мәшһүр бер язучы әсәрен йотылып укыганда, аның тел осталыгына сокланабыз да, моңа ничек ирешкәнен уйлап-төпченеп тормыйча, «талант кодрәте, табигать биргән могҗиза» дип кенә куябыз. Дөрес микән? Хәсән Сарьян — танылган тел остасы, аның үз иҗат алымнары, үз йөзе. Ул моңа ничек ирешкән? Бүген бераз ачыклана төште кебек: язучыбыз укучыга әйтәсе сүзен нәкъ менә бер бөтен сөйләм итеп күзаллап, аның җанын, эчке һәм тышкы сулышын тоеп эш итә. Әйе, әйе, чын-чыннан эш итә. Ягъни армыйталмый эшли!

Язучы Евгений Замятин сүзләре истә калган: «Минем язмаларга карап, ялгышырга да мөмкин — анда сызу-бозу, төзәтүләр күп түгел, җинел язылган кебек тоелырлык. Әмма бу шулай тоела гына, барлык азаплар чаршау артында — һәр фикерне мин башта ун тапкырлап һәртөрле уйлыйм, аннары гына кәгазьгә салам. Эшкәртелеп бетмәгән фикер, гыйбарәләрне калдырмыйм. Язылган фикер иртәгә бәлки миңа ошамас та, үзгәртергә дә туры килер. Әмма бүген ул миңа тәмам ошарга тиеш, югыйсә мин алга бара алмыйм...»

Беләм, Хәсән Сарьян да нәкъ менә шулай эшли иде: һәр сүзен, гыйбарәсен кабат-кабат карар, тыңлар, капшар, аннары гына энҗе бөртекләре белән кебек вак, җыйнак, бер-берсенә тыгыз тезелгән хәрефләр белән кәгазьгә төшерер. Аннары да әле күп зиһенен, хәтерен, көчен салып, кайта-кайта эшкәртер, шомартыр, аһәңгә китерер иде. Менә ничек барлыкка килә бит ул язучының иҗади шәхси йөзе!

Останың йөзен аның куллары шәрехли. Хәсән Сарьян «кулы» дигәндә исә менә нинди конкрет «бизәкләр» күз алдына килеп баса:

— үзенчәлекле мәгънә төсмерләре булган, әмма соңгы вакытларда сөйләмдә пассивлашкан берәмлекләрне җанландыруы (с ы г ы м т а, к ө л л е, к ә с а ф ә т, а с л а һ. б.);

— кайбер алынма һәм үзебезнең гади сөйләм элементларын язма сөйләмгә оста кертүе (з е р ә, к е р ә ч, т а м а н с ы, п р о с т о һ. б.);

— уңышлы атама, терминнар тәкъдим итүе (э л е н м ә а т а м а, т у у т а н ы к л ы г ы һ. б.);

— күп кенә гарәп-фарсы элементларын урынлы куллануга ирешүе (а л ә т, м у а ф ы й к, м ө б ә р ә к, м ө к а м ә л, м ә х б ү с һ. б.);

— сирәк кулланылып, онытылуга дучар ителгән фразеологизмнарны иҗади яңарту мөмкинлекләрен күрсәтеп бирүе (а ч к ы ч я р а т у, б а з а р ы т ө ш ү, с ө н н ә т к ә у т ы р т у, к ү з к а б а г ы н а ч у һ. б.);

— туган телебез хәзинәсендә аныкы гына булып җемелдәгән күп санлы чагыштыру, троп, образлар, канатлы гыйбарәләр иҗат итүе. Менә берничәсе генә: «Әгәр без татар тел гыйлеменең җеп очын эзләп китсәк, ж е п н е с а в а - с а в а мәшһүр бабабыз Каюм Насыйрига барып чыгачакбыз» *(109 б.)*; Бик борынгы баба телендәге уртак тамыр сүзләрне исәпкә алмаганда, берничә сүздән башка, телебездә монголның к а н а т о ч ы б е л ә н с е б е р е р л е к т ә э з е калмаган» *(110 б.)*. Бу соңгы елларда телебезнең грамматик кануннарын, а г а ч к о р т ы д а й, ә к р е н - ә к р е н г е н ә к и м е р ә башладылар» *(116 б.)*.

Сүз җаеннан дигәндәй, грамматик чараларга Хәсән Сарьян үзе аеруча сак, аеруча игътибарлы:

— ярдәмче фигыльләрнең өстәмә мәгънә төсмерләрен ача, шулай итеп, штамп, калыплардан котыла (й о г ы н т ы и т к ә н халык — йогынты ясаган түгел. *(111 б.)*;

— телнең күп санлы синтаксик фигураларын куллана, яңа төрләрен үзе дә иҗат итә, аеруча кабатлауларны иҗади файдалана (... гарәб сүзләре «бер сузыкка бер тартык» моделе белән татар теленә к а л ы п к а к а л ы п, а в а з г а а в а з д и г ә н д ә й к е р г ә н д ә у т ы р г а н, к е р г ә н д ә у т ы р г а н... *(11 б.)*;

— сүзләрнең сирәк кулланыла торган синонимнарын әйләнешкә кертеп, фикри калыплардан, стереотиплардан котылу юлын күрсәтте (телдә дә җәмгыятькә т и ң (кебек, шикелле, сыман, хас, тәңгәл һ. б. урынына) хезмәт бүленеше бар... *(11 б.)*.

Хәсән Сарьянның тел куллануга, сөйләм оештыруга кагылган караш, фикерләренә мисалларны без аның фәнни һәм публицистик әсәрләреннән, анда да әле бер генә китабыннан китердек. Матур әдәбият остасы буларак та Хәсән Сарьянның үз алымнары, үз йөзе бар. Ул соклангыч бай, тәэсирле һәм үзенчәлекле. Анысы — үзе бер дәрья, анысы да фәнни өйрәнү өчен әһәмиятле, мавыктыргыч тема.

*Дискуссия дәвам итә:*

## БЕЗНЕҢ ТОРМЫШ. БЕЗНЕҢ ӘДӘБИЯТ

**Фәрит Бәшир**

# ИСӘ ҖИЛЛӘР...

Каләм! Кальбеңдә ни сер бар — гаян ит,
Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.

*Дәрдемәнд.*

**Әллә нинди гасыр бу егерменче йөз!**

**Бер карасаң, искиткеч ачышлар, зиһен җитмәслек фәнни һәм техник казанышлар, уй белән ниләргә мөмкин булмаган галәм киңлекләренә сәяхәт, иң тылсымлы әкиятләрнең дә фантазиясен томыклардырырга сәләтле акыл тантанасы, тагын әллә нәрсәләр, әллә ниләр... Икенче карасаң, коточкыч киеренке вакыйгалар ташкыны: сугышлар, революцияләр, бәрелешләр; таулар, башбаштаклык, ачлык, кан, дәһшәт, үлем...**

**Капма-каршы төсләрне, алымнарны, законнарны үзенә туплаган, бер-берсен катгый инкяр итүче ике тарафның бәйләнешеннән гыйбарәт булган сәер гасыр бу егерменче йөз...**

**Бу хакта хәзер еш уйланалар.**

**Бу парадокска әле без тора-тора кайтырбыз.**

**Бу язмамда мин фикеремне заман һәм кеше мөнәсәбәтенә юнәлтергә ниятләндем.**

* * *

Жырлыйлар бит әле: «Су өсләре сары абага, авыр килде безгә замана...» Ә ни дәрәҗәдә авыр соң ул замана, билгеләп буламы икән аны? К. Сибгатуллин бу турыда өзеп, бетереп әйтте:

Авыр димим сине,
җиңел димим,
үлчәп булмый сине, Замана.
Утыз яшькә җиткән егетләрнең
икенче кат чәче агара.

Чынлап та, кайгы-хәсрәтләрне, күңел газапларын, җан ачыргалануларын кайсы берәмлекләрдә үлчәргә мөмкин? Аналарның, сабыйларның күз яшьләрен нинди бизмәннәргә салыйк? Ялган, җәбер, золым, хыянәт, хурлыкларның микъдарын нинди дәрәҗәләрдә күзалларга?

Нинди кешеләр соң без? Нинди дөнья соң бу? Нинди соң син, Бүгенгебез? Бумеранг кебек кире кайтып җаныңа суккан бу сорауларның катгыйлыгыннан гаҗиз калгач, ирексездән, Зөлфәт шигырендәге манара нигезенә тере килеш бикләп калдырылган кыз сыман эндәшердәй буласың: «Тышта кайсы гасыр? Сездә кайсы гасыр?»

Ярый, инде замана дигәннәрен үлчәп булмый икән, бәлки төп сыйфатларын билгеләргә мөмкиндер?

Исем-атамалары күп Заманыбызның: үзгәртеп кору, хәбәрдарлык, уяну чоры... Кемнәрдер аны Бишенче ел инкыйлабына тиң карыйлар, «боз кузгалды!»

дип шатланалар (кемнәрдер исә кисәтергә ашыга: «Боз кузгалды диеп сөенәбез, кузгалмады, бары чатнады...»). «Дәверебез — милли-азатлык хәрәкәтенә күтәрелгән дәвердер»,— дип раслыйлар кайберәүләр һәм өзлексез алга әйдиләр. Кемдер үткәндәгеләрне сүгә, кемгәдер бүгенге сәясәтнең башында баручылар золым чыганагы булып күренә, өченчеләре тегесенә дә, монысына да тәнкыйть яудыралар. Дүртенчеләр «бусы да яла» дип юкка чыгарырга итәләр. Бишенчеләр... Кыскасы, мең кешедә мең фикер, һәркемнең үз инануы, үз мәшәкате. Тукайга ияреп әйткәндә:

Һәр заманны монда хәлләр шул икән,
һәркем үз хәле белән мәшгуль икән.

Шулай да, һәр заманда асыл, намуслы ул-кызларның уй-хыяллары иң әүвәл җәмгыятьне, яшәешне ялганнан арындыру булды дисәк, шаять, чынлыктан ерак китмәбездер. Гомумән, кешелекнең үсеш законлалыгы хакыйкать һәм ялганның тартышыннан гыйбарәт тә бугай әле. Кайсы көчнең өстенлек алуына нисбәтән гасырлар «алтын дәвер», «яңарыш чоры» яки «болганчык, гаугалы заман» дип каралдылар.

Бер карасаң, бик гади сыман: табигате белән кеше ялганга каршы булырга, хакыйкатькә генә табынырга тиеш. Ә чынлыкта исә, нигәдер гел киресе... Бу мөгаен, ялганның характер-сыйфатыннан киләдер. Эпитетларына гына игътибар итик: баллы ялган, татлы ялган... Хәтта «изге ялган» дигән төшенчә дә очрый. Хакыйкать исә, әнә ул, үзен ничек бар шулай атауны таләп итә: кырыс, ачы... Авырлыклардан, тормышның ерып чыккысыз каршылыкларыннан чарасыз калган, җаны талчыккан адәм баласы ихтыярсыз Ялганның ымсындыргыч дөньясына тартыла башлый. Биредә матурлык бар. Ямь бар. Ләззәт бар. Дөрес, болар барысы да ясалма, барысы да зәһәр агуны яшерүче тышкы ялтыравык кына. Шуңа күрә ул исерткеч-стимуляторлардан айну процессы гаять газап, җәфаланулар белән бара. Күпләр бу сынаулар уза алмый кабат Ялганның изрәткеч рәхәтлегенә ташланырга ашыгалар. Рухы нык булганнар да аптыраудан, гаҗизлектән азат түгелләр. Чөнки Ялган, хамелеон сыман, кинәт төс-кыяфәтен үзгәртергә сәләтле. Бар, җиңел генә танып кара аны! Үзен яклау, аклау өчен әллә нинди чараларга бара, кирәк булса өркетергә, кирәк икән ялагайланырга оста ул Ялган! Миеңне томалый, зиһенеңне чуалта, уеңны адаштыра, кыйбláңны бутый ул Ялган!

Гасырларда адашып йөрмичә, үзебезнең якын тарихка, өзлексез сөйләнәсүтелә торгач, телләргә төер булып урнашкан 1917 елдан соңгы чорны гына алыйк. Вакыйгалар агышындагы җитди үзгәрешләр, кагыйдә буларак, хакимият иясе алмашынудан башландылар. Чираттагы идарәче үз башбаштаклыгын, үз ялгышларын һәм җинаяте өчен җавапсызлыгын аклау өчен иң әүвәл үзенә кадәрге власть хуҗасын гаепләп чыкты. Бу да ялганның бер формасы һәм, әйтергә кирәк, бик тә отышлысы иде. Чөнки яңа хаким халык белән бергә моннан алдагы «коллегасы» кылганнарга нәфрәт яудырырга керешә, тетә, юкка чыгара. Аның бу юнәлештәге гаять тырышлыгын күреп, халыкта кабат өмет уяна, гаделлекнең, ниһаять, тантана итәчәгенә ышаныч туа. Шул сәбәпле, ул яңа идарәченең кайбер ялгышларына да күз йома, аерым кыланышларын да гафу итә. Мәкале дә бар бит: дүрт аяклы ат та сөртенә. Ләкин аң булырга иде, гади кеше сөртенсә, бары тик аның гына тез башы авыртыр, ә идарәче абынса, ил белән йөзтүбән капланырга мөмкин. Үз мәнфәгатьләре өчен власть алдагы ялганны фаш итә һәм үз ялганын тудыра, чираттагы ялган монысын да юкка чыгара. Менә, тотып кара син шулай булгач Ялганны! Кирәк вакытта, кәлтә елан сыман койрыгын корбан итеп булса да, котылырга тырыша ул.

Ә идарәче-хакимдә ялган — бихисап! Вәгъдәләрне мулдан сибә, чөнки аңа бүгенге рәхәтлек кыйммәт, бүген үз ялганыңа ышандыра алу кирәк. Л. Зөлкарнәй нәкъ шундыйлар турында әйтә дә инде:

Башка сугып имлиләр дә,
Илтеп чыгармаса юлы,
Минем кулым түгел, диләр,
Гайшә Батман кулы...
Ә сәдака —
Кесә тулы!

Соң дәрәҗәдә җитлекмәгән дәүләт төзелеше гарип идеологиягә нигез сала килде, гарип идеология үз чиратында демагог идарәчеләрне яки диктаторларны

тудырды. Шулар аркылы властька үрмәләгән Ялган тырышып-тырышып үз тугры хезмәтчеләрен тупларга кереште, икейөзлелек, әләк, гайбәт, мәкер, ялагайлык, хыянәт — барысын да үзмаксатларында файдаланды. Иң куркынычы шул иде: галиҗәнап Сүз дә аның мәнфәгатьләрендә корбан ителде. Ялган идеологиягә корылган әдәбият, сәнгать, фәлсәфә, тарих китаплары чорның җинаятьчел сәясәтен аклау юлында армый-талмый хезмәт итүгә буйсындырылдылар. Галиҗәнап Сүз шул рәвешле үзенең хакыйкый кодрәтеннән ләббәкәйлек вә шамакайлык мохитенә ташланды. Моның аянычлы нәтиҗәләре дә озак көттермәде... Коръән тәкъбирләрендә тәрбияләнгән халкыбыз ташка басылган сүзгә гомер бакый ышанды, изге итеп таныды, иманы белән табынды. «Китапка язылган» дигән дәлил бөтен шик-шөбһәләрне юкка чыгара, бәхәскә чик куя иде. Ялган шул көчне дә үз максатларына буйсындырды. Бу юнәлештә иң аянычлысы ялган тарих китапларының зәһәрле эшчәнлеге булды. Тарих бит чынбарлыктагы вакыйгалар, конкрет шәхесләр, төгәл дата вә фактлар белән эш итә, үткәннәргә тәфсилле анализ ясап, җәмгыятьнең үсеш закончалыкларын ачыклый. Монда болгатырлык нәрсә булмаска тиеш тә бит, ләкин бар икән, умырткасыз, «йомшак кабыргалы» сүз-дәлилләрне кая теләсәң, шунда борырга мөмкин икән. Мин тарихчылар адресына нәгърә орырга җыенмыйм. Ахыргы сүз — киләчәк буыннарда. Ә ул карар гаять кырыс, рәхимсез булачак. М. Сервантесның шундый сүзләре бар: «Ялган тарихчыларны, ялган акча ясаучылар кебек үк, хөкем итәргә кирәк иде». Шуңа күрә, үткәндәге башбаштаклыклар халыкка рәхмәтләр укып бетерә алмаслык матур тормыш тәэмин итте, дип расланган калын-калын тарих чүпләренә карыйм да, гомерләре заяга узган галим әфәнделәрне ифрат кызганырга керешәм. Һәм киләчәк буыннардан аларга хәл кадәри мәрхәмәтле булуларын сорап калам.

Хәер, кем белә, киләчәктә безнең заман идеологиясен дә, шуңа нисбәтән безнең ялганнан котылуда сайлаган юлыбызны да тетеп, сүтеп ташларлар әле. Ерактан яхшырак күренә, диләр бит.

Шул хәл була калса, моннан бер генә нәтиҗә ясарга мөмкин: ялган безнең дә эш-гамәлләребезне, уй-хыялларыбызны чуалткан, адаштырган һәм без фанилардан каһкаһәле көлгән булган икән.

Бәлки, соң сулышыбыз киселгәндә без ачыргаланып Дәрдемәнд сүзләрен кабатларга мәҗбүр булырбыз:

> ...Җитте дәфнем вакыты,
> Кәфнем бүзләрем маналмадым!..
> Вәйля!..
> Дәри-и-и-гъ!
> Бүзләрем мана алмадым!..

Ә хәзергә:

> Каләм! Кальбеңдә ни сер бар — гаян ит...

Гасырдан азрак вакыт эчендә вакыт эчендә ил, халык өстенә ябырылган дәһшәт-афәтләр турында уйлыйсың да, гәрчә җавап алмаячагыңны белгән хәлдә, үз-үзеңә чарасыз сорау биресең: Ник болай? Ник нәкъ менә без? Ник, нигә, ни өчен... Сораулар ташкыны аркылы Туфанның ерактагы әрнүле тавышын ишеткәндәй булам:

> Кемгә тидек?
> Кемне рәнҗеттек соң?
> Кем соң безне шулай каргады?

Без, бәлки, чынлап та каргалган бер илләр, кавемдер? Бу дөньяга килгәчне үк ләүхелмәхфузебезгә каһәрле ярлык теркәлгән бәхетсез буындыр без, бәлки? Хакыйкать эзләү, дөреслеккә ирешүдән без бөтенләй дә мәхрүмдер? Хакыйкать дигәннәре, гомумән, (һәрхәлдә, безнең өчен) юктыр? Тукайның «Чын вә Ялган» шигырендә әйтелә бит:

> Әүвәле дөньяда җир юк, су гына булган, диләр;
> Анда йөзгәннәр, имеш, тик Чын белән Ялган, диләр...

Бераздан, табигый, алар арасында сугыш куба һәм нәтиҗәдә:

> Көчле кулы берлә Ялган Чынны бер суккан, ди дә,
> Чын батып киткән, ди, чыкмаска җиһанга мәңгегә.

Вәссәлам! Бәс, шулай икән, көрәшеп азапланудан ни файда? Агымга каршы йөзүдән мәгънә юк, җай гына,ипле генә аның тирбәлешенә ярашырга кирәк. Әнә шулай рәхәт була, йокы баса башлый, изрәтә...

Хәерле булсын дисең, тәкъдирдә язылгандыр дип сабырланасың, язмыштан кем узган дип акланасың... Тынычланасың... Бар нәрсәгә кул селтәп, битарафлык, гамьсезлек дәрьясына күмелә баруыңны тоясың.

Инде беттем, югалдым дигәндә, кемнәрнеңдер сынаулы карашларын тоеп, сискәнеп куясың, сагаясың. Авыр күз кабакларыңны күтәреп тирә-юньгә карыйсың да, жаныңа ышаныч, өмет иңдерүче Нәфисәләрне, Акъәбиләрне күрәсең. Әнә алар — халыкның вөҗданы, намусы, рух сакчысы булып якты нурдай балкып торалар. Кыен вакытларда, тормыш агышының хәтәр борылышларында ярдәмгә беренче булып алар ашыгалар. Баласына куркыныч янаганда ярдәмгә иң әүвәл ана киек ташлана. Җәмгыятьтә дә шулай икән бит: милләт өчен иң авыр вакытларда алгы сафта галиҗәнап Татар хатын-кызы барды. Мин Республикабыз өчен гаять киеренке көннәрдә Азатлык мәйданын тутырып ташыган халыкның беренче рәтләрендәге ак яулыклы, ак чәчле татар әбиләрен хәтеремә китерәм. Безнең коргаксыган җаныбыз бүген Акъәбиләргә мохтаҗ икән, димәк, милләтебезгә һәлакәт яный, димәк, кайдадыр читтә генә азатлыгыбызны бугазларга әзер ерткыч йөри. Аналар сизгер затлар, алар юкка борчылмас.

Ил, халык намусының символы булып күтәрелгән Нәфисә, Акъәби янәшәсендә мин бүген «Таң җиле» романындагы Нуриасманы күрәм. Шөкерана итәм, әхлак, иман, вөҗдан төшенчәләрен маяк итеп алган затлар сафына бер көнлек лилипут «геройлар» төркемен ерып, лаеклы юлдаш өстәлде. Милләтебез өчен гаять катлаулы бер заманда килде дә керде ул әдәбиятка. 1992 ел бик авыр, борчулы ел булды дисәк тә, үзенчәлекле язучы Фоат Садриев каләме белән «Таң җиле» романын бүләк иткәне өчен рәхмәтле булыйк аңа.

«Таң җиле»... Беренче карашка, гап-гади авылның гадәти кешеләре турында бу роман. Әмма вакыйгалар агышына керә барган саен, әсәрнең мәгънәсе, тирәнәя, асыл максатының җегәре саллылана баруын тоясың. Роман — яшәү белән үлем хакындагы мәңгелек фәлсәфәгә нигезләнгән. Әсәрдә ул Нуриасма образы аркылы укучыга бәян ителә.

Романның беренче җөмләсе үк сүзнең югары, олуг тема хакында баруына ишарәли.

«Аны фәрештә дип уйларга мөмкин иде. Кардай ак озын күлмәк, кардай ак яулыгы астыннан күренеп торучы кардай ак чәчләр...»

Нуриасма шулай ак фәрештәдәй бөтен кешелек дөньясын яңа туып килгән көн тарафына сәфәргә озата. Әнә ул, Җир-Ана сыман, урман-кырларын, тау-суларын сөеп күздән кичерә, җиһанга алсу нур иңдереп күтәрелеп килүче кояшны сәламли: «Әйдә, рәхмәтең белән, хәерең белән кил!»

Ләкин, «хәере белән килмәде бу көн...»

Әсәрнең тыныч агышына утлы хәнҗәрдәй айкап хәбәр килеп керде: «хәере белән килмәде...» Сискәнергә мәҗбүр итүче, тетрәндергеч вакыйгаларга ишарәләүче шомлы хәбәр бу.

Әсәрдә үзәк сюжет сызыгы шундый дәһшәтле тоннан башлана. Хәтергә Г. Ибраһимовның «Тирән тамырлар» романы килә: «Фәхрине үтереп ташладылар...»

«Таң җиле»ндә дә вакыйгалар башы тыгыз, шартлаулы ситуациядән гыйбарәт: авылның бер дигән асыл ир-егете Рәмзинең гомере фаҗигале өзелә. Бу трагедиянең төп сәбәпчеләре, гаепле кешеләре бар, димәк, Рәмзине дә «үтереп ташладылар».

Игътибар иткәнегез бармы, без соңгы вакытта авария корбаннарына күнегә барабыз бит. Машина-трактор һәлакәтенә эләгеп гомерләре киселгәннәр тетрәнерлек саннарны тәшкил итәләр ләбаса. Андый фаҗигасе булмаган берәр авыл калды микән әле? Фаҗигаләр бүген гадәти хәлләргә әверелеп бара — коточкыч бит бу? Кайчандыр кеше аянычлы, үкенечле вафат булса, исемен яд итеп бәет чыгарганнар, хәзер исә милиция көндәлегендә цифрлар булып чагылыш таба. Бу да заманага хас күренеш микәнни соң?

«Таң җиле» романында да фаҗига: исерек шофер Гарифҗан, текә үрдән төшкәндә, машинасы белән каплана. Үзе җәрәхәтләнеп шифаханәгә эләгә, ә янәшәсендәге Рәмзи тәгәрәгән машина астында кала...

Йортка, гаиләгә кайгы килә. Кешеләргә ифрат ярдәмчел, хөмер кебек нәрсәләрне бар дип тә белмәгән типсә тимер өзәр ир-егет гүр куенына кереп ята. Барысын да калдырып китә Рәмзи, хатыны Мәдинәне, ике газиз баласын, әтиәнисен, туганнарын... Иртә белән генә сау-сәламәт булган, шаярткан, рәхәтләнеп

көлгән ирнең гомере мизгел эчендә өзелә, һәм бу үлем шулкадәр көтелмәгән була ки, беркемнең дә моңа ышанасы килми. Ничек инде Рәмзи үлсен ди, аның бит әле яшьнәр генә чагы, балаларының игелеген күреп, сөенеп, башкаларны да сөендереп яшәр чагы... Ахыр чиктә аның ике ниргәсе генә утыртылган бурасы бар ич әле, бура почмагына чабып кына куелган балтасына кадәр аны көтә бит!

Хәер, шагыйрь әйтмешли: «Һәрбер үлем үкенечле, һәрбер үлем — көтмәгәндә». Рәмзи үлеме дә, бәлки, тора-бара авылның башка мәшәкатьләре артында калып тоныкланыр, тик гаилә җанында гына вакыт-вакыт сыкрап алучы җөй булып калыр иде.

Ләкин бу әле төп эчтәлеккә кереш буларак кабул ителә, автор укучыга сиздерми генә аның зиһенен башка мәсьәләләргә юнәлтә бара, шуларга бәйле рәвештә романда башка ситуацияләр хәрәкәткә килә, вөҗдан һәм бурыч яссылыгыннан күзәтелә торган характерлар, вакыйгалар алгы планга чыга.

Гарифҗанга исерек килеш руль артына утырырга колхоз рәисе Хөснуллин әмер биргән икән, ул гына түгел, машина председательнең үзенә бүрәнәгә җибәрелгән булган. Фаҗига шул рәвешле үз тирәсендәге әлегәчә күләгәдә калып килгән типларны алгы планга чыгара. Хәер, Хөснуллин бу очракта да судан коры чыгачагына ышана. Ул инде больницадан Гарифҗанның айнык булганлыгы турында белешмә яздыртырга өлгергән, Рәмзи үлеменең шаһитларын да үз ягына аударуга ирешкән. Тикшерүче дә аның күзенә генә карап, һәр боерыгын үтәргә әзер тора. Шулай Рәмзи эше дә туктатылыр, бераздан тәмам онытылыр иде.

Әмма астыртынлык, ялган юлына гаделлекнең, хакыйкатьнең үзе булып Нуриасма калка. Рәсми власть гамәл-ниятенә каршы Нуриасманың бары тик дөреслекне генә кыйбла итеп алган яшәү принцибы күтәрелә. Романда «Чын вә Ялганның» көрәше шул конфликттан этәрелеп китә.

Рәмзи — Нуриасманың мәрхүм ире Сәгыйдулла белән бертуганнар, бу, әлбәттә, дөреслекне дәгъваларга тулы хокук бирә. Икенчедән, Нуриасма шофер Идрисовның рәис боерыгы буенча исерек килеш рульгә утыруын үз күзләре белән күргән кеше. Ләкин төп сәбәп эчтәрәк. Рәмзинең үлеме Хөснуллинга чираттагы бер мәшәкать булса (анда да үзенә кагылганы өчен), гаилә өчен бу сыгылып төшәрлек коточкыч зур кайгы-хәсрәт, җандагы канлы җәрәхәт. Бу югалту гөнаһсыз балаларның канлы күз яшьләренә әверелә — Нуриасма менә моны беркайчан да онытмаячак. Язучы бу күренешне тетрәнерлек итеп сурәтли: «Быел сигезенче класста укыйсы кызлары Гүзәлнең кеше кыяфәте калмаган. Ул коты очып әтисенең үле гәүдәсенә карап ала да, сыннары катып, елый башлый». Мәрхүмне зиратка озатырга кузгалган мизгелдә, алты яше тулмаган Рөстәмнең: «Әтием, әтием, әтием! — дип ачыргаланып кычкыруы ишетелде. Аның тавышы үзәк өзгеч нечкә һәм ялварулы иде. Ул җеназа артыннан йөгереп куып җитүгә тузанлы юлга капланды һәм сынсыз булып катты. Хатын-кызлардан кемдер аны күтәреп, өйгә таба алып китте, сабый елый-елый һаман «әтием, әтием, әтием!» дип кычкырды, җиргә төшәргә теләп, аяк-куллары белән чәбәләнде...»

Зиратта Нуриасма Хөснуллинны бөтен барлыгына күрә. Рәис, «кендек тишеген хәтерләтүче кечкенә күзләрен бөрештереп», тотлыга-ялгыша мәрхүм хакында кәгазьдән мактау сүзләре укый. Нуриасма тынсыз-өнсез кала: «Үзең үлеменә сәбәпче булган кешенең изге рухын, җеназа мәрасимен аның якыннары алдында, халык каршында үзеңне аклау өчен файдалану кебек гөнаһны эшләү өчен ни дәрәҗәдә намуссыз булырга кирәк?!» Ачу — рәнҗеш, нәфрәт тудырган сораулар Нуриасманың бөтен җанын бөтереп алалар: «Гаделлек, кешелеклек кануннары хөкем иткәндә, халык хәзер Хөснуллинны аяк астына салып таптарга тиеш иде кебек. Ни өчен соң халык түзә, хәтта моны сизми дә?! Иң котычкычы шушы түгелмени?!»

Нуриасма тишәрдәй булып Хөснуллинның йөзенә текәлә: бу — Ялганның үзе! Танып калырга кирәк аны, хәтергә сеңдерергә кирәк! Икейөзлелеген мәкерле кайгыртучанлык битлеге астына яшергән бу бәндә белән Нуриасма бүгеннән аяусыз көрәш башлаячак.

Ә Хөснуллин инде Ялганның җиңү тантанасы биюен башкарырга әзерләнә. Нуриасманың төпчек улы Мизхәт тә эчке, газаплы көрәштән соң (чөнки җан дусты Гарифҗанның язмышы хәл ителә бит) ялган аңлатма бирергә күнә. Председатель Рәмзинең тол калган хатыны Мәдинәне дә «беркемне гаепләмим» дигән гариза язарга мәҗбүр итә. Бу очракта ул артистларча оста уйный, төче телләнә, кайгы-хәсрәтеннән болай да зиһене томаланган бичара хатынны психологик атака белән бөтенләй исәңгерәтеп ташлый.

«Гарифҗаннарга китергән бәхетсезлекләр өчен Рәмзи сиңа рәнҗемәсме икән?» — дип, агулы энәсен чәнчи Ялган.

«Син үзеңне анын хатыны, балалары, авыру әнисе урынына куеп кара»,— дип җәрәхәтле җанга астыртын суга Ялган.

Монысы хәтәр. Моны тотуы да, инкарь итүе дә кыен. Әхлакый яктан тыелган алым сынсыз итә, каушата, фикерне чуалта, үз гамәлләреннең хаклыгына шик уята. Мәдинә дә бала анасы. Үзенә кайгы килгән ана башкаларның хәсрәтенә битараф кала аламыни? Мәдинә дә чигенә, нинди дер чит көчнең, сизелми торган бер агым кебек, һаман үзе теләмәгән якка этәрүен сизә, җиңелә баруын тоя. Бары шуны гына эшли ала Мәдинә, тикшерүчегә барганда, Рәмзи рухыннан елый-елый гафу сорый...

Ә Хөснуллин өчен бу — сөенеч! Ул тантана итә! Иң борчуга салган, шөбһәләндергән кешеләр дә анын сүзен җөпләргә булдылар бит. Менә Нуриасманы гына күндерәсе иде... Хөснуллин аңа турыдан-туры үзе мөрәҗәгать итүдән тайчына, чөнки ул аннан шактый шикләнә һәм ул гына түгел, өркә дә. Гаделлекне кыйбла итеп алган кеше ниләр әйтмәс тә, ниләр ишеттермәс! Рәис бу уен Мизхәт белән Гарифҗанның әнисе Хәдичә аркылы тормышка ашырырга ниятли.

Ананың улы белән сөйләшүе кыска була. «Без әтиең белән гомер буе саклаган изге әйбергә тап төшердең син!» — ди ул.— Мин исән чакта безнең өйдә ялган була алмый. ...Менә шул: йә мин... йә син...»

Бу — Нуриасманың яшәү принцибы. Гаделлеккә куркыныч яный башлаганда ул кырыс сугышчыга әверелә. Тормышта ачы, авыр вакытлары күп була, иң якын кешеләренең күңеленә авырттырып кагылырга да туры килә аңа, ләкин беркайчан да намуска каршы бармый. Булдыра алмый. Шуңа да, шуның өчен дә ана улын шактый кырыс шартларда тәрбияли, кечкенәдән эш-мәшәкать Мизхәтнең җилкәсеннән төшми. Гамьсез уйнап йөргән яшьтәшләре арасында кимсенгән, гарьләнгән чаклары да еш була аның. Ләкин Нуриасма гамәлләренең асылында бик тирән мәгънә салынган булганлыгын без соңрак аңларбыз. Кырыс мөнәсәбәт артында ананың баласын өзелеп яратуы, улы белән бәгълы иң изге өмет-хыялы яшерелгән булган икән...

Нуриасма белән Хәдичә мөнәсәбәте исә — башка... Романда киеренке психологик кичерешләр төененең иң чуалчыгы да шушы ике характер арасында төйнәлгән. Язмышлар кануны, тәкъдир шаяруы, газаплы кичерешләр, рәхәт истәлекләр, тагын әллә ниләр, әллә кемнәр белән гомер юллары бергә аралашып, буталып, берегеп беткән ике кыз, ике ана, ике тол хатын. Аларның дөньяга карашлары, яшәү принциплары гаять каршылыклы һәм шул ук вакытта ифрат аваздаш та. Менә шушы парадокс заман фәлсәфәсен тәшкил итә дә инде.

Нуриасма белән Хәдичә үз чорының балалары, без хәзер туздырып, угычүгы китереп ташлаган заман вәкилләре.

Нуриасма — эштә-тормышта һәрвакыт беренче булырга тырышып, эш өчен тәүлегенә егерме дүрт сәгать кенә булуына сызланып дөнья йөген тартып баручы кеше. (Күрегез: яшь Нуриасма гаҗәп дәрәҗәдә Нәфисәне хәтерләтә бит. Бу инде кырык еллар элек иҗат ителгән героиняның янә бер кат тормышчан булуын исбатлый.) Авырып аяктан егылган вакытта да кулыннан сәнәген, көрәген, чалгысын ташламас зат. Бушка. Хисапсыз налог-заемнарга да зарланмый, коммунизм була дигәнгә куанып яшәүче, киләчәктәге яхшы тормыш хакына шулай газаплар чигәбез дип, гаделлек бар, дөреслек тантана итәр дип инанып гомер сөрүче замана баласы.

Хәдичә исә дөньяда хакыйкать юклыгына үз тәҗрибәсеннән чыгып инанган адәм. Меңнән артык хезмәт көненә тулар-тулмас бер капчык ашлык тигәннән соң кан яшьләре белән дөньясын каргаган, кол хәлендә булуына бәргәләнгән, аһлар койган күпләгән авыл хатыннарының берсе. Алны-ялны белми заманага риза булып эшләгән дә эшләгән Нуриасма аның нәфрәтен уята: «Кем өчен ертыласың?— дип кычкыра ул аңа.— Бушка бит, бушка! Сизмисеңмени: иелгән саен, бил бөккән саен ныграк мыскыл итәләр, ныграк җәберлиләр!»

Түрәләр исә Нуриасманы үрнәк итеп күрсәтеп, Хәдичә кебекләрне тагын да усалрак кыерсыталар. Нуриасма әнә шулай, телиме-теләмиме, система кулындагы лозунгка да әверелә.

Менә, ике төрле фәлсәфә, ике төрле яшәү принцибы... Кайсы хак та, кайсы нахак? Аерып кара, ярлык сугып кара! Әйтеп кара, кайда ак та, кайда кара! Нәрсә, тоталитар режим хакыйкатьне дә шулай өзгәләп, ике тарафка ыргыта алдымы икәнни? Ике язмыш, ике корбанмы? Әллә, кайдадыр алтын уртасы булып, шулмы заман фәлсәфәсе?

Бу сораулар мине әсәр буенча эзәрлекләделәр һәм киләчәктә дә, белеп торам, тыныч калдырмаячаклар әле.

Нуриасма белән Хәдичәнең дә фәлсәфәсе шулкадәр үзара чуалып, чәбәләнеп беткән, шунадырмы, гомер юлында аларга еш сынашырга туры килә. Әйтерсең тәкъдирнең әмере шундый: аерылып та китә алмыйлар, якынаеп та бетмиләр. Гомер ахырында язмыш аларны соңгы сынауга алып килә.

Биредә бар да бутала: Хөснуллин... Гарифҗан... Мәдинә... Хәдичә... Мизхәт... Нуриасма сизә, күреп тора: Рәмзи рухы өстендә Ялган калыкты. Менә шунда ул үз җанында нидер кузгалганын тоя. Чөнки Нуриасма инде гомернең шундый борылышына житкән: бу — үткәннәргә борылып карап, фикер йөртү, бар тормышына бәя бирү, адәм баласының хәтер көзгесендәге сурәтенең нинди булачагы турында уйлану чоры.

Яшәлгән кадәресен күңелдән кичерә дә Нуриасма, исе-акылы китеп хәвефле уйлар чолганышында кала: баксаң, ялган дигәннәре гел аның янәшәсендә генә йөргән бит! Хөснуллиннар әле алар ялганның бәләкәе генә. «Әле югарыдан ук килгән олы ялган — бөтен халыкны һәр минут, дистә еллар буе агулап килгән олы ялган бар бит! Авылны күтәрәбез, чәчәк аттырабыз, диделәр. Күтәрелмәде дә, чәчәк тә атмады авыл».

Нуриасма, шул рәвешле килә-килә, ялганның иң югары формаларын таный башлый. «...егерме елдан коммунизм була дигәч, и куанган иде Нуриасма!... Ә хәзер ни үзгәрде? Әйберләрнең хакын күтәрмибез, дип сөйләделәр, сөйләделәр дә күз күрмәгән, колак ишетмәгән бәяләр ясадылар да куйдылар». «Иң югары мөнбәрләрдән торып: «Азатлык алыгыз, һәр милләтне чәчәк аттырыйк»,— дип, һәр тумыш көн авызларыннан төкерек чәчәләр, ә үзләре кораллы гаскәр, танклар белән шул сөйләгәннәренә каршы куйдылар».

Нуриасма шул мизгелдә сискәнеп ала: «Ә кем алдашмый соң?» Дөньясын ялган каплагач, аның гына «ак карга» булуыннан ни мәгънә? Әнә, Хәдичәләр җәһәтрәк, олы ялганга каршы алар үзләренең бәләкәй алдау-хәйләләрен куя беләләр. Бу аларның үзләренчә гаделсезлеккә каршы протестлары. Йә, кан тамырлары шартлардай булып дөнья тәртәсенә ябышкан Нуриасма нәрсәгә ирешә? Ялган кимемәде, киресенчә көчәйде генә. Ялганлаучылар исә тагын да мәкерлерәк була бара.

«Бәлкем бу дөньяда ялганламыйча яшәп булмыйдыр?» — ди тәмам хәйран калган Нуриасма. Ләкин бу минутлык кына каушау була. Нуриасма бу дөньяда ни өчен яшәвен шул мизгелдә аңлый. Дөнья күрелмәс дивар белән икегә бүленгән. Әнә ул куркыныч рәвештә аның өстенә авыша. Нуриасмага бер генә адым ясарга кирәк һәм ул диварның теге ягында булачак вә сау-сәламәт калачак. Бары бер адым! Аннан дивар авар да җиһанда бары тик Ялганның шашынып хахылдавы гына яңгырап торыр. Нуриасма үзен шул адымны атлаудан саклап кала. Ул белә: әгәр ул да чигенсә, кешелек коточкыч һәлакәткә дучар булачак.

Әйтәләр бит, Аллаһы Тәгалә тереклекне кара көчләрдән саклау өчен җиргә ак көчләр җибәрә икән, дип. Нуриасма шулар затыннан... Бу аның язмышы да, тәкъдире дә, бәхете дә, яшәү мәгънәсе дә. Андыйлар сирәк була. Безнең гомеребездә аларның да өлеше бар. Туксанынчы еллар башыннан Нуриасмалар яшьлеге калган чорга нәгърә оручылар, белегез, яшәвегез белән сез заманның кыенлыкларына, дөньяның ялган белән шыплап тулуына карамастан, тормыш җебен өзми киләчәккә ялгый алган әнә шул фидакарьләргә бурычлысыз. Зарланудан, карганудан арынып үткәннәргә ихластан карасаң, анда таяныр, табыныр кешеләрне күрергә мөмкин.

Нуриасма — шундыйлардан...

«Аны кемнәр генә нинди генә хурлыклы сүзләр белән тамгаласалар да, кемнәр генә нинди генә ачулы күз карашлары белән чәнчесәләр дә, Нуриасма үзенең алар өчен буй җитмәс биеклектә торуын аңлады. Бу — аның күптәннән төзегән сафлык дөньясы, аңа ул үзе генә патша, күпме генә, ничек кенә һөҗүм итмәсеннәр, бу патшалыкка беркемнең дә теле дә, кулы да зарар сала алмаячак иде».

Әнә ул сыкранмый, зарланмый, заман җил-давылларына бирешми гомер кыры буйлап узып бара. Аның җирдәге миссиясе: ак нур булып башкаларны үз янына чакыру һәм үзеннән соң да сынмый, сыгылмый торган нәсел дәвамчысын калдыру.

Ул егылса... Бу хакта да уйлар вакыт җитә Нуриасмага. Мизхәт... Менә кемгә тапшырырга тиеш ул тормыш эстафетасын! Үзе кебек үк пакь җанлыга, хакыйкатьне кыйбла итеп алучыга — йөрәк парәсенә! Менә ни өчен Нуриасма улын кечкенәдән кырыс шартларда үстерә: иркә булмасын, чыныксын, нык булсын. Аның киләчәктәге миссиясе дә башкалардан үзгәрәк, олырак, мәртәбәлерәк булачак. Шуның өчен дә Нуриасма шәхси мәнфәгатьләрне һәрвакыт икенче

планга калдыра һәм моны бозарга җөрьәт иткән улына бәгырьгә үтәрлек итеп әйткән очраклары була. Чөнки Мизхәт аның дәвамчысы, нәсел, нигез, ниһаять, гореф-гадәт, тел дәвамчысы бит.

Соңгысы — Нуриасманы бик борчый торган мәсьәлә. Балаларын гына кара... Фәритнең күмер чапкан якларда туган ике кызы бөтенләй татарча белмиләр. Шәрифҗаны марҗага өйләнгән. Илсөяре үзбәктә кияүдә... Нуриасманың бар ышаныч-өмете Мизхәттә. Карар катгый: нәселнең тамырын корытырга ирек бирмәячәк ул! Ата-баба нигезеннән аерылган бәндә, чит туфракка утыртылган гөлдәй, тернәкләнеп китә алмый, милләт буларак сула, корый, югала... Бала туган туфрактан аерылмаска тиеш! Әнә, Фәритнең «дүрт яшенә кадәр ун-унбиш сүз әйтә алмаган, башы чирдән чыкмаган» Мараты, авылда калдырганнан соң, бер ел эчендә сихәтләнеп, ныгып китә, рәхәтләнеп сөйләшә башлый. Шатлыкларыннан хушсыз кала язган әти-әнигә Нуриасма моның сәбәбен бик гади аңлата: «Бала туфракта аунап, шуны ашап үссен ул. Туфракта хикмәт. Үзебез дә шул туфрактан яратылган ләбаса».

Бәндә хатадан хали түгел дигәндәй, үз алдына олы максатлар куеп яшәгән Нуриасма шәхси мәнфәгатьләргә мөнәсәбәттә ялгышып та куйгалый.

...Мизхәт белән Зөбәрҗәт арасында дуслык көчәйгән бер вакытта авылда сүз тарала: имеш, кыз егетне үзенең шәһәренә алып китәргә ниятле икән. Гайбәтнең сыланчык дымы Нуриасманың зиһенен чуалтып ташлый. Ул белмимени, шәһәр адәм баласының йөрәген, хәтерен үтерә, шәһәр телне, милли гореф-гадәтләрне йота, сындыра, чүпкә чыгара. Боларның һәммәсен авыл гына саклый, авыл гына хәтерләргә сәләтле. Шәһәр Нуриасманың өч баласын тартып алды, шулай булгач, «дүрт баласының берсен булса да шәһәргә бирмәскә хакы бардыр бит аның?!» «Зинһар алып китмә аны! Калдыра күр...» — дип үтенә ул кыздан. «Мине ятим итмә»,— дип ялвара. Тик соңыннан, инде Зөбәрҗәт авылдан китеп югалгач, Мизхәтнең җан ачысы белән «үтерсәң дә, оныта алмыйм» дип өзгәләнүен ишеткән Нуриасма сискәнеп, тетрәнеп китә. «Йә аллам, мин бит бала гомеренә кергәнмен!» — бу хәтәр уй аны үз ялгышын төзәтергә ашыктыра.

Ашыгырга кирәк Нуриасмага, дөнья эшләрен дөньялыкта бетерү фарыз. Гомер дигәннәре йомгакланып килә. Үкенечтә калмасын... Нуриасма да мәгълүм чиккә житеп килүен тоя. Чикнең теге ягы — мәңгелек. Әлегә ул бу якта, әлегә аның уй-хыяллары, зиһене, аңы тиздән ул калдырып китәчәк тормышка, кешеләргә береккән. Китү — котылгысыз, моны аңлау үткән гомерне янә бер кат хәтердә яңартуны таләп итә.

Нуриасма «... бер сәер хәлне сизеп гаҗәпләнде: ул әле генә яшәп яткан тормышны һәм үзен ничектер читтән, бик ерактан күзәтә, үзенең һәм башкаларның гамәлләренә әллә кайдан ук торып бәя куя иде».

Үз гомерендә беренче мәртәбә булса кирәк, Нуриасма урын өстендә ята. Ләкин моның өчен үзендә уңайсызлану да, хәлсезлегеннән гарьләнү дә сизми. Чөнки белә, бу — адәм баласына килә торган иң дәһшәтле һәм иң соңгы авыру, бу — әҗәлгә тигән чир.

Әнә шулай бер гомер бакыйлыкка күчеп бара... Әлеге халәттә үтә моңлы, сагышлы талгын музыка агылганын ишеткәндәй буласың. Ул көй сагайта, сискәндерә, күңел кылларына кагылгалап зыңлый, нәрсәдәндер хәбәр бирә, кемнәргәдер инәлә, кемнедер кисәтә, әллә ниләр боера, каядыр чакыра... Әйтерсең, Тормыш сәхнәсендә фанилык һәм бакыйлык фәлсәфәсенә корылган спектакль уйнала. Укучы — тамаша залында. Менә скрипка кылларыннан сызылып чыккан аһәң җанга тула, тирә-юнь моңга, сагышка күмелә.

Бу — бәхилләшү көе. Нуриасма урынга егылган мизгелдән башлана ул көй, һәм аның йомшак кына, әмма сизелерлек итеп йөрәкне кыса баруын тоясың, бугазыңа төер утыра һәм ошбу халәт инде сине әсәр ахырына кадәр ычкындырмый.

Нуриасманың авылдашлары белән хушлашу күренешендә әлеге музыка инде бөтен барлыгыңны биләп ала.

Әнә алар — чордашлар, ахирәтләр соңгы мәртәбә бергә җыелып, үткән гомерләрен искә төшереп күңел бушаталар. Болар үзгә буын кешеләре. Алар гомер буе эшли-эшли гарипләнеп беткән, үзләре өчен берни дауламаган, тормыш авырлыгыннан зарланмаган татар хатыннары.

...Әнә Маһинур — унбиш яшеннән пенсиягә чыкканчы колхоз сыерларын сауган, өе — салам түбәле фәкыйрь алачык, ае-ае белән ит шулпасыннан авыз итми яшәү аның өчен табигый хәл. Инде аяклары шеш, кул бармаклары бөгелми. Һәм шушыларның бар рәхмәте — унике сум пенсия...

...Колхозда печән чапса да, сабан сөрсә дә, урман киссә дә ирләрдән уздырган, эшкә ябышса, егылырын, үләрен белми тырмашуы өчен «буран» ләкабе алган Разия. Заманында авылның иң сылу кызы хәзер әнә көянтә кебек җиргә бөгелгән, шулай йөри, сулышын зур авырлык, газап белән генә ала. Күп эшләүдән көч килгән, җене тарта, диләр — шулар нәтиҗәсе.

...Гомер буе кешеләргә яхшылык эшләүдән тәм тапкан, үз хәле, үз язмышы белән килешеп, кояшлы һәр таңны куанып каршы алып, дөньяга (аның нинди-легенә карамастан) булган мәхәббәтенә хыянәт итми яшәгән Гыйздениса. Ире белән бердәнбер улы сугыш кырында ятып калганнар, кыйшаеп беткән өендә ничәмә-ничә елларны ялгыз үткәрә. Зарлану юк, уфтану юк, рәнҗү-үпкә юк. Акны ак, ди, караны — кара... Үлемне дә ул гади бер нәрсә, бер халәттән икенчесенә күчү дип кенә атый. Үлем аның сөйләвендә моңлы мөнәҗәт булып күзаллана: «И, гомерләр диген Нуриасмакаем! Уйлап карасаң, кемнәр бар иде дә кемнәр юк! Картым белән Рәхмәтулламның сөякләре икесе ике кыйтгада яталар. Рәхмәтуллам бит япон сугышында иде. Исемнәрен дә, каберләрен дә белүче юк. Без бит бәхетле, Нуриасмакаем, безне үзебезнең авылга җирлиләр, ата-бабаларыбыз белән янәшә...»

Нуриасма аларны әрнү катыш сокланып күзәтә. Тавыш-тынсыз, дәгъвасыз авыл хатыннары. «Аларның авырып үз гомерләренә бер мәртәбә дә хастаханәгә барырга вакытлары юк. Аларның даруы — җир дә һава, кояш та үлән». Әгәр дә колхоз елга бер мәртәбә ике центнер бодай сатып (!) бирсә, болар өчен шатлык була, башлары күккә тия, колхозны да, хөкүмәтне дә мактап бетерә алмыйлар. Азга да канәгать булып, һәр тыныч көнгә шөкерана кылып гомер сөрәләр. Нуриасма, болардан аермалы буларак — лидер, дәгъвачы. Үзе өчен түгел, нәкъ менә шушы авылдаш-ахирәтләренең хакын хаклап инстанцияләр буйлап йөри, төрле түрәләрнең кабинетларына үтеп керә. Күпмедер уңышка да ирешә. Әмма барысына да, барыбер, ярдәм итеп бетерә алмый. Өлгерми... Өлгерә алмады...

Хәзер әнә ул аларның соңгы сурәтләрен хәтеренә алу өчен сокланып та, яратып та, сагышланып та карап ята. Нуриасмалар буыны киткәч, авылда мондый буын кешеләре калмый инде. Алар — соңгылары...

Укучы, танып кал аларны, хәтереңә сеңдерергә тырыш. Күңел күзең белән карап уйлан да, үз авылыңдагы шундый аналарны исеңә төшер. Алар инде азаеп баралар. Өлгерә күр.

Алмашка каты буын, ашыгучан, кабаланучан төксе буын килә. Тормыш мәгънәсе хакында ашыкмый уйланырга вакыт кызганучы, бер көн белән яшәүче кешеләр кавеменә Разияләр, Гыйзденисалар, Мосалияләр, Мәһинурлар яраша алмыйлар инде. Кешелек әнә шулай үзенең кабатланмас, беркайчан да кире кайтмас буыны белән хушлаша.

... Скрипка баягы үзәк өзгеч көйне инде иң нечкә сыңар кылында гына уйный. Әллә уйный, әллә шулай елый...

Дөньялыкта башкарыласы бер эше калып килә Нуриасманың: Мизхәтне башлы-күзле итеп калдыру һәм шушы берничә көн эчендә. Бу олы һәм четерекле йолада ашыктыру ярап бетмәгәнен сизсә дә, тәвәккәлләргә карар кыла. Ана... күреп китәргә кирәк. Нәселнең, нигезнең, кабилә тамырының дәвамы булачагына инанып китәргә кирәк. Бу карар катгый һәм моның хакына Нуриасма исән чагында бер кем алдында да чигенмәячәк.

Шул рәвешле романда ике тараф — үлем һәм тормыш туе очраша. Бер гомер инде тәгәлләнеп килә, икенчесе исә олы юлга тәүге адымын атларга әзерләнә. Дәһшәтле дә, тантаналы да манзара! Ләкин романда ул аклана, нәкъ менә Нуриасмага бәйле булган өчен, аның ихтыяры белән эшләнгәнгә күрә бу хәл табигый итеп кабул ителә.

Гади генә кеше түгел шул ул Нуриасма. Аның яшәү рәвеше дә, эш-гамәлләре дә күптән инде олы хөрмәткә ия булганнар. Бу юлы да ананың ниятенә ризасызлык белдерүче табылмый: Нуриасма әйткәч, шулай кирәктер, шулай булырга тиештер.

Нуриасма исә үлемен чигендерә-чигендерә Мизхәт белән Зөбәрҗәткә соңгы әманәтен тапшыру минутын көтә. Үлем куркытмый Нуриасманы. Дөрес яшәде, үкенерлек эшләр кылмады. Соңгы юлга җыенганда балалары, иң якыннары янында. Зиһене чиста, фикерләре чуалмаган. Әйтәсе сүзләрен әйтеп, ил йоласын тапшырып калдырырлык кешеләре бар. Шуңа да Нуриасма үз хәлен тыныч, сабыр кабул итә: «Барыбыз да җир куенына керәбез, — ди ул сеңлесе Кифаятә. — Үзем әйтергә өлгермәсәм, син аң бул: берүк табутка сала күрмәгез — рөхсәтем

юк. Ләхет алып күмсеннәр. Гомер бүе җирне яраттым, җиргә терәлеп ятасым килә. Чип-чиста ап-ак кәфен белән күмегез мине. Чиста җиргә чиста килеш...»

Шушында, бәгырьне телгәләп, Акъәби искә төшә, үтә заманча балаларының туң йөрәкләренә бәрелеп чәлпәрәмә килгән соңгы гозере, ачыргаланып әйткән сүзләре, иясез калган васыяте хәтергә килә.

Нуриасма бу җәһәттән күпкә бәхетле. Матур яшәде, матур китә дә. Менә, бу җөмләне яздым да, сәерсенеп куйдым: матур үлем буламыни? Тарих мондый фактларны хәтерли. Безнең эрага кадәр I гасырда яшәгән Мисыр патшасы Клеопатра матур үләргә теләгән. Риваятьләр сөйли: гүзәл хөкемдар ханым үзенең иң затлы киемнәрен кигән һәм чагуга үтерә торган елан салынган кәрзингә кулын тыккан...

Ләкин бу күбрәк тышкы матурлык, форма затлылыгы. Ә Нуриасма бәхилләшүе эчке матурлык булып, яшәү рәвешеннән килә торган олуглык, мәртәбәлек, бөеклек белән сугарылган.

Гомумән, романның икенче өлешендә Нуриасма, конкрет персонаж булудан битәр, гореф-гадәтләрне, буыннардан-буыннарга тапшырыла килә торган яшәү кануннарын, халыкның акылын, тәҗрибәсен үзенә туплаган символ-образ итеп күзаллана. Ул образда татар халкының гамәл-хыяллары да, язучының милләт язмышы турындагы уйланулары дә гәүдәләнеш алган.

Нуриасманың Мизхәт белән Зөбәрҗәткә тапшырган соңгы әманәте — Коръән — гасырлардан килә торган иң мөкатдәс әманәт. Биредә дә олы, тирән мәгънә салынган: кем икәнлегезне, кайдан килүегезне, ил-көн алдында бурычыгызны онытмагыз, хак яшәп ошбу изге китапны пакь кулларга тапшыра күрегез...

Романда вакыйгалар әнә шул рәвешле фәлсәфи гомумиләштерүләр, «тормыш — кеше — гамәл» яссылыгыннан торып, эчке мәгънәви уйланулар белән бергә үрелеп бара. Бу хәл, әлбәттә, беренче чиратта Нуриасма образы аркылы тормышка ашырыла. Төп игътибар үзәк персонажга юнәлтелү сәбәпле, кайбер образлар ачылып бетмәгәндәй тәэсир кала. Шул җәһәттән аерым сораулар да туа. Мәсәлән, Мизхәт белән Гарифҗан мөнәсәбәте ничек булыр? Монда да бит вөҗдан һәм бурычның котылгысыз бәрелеше сизелеп тора. Дөрес, автор фараз кылу рәвешендә үз фикерен сиздереп уза. Ә шулай да, күзгә-күз очрашсалар,ниләр әйтерләр иде икән бу «тәпи йөри башлаган чактан ук тәгәрәшеп, бер кашыктан ашап үскән» ике дус? Бу да бит кырыс чынбарлык тудырган четерекле проблемаларның берсе. Аннан соң, Нуриасма бәхиллегеннән мәхрүм калган Бәриянең бәргәләнүләренә ышанмыйм мин. Бәрия кебек типлар өчен хак яшәү турында уйланулар, эчке газапланулар гайре табигый хәл. Мондый рухи, әхлакый бөкреләрне бары тик кабер генә төзәтә.

Романда гомер турында әйтелгән сүзләр бик тә гыйбрәтле: «Бәндәләрнең яшәүләре таң җиле генә шул. Бик кыска гына арада, табигатьнең уяныр-уянмас серле, моңлы чагында сизелмичә исә дә үтә». Бу хакта һәрберебез уйланырга тиеш. Һәрберебезнең, иртәме-соңмы, яшәлгән елларына, кылган эшләре хисап бирер вакыты җитә. Әлеге юллар шуны тагын бер кат искәртә. Һәм үз гомеренә, һәм кешенекенә игътибарлы булуны таләп итү дә, янәшәңдә кемнәр яши, тирә-юнеңнән кемнәрнең гомерләре узып бара — шуларга күңел күзе белән карау тиешлеген ассызыклау да бар ул сүзләрдә.

Искән җилләрне тыңлый белсәң, әллә ниләр, әллә кемнәр турында сөйләрләр иде алар...

Романның ахырында вакыйгаларга фон булып килгән моңлы, сагышлы көй инде күбәләк канатыдай сизелер-сизелмәс кенә тибрәнә... Бу шулай Нуриасма гомеркәйләренең соңгы аккорды уйнала. Гомумән, роман — музыкаль поэма сыман, яки ниндидер көйле зур әсәр соралып торган җыр кебек күзаллана.

Романның башлангыч һәм соңгы өлешләре үзара охшаш, авазлаш булып, әсәргә бөтенләй, фәлсәфи мәгънә бирәләр.

Вакыйгаларга кереш сыман өлештә Нуриасма изге теләкләр теләп таң каршылый. Ахыр минутларында да табигатьнең шушы мизгелен көтә. Хәере белән килерме яңа көн? Нуриасма инде бу уйлардан азат, бу сорауны инде ул калганнарга тапшырган. Беренче ал нурлар өйгә кергәндә Нуриасма дөньядан үтә. «Таңның тәүге саф тирбәлеше... аның тән һәм җан җылысын сеңдереп, Нуриасма гомере буе омтылган, җанына рәхәтлек, йөрәгенә көч алган Ык буйларына, болыннарга, әрәмәләргә, иген басуларына шул җылыны таратырга очты, аның инде бүтән беркайчан да алар янына килмәячәген хәбәр итәргә ашыкты...»

«И мөкаддәс моңлы сазым...»

**Дөррия Рамазанова,**

филология фәннәре кандидаты.

# УРАЛ БУЕ ТАТАРЛАРЫ: ТАРИХЫ ҺӘМ ТЕЛЕ

**Хәзерге Башкортстанда яшәгән татарларның теле турында соңгы елларда төрле фикерләр языла башлады. Бигрәк тә аларны, башкорт телендә сөйләшүләр, дип күрсәтергә маташу житди борчылу тудыра. Әлбәттә, моның төрле сәбәпләре бар. Ләкин татар телле халыкны башкорт дип күрсәтеп, башкорт халкының санын ясалма үстерергә йөз тоткан сәясәт белән ерак китеп булмастыр. Халыкларга нигездә дусларча яшәү хас дип саныйм мин. Шул ук вакытта ана теле итеп бүтән телне укыттыра башлау — күңелсез эш.**

Бар башкорт теле, бар татар теле, казакъ, каракалпак, нугай һ. б. телләр. Болар барысы бер семьяга керә, кардәш телләр булып тора. Аларның бик күп уртак яклары бар. Уртак сүзләр дә бик күп. Шуңа охшаш кардәш телләр тагын бар, мәсәлән, урыс, украин, белорус телләре: аларның да уртак үзенчәлекләре, уртак сүзләре бик күп. Алар шулай ук, татар белән башкорт кебек үк, бер-берсен тәрҗемәсез аңлый алырга да мөмкин. Ләкин, гомер-гомергә татар дигәннәр, урыс дигәннәр, белорус дигәннәр, ягъни бу халыкларны, аларның телен аерып караганнар. Чөнки һәр халыкның, аның культурасының, теленең үзе өчен генә хас булган аерымлыклары була. Тормыш-көнкүреше, кием-салымы, йөз-сын төзелеше, сөйләшкән теле белән бу халыклар үзләренә генә хас сыйфатларга ия һәм шулардан чыгып алар аерылалар да. Һәр мөстәкыйль телнең үзенә генә хас билгеләре була. Мәсәлән, татар һәм башкорт телләрен чагыштырып карыйк. Башкорт телендәге силәк, сәскә, бакса сүзләре татар телендә чиләк, чәчкә, бакча дип әйтелә. Башкортча һарык, һыу, һәнәк татарча сарык, су, сәнәк. Башкортча йәй, йил, йиләк татарча җәй, жил, җиләк һәм башкалар. Ягъни башкорт теле үзенең авазлар системасы белән татар теленнән шактый аерыла. Әлеге ике телнең грамматикасында житди аерымлыклар бар. Мәсәлән, аттар — атлар, кыззар — кызлар, һугандар — суганнар, таштар — ташлар кебек тәңгәллекләрне китерү дә күп нәрсә турында сөйли. Гомумән, тарихта башкорт теле белән

татар теленең ике тел булуы беркемдә дә бәхәс тудырмаган, әлбәттә. Башкорт теленең төп үзенчәлекләрен, аны мөстәкыйль тел итеп аерып карарга мөмкинлек бирә торган якларын күренекле галимнәр инде күптән ачыклаган. Мәсәлән, Урал тирәсе төрки халыкларның, бигрәк тә башкортларның халык авыз иҗатын җыю, аны бастыру өчен күп өлеш керткән А. Г. Бессонов 1881 елгы хезмәтләрендә үк бу мәсьәләләргә кагыла. Пермь өлкәсендә, Башкортстанда, Оренбург якларында яшәгән татарларның, мишәрләрнең казан татарлары белән бер телдә сөйләшүен ассызыклап үтә. Төрки телләр буенча зур белгеч булуы белән мәшһүр Н. Ф. Катанов та Башкортстанда яши һәм мишәр, керәшен, башкорт, типтәр дигән исем астында йөри торган татарлар теленең чын башкорт теленнән аерылып торуын, башкорт теленең төп билгеләрен берәм-берәм карап чыга, шул турыда хезмәтләр язып калдыра. Танылган тюрколог, СССР ФА әгъза-мөхбире Н. К. Дмитриев башкорт телен беренче мәртәбә фәнни нигездә тасвирлап зур хезмәт яза. Ул анда башкорт теле авазлар системасының төп билгеләре итеп түбәндәгеләрне күрсәтә: татар телендәге **ч** урынына башкорт телендә **с;с** урынына **һ;** сүз башында **җ** урынына **й;** сүз уртасында **җ** урынына **ж** *(хужа, бажа)*; **з** урынына сакау **з.** Менә шушы үзенчәлекләр башкорт телен мөстәкыйль тел итеп формалаштыра инде. Тагын шуны да күрсәтеп үтәргә кирәк, теге яки бу телнең авазлар системасы үзенең тотрыклылыгын аеруча нык саклый торган өлкә булып тора. Ә лексика бүлеге, ягъни теге яки бу телнең сүзлек составы тизрәк үзгәрүчән була. Сүзләр бер телдән икенче телгә тизрәк үтеп керә. Менә бу җәһәттән **тәү, тәүбашлап, токчай** һәм башка шундый кайбер сүзләрне кулланган өчен генә үз теле турында «без әзрәк башкортча сөйләшәбез инде» дип әйтүчеләр белән һич тә килешеп булмый, алар бик нык ялгыша. Мәсәлән, ихата, зәңгәр, акыллы һ. б. сүзләрне кулланган өчен генә без татар яки башкорт телен гарәп, фарсы теле дип атамыйбыз бит. Яки комедия, бюро сүзләре булган өчен генә урыслар үз телләрен француз яки итальян дип атый алмыйлар һәм атамыйлар да. Алынма, ягъни башка телдән кергән сүзләр, һәр телдә дә бик күпләр. Мәсәлән, мондый бер генә мисал китерәсе килә: урысчадан (урыс теле сүзлеге дә ярый) башка телгә тәрҗемә ясый торган бер сүзлекне алып карагыз, андагы а хәрефенә башланган сүзләрнең бары бер-икесе генә урыс сүзе, ә зур күпчелегенең алынма булулары фәндә мәгълүм әйбер. Ләкин телне билгеләүдә сүзлек составының әһәмияте бөтенләй юк икән дигән фикер калмасын. Төп сүзлек байлыгы, шул исәптән, туганлык атамалары «әсә — әни сүзләрен генә алыгыз!» табигатьне, хайваннар һәм үсемлекләр дөньясын һәм башкаларны белдерә торган гаять күп сүзләр бик борынгы заманнардан яшәп киләләр һәм аларда халыкның күп гасырларга сузылган тарихы чагыла. Моны һич тә истән чыгарырга ярамый. Без бу урында бер генә нәрсәне кисәтәсебез килә: берничә башкорт сүзен кулланган өчен генә «без башкортчарак сөйләшәбез инде» дип уйларга ярамый.

Кыскасы, авазлар системасы, сүзләрне төрләндерү чаралары һәм төп сүзлек хәзинәсе — барысы бергә теге яки бу телнең асылын, аерымлыгын, мөстәкыйльлеген оештыралар һәм татар теле дип, башкорт теле дип сөйләгәндә югарыда әйтеп үтелгәннәр, һичшиксез, истә тотылырга тиеш.

Фәндә билгеле булганча, кешеләрнең этник берлеген билгеләгәндә тел факторы төп билгеләрнең берсе булып тора. Теге яки бу халыкның этник нисбәтлеген хәл иткәндә иң башта нинди телдә сөйләвенә игътибар итәләр. Урал тирәләрендә яшәгән татарларның теле һаман да игътибар үзәгендә кала килә. Аларны өйрәнү буенча зур эш совет чорында башкарыла. Пермь өлкәсендәге татарларның сөйләше кырыгынчы елларда Д. М. Сарманаева (ул үзе шунда туып үскән), алтмышынчы елларда безнең тарафтан, житмешенче елларда бер төркем татар этнографлары тарафыннан өйрәнелде. Нәтиҗә бер үк: алар татарча сөйләшә, татарча көн итә. Оренбург өлкәсе татарлары З. Р. Садыйкова, Чиләбе һәм Курган өлкәләрендә татарлар Ф. Ю. Йосыпов тарафыннан өйрәнелеп, күп санлы хезмәтләр дөнья күрде. Әмма аеруча күп тикшеренүләр Башкортстандагы татар сөйләшләренә багышланган: Л. Т. Мәхмүтова, Ә. Ш. Әфләтунов, Җ. Алмаз, Д. Б. Рамазанова, Т. Х. Хәйретдинова, Ф. С. Баязитова һ. б. галимнәрнең барысы да Көнбатыш Башкортстанда таралган сөйләшләрне татар теле диалектлары системасына керә, дип саныйлар. Алай гына да түгел, бу сөйләшләрнең татар әдәби теленә аеруча якын торуларын басым ясап күрсәтәләр.

Шушы ук фикерләр башкорт телчеләре тарафыннан да әйтелгән. Мәсәлән, Җ. Г. Киекбаев, Ә. Ә. Юлдашев, Н. Х. Ишбулатов, Т. М. Гарипов хезмәтләрен карарга мөмкин. Ләкин соңгы бер-ике дистә елда башкорт диалектологларының фикерләре үзгәреп китте. **Гомумән, кайсыдыр бер заманда, бары җир алыр өчен генә башкорт булып язылган татарларны «башкортлаштыру»ның ямьсез чаралары**

**эшкә ашырыла башлады. Мәсәлән, аларның балаларына күпчелек башкортларның үз балалары да укымаган башкорт телен көчләп ана теле итеп укыта башладылар.**

Башкортстандагы татар сөйләшләре безнең телчеләр тарафыннан кырык ел буе төрле ысуллар белән өйрәнелде. Иң әһәмиятлесе — аларны бер уртак программа нигезендә, ягъни диалектологик атлас өчен өйрәнү уздырылды. Билгеле бер еракльктагы авыллар буенча бер үк сорауларга җаваплар язып алынды. Магнитофон тасмасына язган текстлар аеруча мөһим. Бу текстларның бер өлеше күп санлы хезмәтләрдә дөнья күрде инде (Мәсәлән: *«Материалы по татарской диалектологии». 1962, 1974, 1978, 1983, 1987, 1988, 1989 һ. б.*). Аларның тел үзенчәлекләренең карталары — атлас төзелде: Казан арты сөйләшләрендәге үзенчәлекләрнең Көнбатыш Башкортстан, Пермь һәм Оренбург өлкәләрендә дәвам иткәнлеге анда ап-ачык ярылып ята. Һәм, киресенчә, әлеге җирләрдә башкорт теленең үзенчәлекле билгеләре табылмый. Ә бу картада Урал тирәсендәге 400 авылның сөйләше төшерелгән. Сөйләшләрне бердәм программа нигезендә өйрәнеп, паспортлаштырылган материалны картага төшерү телне өйрәнүнең иң объектив, иң ышанычлы ысулы санала. Безнең тикшеренүләр, атлас нәтиҗәләре түбәндәгеләрне күрсәтте: авазлар составы буенча да, грамматик төзелеше ягыннан да, төп сүзлек хәзинәсе белән дә Башкортстандагы татар сөйләшләре татар теле белән бертөсле. Бу фәнни нәтиҗәләрне бернинди боргалаулар да юкка чыгара алмый. Халык үзе дә туган телен татар дип күрсәтә бит. Менә шуңа күрә дә туган теле татар булган башкортларның ничек барлыкка килүен ачыкларга, аларның тарихын өйрәнергә кирәк.

Билгеле ки, Урал алды төбәгендә дә катлаулы тарихи вакыйгалар була. Алар бу төбәктә төрле төстә барган күчешләргә этәргеч бирә. Монгол яуларыннан соң Болгар дәүләте тар-мар ителә. Ә халкы исә төньякка һәм көнчыгышка качып урнашырга мәҗбүр була. Казан ханлыгының 1552 елда тар-мар ителүе гомумән зур күчешләр китереп чыгара. Бер яктан, Казан белән тыгыз элемтәдә яшәгән Идел буе халыкларының зур дулкыны Урал буена чигенә, күчеш XX гасырга хәтле дәвам итә. Икенче яктан, Урал алдындагы башкорт кабиләләре каушап, куркып калып, Урал арьягына кача. Бу хәлләр белгечләр тарафыннан тарафсыз рәвештә махсус өйрәнелергә тиеш.

* * *

Җирле сөйләшләрне өйрәнүче галимнәрнең барында да бер сорау туа: ни өчен бу авылларда яшәүчеләр бер үк телдә сөйләшсәләр дә, төрлечә аталып йөртеләләр соң? Кайсы башкорт дип, кайсы типтәр дип, кайсы казан кешесе дип, кайсы ясашныйлар, кайсы керәшеннәр дип атала, ләкин бер үк телдә сөйләшәләр. 50 — 60 елларда Көнбатыш Башкортстандагы татар сөйләшләрен өйрәнгән галимнәр Л. Т. Мәхмүтова, Ә. Ш. Әфләтунов, Җ. Алмаз һ. б. барысы да бу сорауны ачыклау йөзеннән тарих, архив материалларына, легендаларга мөрәҗәгать иткән, һәм халыкның төрлечә аталуы аларның җиргә мөнәсәбәтләре белән бәйле булуын ачыклаганнар. Безгә дә мондагы татарларның күчү тарихын шактый озак өйрәнергә туры килде. Без Башкортстанның 27 районындагы татарлар яши торган 160 лап авылда булдык, аларның сөйләм үрнәкләрен магнитофон язмаларына тупладык. Бу материалларның зур өлешен матбугатта бастырып чыгардык. Сөйләм үрнәкләре хәзер дә Институтның диалектология фондында саклана. Болар белән генә чикләнмәстән, Башкортстанның тарихы турындагы хезмәтләр белән таныштык, революциягә кадәр дә, совет чорында да бу якның тарихы, андагы катлаулы этнологик хәл күп төрле белгечләрнең игътибарын үзенә җәлеп иткән. Мәскәү, Оренбург, Пермь, Уфа шәһәрләре архивларында сакланып килә торган күп санлы документлар белән танышу исә тагын да кызыклы һәм бай материаллар белән эш итәргә мөмкинлек тудырды. Урал буен үзләштерүнең күпьяклы һәм гаять катлаулы тарихын берникадәр яктырткан хезмәтләр дә язарга мөмкинлек бирде.

**Тарих, этнография, археология белгечләренең нәтиҗәләре буенча, хәзерге Көнбатыш Башкортстан халкы үзенең килеп чыгышы белән үк Идел буе татарлары белән бәйләнгән. Бу якка чыгышы белән үк болгарлардан булган яки болгарларның көчле йогынтысында яшәгән кабиләләр килеп урнашканнар.** Бу турыда башкорт тарихчылары Р. Г. Кузеев, шулай ук С. И. Руденко, Н. С. Акимова, С. Н. Шитова, Р. З. Янгузин, Н. А. Мәҗитов һ. б. хезмәтләрендә бик бай мәгълүматлар тупланган. Алардан күренгәнчә, хәзерге Көнбатыш Башкортстан җирендә бик борынгы заманнардан бирле утрак тормышлы, җир эш-

кәртү белән көн күрүче халык яшәгән. Ул Болгар дәүләте белән бик тыгыз бәйләнештә торган, аерым чорларда хәтта Болгар дәүләте ватандары да булып киткән. Алтын Урда, аннан соң Казан ханлыгы заманында да шулай ук булган. Монгол яулары соңында хәзерге Көнбатыш Башкортстанга күчеп килгән болгар кабиләләреннән түбәндәгеләрне саныйлар: юрматы, еней, биләр, юрмый, гайнә-тархан, бүләр, танып. Бу кабиләләр хәзерге Танып, Агыйдел, Ык, Дим буйларында яшәгән. Хәзерге көндә менә шушы төбәкләрдәге халыкның сөйләше татар әдәби теленә бик якын булуының нигезендә күрсәтелгән вакыйгалар ята, күрәсең. Һәрхәлдә, хәзерге Көнбатыш Башкортстанда яшәүче татарларның саф татарча сөйләүләренә әлеге менә шушы Болгар дәүләте даирәсендәге кабиләләр нигез салган, хәлиткеч роль уйнаган.

Казан ханлыгы чорында бу уртак тамырлы бәйләнешләр дәвам итеп кенә калмый, бәлки тагын да үстерелә. Ык буе тирәләрен биләү өчен бирелгән ярлыклар шул турыда сөйли. Мәсәлән, Ык буе җирләрен (хәзерге Башкортстанның Ярмәкәй районы) 1523 елда Сәхип-Гәрәй хан биргән тархан ярлыгы нигезендә хәзерге Питрәч, Саба районнарына керә торган авыллардан чыккан кешеләр биләгән (**Ахметзянов М. И.** *К этнолингвистическим процессам в бассейне р. Ик.—«К формированию языка татар Поволжья и Приуралья». Казан, 1985. 63 б.).*

Хәзерге Татарстанның Актаныш районына керә торган Мөшегә авылы игенчеләре кузгаткан бәхәсне хәл иткән чакта, аларның да үз җирләрен Казан ханы Сәхип-Гәрәй тарафыннан 1523 елда бирелгән ярлык нигезендә биләгәнлекләре мәгълүм була (**Исхаков Д. М.** *Из этнической истории татар восточных районов Татарской АССР до начала XX века.—«К вопросу этнической истории татарского народа». Казан, 1985. 43 б.*). Тайламас авылы татары Котлымәт Котлыгашевларга тарханлык грамотасы Ибраһим хан (1467—1478 елларда идарә иткән) тарафыннан бирелгән булган. (Борынгы документларның үзәк дәүләт архивы—моннан соң БДҮДА дип биреләчәк *(1173 ф., 1 нче тасвирлама, 196 сакл. бер.).* Ирәкте волосте кешеләренең бабалары Шәех-Әхмәт һәм аның иптәшләренә дә тарханлык Сәхип-Гәрәй тарафыннан бирелгән булган (**Любавский М. К.** *Вотчинники-башкиры и их припущенники в XVII, XVIII вв.:—В. И. Ленин ис. дәүләт китапханәсенең кульъязмалар фонды, 364 ф., 2 тасвирлама, 6 карточка, I очерк, 13 б.*).

Русия идарә итә башлагач, баштагы чорларда Казан ханнары биргән ярлыклар үз көчендә калдырыла яки тарханнарга шул ярлыкларны раслый торган өстәмә грамоталар бирелә. Мәсәлән, 1595 елгы грамота нигезендә Саралы авылында яшәүче Туктамыш һәм аның иптәшләренә Кабан, Ургузе, Тәкермән, Мәләкәс, Кузабы, Итнә, Карамалы, Каужияк, Тегерманлек, Сурынчак һәм башка елгалар бассейннарындагы җирләрне биләргә грамота бирелә. XVIII гасыр ахырында исә, түбәндәге авыллар үзләрен Туктамыш нәселләре, дәвамчылары дип саныйлар: Саклаубаш, Өчиле Саклау, Иман, Сарсаз, Тәкермән, Чураш, Саралы Бикмәт, Сулюково*, Абдул, Сәет, Сәмәкәй, Күгәш, Каран, Келәнчетамак, Сарман, Рангазар *(БДҮДА, 1324 ф., 2 тасв., сакл. бер. 1249, 55—56 б.)*.

**Казан ханлыгы җимерелгәч, Урал алды җирләренә Идел буе халыкларының күпләп күчүе башлана. Әлбәттә, бу күчеш кисәк кенә купмаган. Элек-электән яшәп килгән бәйләнешләр булган җирләргә күчә халык. Традицион бәйләнешләр күчеш юнәлешен билгеләүдә хәлиткеч роль уйныйлар.**

## Идел—Урал буе Мәскәү дәүләтенә кушылганда

Урал ягына күчүнең төп сәбәпләре фәндә билгеле: Идел буенда җирләрнең үзләштерелгән булуы, халыкның тыгыз утыруы, урыс хөкүмәтенең көчләп чукындыру сәясәте алып баруы һәм, әлбәттә, Казан ханлыгының бетерелүе белән килешмәү. Идел буе халыкларының, аеруча татарларның, Урал тирәсенә күпләп күчүләренә ярдәм итә торган башка сәбәпләр дә булган. Алар арасында иң әһәмиятлесе Идел буе белән Урал тирәсенең Русиягә кушылу шартларының төрле булуы. Яңа кушылган халыкларның Русия составында төрле иҗтимагый-икътисадый хәлдә булуы Урал алды җирләрендәге этник хәлнең алга

---

* Тарихи язмаларда теркәлгән исемнәрнең кайберләре мәкаләдә асыл нөсхәдәгечә бирелә.

таба үзгәрешендә зур роль уйнаган. Мәсәлән, Казан ханлыгы халкы үзенең җайлашкан яшәү урыннарыннан куыла, авыр салым (ясак) түләргә мәҗбүр ителә, ул салым һәртөрле өстәмә җыемнар исәбенә тагын да авырая. Халыкларны көчләп чукындыру башлана, колониаль изү көчәя. Ә Урал алды төбәкләрендә шартлар башкачарак була. Төрле якка сугышлар алып бару нәтиҗәсендә көчен шактый югалткан Русия дәүләте көнчыгыштагы әлеге бик аңлашылып та бетмәгән төбәкләр белән саграк эш итәргә тырыша. Урал алдында үзенең катгый хакимлеген урнаштыруда бераз тыелыбрак тора. Мәсәлән, Урал тирәсендәге халыкка үз җирләре белән үзләре теләгәнчә идарә итәргә мөмкинлек вәгъдә ителә, ягъни андагы җирләр вотчина рәвешендә биләүчеләрнең үз карамагында кала (дөрес, вотчина хуҗасына җирләрне сату тыелган була). Сүз уңаенда күрсәтеп китәргә кирәк, урыс дәүләтенә буйсындырылган бер генә төбәктә дә, бер генә халыкка да мондый вотчина хокукы бирелмәгән. Шулай итеп, хәзерге Башкортстан мәйданында җир биләгән һәркем (әлбәттә, аларның зур күпчелеге шундагы җирле төрки халык, аларның татармы, башкортмы яки башка халыкмы булуын без белгечләр хөкеменә калдырабыз) башкорт-вотчиналы булып исәпләнә башлый. Гомумән, Урал буендагы барлык кешеләр дә «башкортлар» дип аталып китәләр. Бу турыда архив документларын өйрәнү буенча зур эш башкарган башкорт тарихчысы У. Х. Рәхмәтуллин болай дип яза: ***«Уфа өязенең көнбатыш һәм төньяк өлешләрендә яшәүче чувашлар, татарлар һәм марилар XVII гасырда башкорт дип аталып йөртелә башлый»*** (**Рахматуллин У. Х.** *Крестьянское заселение Башкирии в XVII — начале XVIII вв. — «Крестьянство и крестьянское движение в Башкирии в XII — начале XX вв.» Уфа, 1981. 7 бит*).

Ягъни, билгеле бер чорда, бигрәк тә XVI гасырның икенче яртысында һәм XVII гасырда башкорт сүзе административ термин һәм сословие атамасы буларак кулланылган. Бу факт патша чиновниклары язмаларында да, тарих, этнография, география белән бәйле хезмәтләрдә дә, эш кәгазьләрендә дә билгеле, хәтта гадәти хәл буларак чагылыш тапкан һәм беркем тарафыннан да бәхәс тудырмаган. Безнең бу язмада вотчиналылар, башкорт-вотчиналылар дигән атамалар кулланыла. Ләкин аларны хәзерге милли башкортлар белән тиңләү һич тә дөрес түгел. Шулай итеп, урыс дәүләтенә кушылгач, баштагы чорларда Урал буе җир биләүчеләре үз җирләрен вотчиналы буларак били башлыйлар, үзләре теләгәнчә идарә итәргә хокуклы булалар. Бусы — **беренчедән.**

**Икенчедән,** түләү буенча да Урал буе элекке Казан ханлыгы территориясеннән аерылып торган. Язма чыганаклар, архив документлары башкорт ясагының Казан өязендәге халыкларга салган ясактан бермә-бер җиңелрәк булуы турында сөйли.

Мәсәлән, вотчиналылар, үз җирләрендә яшәүче күчмәннәрне тотып, хакимнәргә бирергә кушылгач, болай дип җавап бирәләр: вотчиналылар 8 ясакка бер сусар тиресе түли, ягъни бер ясакка бер гривна булса, ә Казанда бер ясак 8 сум 26 барнау (урысча: алтын) ярты тәңкә (осемь рублев двадцать шесть алтын с полу деньгою) хасил итә, менә шуңа күрә дә ул качаклар бездә яши дә, бездә татарлар гына түгел, башкалар да, урыслар да яши бирә, җир сөрә... *(БДУДА, 248 фонд, 3 тасв., 115 китап, 978 б.)*. Башкортстанда ясакның икенче серле ягы да була: ул һәр аерым кеше тарафыннан түгел, ә җәмәгатьчелек тарафыннан гомуми рәвештә, бергәләп түләнә, ягъни нинди дә булса бер авылга ике ясак салынган икән, аны түләүдә ничә кеше катнашуының әһәмияте булмый, ул тикшерелми дә. Ясак түләүчеләр үз җирләренә кемне дә булса кертә һәм ясак түләүне шул кергән кешегә тапшыра алганнар. Еллар үткән саен теге кергән кешеләр үзләре ясакчы «башкорт» булып китә алган. Башкорт ясагының чагыштырмача җиңелрәк булуы турында күп кенә дәүләт эшлеклеләре (П. И. Рычков), тарихчылар (В. Филоненко, Р. Н. Степанов) һ.б. язып калдырган.

**Өченчедән,** Башкортстан дигән яңа территориаль берәмлек урыс дәүләтенең читендәрәк булган, XVI — XVII гасырларда тиешле күзәтү булмаган, ә Урал буен идарә итү әле җайга салынып кына килгән. Бу исә мондагы халыкны барлау, аның санын алу кебек эшләрнең начар үтәлүенә китергән, Башкортстандагы халыкның саны беренче мәртәбә III ревизиядә (1762 ел) алынган.

**Дүртенчедән,** Башкортстан җирләре чагыштырмача иркен булган, Урал алды табигатенең әле кул тимәгән почмаклары җирсезлектән интеккән халыкны шулай ук үзенә тартып торган.

**Менә бу санап кителгән факторлар, берьяктан, элек Казан ханлыгы составында яисә аның карамагында яшәүче халыкларның тормыш шартлары тагын да авыраюга, ризасызлык артуга китерсә, ягъни аларны кысып чыгарса, икенче яктан,**

**Урал буена качып килгән халыкны кертә, сыйдыра һәм урнаштыра торган мөмкинлекләр тудыра.**

## Идел буеннан Уралга таба

Архив документларыннан күренгәнчә, Казан ханлыгы җимерелгәч, аның составындагы халыклар бик зур төркемнәр булып, масса төсендә Урал буена күчә. Мәсәлән, 1688 елгы документта Оса даругасы* Уран волостенда 50 татар, мари, удмурт авыллары барлыкка килүе турында күрсәтелә. Шуларның 37 се 1662 елга кадәр, 13 е 1662 елдан соң барлыкка килгән булган *(БДУДА, 1173 ф., 1 тасв., 980 сакл. бер.)*. 1701 елгы документтан күренгәнчә, Ирәкте өязенең Мөшөгә авылы татарлары-вотчиналылары аларның җирендә 20 авылның рөхсәтсез килеп утыруы турында шикаять язалар *(БДУДА, 615 ф., 1 тасв., сакл. бер. 12157)*. Тикшерү барышында бу авыл кешеләренең күбесе инде җитмеш елдан артык монда яшәүләре мәгълүм була.

Мондый фактлар гына да XVI гасыр ахырында, XVII гасырның беренче яртысында Урал буена күчеп килүнең нинди киң колачлы булуы турында сөйли. Шунда ук бу авылларга нигез салучыларның Казан һәм Зөя өязеннән икәнлекләре дә күрсәтелә.

Халыкларның күчеп китүе шул дәрәҗәгә барып җитә ки, Казан өязе авылларында ясак түләүчеләр саны күпкә кими. Билгеле, бу хәл чиновникларның игътибарыннан читтә кала алмый. Казанның вице-губернаторы Н. Кудрявцев 1719 елны Сенатка язган хатында татарлар, ясаклы башка халыклар башкортларга качалар, ә аларга салынган салымнар җыелмый, дип яза *(БДУДА, 248 ф., 3 тасв., 101 китап, 457 б.)*. «Казан өязендә 6006 ясаклының җирләре буш калган», дип языла икенче бер документта *(БДУДА, 248 ф., 3 тасв., 115 кит., 978 б.)*. Урал тирәләренә качу шулкадәр көчәеп киткәч, аларны тоту, кире кайтару эшләре җәелдерелә, юлларга сак куела һ.б. Нәтиҗәдә, 1707—1720 елларда Казан һәм Уржум өязләреннән генә дә 17920 гаилә качаклар теркәлә. Шулардан, 8613 татар, 3863 мари, 3303 рус, 991 удмурт, 896 яңа гына чукындырылганнар, 196 чуваш, 58 мордва (**Шунда ук,** *115 кит., 283—284 б.*). 1720—1722 еллар эчендә Уфа губернасында 5031 күчеп килгән гаилә (яки 20105 кеше) табыла, аларны элек торган җирләренә кайтарырга телиләр. Шулардан иң күбесе Казан (3814 гаилә), Зөя (550), Сембер (254), Уржум (92) өязләренә туры килә (**Шунда ук,** *922—931 битләр*). Күргәнебезчә, күчеп китүчеләрнең зур өлеше Казан өязеннән була, милләтләре ягыннан караганда да, татарлар иң зур күпчелекне алып тора. Патша түрәләре дә моңа еш игътибар итә, игенчеләрнең күчеп килүе мәсьәләсен өйрәнүче галимнәр дә шундый ук нәтиҗәләр ясый (С. М. Васильев, У. Х. Рәхмәтуллин һ.б.). Әле яңа чукындырылган дигән (896 гаилә) төркемнең дә зур өлеше татарлар булырга тиеш. 1701 елга караган бер документта, мәсәлән, качакларның күпчелегенең элек Казан өязе Арча даругасына караган авыллардан булуы турында мәгълүматлар теркәлгән *(БДУДА, 452 ф., 2 тасв., 85 сакл. бер., 2 б.;* Васильев С. М. ***Припущенники на башкирских землях в I половине XVIII в.*** *(Канд. дисс., М., 1950. 63 б. һ.б.)*.

Югарыда башкорт ясагын түләүнең кайбер серле якларын күрсәтеп киткән идек. Тагын икенче әһәмиятле якны да истә тотарга кирәк. 1649 елгы указ нигезендә Урал буендагы җир хуҗаларыннан (вотчиналы-башкортлардан, морзалардан, татарлардан) җир сатып алу тыелган була. Ягъни килгән кешеләргә җирне сатып алмыйча, башкача урнашу юлларын эзләргә кирәк булып чыга. Менә шунда инде ясакның уртак җир өчен гомум рәвештә түләнү факторы искиткеч әһәмиятле роль казана: килгән кешеләргә общинага кереп китү мөмкинлеге туа. Һәм мондый шартларда Башкортстан вотчиналылары җирләренә бары теле, дине һәм культурасы уртак булган халык кына — татарлар гына кереп утыра ала. Шуңа күрә дә, урыс тарихчылары күрсәтеп киткәнчә (Н. Н. Фирсов, С. В. Бахрушин, А. П. Волынский), Башкортстан халкы XVII гасырда да әле

---

* Ул чорлардагы территориаль-административ бүленеш буенча Казан өязе Арча, Җөри, Нугай, Галеч даругаларына бүленгән булган. Шул ук принцип Башкортстанга да күчерелгән. Ул Оса (Уфадан хәзерге Пермь өлкәсе шәһәренә хәтле), Казан (хәзерге Көнбатыш Башкортстан, Татарстанның Ык һәм Агыйделнең түбән агымы бассейннары), Нугай (Уфадан Агыйдел буйлап көньякка таба, Димнең уң як бассейны), Себер (Көнчыгыш Башкортстан) даругаларына бүленгән.

нигездә урыс булмаган халыклардан торган. 1736 елда башкорт җирләрен сатарга рөхсәт ителгән указ чыга. Шуннан соң гына бу тирәләрне үзләштерүдә урыс крестьяннары да катнаша башлый (шәһәрләр һәм кайбер урыннарда чиркәүләр салуны исәпкә алмаганда).

Язма чыганаклардан күренгәнчә, көчеп килеп утыручы халыкка вотчиналылар төрле чорда төрлечәрәк мөнәсәбәттә булган. Башта еш кына алар үз җирләрендә күпме кеше яшәгәнен белеп тә бетермәгән. Ләкин җирләре тарая, ау урыннары кысыла башлагач, XVIII гасыр башында алар тарафыннан бик күп шикаять язылуы билгеле. Аларда Казан ягыннан бик күп кешеләрнең килүе, рөхсәтсез-нисез утырулары турында күрсәтелә. Шул ук вакытта, патша чиновниклары язмаларында көчеп килүчеләрне вотчиналыларның кабул итүе турында фактлар да күп теркәлгән. 1719 елда Н. Кудрявцев Сенатка җибәргән хәбәрендә болай дип күрсәтә: «башкортлар» йомышлы татарларны һәм урыс булмаган башка ясаклы халыкларны үз биләмәләренә кертә, үзләрендә тота» *(БДУДА, 248 ф., 3 тасв., 101 кит., 39 б.)*. 1730 елда А. П. Волынский «башкортлар, бернинди фәрманнарга да карамастан, качып килүчеләрне кабул итәләр», дип зарлана *(История Татарии в документах и материалах. М., 1937, 387—388 битләр)*. Хәтта 1704—1708 еллардагы башкорт баш күтәрүенең сәбәпләреннән берсе итеп тә Казан комиссары А. С. Сергеевның башкортлардан көчеп килеп утыручыларны бирүләрен катгый таләп итүен күрсәтәләр (**Рычков П. И.** *Топография Оренбургская, ч. 1, СПб., 1792, 89 бит*). Чыннан да, күп кенә архив документларында вотчиналыларның көчеп килеп утыручыларны чиновникларга тотып бирергә ашыкмаулары күренә. Еш кына, без инде күптән яшибез, аларның безгә бурычлары бар, дип та аңлаталар. Оса һәм Себер даругасындагы татарлар үзләрен туган якларына җибәрмәүне үтенәләр. Алар: «Безнең ата-бабаларыбыз гына түгел, хәтта бабаларыбызның бабалары да инде бу җирләрдә яшәгән булган, туган җирләребезнең кайда икәнен дә белмибез», дип күрсәтәләр *(БДУДА, 248 ф., 3 тасв., 115 кит., 371 бит)*. Менә мондый фактлар Урал тирәсенә татарларның күчүе, җирле вотчиналылар белән аларның үзара мөнәсәбәте мәсьәләсенең гаять катлаулы, гаять күпкырлы икәнлеген күрсәтә. Бу катлаулылык патша хөкүмәте сәясәте белән бәйле рәвештә тагын да тирәнәя. Эш шунда ки, дәүләт өчен салымнарның күбрәк җыелуы әһәмиятлерәк. Шуңа күрә дә хөкүмәт, бер яктан, крестьяннарның качып китүенә каршы көрәшсә, икенче яктан, вотчиналардан җыела торган ясакның артуын да күздә тота, алар җиренә көчеп килеп утыручыларны ясак түләү шарты белән калдыра килә.

Иделдән Уралга таба күчүнең төп алшартларыннан берсе — Башкортстанда килгән кешеләрне вотчинага кертү мөмкинлеге (припуск) булу. Җирне кабиләләр уртагыннан биләгәндә башка кабиләдән теге яки бу сәбәп белән аерылып чыккан кешеләрне кертеп тору гадәте элек-электән яшәп килгән. Көчеп килүчеләр дә яңа җирләргә шушы гадәт нигезендә урнашкан. Килешү, әлбәттә, сүздә генә булган. Ләкин тора-бара көчеп килеп утыручылар саны бик нык арта, ау урыннары кысыла башлагач, кыскасы, җир әзәя башлагач, аны биләүне законлаштыру зарурлыгы туа. Урыс дәүләте тарафыннан күпсанлы монастырьлар салыну, ныгытылган калалар төзелү дә вотчиналыларның җирләре кимүенә китерә. Нәтиҗәдә, күп кенә вотчиналылар үз җирләренә булган хокукларын язма документлар нигезендә законлаштыра башлыйлар. Тол буендагы гайнә кабиләсе 1597 елда, Агыйдел бассейнындагы юрматы кабиләсе патша Ал. Михайлович вакытында үз җирләренә грамота алалар. 1671 елда мин кабиләсенең 11 ыруы җирләрен үзара бүлешә һәм Ал. Михайловичтан бүлешү турында грамота ала. Телдән генә сөйләнеп, буыннан-буынга тапшырыла торган шәҗәрәләрнең язма вариантлары барлыкка килә. Болар барысы да килгән кешеләрнең артык күбәеп китүе белән бәйле, чөнки килгән кешеләр үзләрен шулай ук хуҗалар итеп күрсәтә башлый.

Ырууларда яңа бүленешләр барлыкка килә. Мәсәлән, XVIII гасыр башында ырулардагы түбәндәге нәсел-тармаклар игътибарга лаек: бөрҗән кабиләсендә чуваштай, татар, чирмеш; юрматы кабиләсендә мукшы, нугай, чуваш; кыпчак кабиләсендә чуваш, табын кабиләсендә ар, чувашбирде, казантатар, чирмеш, әпсәләм; катай кабиләсендә казан; ай кабиләсендә арый; мин кабиләсендә нугай, кушылды, юлдаш, калмак нәселләре һ.б. Кайбер кабиләләр составында килгән кешеләр зуррак бүленешләрне тәшкил итә. Мәсәлән, юрматы кабиләсендә мишәр ыруы, танып кабиләсендә казанчы ыруы, ай кабиләсендә морзалар ыруы һ.б.ш. (**Кузеев Р. Г.** *Очерки исторической этнографии башкир. ч. I, Уфа, 1957, 48—57 бб.*). Яңа ырулар барлыкка килүгә башка галимнәр дә игътибар итә, бу факт әкиятләрдә дә, легендаларда да чагылыш таба. Мәсәлән, дуван-әйле ыруының

казан ягыннан килгән кешеләр исәбенә бермә-бер артуы турындагы легенда аеруча игътибарга лаек (**Кузеев Р. Г.** *Шунда ук, 68 бит*).

Шәҗәрәләр генә түгел, яңа килгән кешеләргә җирдән файдаланырга рөхсәт бирү актлары да язма рәвештә рәсмиләштерелә башлый. XVII гасыр ахырыннан башлап мондый актларны бары язма рәвештә генә һәм бары дәүләт учреждениеләрендә генә формалаштыру мәҗбүриләштерелә. Бу бигрәк тә яңа килгән халыкны исәпкә алып ясак түләтә башлау өчен шулай эшләнә.

Татарларның Урал алды төбәкләренә күчүләренең алшартларын сөйләгәндә һәм шул хәлләр барган тарихи җирләрне сыйфатлаганда тагын бер якны аерым күрсәтеп үтәргә кирәк. Татарларның һәм татарлар белән тыгыз элемтәдә торган башка Идел буе халыкларының Башкортстан җирләренә күчүе XVI—XVII гасырның беренче яртысында ук аеруча зур күләмдә булган инде. С. М. Васильев фикеренчә, урыс булмаган күчеп килүчеләр саны XVIII гасыр уртасында Уфа провинциясе халкының яртысын тәшкил иткән (**Васильев С. М.** *Башкорт ерендә припущенниктәр.— «Әзәби Башкортстан», 1951, № 2*). Бу чорда Урал буе җирләренең күчеп килгән кешеләр тарафыннан күпләп үзләштерелүе турында башка галимнәр дә яза. Мәсәлән, П. И. Рычковның «История Оренбургская (1730—1750)» (Оренбург, 1896) дигән хезмәтен карарга мөмкин. Шул чорның, ягъни XVIII гасырның патша чиновниклары, администрация вәкилләре башкортлар санының XVIII гасыр башына ике мәртәбәгә якын артуын һәм бу артуның нәкъ менә күчеп килеп утыручылар исәбенә булуын кат-кат күрсәткәннәр *(История Татарии в документах и материалах, М., 1937, 399, 402 битләр; Материалы по истории Башкирской АССР, ч. III, М.-Л., 1949. 526 бит;* **Добросмыслов А. И.** *Материалы по истории России, т. I, II, Оренбург, 1900, 10 бит, һ.б.ш.).* Менә бу факт һәрчак игътибар үзәгендә торырга тиеш.

Димәк, Урал ягына Идел буе халыкларының, бигрәк тә татарларның, XVIII гасыр башына хәтле күпләп күчеп килеп төрле ысуллар белән утырулары чын һәм бәхәссез факт. Алар шул вакытта ук крайның иҗтимагый-икътисадый хәленә сизелерлек йогынты ясарлык күләмдә булганнар инде.

## Яңа җирләргә урнашу

Сорау туа: ни өчен соң Башкорстандагы татарлар, бер генә исем белән аталмыйча, күп төрле исем астында йөриләр? Халык арасында бүгенгә кадәр сакланып килә торган легендалар, тарих, этнография, археология, фольклор һ.б. өлкәләргә караган әдәбият белән танышу, күпсанлы архив документларын өйрәнү әлеге күптөрлелекнең килгән халыкның яңа җирләргә урнашу ысуллары белән бәйле булуын күрсәтте: алар төрле юллар белән җир хуҗалары булып киткәннәр һәм шуңа бәйле рәвештә төрле исемнәр белән йөртелә башлаганнар.

Яңа җирләргә урнашуның иң таралган ысулы — үзлегеннән теге яки бу җирне били башлау. Үз белдегең белән, рөхсәтсез килеп утыру шулкадәр киң колач ала ки, XVII гасырның ахырында — XVIII гасырның беренче ун елында җирле вотчиналылар хөкүмәт учреждениеләренә бер-бер артлы шикаять яудыра башлый. А. И. Добросмыслов, В. Филоненко туплап чыгарган материаллардан күренгәнчә, Уфа ягының барлык даругаларыннан да килә бу шикаятьләр. Аларның барысында да Казаннан, Казан ягыннан килгән кешеләр, Казан татарларының рөхсәтсез килеп утырып җирләрне сөрүләре турында әйтелә. Берничә генә өзек тәкъдим итәбез: ***«Казан өязеннән килгән кешеләр үз белдекләре белән урнашып яши бирә»; «безнең вотчиналарыбызда Казан һәм башка өязләрдән килгән татарлар һәм урыс булмаган башка халыклар яши һәм җирне сорамыйча били, бөтен байлыкларыбыздан файдалана»*** *(«Казан даругасындагы ясаклы татарлар...» һ. б. ш.).*

Рөхсәтсез килеп утыручыларның кайберләре җир хуҗалары белән үзара телдән генә килешкән булырга да мөмкин. Тик алар тора-бара барыбер үз белдекләре белән килеп утыручылар рәтендә санала башлыйлар.

Бернинди ярлыксыз, сорамыйча килеп җир табып утыручылар, анда хуҗалыгын төзегәч, йортын-җирен булдыргач, ясаклы ялгызак* катламына язылалар һәм ялгызак ясагы дип атала торган ясак түли башлыйлар.

---

* Атама шартлы рәвештә алына. Документларда бу катлам бобыльләр дип атала. Ләкин эчтәлеге белән ул Русия тарихындагы бобыльләрдән аерыла: ялгызакларның гаиләсе, хуҗалыгы, биләгән җире дә булган.

Аерым күрсәтеп үтәргә кирәк, ясак түләүнең ул заман Урал буе шартларында зур әһәмияте булган. Әгәр дә берәү ниндидер жир өчен ясак түли икән, димәк, бу кеше инде шушы жирнең хужасы, жир аныкы, дигән сүз. Нинди генә бәхәсләр туса да, жир турында нинди генә хөкем һ.б. тикшерү эшләре кузгатылса да, бу жир, кем аның өчен ясак түләгән, шуныкы булып кала торган булган. Жир ул тормыш, жир ул тереклек чыганагы, жир — яшәү дигән сүз булган, ә аның өчен түләнә торган ясак синең бердәнбер дәлилең. Башкортстан шартларында ясакның чагыштырмача жиңел булуын да тагын бер кат искә төшерик. Шуңа күрә дә килеп жир били башлаган кешеләрнең ясакка язылырга омтылулары бик табигый.

XVII гасыр башына караган документларда Уфа ясагы һәм Казан ясагы дигән атамалар еш кулланыла. Мәсәлән, Симәк авылыннан Байморза Байчурин ясакны элек Казанда түләгән. Ә утыз ел элек Уфа өязендә татар Апас Әхмәтев янына килеп яши башлый. Хужалык каралтылары төзегәч, ясак жыючы аны ике сусардан торган ясакка язып куя (**Васильев С. М.** *Припущенники на башкирских..., 133 б.*).

Казан ясагы дигәндә Русия дәүләтенең Казан Приказына (ул Казан шәһәрендә урнашкан була) түләнә торган ясак күздә тотыла. XVI — XVII гасырларда аны Казан өязендә яшәүчеләр түләгән. Шуның белән бергә, элек Казан ханлыгы составында булып, Русия жиңүләреннән соң Уфа провинциясе составында калган кешеләр дә ясагын Казанда түләүне дәвам иткәннәр булса кирәк. Чөнки документларда еш кына үзләренең ясакларын Казаннан Уфага күчерү фактлары күзәтелә. Мәсәлән, Уфа өязе Оса даругасы вотчиналыларының бабаларының бабалары Тулыбай ясакны Казанга түләп килгән, «һәм Уфа шәһәре төзелгәч,... Уфага түләгән». Уфа өязе Казан даругасы Көчек һәм Тугыз (хәзерге Әгерже районы) авыллары татарлары да Казан ясагы түләгән, ә аларның туганы Иткенә ясакны Еней волосте (шул ук Әгерже районының Тугыз буй ягы) «башкортлары» белән бергә түләгән. 1689 елда әлеге татарлар Иткенә белән бер ясакка күчәләр, Уфага түли башлыйлар. 1658 елгы документтан күренгәнчә, Талламас авылы ялгызаклары да ясакны ике якка түләгән: Казанга да, Уфага да, шул ук вакытта алар вотчиналарын «борын-борыннан, ата-бабаларыбыздан килә» дип язалар *(БДҮДА, 1173 ф., 1 тасв., сакл. бер. 980, 1037, 745, 476 һ. б.)*. Мондый фактлар әлеге авылларның Казан ханлыгы заманында ук булганлыклары турында фараз итәргә дә мөмкинлек бирә. Тагын шуны күрсәтеп үтәргә кирәк, Казан ясагы билгеле бер төбәккә караган документларда гына очрый: Ык бассейны һәм Агыйделнең түбән агымы бассейны. Казан ясагын тарихчы белгечләр махсус тикшерсә, Казан ханлыгының көнчыгыш чикләре турындагы мәсьәлә дә ачыклана төшәр иде. Әлбәттә, XVI һәм XVII гасыр турында сүз йөрткәндә Казан ясагы күбесенчә Казан өязендә яшәүчеләрнең Казан Приказына түләгән ясагы күздә тотылган. Мисалларны дәвам итәргә мөмкин.

Казан чувашы (Казан өязе татарларының бер катламы ул елларда документларда шулай аталып йөртелгән) Максут Ураков (Жөри даругасы Бирсут авылыннан була) 1627 елда язган челобитиесендә Ык елгасының югары агымында вотчинасы булуын, ә ясакны Казанда түләвен хәбәр итә *(БДҮДА, 1173 фонд., 1 тасв., 321 сакл.бер., 1 б.)*. Арча даругасы Ашытбаш авылы татары Котлы Ишменев Казанда ясак түләгән, ә үзе Уфа өязе Уран волостенда яши (**Васильев С. М.** *Шунда ук, 63 б.*). Уфа өязе Казан даругасы Иске Юшады авылы ясаклы татарлары да Уфага берәр сусар ясагы, Казанга жан башына салына торган ясак түләгәннәр *(БДҮДА, 452 ф., 2 тасв., 85 сакл.бер., 2 б.)*. 1688 елга кадәр Уфа өязе Уран волосте жирләрендә барлыкка килгән 50 авылның 18 е генә Уфадагы ясак кенәгәләренә язылган булган. Калганнары исә ясакны Казанга түли, ә монда вотчиналылар ясагын түләргә булышалар һәм шуның өчен жир хужаларына елына кырык сусар түләп торалар. Документтан күренгәнчә, бу авыллар урыннарында калдырыла *(БДҮДА, 1173 ф., 1 тасв., 980 сакл.бер., 12 б.)*. Чапкын авылыннан Алкач Яхин болай дип күрсәтә: алар авылында (док. 1688 елга карый) барлыгы 9 ялгызак, алар 20 елдан күбрәк элек Морзакай Юкачев вотчинасында рөхсәтсез-нисез авыл булып утыралар, йортлар салалар һәм казнага ялгызак ясагы түли башлыйлар. Тикшерү барышында Морзакай Юкачевлар вотчинасында 24 авыл (276 семья) барлыкка килгәнлеге мәгълүм була, шуларның 14 е (165 семья) инде 50-70 елдан да күбрәк шушында яшиләр икән. Патша хөкүмәте өчен ясак түләүчеләрнең саклануы хаерлерәк булганга, бу авыллар да урыннарында калдырыла (**Васильев С. М.** *Припущенники на башкирских землях..., 129 — 138 бб.*).

Хөкүмәт көчеп килеп үзирекле яшәүчеләрне барлау эшләре дә алып бара. Мәсәлән, 1678 елны 2571 кеше (элек «кеше» дигәндә гаилә башлыгы күздә

тотылуы, ә гаиләләрнең бик ишле булуын, йортта еш кына берничәшәр киленнең бергә яшәвен истән чыгармыйк) барланып, акча яки сусар ясагына билгеләнәләр (**Новиков В. А.** *Сборник материалов для истории Уфимского дворянства. СПб., 1879*). Воевода В. Ф. Стрешнев заманында һәр яңа килгән кешене барлап торырга, килгән берен ясаклылар исемлегенә яза барырга, вотчиналарда хуҗаларга оброк түләүчеләрне барлап, ачыклап, аларны ясаклылар исемлегенә теркәргә дигән фәрман чыгарыла *(БДУДА, 1173 ф., 1 тасв., 1167 сакл.бер., 2 б.)*. Нәтиҗәдә, 1693—1694 елларга караган эш кәгазьләрендә ясаксызларны ялгызак ясагына, ә ялгызак ясагындагыларны оклад ясагына язу турында бик күп фактлар теркәлгән.

Ялгызаклар чагыштырмача аз җирле крестьяннар катламын тәшкил иткән. Алар бу яклар Мәскәү дәүләтенә кушылганчы ук монда яшәгән булырга мөмкин. Мәсәлән, Уфа өязе Казан даругасы Уран волосте Кичкутан авылы кешеләре 1622 елда ук ясаклы ялгызак булып исәпләнгәннәр *(БДУДА, 1173 ф., 1 тасв., 642 сакл. бер.)*. Баржы авылының кешеләре шул ук документта «старожилые бобыли» (иске ялгызаклар) дип аталганнар *(25 б.)*. Бөре өязе Туйкаш авылы типтәрләренең дә борынгы бабалары ялгызак булган. Алар ялгызак ясагын 1744 елга хәтле, ягъни типтәр исеме алганчы түләгәннәр *(БДУДА, 1324 ф., 1 тасв., 4152 сакл.бер. 265—273 битләр)*. Ялгызаклар катламында бөлгенлеккә төшкән җирле крестьяннар да, йомышлы татарлар да булган.

Тора-бара, үзенең хәлен нығыткач, кайбер ялгызаклар, кайдагы җирне биләүләрен, ул вотчинаның чикләрен күрсәтеп, үзләрен оклад ясагына күчерүне сорап, административ учреждениеләргә үтенеч язалар.

Шул үтенеч нигезендә аларга грамоталар, биләмә язуы дигән документлар бирелә. Нәтиҗәдә, үтенеч язучы үз җиренең законлы хуҗасы буларак хәлен тагын да ныгыта. Мәсьәләнең икенче ягы да бар. Оклад ясагы дигән ясакны җирле вотчиналылар түли торган була. Димәк, шулай итеп ялгызаклар вотчиналылар катламына күтәрелә. Башкортстанда XVI—XVII гасыр шартларында вотчиналылар һәм «башкортлар» дигән сүзләрнең бәрабәр атамалар булуын да истән чыгармаска кирәк. Берничә мисал китерик. Уфа өязе Нугай даругасы Табын волосте тарханы Янбахтин җирендә яшәүче ялгызак Зяникак Елымов 1673 елда башкорт хезмәтенә күчә *(БДУДА, 1137 ф., 1 тасв., 539 сакл.бер., 2 б.)*. Шундый ук юл белән Табын волосте ялгызаклары Уразай һәм Акпердай («Матросовы дети») да башкортка күчкәннәр *(Шунда ук)*. Кыпчак волосте Бурлы авылыннан Качаковлар, Илтудиннарның аталары һәм бабалары шул ук волостьныкы, бөлгәч ялгызакка язылган булганнар, үтенечләрен канәгатьләндереп, аларны, кайсы ясак күбрәк булса, шуңа язарга кушылган грамота бирелә *(Шунда ук, 933 сакл.бер., 7, 37 б.б.)*.

Уфа өязе Казан даругасы Турай авылы татары Колмәт Еналеев 1677 елда үзенең ялгызак ясагын ирекле һәм ясаксыз булган кешеләргә тапшыра, ә үзе оклад ясагына языла. Ул үзенең үтенечендә «минем шунда-шунда биләмәм бар» дип күрсәтә. Ә 1689 елда аның улы (?) Якуп Колмәтов Турай авылы башкортлары арасында саналган *(Материалы..., ч. 1., 224 б.)*.

Нугай һәм Себер даругаларындагы ялгызаклар XVII гасыр ахырында Нугай даругасы Мин волосте башкортлары белән уртак ясакка язылалар, ә аларның балалары 1728 елда язган үтенечләрендә инде башкортлар белән бертигез хокуклар даулыйлар *(Шунда ук, 128 б.)*.

Оклад ясагына күчкәндә ялгызаклар еш кына «патша казнасына файдага» өстәмә ясак түләргә вәгъдә итәләр. Югарыда телгә алынган Талламас авылы кешеләре, оклад ясагына күчерүне сораганда, файдага елына ике сусар өстәп түләргә язылалар, безнең биләмәбез Ык буенда, бик борынгыдан килә, аталарыбыз-бабаларыбыздан калган, дип язалар. Уран волостеннан Москов Бахтыбаев, карт булганга күрә, үзенең буш вотчинасын ялгызак ясагындагы татарларга (Мыстяч Бахтыбаев һәм Якуп Танатмышевларга) бирә. Соңгылары әлеге биләмәнең ясагын («10 куниц да батман меду да прибыль куницу») түләргә тиеш булалар, ә аларның ялгызак ясагы бер дә ясагы булмаганнарга күчерелә *(БДУДА, 1173 ф., 1 тасв., 1035 сакл.бер., 7 б.)*.

Еш кына оклад ясагына күчүчеләр үзләре белән бергә кардәшләрен, алардан туган энеләрен (яңа күчеп килгән кешеләрне) дә язалар, аның өчен өстәмә сусар түләргә алыналар. Мәсәлән, Уфа өязе Казан даругасы Байлар волосте Русай авылыннан Чурабол Токаев Уфага 20 ел ялгызак ясагы (2 сусар) түли, ә аның Ык башында вотчинасы бар икән. Үзен, ялгызак ясагыннан сызып, туганының улы белән бергә оклад ясагына күчереп язуларын сорый. Аның да соравы канәгатьләндерелә һәм ул Уфага өч сусар, патша файдасына тагын бер сусар түләргә

тиеш була *(Шунда ук, 470 сакл. бер., 1, 7 бб.).* Колмәт Еналеев та оклад ясагына энесе Измаил белән бергә күчә, вотчинасы Ык буенда, борын-борыннан бар, дип аңлата. Дуван волосте Кыркалны авылы ясаклы татарлары да оклад ясагына күчәләр *(Шунда ук, 858 сакл.бер., 5 б.).* Менә бу фактлар атап кителгән авылларны Казан ханлыгы чорында ук шунда булганнардыр дип фараз итәргә мөмкинлек бирә.

**Шулай итеп, яңа күчеп килгән кешеләрнең бер өлеше башта үз белдекләре белән, рөхсәтсез утырып, ясаксыз яшәп, аннан соң җир юнәтеп хуҗалыгын ныгыткач, ялгызак ясагына языла торган булган. Алар тора-бара җирләрен арттыргач, оклад ясагына, башкорт-вотчиналылар дигән социаль катлам түли торган ясакка, күчә алганнар. Күчеп килгән кешеләр шундый юллар белән яңа җирләрдә үзләренең хәлләрен ныгыта килгәннәр, җир хуҗаларына — башкортларга әверелә барганнар. Бу хәлләр, һичшиксез, татар телле «башкортлар» килеп чыгуга сәбәпче булып торалар. Ялгызакларның һәм үз белдекләре белән утырган татарларның бер өлеше типтәрләр булып киткән** (бу мәсьәләгә түбәндәрәк туктарбыз).

Припуск (үз җиреңә чит кешеләрне урнаштыру). Үз җиреңә чит кешеләрне торырга кертү, башкорт галимнәре фикере буенча, беренчедән, күптәннән яшәп килә, икенчедән, ул бары Көнбатыш Башкортстан өчен генә хас булган. Припуск ике юл белән башкарылган: **1) телдән килешү; 2) язма нигезендә килешү.** Телдән килешеп урнашу бик борынгыдан килгән. Бу форма башта иң төп форма булган. XVII гасырга караган документларда крестьяннар күпчелек очракта «без монда бик күптәннән яшибез инде, без урнашкан вакытта бернинди дә язулар бирү юк иде», дип язалар. Югарыда әйтеп үткәнебезчә, килгән кешеләрнең крайда нык артып китүе, вотчиналыларның җирләре һәм ау урыннары кысыла башлау һ. б. ш. сәбәпләр нәтиҗәсендә XVII гасырның соңгы чирегендә җир турында күпсанлы бәхәсләр кузгала. Биләмәләреңне үзеңә язма документлар нигезендә беркетү зарурлыгы бик нык көчәя. Припуск, нигездә, язма рәвештә генә башкарыла башлый. Язма припуск билгеле бер традицион рәвештә, татар телендә языла торган булган, дәүләт учреждениеләрендә аның тәрҗемәсе («перевод с татарского письма» дип атала) саклана торган булган. Гомумән, **күп төрле халыклар килеп урнашкан Башкортстан шартларында татар теле бу халыклар өчен төп аралашу чарасы булып хезмәт иткән, эш кәгазьләре дә татар телендә алып барылган.** Припускны дәүләт учреждениесендә, рус теленә тәрҗемә белән формалаштыру 1700 елдан фәрман нигезендә закон итеп кертелә. Бу фәрманга кадәр төзелгән припуск актлары 1700 елда язма формага күчереләләр.

Припускның шартлары бик күп төрле, һәр вотчиналы аны үзенчә хәл иткән. Шулай да аларны төп өч төргә бүләргә мөмкин.

1. Килеп, авыл булып утырган кешеләр вотчиналыларга оброк түлиләр, мәңгегә яки билгеле бер вакытка урнашалар, вәгъдәсе тулгач, килешүне яңарталар.

2. Килеп вотчинада мәңгегә урнашалар һәм вотчиналылар белән бер ук хокуклы булып яши башлыйлар, ясакны бергә түлиләр. Шулай итеп, вотчинаның тигез хокуклы хуҗаларына, ягъни вотчиналыларга әвереләләр, документларда бу төр күпчелек очракта «ясак түләргә ярдәм итәр өчен» дип күрсәтелә торган булган *(Материалы по истории..., т. III, 60, 78, 136 һ. б. битләр).*

3. Төрле юллар белән аерым вотчинага мәңгегә хуҗа булып китәләр. Мәсәлән, Бюляр волосте башкорты Ишкәй Карманов, карт, ялгыз, бала-чагасыз булу сәбәпле, үзенең повытьесын, бөтен уңайлыклары белән Тюрячеево авылы ясаклы татары Салтанай Исаков һәм аның иптәшләренә бирә. Соңгылары бөтен нәрсәдән файдаланырга, Ишкәй өчен ясак түләргә тиеш һәм, кайда теләсәләр, шунда авыл булып утыра алалар. Документта Ишкәйнең алдагы көннәрдә ул повытьеда бернинди дә эше булмаячагы басым ясап күрсәтелә. Шундый ук припуск Дуван (үлгән башкорт урынына), Юрматы (васыять буенча), Кыр-Илан, Елдят (үлгән башкорт урынына) һәм башка бик күп волостьларга рәсмиләштерелгәннәр *(Материалы по истории Башкирской АССР, т. III, 10—11, 178, 290, 315 һ. б. битләр; БДУДА, 1173 ф., I тасв., сакл. бер. 1331, 1—3 б.б. 615 ф., I тасв., сакл. бер. 12149, 11 бит; һ. б. ш.).* Бушап калган повытоклар да тизрәк ялгызакларга яки ясаклы татарларга күчереп языла торган булган, мондый очракта алар ялгызак һәм Казан ясагыннан, җирле вотчиналыларга түли торган оброктан азат ителәләр һәм оклад ясагына күчереләләр *(Мәсәлән: БДУДА, 1173 ф., I тасв., сакл. бер. 1034, 1035).*

Припуск күчеп килгән кешеләргә яңа җирләрдә урнашып калырга ярдәм иткән, аларга вотчиналы-башкорт булып китәргә, башкорт катламында (сословиесендә) исәпләнә башларга зур мөмкинлекләр биргән. Җир сату патша

фәрманы нигезендә тыелган булса да, вотчиналылар аны сатуның башка ысулларын тапканнар. Припускның шул ук җир сату икәнен XVIII гасыр идарә вәкилләре дә, башкорт тарихчылары да язганнар. Мәсәлән, К. Ураков үзенең 1744 елда императрица Елизавета Петровнага башкорт халкының тарихы турында язган гаризасында вотчиналылар припущенникларга үзләренең бер өлеш ясакларын бүлеп бирделәр, ә кайберләре ясакларына ярдәмгә алдылар, ә кайберләре исә алар белән бөтенләй туганлаштылар, дип яза *(Материалы..., т. III, 556 бит)*. «Материалы по истории Башкирской АССР» дигән хезмәтне бастыручылар припускның эчтәлеге төрлечә булуын, аның җирне аренда рәвешендә биләүдән башлап, вотчиналы-башкортлар белән тигез хокукта идарә итү һәм сатып алуга кадәр барып җитүе турында язалар *(Материалы..., т. IV, 393 бит, № 30 нчы документта бирелгән искәрмә)*.

Р. Г. Кузеев, аренда еш кына чикләнмәгән срокльпа әйләнә торган булган, ягъни чынбарлыкта сату дигән сүз булган, дип яза *(Башкирские шежере. Уфа, 1960. 185 б.)*. Күпсанлы архив документларына таянып, без дә припуск җирне алу-сату дигән сүз булган дип саныйбыз. Алай гына да түгел, ул килгән кешеләрнең вотчиналы-башкортлар катламына үтеп кереп, яңа җирләрдә үзләренең статусларын ныгыту ысулы да булып хезмәт иткән. «Үз җиренә кертү... читләрнең башкорт общинасына үтеп керү формасы» (**С. М. Васильев.** *Припущенники...*, *130 б.*). Бу урында тагын бер мәртәбә ясакның роле турында берничә сүз әйтми мөмкин түгел. Ясак кешеләрнең яңа җирләргә төрле юллар белән урнашуына гына түгел, инде урнашкан кешеләрнең үз хәлләрен яхшыртуга тагын да көчле этәргеч булып торган. Ясак түләгән икән, хөкүмәт аны, нинди генә бәхәсләр чыкса да, үз җирендә калдыра килә. Дәүләт органнарының ясакның күләмен арттыра бару сәясәте дә күчеп килгән кешеләргә яңа җирдә урнашырга уңайлыклар тудырган. Р. Г. Кузеев «Ясакны башкортлар җирне биләү хокукының билгесе итеп күзаллый,— дип яза.— Әгәр ниндидер бер билгеле җир кисентесе өчен казнага ясак түләнә икән, аны түләгән кеше шул ясак нигезендә әлеге җирнең хуҗасы булып китә» *(Башкирские шежере, 209 б.)*. Бу әйтелгәннәрнең чынбарлыкка туры килүе һәм припускның нәтиҗәләре XVII гасыр ахырында, XVIII гасыр башында ук инде ачыклана. XVIII гасырның беренче яртысында Уфа краенда яшәгән һәм эшләгән И. К. Кириллов болай дип яза: «Чын башкортлар припущенникларны язма килешү нигезендә, алар өчен казнага ясак түләргә дип үз җирләренә керттеләр, ә хәзер ул припущенникларны чын табигый башкортлар дип атадылар һәм атыйлар» *(Материалы..., т. III, 493 б.)*.

## Татарларны хөкүмәт карарлары нигезендә күчерү

Бу мәсьәләләр дә белгечләр тарафыннан әлегә өйрәнелгән дип әйтеп булмый. Без исә биредә төп ике нәрсәгә генә тукталабыз.

1. **Йомышлы татарларны Башкортстан якларына күчерү.** Казан ханлыгын Русия дәүләтенә кушу белән, яңа чикләрне саклау һәм ул тирәләрдәге халыкка күз-колак булу өчен ныгытмалар төзелә (Бөре, Уфа, Минзәлә, Самар һ. б.), алар тирәсенә йомышлылар күчерелә башлый. Йомышлы татарлар (алар нигездә мишәрләрдән торган) хәзерге Байкыбаш, Бөре, Уфа төбәкләренә утыртылган булганнар. К. Ураков, И. К. Кириллов язмаларына һәм башка кайбер документларга караганда, мишәрләр, Уфа каласы төзелгәч, шул шәһәр карамагында хезмәт итү өчен Казан һәм Воронеж өязләреннән 1597/98 (кайбер документлар буенча — 1573) елгы грамота нигезендә китерелгәннәр. Йомышлы татар-мишәрләр вотчиналыларга оброк түләү шарты белән Оса даругасының Дуван, Карши, Кошчы, Унлар һ. б. волость җирләренә утыртылганнар. Архив чыганакларында мишәрләрнең тагын 1658/59, 1695 һ. б. елларда да хезмәткә алынганнары билгеле. Аларга азлап-азлап яңа мишәрләр дә килеп кушыла торган *(БДУДА, 248 ф., 3 тасв., 115 кит., 562—631 б.б.)*.

Арта барган саен бу йомышлы мишәрләр көньякка, көнчыгышка таба яңа җирләргә күчә барганнар. Бүгенге көндә Чакмагыш, Чишмә, Кушнарин, Кырмыскалы, хәтта Стәрлебаш һәм Федоровка районнарындагы мишәрләр дә үзләренең чыгышлары белән әлеге Оса доругасы йомышлыларына барып тоташалар. Документлар ЫК буе волостьларында да бу йомышлы мишәрләрнең припущенник буларак җирләр алып утыруы турында сөйли.

Мишәрләр арасында казан татарлары һәм башка кешеләр дә булган. Мәсәлән, Чакмагыш авылында яшәүче Ибраһим Мансуров йомышлы мишәр булып

саналган, аның туганы (бабалары бертуган) Йөзекәй Ишалин ясаклы татар булып исәпләнә *(БДУДА, 452 ф., 2 тасв., 74 сакл. бер.)*. Күп кенә документлар йомышлы татарларның этник яктан бертөрле генә булмавы турында сөйли. Мәсәлән, 1787 елны да мишәрләр катламына ясаклы татарларны да, милләте билгеле булмаган башка кешеләрне дә язып куюлары билгеле.

Башкортстандагы йомышлы татарлар арасында да мөлкәт ягыннан тигезсезлек, аерым кешеләрнең баеп китүләре, җирләрен күбәйтүләре кебек процесслар булып торган. Мәсәлән, Оса даругасы йомышлы мишәрләре тарафыннан нигез салынган Тимкә авылы кешеләре башкорт катламына күчәләр; Сафар һәм Тирмә авыллары мишәрләре (хәзерге Чишмә районы) XIX гасыр уртасында башкортлар исәбендә йөриләр, документта алар «мишәрләрдән чыккан башкортлар», «мишәрләр, хәзер инде башкортлар» дип аталган; Халикәй, Яңа Муса авылы халкы да «мещеряклардан чыккан башкортлар» дип аталалар; Чиләбе өязе башкортларының да бер өлеше элекке морзалардан торган; Стәрлетамак өязе Балыклыкүл авылыннан Туктар Аликаев — иптәшләре белән барлыгы 26 кеше — башкортка күчкән *(Башк. ДУА, 172 ф., I тасв., 45 сакл. бер., 81 бит; 46 сакл. бер., 101, 148, 160 бит.; 101 сакл. бер., 96 бит; Оренб. өлкә архивы, 13 ф., I тасв., 80 сакл. бер., 3—5 бит; 98 ф., 2 тасв., 33 сакл. бер. һ. б.)*. Легендаларга Авыргазы районы Иске Тимешкә, Тукай, Солтанморат, Әлшәй районы Туктар-Әптерәшит һ. б. бик күп авылларда яшәүчеләрнең бер өлеше башкорт дип йөртелгәнлеге турында сөйләнә. Әмма ләкин бу авылларның халкы сөйләү теле, тормыш-көнкүрешләре, кием-салымнары, йөз төзелешләре һ. б. сыйфатлары белән бер төрле.

Башкортстандагы мишәрләрне күршеләре төрле исемнәр белән атап йөртәләр: төмәннәр, алатырлар, мишәрләр. Ә мишәрләр үзләрен татар дип, урта диалектча сөйләшүче татарларны типтәр дип, хәтта, Казан ягы авылларындагы татарларны да Казан типтәрләре дип атыйлар.

Төмән, алатыр атамалары аларның элеккеге үзәкләре (Темников, Алатырь) белән бәйле. Төмәннәр һәм мишәрләр башкорт, типтәр, мещан, крестьян дигән катламнарга, алатырлар мещан һәм типтәр дигән катламнарга караган, җирләре аз булган, төрле эшләрдә эшләп тамак туйдырганнар.

Архив документлары мишәрләрнең Уфа ягы халыкларының мәдәни-этник формалашуында сизелерлек роль уйнавы турында сөйли. Документларда бай морзаларның йогынтысы көчле икәнен күрсәткән фактлар теркәлеп калган, аларның урысча уку-язуга омтылышлары абайлана. Уфа краеның дворяннары, офицерлары гына түгел, күп кенә муллалары, тылмачлары, крайда булган баш күтәрүчеләрнең әйдәп баручылары да мишәрләр булган.

XVIII гасырда йомышлы татарларның бер өлеше Сөет бистәсенә һәм Яңа Мәскәү тракты буена утыртылалар. Бу төркем инде этник яктан төрлерәк, зур урыны Казан өязеннән чыккан йомышлы татарлар алып торган.

2. **Төрле төркем татарларның хөкүмәт рөхсәте белән Башкортстанга күчүләре** 1736 елгы 11 январь фәрманы нигезендә вотчинаһыларга җирләрен аерым катлау кешеләренә сатарга рөхсәт бирелә. Моңа кадәр Башкортстанга күчеп килү нигездә качып, рөхсәтсез булса, бу указ чыкканның соңында, Идел буе крестьяннарының тагын бер көчле күчеш дулкыны барлыкка килә. Бу күчеш аеруча ревизия материалларында чагылыш тапкан. Кызганыч ки, I (1715—1720), II (1745) ревизия (кешеләрне җан башыннан исәпкә алу) материаллары тулы түгел. III ревизия материаллары шактый бай мәгълүматлылык белән аерылып тора. 1736 елгы указ буенча һәм бу III ревизия вакытында башкорт җирләрендә припуск нигезендә яши торган барлык ясаклы һәм йомышлы татарлар шул яшәгән җирләрендә мәңгегә калдырыла. Халыкны милләтләре буенча түгел, ә катламнары буенча исәпкә алалар. III ревизия вакытында яңа күчеп килеп утырган авыллар аерым күрсәтелгән, алар да мәңгегә урыннарында калдырылган. Алар ясаклы, йомышлы, однодворцы дигән исемнәр белән атала, типтәр катламына да кертелми. Ревизия материаллары күчеп килүчеләрнең социаль катламы, элек яшәгән урыннары, яңа җиргә урнашу ысулы һ. б. турында сөйли.

Мәсәлән, кайберләрен күрсәтеп үтик:

| | Сословие | Хәзерге бүленеш | Саны | Кайдан килгәннәр |
|---|---|---|---|---|
| Биктимер | Ясаклы | ? | 94 | Казан ө., Арча д. Биктимер авылын |
| Мәтәү-Тамак | —»— | Туймазы р-ны | 15 | Арча дар., Анак ав. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Кузеево-Морза | Морза | ? | 3 | Шацкий ө., Тенишев ав., 1754 елда күчкән |
| Казанлы-Тамак | Адмиралтействога караган татарлар | Бәләбәй р-ны | 25 | Зөя ө., Малый Чирки ав., Сембер ө., Ельшанка ав. |
| Ташлы (Дым Тамак) | Ясаклы | Татарстан, Баулы р-ны | 6 | Казан ө., Җөри дар., Шумилин ав. |
| Чакмак | Адмиралтействога караган татарлар | Татарстан, Мөслим р-ны | 42 | Арча даругасы Кулкувады, Сосновый поч., Ст. Ушман авыллары |
| Каүҗияк-Тамак | Ясаклы | Татарстан, Сарман р-ны | 84 | Казан ө., Арча дар., Мәңгәр., Урта Саба, Курса, Югары Әйшә, Шәмәрдән, Кукмара авылларыннан |
| Исергәп | Адмиралтействога караган татарлар | Татарстан, Баулы р-ны | 15 | Казан ө., Арча дар., Курса авылы, 1751 елда күчкәннәр |

Бу исемлекне тагын да дәвам итәргә мөмкин булыр иде.

1736 елгы фәрманнан соң вотчиналылар һәм припущенниклар арасында җир сату-алу турындагы телдән килешүләр язма формага әйләндерелә, шул турыда бик күп актлар төзелә. Слак авылы мишәрләре Яиксубимин волосте башкортлары белән 1759 елда килешү шартнамәсе төзиләр *(Башкортстан ҮДА, 2 ф., I тасв., 640 сакл. бер., 173 б.)*. Кыешкы, Тимкә, Салҗәгут авылы кешеләре типтәр була, аннары башкорт катламына күчә, припуск 1764 елда язылган *(Шунда ук, 172 ф., I тасв., 45 сакл., бер., 81 бит)*. Биштәкә (хәзер Шәйморатов) авылы Уфа ө. Нугай даругасы вотчиналыларыннан оброкка алган җирдә мишәрләр тарафыннан нигезләнә, припуск 1755 елда языла, 1811 елдан анда типтәрләр һәм мишәрләр (ләкин сөйләшләре һәм башка яклары белән аерылмыйлар) яши *(Шунда ук, 138 ф., I тасв., 124 сакл. бер., 391 бит)*. Атҗитәр авылына 1739 елда типтәрләр (мишәр-типтәрләр — Д. Р.) утыра, җирне Уршакмин волосте башкортларыннан мәңгегә алалар; аннан соң 1758 елда ук авылга башкортлар тарафыннан яңадан мишәрләр кертелә *(Шунда ук, 9 ф., I тасв., 125 сакл. бер., 118 бит)*.

Татар крестьяннарының хөкүмәт рөхсәте белән Урал якларына күчүе XX гасырга кадәр дәвам итә. XVIII гасыр ахырында һәм XIX гасыр башында күчешнең тагын бер зур дулкыны уза. Бу исә XVIII гасыр ахырында Башкортстан җирләренә генераль межалау уздыру белән бәйле була. Бу межалау вотчиналыларның җирен чикләү, аларның мөмкин кадәр зуррак өлешен казна хисабына калдыру максатын күздә тотып эшләнә. Башкортстанда казна җирләренең артып китүе крайга күчеп килүчеләр агымын көчәйтә, яңа килгән кешеләрнең анда урнашу мөмкинлекләрен җиңеләйтә (XVIII һәм XIX гасырның башында күчеп килүчеләр — нигездә, мишәрләр).

Шланлыкул авылына 1795—1796 елларда мәңгегә дип төзелгән шартнамә буенча Пенза губернасыннан ясаклы татарлар (мишәрләр — Д. Р.) күчеп килә *(Шунда ук, 138 ф., 2 тасв., 47 сакл. бер., 185, 648 битләр)*. Әүрезтамак авылына Казанлы Тамактан йомышлы татарлар күчеп утыра *(Шунда ук, 35 сакл. бер., 935 бит)*, безнең тарафтан тупланган материаллар аларның мишәрлеге турында сөйли. Мәндән авылына 1795 елда Карсун округы Шлемасс авылыннан мишәрләр күчеп килеп утыра *(Шунда ук, 115 б.)*. һ. б. ш. Гомумән, бу елларда Башкортстанга мишәрләр яши торган губерналардан күчү күбрәк булуы күзгә ташлана.

XIX гасыр урталарында да татарлар һәм башка халыклар күчеп килүнең җанлы күренеше күзәтелә. Тик бу күчеш Башкортстанның бигрәк тә көньяк-

көнбатыш өлешенә булган, чөнки төньяк-көнбатышына элек-электән үк җир эшкәртеп көн итү хас, андагы җирләр инде үзләштерелгән булган.

Тагын бер кызыклы якны күрсәтеп үтәргә кирәк: XIX гасырда күчеп килгән татарларга төрле-төрле исемнәр бирелгән. Мәсәлән, «габдерәшитләр» (күчеп килүчеләр арасында баш кеше булып Габдерәшит торган), «Мөлкәйләр» (алар Гайны-Ямак авылыннан аерылып чыгып, Кече Гәйнә — халыкча әйтсәк, Мөлкәй авылын төзиләр), «Дистәннәр» (Бүздәк районында Дистанов фамилиясе таралган), «яңалар», казаннар, «казан кешесе» һ. б. ш. Бу төркемнәр бик соң күчеп килгән, җирләре аз булган, төрле эшләр эшләп көн күргәннәр, документларда еш кына мещан катламында исәпләнгәннәр. Өлкән буын кешеләренең раславына караганда, аларның сөйләү телендә дә аерымлыклар булган. Безнең күзәтүләр бу аерымлыкларның инде юк дәрәҗәсенә җитүен күрсәтте. Алардан бары «яңалар» (Яңа Кыешкы, Иске Шәрәй авылларында) гына әле үзләренең элек яшәгән җирдәге сөйләшкә хас үзенчәлекләрне шактый нык саклап килә.

**Шулай итеп, хөкүмәт рөхсәте белән күчеп килеп утыру төрле юллар белән барган. Иң борынгысы — йомышлы татар-мишәрләрнең килүе; XVIII гасырдан башлап йомышлылар арасында казан татарлары да күренә. Соңга таба, 1736 ел указыннан соң, төрле-төрле төркем крестьяннар күчеп килгән. Алар арасында да типтәр яки башкорт катламнарына күчү таралган булган.**

## Типтәрләр

Типтәрләр, аларның килеп чыгышы күптәннән инде төрле эшлекләләрнең, галимнәрнең игътибар үзәгендә тора һәм шуңа күрә дә алар турында бай әдәбият тупланган (Мәсәлән, түбәндәге хезмәтне карарга мөмкин: **Рамазанова Д. Б.** *Формирование татарских говоров юго-западной Башкирии. Казан, 1984*).

Типтәрләр Идел буе тирәләреннән үз ирекләре белән күчеп килеп урнашкан халыклардан формалаша, җир эшкәртү белән көн итүче катлам булып башкорт припущенникларының бер өлешен тәшкил итә. Алар турында В. М. Черемшанский, Е. С. Филимонов, Н. А. Гурвич, Г. Н. Әхмәрев, Р. Г. Кузеев, С. М. Васильев һ. б. галимнәрнең хезмәтләрендә нигезле мәгълүматлар китерелгән.

Типтәрләр категориясе составында типтәр-татарлар, типтәр-марилар, типтәр-удмуртлар, типтәр-башкортлар һәм хәтта типтәр-урыслар да булган (**Васильев С. М.** *К вопросу о землепользовании пришлого нерусского населения в конце XVII — начале XVIII вв. — «400-летие присоединения Башкирии к Русскому государству». Уфа, 1958. 132 б. h. б.*). **Р. Г. Кузеев типтәрләрнең килеп чыгышын «татарларның төрле этнографик төркемнәре» белән бәйли.**

Телче галимнәр дә типтәрләрне сословиечел категория буларак карый, Башкортстандагы крестьяннарның билгеле бер катламын тәшкил иткән дип күрсәтәләр (А. А. Юлдашев, Л. Т. Мәхмүтова, Ә. Ш. Әфләтунов, Ж. Алмаз, Д. Б. Рамазанова һ. б.).

Галимнәр татар-типтәрләрнең татар халкыннан берни белән дә аерылмавын һәрвакыт басым ясап күрсәтеп килгән (П. И. Небольсин, Г. Н. Әхмәров һ. б.). Революциягә кадәрге телчеләр дә (А. Г. Бессонов, Н. Ф. Катанов) бу турыда язып калдырганнар.

Безнең күзәтүләребез буенча да, татар-типтәрләр татар халкыннан берни белән дә аерылмый: телләре татар әдәби теленә бик якын; йөз, гәүдә төзелешләре белән дә алар татарлар белән бертөсле, кием-салым, йорт-җир төзелеше, өй җиһазлау, аш-су һ. б. — барысы да татарча аларның. Бусы — бер. Икенчедән, алар үзләренең күршеләрендә яшәүче башкорт, казаннар, казан кешесе, ясаклы дип йөртелә торган төркемнәрдән дә берни белән дә аерылмыйлар.

**Гомумән, Көнбатыш Башкортстандагы татарларны сөйләшүләре ягыннан икегә генә бүлергә мөмкин: мишәр шивәсе һәм урта шивә вәкилләре.** Бу турыда башкорт телчесе С. Ф. Миржанова да күрсәтә: «Халык үзе... татар һәм мишәр телләрен генә аера» (Миржанова С. Ф. *Этнолингвистические процессы на северо-западе Башкирской АССР. — «Развитие языков и культур народов СССР в их взаимосвязи и взаимодействии». Уфа, 1976. 238 б.*)

Бу язмабызда без архив документларына таянып әзерләгән типтәрләр турындагы күзәтүләребезне тәкъдим итәбез.

Билгеле булганча, Башкортстанга бәйле урысча беренче язма документлар XVII гасырның урталарына карый (элеккерәк замандагылары безгә килеп җитмәгән). Аларда типтәр сүзе «окладной тептярской ясак» дигән тәгъбирдә генә очрый. Ул ясакны Башкортстанның җирле, башкорт дип аталып киткән һәм

оклад ясагына кертелгән халкы түләгән. Мәсәлән, Якшиван авылы «башкорты» үтенечендә: «Мин Уфада елына бер сусардан торган дәфтәр ясагы түләдем», дип яза *(БДУДА, 1173 ф., 1 тасв., 1198 сакл. бер., 3 б.)*. Монда дәфтәр сүзенең татар телендәге кебек яңгырау авазга башлануына да игътибар итәсе килә. Башкорт Умряс Ишеев елына 4 сусардан торган типтәр ясагы түләгән *(док. 1700 елгы; Материалы..., ч. 1: 100—102 б.)*. 1693 елгы документта Табын волосте башкортларының ясагы да «окладной тептярской ясак» (окладка тиеш типтәр ясагы) дип атала *(БДУДА, 1173 ф., 1 тасв., 1152 сакл. бер., 38 б.)*. Уфа өязе Казан даругасы Котый авылы ясаклы татарлары, башкорт Сартыбуч Төмәнчурин үлгәч, 1701 елда шуның окладына тиеш булган типтәр ясагына язылалар *(Шунда ук, 1329 сакл. бер., 3—4 б. б.)*. Казан даругасы Каршы волосте мишәре Абдрахман (аның атасы 23 ел элек Сембер өязеннән килгән булган) 1721 елда, мин патшага башкортлар белән бергә типтәр ясагы түләдем, дип яза *(БДУДА, 248., 3 тасв., 115 китап, 775 б.; Материалы..., I ч., 292 б.)*. **Безнеңчә китерелгән фактларда типтәр ясагы төгъбире кенәгәгә язылган ясакны белдерә, типтәр сүзе фарсы теленнән кергән дәфтәр сүзенә барып тоташа.** Ул борынгы төрки ядкаре «Котадгу белек»тә дә булган инде. С. Е. Малов аны тәптәр — тетрадь, рукопись, дип тәрҗемә иткән. Танылган галим В. В. Бартольд *(Сочинения, т. 1., М., 1963, 457 б.)* әйтүенчә, төрекләрдә, монголларда бу сүз «исемлек, канун, кагыйдә» мәгънәләрендә булган. Уйгырларда тәбтәр сүзе салым түләүчеләрнең исемлеген, хөкем карарларын яза торган дәфтәрне белдергән (**Р. Г. Ахметьянов.** *Сравнительное исследование татарского и чувашского языков. М., 1978. 135; 136 б.б.)*. Ә югарыда китерелгән документларда исемлек буенча, ясак кенәгәләре буенча алына торган ясакны белдерә. Әйтеп үткәнебезчә, ул ясак Башкортстандагы вотчиналыларга — «башкорт»ка әйләнгән җирбиләүчеләргә салынган.

XVIII гасырның кырыгынчы елларыннан башлап урыс хөкүмәте Башкортстанны ныклап сәяси-икътисадый үзләштерү эшләрен җәелдереп җибәрә: Оренбург экспедициясен оештыра, Ор елгасы буйлап саклану сызыклары төзи башлый, Оренбург шәһәренә нигез сала һәм шулай итеп Русия империясенең көньяк-көнчыгыштагы яңа чикләрен ныгыта. Урал буеның табигый байлыкларын барлап заводлар төзү, җирләрен урыс дворяннарына һәм офицерларына бирү, крайдагы халыкны, салым түләрлек катламнарны ныклап ачыклау башлана. Шушы максатлардан чыгып, 1734 елның 31 мартында Сенатның фәрманы игълан ителә. Анда: «...Кемнәр кайдан килгән, күптән килгәннәрме һәм аларга җан башыннан түләнә торган салым (ул подушный оклад дип аталган һәм 1720 еллардан гамәлгә кертелгән — Д. Р.» салынганмы, барысын да сорашып, белешеп язып алырга), диелгән була (Полное собрание законов, IX т., 337—338 б.).

XVIII гасырның кырыгынчы елларында шунда яшәгән һәм эшләгән тылмач А. И. Тәфкилев, Оренбург экспедициясе башлыгы И. К. Кириллов җирле халык арасында белешеп, сорашып чыкканнан соң, Сенатка хәбәрләмә төзиләр. Анда Башкортстан халкының түбәндәге разрядлары күрсәтелә: башкортлар, тарханнар, ялгызаклар, типтәрләр, йомышлы татарлар, туснаклар һ. б.

И. К. Кирилловның Сенатка язган хәбәрләмәсендә кайбер фактлар игътибарга лаек. Аның белдерүенчә, вотчиналы өчен казнага ясак түләү шарты белән утырган припущенниклар үзләрен чын башкортлар дип күрсәтәләр, ләкин кайбер волостьларда аларны аерып чыгаралар, шулар типтәр кенәгәсе дигән исемлеккә теркәлеп, типтәр дип йөртелә башлый. Безнеңчә, бу аерым чыгаруның сәбәбе килгән кешеләрнең бик күбәеп, вотчиналыларның җирләре кысыла башлавында. Шулай ук кайбер тагын башка сәбәпләр дә булырга мөмкин. Ләкин күчеп килеп вотчиналы булып киткәннәрнең бер өлеше генә аерып чыгарылган, ахры. Һәрхәлдә, килгән кешеләрне сорашып язарга дигән фәрман бирелгәч, әлеге припущенникларның бер өлеше урыс администрациясенә билгеле була. Патша хөкүмәтенең салым түләүчеләргә һаман ныграк мохтаҗлануы, крайда планлаштырылган яңа чараларны эшкә ашырырга көчләрнең кирәклеге дә һәртөрле салым түләүчеләр төркемен тизрәк күбәйтүне кайгыртуга китерә.

Кыскасы, типтәрләр типтәр дигән аерым катлам буларак нәкъ менә шушы 1734 елгы указдан соң тарихи мәйданга килеп чыга. Аларны аерым төр эшләрдә файдалана башлыйлар. Мәсәлән, Оренбург шәһәрен төзүдә *(А. И. Добросмыслов, 63—78 б. б.)*, тоз ташуда *(Материалы... IV кис., 398 б.)*, Табын шәһәрен торгызуда *(Материалы..., V кис., 685 б.)* һ. б. Аерым, махсус типтәр кенәгәсе булдырыла һәм типтәрләр үзләренә бер разряд буларак исәпләнеп йөртелә башлыйлар. 1736 елгы фәрманнан соң, хөкүмәт рөхсәте һәм контроле белән килгән татарлар башка исемнәр белән аталып йөртелә башлыйлар һәм шунлыктан типтәрләр категориясенә яңа килүчеләр кушылып китә алмый. Нәтиҗәдә,

мөстәкыйль, башка разряд крестьяннардан сословие буларак аерымланган типтәрләр дигән катлам барлыкка килә. Бу катлам башта типтәрләр ялгызаклар дип аталып йөртелә, тора-бара типтәр сүзе генә кулланыла башлый. Димәк, типтәрләр Казан ягыннан күчеп барып, Башкортстанда 1736 елгы фәрманга хәтле урнашып җирле булып өлгергән, 1734 елда типтәр кенәгәсенә язылган крестьяннар. Чыганаклардан күренгәнчә, типтәрләрнең формалашуында иң хәлиткеч дәвер, Казан ханлыгы җимерелгәч, Идел буе халыкларының күчеп килүе белән бәйле. Бу хәрәкәттә төп рольне татарлар уйнаган, чөнки алар сан ягыннан зур күпчелекне тәшкил иткән, җир эшкәртүче татарлар тормыш-көнкүреш дәрәҗәсе ягыннан да өстенрәк торганнар. Татар-типтәрләрнең бабалары кайчандыр казан татарлары булганлыгы турында сөйли торган документларны архивларда бик күп укырга туры килде. Мәсәлән, Бөре өязе Сунлар волосте Хәлил авылы вотчиналылары 1784 елны шул тирәдәге Рякай авылы ясаклы татарларын вотчиналарына кертә, ә 1804—1828 елгы документларда бу татарлар типтәр катламында йөртелә *(БДУДА, 1324 ф., 1 тасв., 4152 сакл. бер., 80 б.)*. Себер даругасы Кирунлар волосте вотчиналылары 1738 елда җирләрнең бер өлешен 20 тиен оброкка Якшы авылы ясаклы татарларына бирәләр. Бу авыл элек тә шушы ук вотчиналылар биргән припуск язуы буенча утырган булган. 1817 елгы документларда инде Якшы авылы типтәрләре турында сүз бара *(Шунда ук, 4160 сакл. бер., 3—8 б.б.)*. 1739 елда төзелгән припуск язуында Шәрәй авылы халкы (бәлки, бер өлешедер) ясаклы татарлар дип, ә генераль межалау делоларында «типтәрләр» дип аталган *(Шунда ук, 258 сакл. бер., 15 б.)*. Сунлар волосте Юныс авылы типтәрләре генераль межалау вакытында биргән үтенечләрендә, безнең авыл борынгы бабабыз ясаклы татар Юныс Досмаметевка вотчиналы-башкортлар тарафыннан 1714 елда бирелгән припуск язуы нигезендә утырган, дип язалар *(Шунда ук, 4152 сакл. бер., 150 б.)*. Сахай авылы кешеләренең бабалары ялгызаклар булган, аларны Бишаултабын вотчиналылары заманында үз җирләренә керткән, ә 1791 елда алар типтәрләр дип аталган *(Шунда ук, 270 сакл. бер., 7—8 бб.)*. Илморза авылына 1691 елда татарлар тарафыннан нигез салына. Межалау канцеляриясе документларында бу авыл кешеләре ясаклы татарлар дип, XIX гасыр башындагы ревизия материалларында типтәрләр дип аталган *(Шунда ук, 288 сакл. бер., 360 б.)*.

Типтәр катламына XVIII гасырның кырыгынчы елларына кадәр татарлар һаман килеп өстәлә торган. 1736 һәм 1747 елгы указлар нигезендә типтәрләр ялгызаклар белән берлектә башкортларга оброк түләүдән азат ителә, җирләрендә мәңгегә калдырыла һәм җан башына елына 80 тиенлек типтәр ясагы түләргә тиеш була.

**Типтәр категориясе дә, иҗтимагый-икътисадый күренеш төсендә даими хәрәкәттә була, үсеш-үзгәреш кичерә. Берьяктан, бу катламга яңа кешеләр кушыла торса, икенче яктан, типтәрләр үзләре дә өстенлеклерәк булган һәм ясакны әзрәк түләгән башкорт катламына күчә, барган.** Мәсәлән, 1849 елны, типтәр полклары гамәлдән чыгарылганнан соң, аларның бер өлеше башкорт катламына кушып исәпләнеп китә. 10 ревизия (1859 ел) материалларында унҗиденче кантоннан (Алабуга өязе) 3010 ир «типтәрдән булган, башкортлар» дип аталган (димәк, Минзәлә «башкортларының» тамырында кемнәр ятканын әле ачыкларга кирәк). Оса өязеннән (Беренче кантон) 22 җан типтәр башкорт ведомоствосына күчерелгән. Оса өязе Танып волостеннан (хәзерге Пермь өлкәсе Барда районы) 442 җан шулай ук башкорт катламына язылган. Кызылуфа өязеннән 1506 ир җан шулай ук «типтәрдән булган башкортлар» дип аталганнар (**Любавский М. К.** *Вотчинники-башкиры и их припущенники в XVII, XVIII вв.— В. И. Ленин исемендәге дәүләт китапханәсенең кульязмалар бүлеге, 364 ф., 2 тасв., 6 карточка, I очерк, 33 б.)*.

Типтәрләрнең милекләре буенча бертигез булмавы турында мәгълүматлар әдәбиятта да, архив чыганакларында да күп теркәлгән. Алар арасында ясаклылар да, вотчиналылар да булган. Мәсәлән, Бәләбәй өязе Базгыя волосте Атнагол авылы типтәрләр җирендә барлыкка килгән, ул җир аларның бабаларына бирелгән булган, анда 92 җан вотчиналы типтәрләр яши. Алар, башкорт-вотчиналылар шикелле үк, читтән 40 җан припущенниклар керткән *(Башкортстан ҮДА, 138 ф., 2 тасв., 147 сакл. бер., 187 б.)*. Е. С. Филимонов та, кайбер типтәрләр ил каршында күрсәткән хезмәтләре өчен урыс хөкүмәтеннән җирләрен вотчина хокукында идарә итү өчен грамоталар алганнар, дип яза *(54 б.)*. XIX гасыр ахырына типтәрләр типтәрләр-вотчиналылар, типтәрләр-припущенниклар дигән төрләргә бүленгән *(Шунда ук)*. Р. Г. Кузеев типтәрләрнең байлары да, ярлылары да булуын, кайбер типтәрләрнең, җирләрен күбәйтеп, башкорт булып та китүләре хакында яза (**Кузеев Р. Г.** *Происхождение башкирского народа. М., 1974. 323 б.*).

Башкортстанда туып үскән телче галим Р. Г. Әхмәтҗанов, башкортларның ясагы җиңел булуын, кайбер очракларда аларның ясактан гомумән азат булуларын искәртә һәм типтәрләр еш кына төрле юллар белән «башкорт» булып китә торган булганнар, дип яза (**Ахметьянов Р. Г.** *Сравнительное..., 135 б.*).

Шулай итеп, ике гасыр чамасы чорда типтәрләр дип аталган игенче крестьяннар башка категорияләрдән аерып йөртелгәннәр, типтәр дигән тотрыклы төркем формалашкан. Ләкин бу төркем этник төркем түгел, бәлки социаль катлам. Бу түбәндәге фактта да ачык күренә: типтәр категориясенә кергән этник төркемнәр үзләренең элек-электән килә торган үз рухи материаль культураларын, көнкүреш үзенчәлекләрен, гореф-гадәт һәм йолаларын, туган телләрен саклап калган. Хәзерге көндә дә типтәр-татарлар, типтәр-удмуртлар, типтәр-чувашлар яшәп килә. Мәсәлән, типтәр-татарларның сөйләше татар әдәби теленә аеруча якын булуына барлык галимнәр дә игътибар итә. Шул ук вакытта, башкортлар белән дә бик озак вакытлар үзара бер-берсенә тәэсир итешеп яшәгәнгә күрә, аларның телендә башкорт теле белән уртак сүзләр дә бар. Тагын шуны күрсәтергә кирәк, типтәр-татарларның теле алар белән бергә аралашып яши торган казаннар, казан кешеләре, ясаклылар, башкортлар, яңа башкортлар дигән төркемнәрнең теле белән бертөсле.

## Башкортлар

**Ю**гарыда, Русия дәүләтенә кушылганның соңында, Башкортстан җирбиләүчеләренә вотчина хокукы бирелүе, вотчиналы һәм башкорт сүзләренең шушы чорда бәрабәр социаль атамалар булып китүе турында әйтеп уздык. Монда исә әйтелгәннәргә тагын бер якны өстәп күрсәтү кирәктер.

XVII гасырга караган архив документларында Көнбатыш Башкортстанның бөтен халкына карата башкорт атамасының ничек итеп әкренләп урнаша баруын күрсәтеп тора торган фактлар бар. Мәсәлән, XVII гасыр уртасында язылган бер грамотада Уфа өязе карин татарлары әле башкорт, әле ясаклы ялгызак, әле татар дип аталганнар, өстәвенә башкорт һәм ялгызак сүзләре бернинди аермасы булмаган, бәрабәр атамалар кебек кулланыла *(БДУДА, 1173 ф., 1 тасв., 271 сакл. бер.)*. Шул ук чорга караган икенче бер документта башкорт Янгильдик Тлявлиев, Исәнчура Истякаев вә башкалар, һәм ясаклы татар Миңлегоз Кулчимов, Тормогуз Истяковлар турында: «Башкирам и татарам Янгилдейко с товарищами и роду их, и племянникам», дип языла, аларның фамилияләре дә бер, вотчиналары да уртак *(Шунда ук, 50 сакл. бер., 1—2 б. б.)*. Күгәрчен (Нугай даругасы) авылы ясаклы татарлары безнең бабабыз Кырилан волосте башкорты булып исәпләнгән, 70 еллар чамасы элек монда күчкән (док. 1691 елга карый), дип язалар *(Шунда ук, 1095 сакл. бер., 2 б.)*. 1639 елга караган документта сүз «башкорт йөзбашы», «ясаклы башкортлар йөзбашы» Ишимбай Кулушевны яклау һәм саклау турында бара, ә документның азагында Ишимбай «ясаклы вогулятин» дип аталган *(Материалы..., I кисәк, 73 б.)*. 1662 елгы башкорт восстаниесенә катнашучы «Уфа татары Арслан-бәк» бер үк документта «иң билгеле башкортлар» арасында да саналган *(Шунда ук, 92—93 б.)*. Йомышлы морза Умряс Ишеев (док. 1700 елгы) әле башкорт, әле татар дип исемләнә *(Шунда ук, 100 б.)*. Себер даругасы Танып волосте Унлар авылы вотчиналыларының (док. 1830 елгы) бабалары шул ук документта башкорт татарлары дип аталганнар *(БДУДА, 1324 ф., I тасв., 4166 сакл. бер., 279 б.)*. 1679 елда үтенеч язган Байляр волосте (Казан даругасы) «башкортлары» арасында Арыч Туктамышев та бар. Шул ук документта ул чуваш дип тә аталган *(Шунда ук, 745 сакл. бер., 2—3 б. б.)*. XVII гасырның егерменче елларында башкорт үтенеченә беренчеләрдән кул куйган Дәмәй дә татар икән, крайдагы 1682, 1705 елгы баш күтәрүләрдә катнашкан *(Шунда ук, 248 ф., 3 тасв., 115 кит., 1196 б.)*. 1712 елгы документта Оса даругасы Ирәкте волосте Сарбаш авылы кешеләре Бекимбет һәм Сарыбаш (Башкортстандагы татар авылларының зур күпчелеге кеше исемнәреннән килеп чыккан) Акимбетевлар татар телендә сөйләшә торган башкортлар («башкирцы татарского языку») дип аталганнар. *(Материалы, III кисәк, 81 б.)*.

Шулай итеп, XVII гасыр урталарында катлам һәм бүленеш атамасы рәвешендә башкорт сүзе урнашып бетмәгән. Ул төрле милләт, төрле катлам (йомышлы морза!) кешеләренә карата кулланылган.

Башкорт тарихчыларының язуынча, Русия дәүләтенә кушылган чакта ук Башкортстан халкы төрле булган, төп халык исә башкортлардан һәм татарлар-

дан торган. Яңа шартларда, башкорт исеме астында вотчиналы булып киткән халык ясак түләү ягыннан отышлы хәлдә калган. Менә бу фактор Урал буена күчеп килүчеләрдә үзенчәлекле омтылыш барлыкка килүгә җитди сәбәпкә әйләнгән. Алар һәртөрле юллар белән вотчиналы, ягъни башкорт булып китәргә тырышалар. Һәм, документлар тарихи әдәбият күрсәтүенә караганда, алар максатларына ирешәләр дә. Башкортстанның Русиягә үзенчәлекле шартларда кушылуы, припускның югарыда күрсәтеп киткән формалары, патша хөкүмәтенең крайны тиз арада нык күзәтү астына алып житкерә алмавы. **Ике гасыр буе халык санының исәпкә алынмавы, крайда буш җирләрнең күплеге һәм, ниһаять, хөкүмәт органнарының күчеп килгәннәрне ясакка язарга тырышу сәясәте — барысы да күчеп килүчеләрнең, яңа җирләрдә урнашып кына калмыйча, иң югары катлам — башкорт-вотчинальлар арасына үтеп керә алуларына да мөмкинлекләр тудыра.** Бу турыда XVII гасырның икенче яртысына, XVIII гасырның беренче яртысына караган документлар ачык күрсәтә. Без аларның бер өлешен югарыда китердек инде. Бу документларда ялгызакларның, типтәрләрнең һ. б. башкортка күчүе күрсәтелгән иде. Бер төркем язмалар исә ясаклы татарларның да турыдан-туры башкортка күчү очраклары булу турында сөйли. Уфа өязе Казан даругасы Исенсубино ясаклы татарлар һәм аларның ясаксыз уллары 1693 елда Баляр волосте башкортлары белән бергә түләргә оклад ясагына языла *(БДУДА, 1173 ф., 1 тасв., 1152 сакл. бер., 27 б.)*. Енаберде һәм Камай авыллары татарларына 1688 елда оклад ясагы түләргә кушыла *(Шунда ук, 34 б.)*. Оса даругасы Зур Инәк авылы ясаклы татары Исәнбай Сәйдяковка абыйсы Яшбулды Сәйдяков түли торган оклад ясагына язылырга рөхсәт ителә *(Шунда ук, 1107 сакл. бер., 1692 ел)*.

Бернинди ясакта да тормаган татарларны да турыдан-туры оклад ясагына язу XVII гасыр ахырына бик хас күренеш. Мәсәлән, Зөя өязеннән килгән ясаксыз татарлар Нугай даругасы Колябай авылында 1694 елда оклад ясагына язылган *(Шунда ук, 1167 сакл. бер., 17, 20 битләр)*. Казан даругасы Кубады авылы ясаксыз татарлары да 1698 елда оклад ясагына язылган *(Шунда ук, 1167 сакл. бер., 17, 20 битләр)*. Казан даругасы Кубады авылы ясаксыз татарлары да 1698 елда «үзләренең туганнары белән бер ясакка» — оклад ясагына язылганнар *(Шунда ук, 1152 сакл. бер., 5, 7 б. б.)*. 1685 елда ясаксыз татар Туйбулат Урмасевка Илан волосте башкорты Сулеман Боянов белән бер ясак — оклад ясагы түләргә кушып грамота бирелә *(Шунда ук, 25 б.)*. Казан даругасы Шемшады волосте Янтуды авылы ясаксыз татарлары да 1694 елда вотчинальлар түли торган типтәр ясагына языла *(Шунда ук 1167 сакл. бер., 7—10 бб.)*. Шунысы кызык, бу документларның күпчелегендә: «Мондый хәлләр элек тә булган инде» («... И перед сего такие случаи бывали...»), дип тә күрсәтелеп барыла. Зөя өязеннән күчеп килгән Рысай һәм Әхмәт Чуденевлар, 1692 елгы документтан күренгәнчә, үлеп киткән башкорт (хәзерге Актаныш тирәсендә) биләмәсе өчен түләнә торган оклад ясагына язылалар *(Шунда ук, 1110 сакл. бер.)*. Ясаклы татар Габделлатыйп Сәгыйтов 1780 елда Борай авылы вотчиналары җиренә припуск язуы нигезендә кертелгән була, 1815 елда аның нәселе кешеләре 7 җанга җитә, ә 1832 елда «башкорт исеменә» күчерүне сорыйлар һәм: «Бер катламнан икенчегә күчерү хәзер гамәлдә булуы, аннан күпләрнең файдалануы безгә мәгълүм», дип язалар *(Башкортстан ҮДА, 2 ф., 1 тасв., 3071 сакл. бер., 1 б.)*. 1831 елда тугызынчы кантонга караган Зиянчура, Собханкул, Канчура авыллары вотчинальлары аларга килеп кушылган «Татардан башкорт булганнарның» (из татар башкирцов) һәртөрле кысуларына зарланалар *(Шунда ук, 2774 сакл. бер., 1 б.)*.

Китерелгән мисаллар XVII гасыр ахырына вотчиналы катламына күчүнең билгеле бер рәвештәге гадәткә әйләнгәнлеген күрсәтәләр. Килгән кешеләр (аларның кайберләре электән үк шунда яшәгән булырга мөмкин) төрле юллар белән, аеруча оклад ясагына язылу ысулы белән, вотчинальлар составына керә бара.

В. Филоненко үзенең хезмәтендә төрле даругаларның башкортлары килгән кешеләрнең аларның җирләрен тартып алулары турында язган бик күп үтенечләрне китерә һәм болай дип яза: **«Килгән кешеләр, бигрәк тә мөселманнар, вотчинальларга бирен дә түләмәскә, вотчиналы булып китәргә, башкорт исеменә керергә тырышалар» (Филоненко В.** *Башкиры. Уфа, 1915: 43—44 бб.)*. И. И. Кириллов 1735 елның гыйнварында Сенатка язган «Аңлашу»ында башкортлар, үзләренең ясагын күчерү өчен, килгән кешеләрне үз җирләренә җибәрәләр, ә хәзер инде аларны (ягъни припущенникларны — Д. Р.) чын башкортлар дип атаганнар һәм атыйлар *(Материалы..., т. III., 493 б.)* дип яза. Ә шул ук елның августында язган хәбәрләмәсендә мондый юллар бар: **«Башкортлар... Казан һәм бүтән өязләрдән качканнарны типтәр һәм ялгызак дип атап, биләмәләрендә урнашырга рөхсәт итәләр, аларның күпләрен башкорт исеменә язалар, ә воеводалар моңа**

**карышмый, юмалап яки ачуларын чыгарып, бөлдереп, шулар хисабына баерга тырышалар...»** *(БДУДА, 248 ф., 4 тасв., 109 кит., 602 б.).*

Күчеп килгән кешеләрнең башкорт исемен алулары XVIII гасыр башында ачык күренеп тора торган, хәтта, гадәти күренеш булган.

Башкорт исеменә күчү башкортларның санында да чагылмый калмаган, билгеле. Башкортлар, Русия дәүләтенә кушылганнан башлап XIX гасыр урталарында кантоннар бетерелгәнчегә кадәр, крайдагы ялгызаклар, типтәрләр, ясаклылар һәм башка налог түләүче катламнар белән чагыштырганда өстенрәк хокуклы булган. Нәтиҗәдә, алар катламы даими рәвештә читтән килүчеләр һәм түбәнрәк дәрәҗәдә торучылар исәбенә арта торган.

Р. Г. Кузеев, XIX гасырда килгән кешеләрнең башкортлар арасына үтеп керүе булган, дип язуы белән бик хаклы (**Кузеев Р. Г.** *Численность башкир..., 347—348 б. б.).* Чыннан да, XVIII гасыр ахырында, XIX гасыр башында кантоннар төзелеп, башкортлар Русия чикләрен сакларга йөрергә билгеләнгәч, бу катламга бик күпләп яңа кешеләр языла. Архив материаллары, китерелгән әдәбият бу үтеп керүнең XIX гасырда гына түгел, бәлки шактый элегрәк тә булуы турында сөйли. XVII гасыр ахырында — XVIII гасыр башында башкортлар тарафыннан язылган күпсанлы үтенечләр, шикаятьләр, хөкүмәт тарафыннан бирелгән грамоталар да башкорт катламына башка категория кешеләренең үтеп керүен ап-ачык раслый.

Монда тагын бер якка игътибар итми мөмкин түгел. Кайбер галимнәр башкортларның сан ягыннан табигый рәвештә арта баруы бозылмаган, ул һаман үсә барган, дип карый. Безгә калса, монда шулай ук башкортка күчүчеләрнең дә роле зур булган. Чөнки Башкортстанда 200 ел буе (1570—1770) бер-бер артлы күп төрле баш күтәрүләр булып тора, аларда башкортлар бик актив катнаша һәм бу чуалышлар вакытында күпләп кырыла, җәзалана.

Башкортларның саны үсүдә килгән кешеләрнең шушы катламга күчә баруының зур роле булуы турындагы фикерләрнең кайберләрен китерми мөмкин түгел, П. И. Рычков XVIII гасырда, башкортлар үз яннарына качып килүчеләрне кертеп аз гына вакыт эчендә шулкадәр көчәйделәр, дип яза (**П. И. Рычков.** *История Оренбургская (1730—1750). Оренбург, 1896, 4 б.*). Казан губернаторы А. П. Волынский «Русия империясендә башкорт мәсьәләсенең хәле турындагы язу»да (1730 ел) башкортларның саны туктаусыз күбәя бара һәм шул рәвешле үсә: **20 ел элек чын башкортларның саны 35 мең, иң күбендә 40 меңнән артмаса, быел күчеп килүчеләр белән инде 100 меңнән артып китте, «Казан, Сембер, Темников һәм андагы башка өязләрдән килгән татарларның яртыдан күбрәге башкортка күчтеләр, өстәвенә тагы башка урыс булмаган халыклар да, мордва, чуваш, мари, удмуртлар бөтен авыллары-авыллары белән ясаклы башкортка күчтеләр... инде хәзер күпсанлы урыслар да җан башына түләүдән башкорт исеменә күчте»** *(История Татарии..., 399 б.).*

Акай восстаниесе (1735—1741 еллар) турындагы кульязма документта казан чувашлары, чирмешләр, мордва һәм уржум халыклары кенәгәләрдә «башкорт» булып языла, башкорт арасында алар бик күп, ләкин алар үзләрен башкорт дип әйткәч, аларны танып булмый, дигән юллар бар *(История Татарии..., 402 б.).*

П. Д. Аксаков 1743 елда: Русиягә баш игәндә башкортлар күп түгел иде, ләкин Казан һәм башка өязләрдән, Идел аръягыннан, Касыймнан, Зөядән, Сембердән татарлар килгәч, шул хәтле күбәйделәр ки, 1735 елгы чуалышлардан күренгәнчә, аларның ирләр саны гына да 100 меңнән артып китте, дип яза *(Материалы..., ч. III, 526 б.).*

И. К. Кириллов (1735 елда) тагын да кызык нәтиҗәләр китерә: җирләр киң һәм күп булганга күрә, башкортлар янына ирекле яшәр өчен чиксез күп тау ягы татарлары, чирмешләр һ. б. килде, хәзер инде килгән кешеләр башкортлардан ике өлешкә артык (**Добросмыслов А. И.** *Башкирский бунт в 1735, 1736 и 1737 гг. Оренбург, 1900, 10 б.*).

Дөрес, югарыда китергән саннарны чынбарлыкка төгәл туры килә дип әйтеп булмый, билгеле. Ләкин алар татарларның, алар белән бергә башка халыкларның да күпләп башкортлар исеменә керүен чагылдыра торган ышандыргыч, дәлилле фактлар булып тора.

Икенчедән, документларда «чын башкортлар» дигән тәкъбирне куллану төрле төрдәге башкортлар барлыгы турында хәбәр итә: төп башкортлар һәм башкорт булып исәпләнә торган гына башкортлар («яңа башкортлар»?). Ни генә булган очракта да без бу фактлардан читкә китә алмыйбыз, ә бәлки аларны аңларга һәм аңлатырга тырышырга тиешбез. XVIII гасыр башындагы документларда яшәештә булган «прямые башкирцы», «природные башкирцы», «насто-

ящие башкирцы», «счисляющиеся башкирцами иноверцы», «неприродные башкирцы» дигән тәгъбирләрне чынбарлык үзе тудырган.

Күп кенә галимнәр дә үзләренең хезмәтләрендә килгән кешеләрнең башкорт исеменә язылып китүләре турында кабат-кабат күрсәтеп узалар (В. М. Черемшанский, В. Филоненко, Н. В. Никольский, Р. Г. Игнатьев, М. Кармин, С. И. Руденко, М. К. Любавский һ. б.). **И. И. Неплюев «башкортлар» дигән сүз Башкортстан дигән административ атамадан чыккан, ул гомумән Башкортстан халкын, мишәрләрдән, вотяклардан, мордва, чирмеш һәм чувашлардан торган халыкны белдерә,** дип санаган *(Материалы..., т. I, 105 б.; т II, 81 б. һ. б. ш.)*. В. Н. Витебский, җир өчен түләүдән качып, бик күп типтәрләр, хәтта христиан типтәрләр дә мөселман динен алып, күпме тыюга карамастан, башкорт булып атала башладылар, дип яза (**Витебский В. Н.** *И. И. Неплюев и Оренбургский край в прежнем его составе до 1758 г. Казан, 1897. 391 б.)*.

Р. Г. Кузеев әйткәнчә *(Происхождение..., 164 б.)*, башкорт исемен алу бигрәк тә теле, культурасы һәм дине уртак булган татарларга җиңелрәк булган. Мәсәлән, бөрҗән, тангаур, үсергәннәр составында татар, мишәр, казанлылар дигән 15 ләп аймак теркәлгән. Ә башка халыклардан булган кешеләр башкорт исеменә керү өчен мөселман динен кабул итә торган булганнар *(Шунда ук)*. Чыннан да, безнең тарафтан өйрәнелгән авылларның күпчелегендә удмурт нәселе, чуваш нәселе яки мари нәселе дип аталып йөртелә торган нәселләр бар.

Башкорт исеменә күчү очраклары патша хөкүмәте указларында да чагыла: «Килгән кешеләрнең... башкорт исеменә кергәннәре турында дәшми торырга кирәк» *(История Татарии..., 408 б.)*. Күрәсең, башта яңа җирләрнең тизрәк үзләштерүен күздә тотыпмы, хөкүмәт әлеге кешеләргә кагылмау ягында була. Ләкин аның сәясәте бик тиз үзгәрә. Икенче ревизия (1745 ел) вакытында ук хөкүмәт һәр катламны аерым-аерым исәпкә алырга, яңа килгәннәрне теркәп барырга тырыша.

Башкорт исеменә язу Оренбург тирәләрендә ныгытылган сызыклар төзү, кантоннар төзелеп башкортлар хәрби катламга әйләндерелгәч тә дәвам иткән. Мәсәлән, бишенче һәм алтынчы ревизия һ. б. материалларда төрле-төрле кешеләрне башкорт катламына язу турында мәгълүматлар бик күп теркәлгән *(Башкортстан УДА, 2 ф., I тасв., 561 сакл. бер., 1 б.; 2 тасв., 35 сакл. бер., 118 б., 172 ф., I тасв., 45 сакл. бер., 81 б.; 101 сакл. бер., 96 б. һ. б. ш.)*. Никольская дигән станицадагы татарлар бөтенесе башкортка күчереләләр *(Оренбург өлкә архивы, 98 ф., 2 оп., 25 сакл. бер, 142 б.)*. Уршакмин һәм Куркульмин волостьлары җирләренә урнашкан түбәндәге авыллардан Бәләбәй өязе типтәрләре башкорт гаскәрләренә күчереләләр: Югары Имай-Карамалы, Биктимер, Ташлы Шәрип, Дәүләкән, Япар һ. б. *(Башк. УДА, 172 ф., I оп., 98 сакл. бер., 96 б.)*. 1814 елны башкорт исеменә яңа күчеп килгән мишәрләр, ясаклы татарлар, мещаннар, Сәет бистәсе сәүдәгәрләре балалары, законсыз туганнар һ. б. языла; алар чыгышлары белән Буа, Курмыш, Карсун, Алабуга, Бәләбәй округларыннан була *(Шунда ук, 2 ф., II оп., 1116 сакл. бер., 5, 6 б.)*. Архив документлары башкорт катламының составы этник яктан гаҗәп чуар булуы турында сөйли. Мәсәлән, бу катламга казакълар да (109 ир кеше. *Шунда ук, 1246 сакл. бер., 28—62 бб.*), 1813 елда кундрау татарлары да язылган *(Оренб. өлкә архивы, 98 ф., 2 оп., 25 сакл. бер., 128—133 бб.)*.

Р. Г. Кузеев башкорт һәм типтәр этнонимнарының этник эчтәлеген билгеләве авыр икәнен яза. Аның фикеренчә, XVIII—XIX гасырларда ыру-кабиләләргә бүленеш булмаган, ә авыл общинасының нигезендә үзенең җирләре белән хуҗалык тормышы итүче авыл тора (**Кузеев Р. Г.** *Происхождение... 322 б.*). Аеруча Көнбатыш Башкортстанга карата бу бик дөрес сүзләр. Архив документлары исә анда мондый күренешнең иртәрәк башланганлыгын фараз итәргә мөмкинлек бирә. У. Х. Рәхматуллин XVIII гасырда башкорт булып исәпләнү өстенлеклерәк катлам составында булу белән бәрабәр дип яза; башкорт исемен алу игенчеләргә бик күп авыр салымнардан котылырга мөмкинлек биргән, дип күрсәтә (**Рахматуллин У. Х.** *Заселение Башкирии 30—90-е годы XVIII в. Кандидатлык дисс., М., 1975. 45 б.*).

1782, 1812 елларда төрле салым салынган катлам кешеләренең башкортка күчүен тыя торган фәрманнар чыгарыла. Шуннан соң, башкорт катламыннан очраклы рәвештә төшеп калган башкортлар да башкорт катламына кире кайтарылмый башлый *(Башкортстан УДА, 2 ф., 2 оп., 561 сакл. бер., 2 б. һ. б. ш.)*. Хөкүмәт өчен өстенлекле хокуклы катлам түгел, ә бәлки салым түли торган катламның күбәюе кирәгрәк була. XIX гасыр уртасында Русиянең чикләре тагын да көнчыгышка күчкәч, башкорт гаскәренең — кантоннарның кирәге бетә. Нәти-

җәдә, XIX гасырның урталарыннан җирләр башкорт-вотчиналыларга җан башына кырыгар, мишәрләргә, типтәрләргә җан башына утызар, төрле категория крестьяннарга җан башына унбишәр дисәтинә хисабыннан бүлеп бирелә. Күргәнебезчә, башкорт-вотчиналылар һаман да өстенлеклерәк булып кала килә. **Шуңа күрә, авылдагы халыкны башкорт дип, типтәр дип, «саклы» һ. б. төрле төркемнәргә бүлү Совет чорына кадәр тотрыклы рәвештә саклана. Бу бүленеш хәтта бер семья эчендә дә күзәтелә: еш кына туганнарның берсе башкорт, берсе татар булып исәпләнеп йөри. Әлбәттә, алар бертөсле тормыш-көнкүреш алып бара, бер үк телдә сөйләшә!**

Димәк, Башкортстан халкының этник составы, андагы татар телле башкортларның кем булуы турында фикер йөрткәндә бик күп факторларны истә тотарга кирәк. Башкортстандагы халыклар тарихы бик катлаулы һәм күп төрле чорларны кичерә, аларны мөмкин кадәр объектив өйрәнергә тырышырга кирәк һәм шул өйрәнүләр барышында югарыда күрсәтелгән үзенчәлекләр, һичшиксез, искә алынырга тиеш. Гомер-гомергә бергә үрелеп, бер казанда кайнаган ут күршеләр һаман шулай дуслыклы, ярдәмлекле булып калырлар дип ышанасы килә.



Флера Баязитова

# КЕРӘШЕН ТАТАРЛАРЫНЫҢ ТУЙ ЙОЛАЛАРЫ ҺӘМ ҖЫРЛАРЫ

***Керәшен татарларының туй йолалары һәм шигърияте бик күп борынгылык эзләрен саклап килә. Һәртөрле ышануларга, җырларга бай булган туй йолаларында халыкның күп еллар буе үстерелеп килгән катлаулы иҗаты, үзенчәлекле культура тарихы чагыла.***

Татар халкының башка этник төркемнәрендәге кебек үк, керәшен татарларында, егет белән кыз танышып-йөрешеп үзара килешсәләр дә, егет ягы димче җибәреп, түбәнчелек белән кызны сората. Димче кеше кыз йортына: «Утырган урыным мендәрле, аяк астым бүкәнле»,— дигән сүзләр белән килеп керә. Кызның ата-анасы димчене олылап, хөрмәт белән каршы алалар, мендәргә утыртып кунак итәләр. Сөйләшү-килешүләрдән соң **аклашу** була: кызның үзе сугып әзерләгән чиккән сөлгесен (керәшеннәр аны **бистәр** дип әйтә) яки ашъяулыгын егет ягына биреп җибәрәләр, ул **ак бирү** дип атала. Егет ягы кызга шулай ук нинди дә булса бүләк бирә, ягъни **ак алыштыру** була. Аклашканнан соң кыз ярәшелгән исәпләнә, бүтән кешегә кияүгә китә алмый, шулай ук егет тә бүтән кешегә өйләнергә тиеш түгел. **Ак бирү, аклашуга** халык бик житди караган, әгәр ак биреп, ягъни вәгъдә бүләге биреп тә кыз башка кияүгә чыга икән, аның вәгъдә бүләге белән төрле бозымнар эшләп була, аларның киләчәк тормышы уңышлы булмый, дип ышанганнар. Кызның акка салган әйберсен туй мәҗлесендә кунакларга күрсәтү гадәте дә булган. Ул — **ак чыгару** дип әйтелә. Мәсәлән, Чистай төбәге керәшеннәрендә туйда жиңгә тиешле хатын-кыз килейнең чигеп эшләгән сөлгесен яки ашъяулыгын зур подноска куеп, кунаклар алдына болай дип жырлап чыгара:

Агы килә, агы килә,
Ак артыннан тагы килә.
Алтмыш агасы, житмеш жиңгәсе,
Тулмаганын тутырыгыз,
Җитмәгәнен житкерегез,
Шалтыратып салыгыз,
Җалтыратып алыгыз.

Шушы сүзләрдән соң, мәҗлестәге кунаклар, килениең яшьлек, сафлык билгесе булган чиккән сөлгесен җәеп-җәеп карыйлар: һәркем мактау сүзләре әйтәәйтә, яшь киленне котлап, үзе алып килгән бүләкләрне подноска куя. Ул — **акны котлау** була.

Элек, дини йола буенча, егет белән кыз чиркәүдә никахлашырга тиеш булганнар, ул — **кәбен кою** дип атала. **Кәбен** сүзе бик борынгы заманнарда ук

фарсы теленнән кергән сүз, ул татар халкының борынгылыкны саклаган төркемнәрендә: нократ, пермь татарлары, мишәр һәм казан арты сөйләшләрендә дә кулланыла. Кәбен җою сүзе керәшен татарларының борынгы җырларында да еш очрый:

Җегет булсаң, бул җегет,
Көмеш койдыр каеш җөгәнгә.
Җегет гумерен зая үткәрмә,
Кәбен койдыр җаның сөйгәнгә.

Кәбен күлмәкләрен (туй күлмәген) киеп, матур итеп бизәлгән атларга утырып кәбен койдырып кайткач, егет белән кызны үз өйләренә түгел, ә **«кунак өе»** дип аталган, махсус әзерләнгән өйгә алып керәләр. Кызны, турыдан-туры кияү йортына алып кайтмыйча, башка өйгә кертеп тору бик борынгы йола, ул килен буласы кешегә чит гаиләгә керү алдыннан үзен әзерләргә, тәртипкә китерергә мөмкинлек бирә.

Кунак өе итеп, гадәттә, егет белән кызга кыяматлык булган кешенең өе билгеләнә. Кыяматлыкка кияү ягыннан туган тиешлерәк хатын-кыз һәм аның ире сайлап алына. **Кыяматлык** (гарәп теленнән кергән кыямәт сүзеннән ясалган), исеменнән үк күренгәнчә, бу гаиләнең никахына кыямәт көненә (ягъни үлеп яңадан терелгәч) шаһит булып торырга тиеш дип исәпләнгән. Ул гомер буе бу ир белән хатынның иң ышанычлы дусы, киңәшчесе һәм таянычы булырга тиеш. Ир белән хатын, яки килен белән кайнана арасында низаглар килеп чыкса, кыяматлыкка серләрен сөйләгәннәр. Ул исә һәр ике якны да көйләргә, тынычландырырга, килештерергә омтылган. Кыяматлык итеп яшь кешеләр сайлап куелган очракта да кияү белән килен аларга **әнеки, әтеки** дип эндәшергә тиеш, ә кыяматлык үзе киленгә **кыяматлык кызым** дип эндәшкән:

Кыяматлык кызым, үз кызым,
Чәчләреңне тарап үр, кызым.
Ата-анаң йорты калды инде,
Күзләреңне ачып күр, кызым.

Кыяматлык булган кешеләргә кияү белән киленнең балалары әнеки **әби, әтеки бабай** дип зурлап эндәшкәннәр. Шунысы кызыклы, кыяматлык сүзе шул ук мәгънәдә башкорт телендә, **хайматлык** формасында чуваш телендә бар, ә мари телендә **кийамат ава** — кыяматлык әни, **кийамат ага** — кыяматлык әти мәгънәсендә кулланыла. Димәк, **кыяматлык** сүзе Идел буе халыкларының бик борынгы уртак йолаларын чагылдыра.

Туйда кыяматлык булган кешене шаяртып, аңа төрлечә җырлар җырлаганнар, кыяматлык та җавапсыз калмаган:

Алпан да тилпән йөрергә
Аю балаларына ла килешә.
Аяклар тибеп биергә
Кыяматлыкларга ла килешә.

Тау астыннан килгәнче,
Тау өстеннән килсәнче,
Кыяматлык булып килгәнче,
Мәләнчек[1] алдыңны жусанчы.

Шакыр гына шакыр саескан
Тәрәзә башларына ла җабышкан.
Кыяматлыклар ла булыр өчен
Өч көн карабодайлар чабышкан.

Кыяматлык җырлый:

Карабодайлар ла чабар ием,
Карабодайларыгыз атлыклы.
Җырлыйым әле мин җырларны,
Кыяматлыклар булу шатлыклы.

Аргы якта чеметем,
Бирге якта чеметем.
Бу кызларны алып киткәч,
Бүтән кызда өметем.

Кыяматлык итеп куелган хатын-кыз үзенең өендә (алда әйткәнебезчә, ул **«кунак өе»** дип атала) киленнең кәбеннән кайткан киемнәрен салдырып, йола буенча, яшь киленнәр киенергә тиешле махсус әзерләнеп куелган киемнәрен киендерә, киленнең чәчен тарап, толымнарын икегә аерып үрә һәм баш тирәли чолгап куя. Кызлар кия торган баш киемнәрен салдырып, яшь киленнәр кия торганын кигертү **баш бәйләү** дип әйтелә. Кыяматлык әни яшь киленнең башына **мәләнчек,** ике як чигәсенә тәңкәләр тезеп эшләнгән **чигәчә** киертә, аның өстеннән түгәрәк яулык бөркәндерә. **Түгәрәк яулык** дип аталса да, бу баш киеме дүрт

[1] Мәләнчек — башны кысып бәйләп куела торган, чепчик сыман баш киеме.

почмаклы, калын материягә чигеп, кырыйлары чачаклап эшләнгән була. **Баш бәйләү** дип аталган шушы җаваплы эшне башкарганнан соң, яшь килен өстенә шакмаклап сугылган материядән тегелгән бөркәнчек бөркәндерәләр.

Имәннәр сайгак имерек,
Юкәләр сайгак җимерек.
Атлар җигеп, бөркәнчек салып,
Кыз алырга килдек җилдереп.

Кара сыерларның каймагын
Каерып алырларга без килдек.

Әнекәсеннән бәбекәсен
Аерып алырларга без килдек.

Биек икән тавыгыз,
Каршы ява карыгыз.
Яшь киленне китерәбез,
Каршы чыгып алыгыз.

Туй мәҗлесе егет өендә, барлык туганнар, якын кардәш-ырулар, дусларын чакырып, тантаналы төстә үткәрелә. Килен төшерү туй мәҗлесе көнне яки алданрак та булырга мөмкин. Туй атлары капкадан кергән чагында өч мәртәбә мылтык атып җибәрү, килен арбадан яки чанадан төшкәндә учлап-учлап колмак сибү гадәтләре әле соңгы елларда да күзәтелә торган була. Яшь килен капкадан кереп, ишегалдына аяк басуга, абзардан бер сарык яки тай житәкләп чыгып, киленнең янына китерәләр: ***«Таян, килен, бу сиңа таянчык булыр»,*** — диләр. Килен аны кулы белән сыйпап ала һәм кияүнең әти-әнисе каршына килеп баш ия: «Рәхмәт сезгә бианам, рәхмәт биатам». Шуннан соң «таянчык»ны абзарга кертеп ябалар.

Килен төшергәннән соң кияү йортына кызның ата-анасы килә. Монда һәр туй өчен хас булган сөйләшү булып ала:

— Без тана җуйып килгәнийек, сезгә кермәдеме ул?

— Бездә бар барын да, тамгасы билгеле түгел, мөгезлеме сезнең?

— Юк, мөгезле түгел ие.

— Бездә мөгезле тана (яшь киленнәр кия торган баш киемнәрен кигәч, мөгез сыман тора, янәсе).

Ишегалдындагы кода-кодачалар «патир сорап», ягъни мәҗлестә урын сорап шаян җырлар башлыйлар:

Сары майлар каптым күберәк,
Ак майлар да каптым әзерәк.
Кодачалый булып килгән ием,
Урын бирмәссезме әзерәк?

Челтерәп үк аккан ай чишмәләрдән
Аткынаем эчми лә, нишләйем?

Кодачалый булып килгән ием,
Урыннар бирмәгәч, нишләем?

Түрдә бистәрләрем лә ай чүпләмле,
Чөйдә бистәрләрем лә чигүле.
Урын бирмәсәгез, без китәбез,
Безнең атларыбыз җигүле.

— Урын бирәбез, түрдән узыгыз, хуш киләсез, кодалар!

Эзәйнең буйлары иләр туера,
Җапыраккай җаргач куера.
Чишенегез инде, әй кодачалар,
Хуҗаиннары шулай боера.

Кодалар, кунаклар җыелып өстәл янына утырышкач, киленнең әти-әниләре кызларын күрсәтүне сорап җыр әйтәләр:

Биеккәй тауларның башында
Җәш үләннәр җата җәшәреп.
Безнең бәбекәйләр сезләрнең кулда,
Кайда тотасыз аны җәшереп?

Бөркәнчек бөркәнгән, мәләнчек, чигәчәләр кигән, түгәрәк яулык ябынган яшь киленне кунаклар алдына, табын янына чыгаралар, шул вакытта **бөркәнчек ачу** йоласы башлана. Яшь киленнең бөркәнчеген, гадәттә, кияүнең энесе (жанагай) уклау белән килеп, әкрен генә күтәреп ача, җөгән чылтырата. Бөркәнчек ачкан өчен килен аңарга янчык яки кульяулыгы бүләк итә.

Туй вакытында шулай ук **аргыш** булган кешенең роле турында да әйтеп китәргә кирәк. Туйда кияү белән киленнең бер ягында кыяматлык булган кешеләр утырса, икенче ягында аргыш утыра. Аргыш сүзе Казан арты, Чистай керәшеннәрендә **туй башлыгы,** олы дәрәҗәле кешене белдерә, ә Алабуга, Зәй тирәсе керәшеннәрендә **кияү егете** мәгънәсендә кулланыла. Бу сүз пермь, себер татарларында һәм кайбер төрки телләрдә (мәсәлән, алтай телләрендә) дә бар. Аргышка туй вакытында шаян җырлар җырлыйлар:

Биек тауның башларында
Өлгерә микән сабан ашлыгы?
Сиңа жырламыйча кемгә жырлыйм,
Син бит бу туйларның башлыгы.

Ай-һай, ашык син, ашык син,
Ашый гына торган кашык син.
Ашый гына торган кашык син,
Шушы туйларга да башлык син.

Чистай керәшеннәрендә аргышка туйда каз турау кебек җаваплы эшләр дә тапшырылган, шул вакытта ул үзе дә шаян җырлар җырлый:

Мин пычаклар кайрый алмыйм,
Әти чалгы да кайрый.
Каз канатларына берләр кош кунган —
Бирнә булмас микән, дип сайрый.

Аңа, бүләк итеп, яулык яки янчык бирәләр.
Туйда килennең алып килгән әйберләрен, **өшәнчеген элү, өй бизәү, бүләкләрен өләшү башлана,** ул шулай ук җырлар белән үрелеп бара:

Мылтыгымны алып кырга чыктым
Ак та куяннарны атарга.
Рөхсәт итәрсезме, кодаларым,
Сандык ачып товар сатарга?

Бадияннар салдым миннәр батмаска,
Кәләмперләр салдым акмаска.
Бу да әйберләрне без элеп куйдык
Берсесе дә әйләнеп кайтмаска.

Киленнең әйберләрен элеп куйгач, **«бирнә ябу»,** ягъни бием, биатага, кияүнең туганнарына (җанагай — энесе, биагай — абыйсы, печкәчә — сеңлесе) бүләк өләшенә, шулай ук аргышка, кыяматлыкка да бүләк бирелә. Кайбер очракта **бирнә** (бүләк) өләшкәндә «онытылып» калган кунаклар тарафыннан үпкә белдереп җырлау да була:

Минем туннарым кутиклы,
Нигә җырлыйм икән бу тикле?
Асыл күлмәгеме киеп туйга килдем,
Нигә хурладыгыз бу тикле?

Туйга килгәндә кода-кодагыйлар **савым,** ягъни күчтәнәчләр белән киләләр. **Савым** — борынгы төрки сүз, туй күчтәнәчләре мәгънәсендә урта диалектның күпчелек сөйләшләрендә билгеле. Туй вакытында кода күчтәнәчләрен табынга чыгару үзенчәлекле шаян җырлар белән бара, **ул кода ипие чыгару** дип атала. Билгеле булганча, туйда ике гаилә арасында икмәк алмашу, туй өстәленә бөтен түгәрәк икмәк кую һ. б. халыкта бик киң таралган борынгы йолалардан санала, «бер өстәлдән ипи ашау» ике гаиләнең үзара якынлыгын ныгыта, дип ышанганнар.

Суның буйларына төшеп
Агым суда атны сугарам.
Кодаларның талчыкканын белеп
Кода ипиләрен чыгарам.

Сары сандугачның балалары
Басып сайрый, диләр, таякка.

Ипиегез килә бу якка
Басыгыз, кодалар, аякка.

Безнең урам буйларыннан
Ак калпаккай кигән кыз килә.
Басыгыз, кодаларым, аякка,
Ипекәйләр белән тоз килә.

Кунак кодалар үзләре алып килгән күчтәнәчләрне хуҗалар табынга чыгаргач, болай җырлыйлар:

Карурманга кергән чакта
Куак сындырып алдым таякка.
Үз ипекәебез килгән чакта
Басып торабыз аякка.

Сезнең янга килгән чакта
Су буенда үсә тал чыбык.

Үз ипекәебезне күтәбез
Тал чыбыклар кебек талчыгып.

Таллардан талларга жефәк элдем
Тарта гына тарта ялыктым.
Үз ипекәебез килми торгач,
Көтә генә көтә зарыктым.

Күчтәнәч чыгарган өчен нинди дә булса бүләк («ачкыч») сорыйлар:

Әтекәем куйган кибәнгә
Бармы менәрләргә баскычың?
Үз ипекәебез килде инде,
Бармы ачарларга ачкычың?

Җавап итеп җырлыйлар:

Әтекәем куйган кибәнгә
Бардыр менәргә баскычым.
Ачаемнар дисәм бар ачкычым,
Жук бит җабарларга җапкычың.

Күчтәнәчләрнең өстенә матурлап чигелгән яулык яки тастымал ябып чыгарырга тиеш булалар, ул **җапкыч** дип атала.

Татар халкының башка төркемнәрендәге кебек, яшь киленгә **су юлы күрсәтү** туйның традицион йоласы булып тора. Кияүнең сеңлесе (керәшеннәрдә ул печкәчә, печкәчәм дип йөртелә) яшь киленне чишмәгә суга алып төшә. Килен алып кайткан суны **«килен ширбәте сонабыз»**, дип табында кунакларга тараталар. Бу вакытта яшь килен **«баш орыш»**, ягъни түбәнчелек белән баш иеп кенә тора. «Баш ору» сүзе шул ук мәгънәдә башка төрки халыкларда, мәсәлән, комыкларда бар.

Кайбер авылларда туй көннәрендә кияү белән киленне уртага алып, яшьләр урамда күңел ачып йөргәннәр. Бу — **мәрәкә** йөрү дип атала. **Мәрәкә** сүзе Башкортстандагы татар сөйләшләрендә, Оренбур өлкәсенең мишәр сөйләшләрендә һәм нагайбәк керәшеннәре сөйләшләрендә, шулай ук башка төрки телләр, әзербайҗан, каракалпак, башкорт, төрек, чуваш телләрендә дә бар. Туйда табын янында да, мәрәкә йөргәндә дә егет белән кызны мактап җырлаулар дәвам итә.

Минем алҗапкычым — и җарма бүз,
Синең сөйгәннәрең — кара күз,
Кара да күзләрең үз җаныңда,
Инде әйтешмәгез авыр сүз.

Безнең авылның җегетләре
Биек итеп сала өйләрен.
Җегетенә ошап кызы туган —
Тибрәндереп сөйли сүзләрен.

Безнең авыл җегетенең
Ак укадан үргән камчысы.
Җегетенә ошап кызы туган —
Алтыннардан тамган тамчысы.

Туйда кара-каршы җырлана торган җырларда һәр ике як кодаларының бер-берсен олылау, зурлау, туганлашуга, якынлашуга омтылу, бер-берсенә теләге, үтенече, шулай ук бу гаиләдә каласы кызларына үгет-нәсихәтләре, киңәшләр чагыла:

Иртә торып битләр сөртергә
Чөйдәге бистәрләрең ак булсын.
Төнге җокыларың татлы булсын.
Иртәнге җокыларың сак булсын.

Табаккай-табаккай ак борчак,
Түкми-чәчми ашагыз.
Кызыбызны сезгә бирәбез,
Какмый-сукмый асрагыз.

Су, ди, жулларыгыз киртә булса,
Ак каеннан киртә тотарбыз.
Кызыгыз өчен борчылмагыз,
Үзегездән иркә тотарбыз.

Бусагагыз бадиян агачы,
Кемнәр әйтер аны тимер дип.
Сагынган чакта җибәрегез,
Әнекәсе көтәр, килер дип.

Муйнымдагы мунҗакымның
Җиде бөтен икән тәңкәсе.
Мин балакаемны сиңа бирдем,
Син булырсың инде әнкәсе.

Быел, ди, эрләгән җепләремне
Чорнап кына куйдым йомгакка.
Кызыбыз кала дип елашмагыз,
Кызыгыз керде безнең җомакка.

Айлар үлдинде, үлдинде,
Туасы айларыбыз тулдинде,
Сез кодалар белән бер күрешкәч,
Безнең күңелләребез булдинде...

Туй мәҗлесе ахырына якынлашып килгәндә **«кодалар озату»** йоласы шаян җырлар белән бара. Чистай керәшеннәрендә, мәсәлән, кодаларны озату көнендә аргыш булган кеше ипи яки көлчә пешереп табынга чыгарырга тиеш.

Сары сандугачның баласы
Сайрый-сайрый җырләргә төшәме?
Безгә китәр вакытлар житә,
Аргыш көлчәләрегез пешәме?

Көлчә пешеп чыккач, аргыш кеше көлчәне ипи көрәгенә бәйли дә кодаларны көш-көш дип куалый, өч тапкыр өстәл тирәсендә әйләнеп шаян җырлар җырлап йөри. Кыяматлык булган кеше көлчәне тотып карый да: «Юк әле, көлчә пешеп җитмәгән, утырыгыз, кунаклар», — ди.

Шыңгыр-шыңгыр килә дугалар,
Әллә китәләр дәме кодалар?
Китмәсләр ие кодалар,
Көш-көш диеб үк куалар.

Кара тавыккаем ындырчы,
Аяккаен бөреп сындырчы.
Җырласы жыруым бик күп калды,
Тагы бер генә кич кундырчы.

Ары да оча бытбылдык,
Бире дә оча бытбылдык,
Инде лә шөкер бер ходайга,
Шушы кодалардан да котылдык...

Борынгыдан калган йола буенча, кияүгә китәсе кыз туй вакытында елап җырларга тиеш булган. Үзе теләмәгән кешегә бирелгән очракта ул үпкәләү, рәнҗү сүзләрен башлап әти-әнисенә җиткерә, туганнары, дуслары белән саубуллаша. Туган йортыннан аерылып чит-ят кешеләр арасында яшәүнең бөтен авырлыгын күз алдына китереп, мәҗбүри рәвештә китүенә ачынып, моңлы көй белән җырлый-җырлый елый торган булган. Керәшен татарлары яшәгән кайбер төбәкләрдә, мәсәлән, Чистай, Апас районы авылларында туйда кыз елату — «чеңләтү» йоласын һәм аңа караган җырларны әле хәзер дә яхшы хәтерләүчеләр, көйләре белән «чеңләп» күрсәтүчеләр бар. Мәсәлән, Апас районы Тәрбит авылында яшәүче туталы-сеңелле Шуркина Ирина Никитична (48 яшьтә), Васильевна Анна Никитична (50 яшьтә) безгә туйда кыз елау җырларын үзенчәлекле моңлы көй белән башкардылар. Бу як керәшеннәрендә ул җырлар «әтекәем елату» дип атала. Чөнки кияүгә китәсе кыз үзенең үпкәсен, моң-зарларын башлап әтиәнисенә белдергән. Инде күп кешеләр тарафыннан онытылып бара торган бу җырлар бүгенге көндә дә бик гыйбрәтле булып яңгырыйлар.

Туган гына әтәвем,
Туган гына әнәвем,
Җиде бала эчендә
Ят күренгән мин булдым.

Әнкәй, иртә торырсың,
Битләреңне юарсың,
Битләреңне юарсың,
Кызым юк, дип еларсың.

Әнкәй, ашың пешкән булса,
Бик болгатып суытма,
Янда балалар бар диеп,
Читтәгесен онытма.

Башламам да дигән кибәнең
Башлыйсыңмы, әтекәй?
Ташламам да дигән бәбекәң
Ташлыйсыңмы, әтекәй?

Бөркәнчәгем күк нагыш,
Күчерәлмам мин ялгыз.
Эчем тулып житкәчтен,
Бушаталмам мин ялгыз.

Туган әтисе йортындагы тормыш һәм «җиде йат», ягъни чит семьядагы тормыш символик рәвештә берсенә-берсе капма-каршы куела.

Әткәемнең капкасы,
Капка төбендә бакчасы,
Бакчасында җиләклек —
Кергәндә дә өзәйдем,
Чыкканда да өзәйдем.

Җиде ятның капкасы,
Капка төбендә бакчасы,
Бакчасында еланлык —
Кергәндә дә чашкырыр
Чыкканда да чашкырыр...

Апас керәшеннәрендә туйда кыз кешенең баш киеме булган **кашбу** (таңкәләр тезеп эшләнгән баш киеме) салдырып, киленнәр баш киеме — **тастар,** сөлге сыман озын материя чорнала:

Ак юкагач суйдыгыз,
Кабыгын кая куйдыгыз?
Ап-ак тастар сардыгыз,
Яулыгым кая куйдыгыз?

Атка утырып йорттан чыгып китәргә җыенганда, капка ачкан чагында тагын җырлый:

И атым син, туратым,
Минем якшы күрәс булса,
Уң аягың алдан бас.
И атым син, туратым,
Минем кәйлек[1] күрәс булса,
Сул аягың алдан бас.

Шул сүзләрдән соң бөтен халык җыела, игътибар белән атны кайсы аягын алдан басар икән, дип карап тора. Уң аягын алдан басса — яхшыга, сул аягын алдан басса — начарга юрыйлар. Атлар белән кияү йортына барып төшкәч, килен болай дип җырлый:

Тиңдәш кенә алашам,
Мине тартып килгәндә,
Колмактан җиңел булдыммы?
Мине ташлап китәсең,
Таштан авыр булдыммы?

Ах, алашам, алашам,
Тартып килдең, тартып кит.
Таштан авыр мин булдым,
Колмактан җиңел син булдың.

[1] Кәйлек, кәй — начарлык, начар.

Зәй буе керәшеннәрендә, мәсәлән, Сәвәләй авылында туйда килен үзе чеңләмәсә дә, кыз елату җырларын җырлап кызны елатканнар:

И шаулыйлар нарат,
Шаулыйлар нарат,
Нигә шаулыйлар икәннәр бу нарат?
Шауламаслар иеләр бу нарат,
Аерылып кала ла бер канат.

Суларга ла төшсәң, син иртә төш.
Соңга калсаң, сулар да болгана.

Әнекәсеннән дә аерылганда
Кызлар түгел, кошлар да моңлана.

Сары сандугачның балалары
Талларга басып ла ял итә.
Кыз балалар дигән мескен лә бала
Ятларга ялынып ла көн итә...

Тукай (элеккеге Чаллы) районы Мәләкәс, Пәнәче авылларында туйда кыз елатканда «Ил ташлап киткән кызлар җыры»н җырлыйлар:

Түгәрәккәй алан, киңнәр ялан,
Печәннәрс төшми ай шул яман,
Буйны үстерүләре берләр дә заман,
Ил ташлап китүләре ай бик яман.

Тарылар чәчтем мин тамырга,
Тамырыннан таныш ла алырга.
Сагынмыем түгел лә, бикләр сагынам,
Белгертмием үзем сабырга.

Аязлар да аяз, бигрәк аяз
Һавалардан очкан казларга.
Быел гына еллар бик ямансу
Илен ташлап киткән кызларга...

**Тәфкил Камал,**
философия фәннәре кандидаты

# РУХ

СӨЕКЛЕ ӘБИЕМ ФАКИЯ ФӘТХУЛЛА КЫЗЫ ИСТӘЛЕГЕНӘ

Рух, рухи эшчәнлек мәсьәләсе фикер ияләренең бер генә буынын борчымаган. Рух һәм аны аңлатуларның төрле юлларын эзләүнең зур тарихы бар. Традицион совет әдәбиятында исә рухка карата чикле һәм берьяклырак караш яшәп килде. Рух күбрәк матди дөньядан икенчел, аннан турыдан-туры килеп чыга торган нәрсә итеп каралды. Иҗтимагый аңның төрләре хакында күп кенә китаплар, мәкаләләр чыга торса да, рәсми пропаганда кешеләрнең идея инанганлыгы хакында күп сөйләсә дә, рухның асыл табигате мәсьәләсе һаман читтә кала килде. Табигать, материя — беренчел, аң, рух — икенчел, ә Алла — юк, дигән схемаларга гына корылган фәлсәфәдән башканы көтеп тә булмый иде.

Рухның үз табигате булуы, аның яшәештәге мөһим роле нәкъ менә шуннан килеп чыгуы фәлсәфә тарихында күптән танылган хакыйкатьләрдән санала. Мондый караш татар фәлсәфәсе тарихында да гәүдәләнә килде. Рухны коры схоластик бәхәсләр һәм фанатиклык сазлыгыннан алып чыгуда иң беренче адымнарны ясаучы, аны дин гыйлеменнән тыш итеп игълан итүгә нигез салучы Ш. Мәрҗани булды. Коръәннең 17:87 (КР.) аятенә нигезләнеп һәм гарәп-мөселман фәлсәфәсе, аерым алганда, әл-Газәли фикерләренә таянып, ул рухны кеше гакылыннан өстен һәм мәңгелек, шул ук вакытта Алланың затына да хас түгел, дип билгели.[1] XIX гасыр ахырында формалашкан җәдитчелек хәрәкәтенең күренекле эшлеклеләре Ш. Мәрҗанинең мирасын дәвам итүчеләр буларак фикер йөрттеләр. «Дин ислам каршында,— дип яза бу уңайдан Зыя Камали,— рух бөтенләй Аллаһыга башкадыр».[2] М. Биги, З. Кадыйри, Җ. Абызгилдин һ. б. фикер ияләре дә шундыйрак мәсләктә тордылар. Алар рухны кешегә гыйлем һәм мәгариф бирелүдән килеп чыга торган күренеш буларак бәялиләр. Муса Биги, мәсәлән, рухның табигате турындагы мәсьәләне И. Кант нигез салган яңа фәлсәфи башлангыч нигезендә хәл итүне мәгъкуль санавын белдерә. Ул аны тәҗрибә һәм акыл аркылы гына ирешеп була торган нәрсә итеп саный.[3]

Гомумән, нәрсә соң ул рух?

Билгеле булганча, бөтен әйләнә-тирә дөнья, анда баручы төрле процесслар, ягъни табигать, җәмгыять үсеше һ. б. бер-берсе белән бәйле рәвештә яшиләр. Болар барысы яшәешне, ягъни барлыкны хасил итәләр. Яшәеш — чиксез, мәңгелек һәм үлемсез. Аның эчендә туктаусыз хәрәкәт булып тора, мәңгелек космик процесслар, химик элементларның төрләнүе, туу һәм үлү, кеше тарафыннан матди һәм рухи байлыклар тудыру, төрле идеяләрнең калкып чыгуы һәм сүнә баруы, онытылуы һ. б. күзәтелә. Яшәеш, ягъни чынбарлык танып-беленә ала, һәрхәлдә, без аның бер өлешен билгели алабыз. Аерым әйбер яки кеше чынбарлыкны тәшкил иткән кебек, дөньяда рухилык та бар. Чынбарлык үз чиратында рухи, чөнки моны кешелекнең яшәеше раслап тора. Кеше тарафыннан үзгәртелә

---

[1] Мәрҗани Ш. Әл-Хикмәт әл-балига. Казан, 1888. 81-82 бб.
[2] Камали З. Фәлсәфәи исламия. I кисәк. Уфа, 1910. 313 б.
[3] Биги М. Гыйлем әхваль рух. «Шура», 1909, № 22. 691 б.

торган табигатьтә, ягъни җәмгыять өлкәсендә бер генә предмет яки процесс та идея һәм акыл катнашуыннан башка тудырыла алмый. Идея исә рухилыкның тышкы чагылышы булып, аның ярдәмендә рухның барлыгы тәэмин ителә. Бу җәһәттән күренекле испан философы Хосе Ортега-и-Гассетның фикере кызыклы: «Кеше дөньяны гуманлаштыра, ул үзен аңа күчерә, идеальның үзгәрмәс асылын сеңдерә, һәм кайчан да булса, ерак киләчәктә бу тышкы мәхшәр дөньясы кеше белән шулкадәр туенган булыр ки, без хәзер эчке дөньябызда фикер йөрткән кебек, бездән соң киләсе буыннар анда йөри алыр, дөнья, үз-үзе булудан туктамыйча, нинди дер матдиләшкән җанга әверелер...», дип фараз итәргә мөмкин»,[1] ди философ. Гамәлдә бу көрәзәлек чынлап та тормышка ашармы, юкмы — монысын әйтүе кыен. Ләкин Х. Ортега-и-Гассетның хаклыгы шунда: кеше үзенең рухын идеягә таянып саклый, һәм бу аның киләчәген тәэмин итүче булып чыга.

Рух, саклануга, мәңгелеккә һәм чиксезлеккә омтылыш буларак, чынбарлыкның мөһим өлешен тәшкил итә. Аның тамырлары исә табигатькә барып тоташа. Ләкин рухның табигать белән бәйләнеше каршылыклы һәм шактый үзенчәлекле. Һегельнең фикеренчә, рух табигатьне инкяр итеп, аның хакыйкатен ачуда ята; бу процесста табигать үзе юкка чыгып, рух идея булып мәйданга килә. Ул рухны үзенең гәүдәләнешенә кадәр үк тудырылган нәрсә түгел, ә бәлки тән белән эчке бер бәйләнеш хисабына яши торган күренеш итеп тасвирлый.[2] Дөрес, Һегель тән белән рух берлеген аларның «төшенчә»дә берлегенә нисби итә, монда аның фәлсәфи системасының үзенчәлеге сизелә. Һәм, гомумән, тән белән рух мөнәсәбәтен ничек күзаллаудан төрле фәлсәфи алымнарның табигате ачык күренә.

Рух һәм тән, идея һәм матди җирлек берлеге юнәлешендә фикер йөртү, кайвакыт рухны кеше тормышында хисси күренеш буларак кына бәяләүгә дә этәрә. Аерым алганда, нигезләре белән З. Фрейдка барып тоташучы экзистенциаль фәлсәфә тарафдарлары үзеннән-үзе шул якка авыша. Ләкин, мондый карашның файдалы яклары булуга карамастан, аңа чикләнгәнлек, ягъни рухны аның бер гәүдәләнеше төре белән тәңгәлләштерү хас булып тора.

Рух үзе күпъяклы күренеш һәм аның бу үзенчәлеге татар фәлсәфәсе өчен яңалык та түгел. З. Кадыйри: «Рух куәтләре өчдер. Тәфкир (фикер), хис вә ирадәдер (эстәү, ихтияр)[3]», — дип яза. Рухның хисси нигезе булса да, асылда ул гакыли булып кала. Әле б. э. кадәр V—VI гасыр элек яшәгән Һераклит: «Кешенең табигате акыллы була алмый, ә илаһилыкныкы — була ала»,[4] — дип язган. Ягъни борынгы грек философы, үз күзлегеннән карап, акылның чиксезлеккә, мәңгелеккә, илаһилыкка илтүен ачыклаган булган.

Әмма рухның эчтәлеге акыл белән генә дә чикләнми, чөнки аның яшәештәге урынын билгеләүдә ихтыяр да катнаша. Ихтыяр — рух мөнәсәбәтләрендә ихтыярны алга чыгаруны А. Шопенгауэр һәм Ф. Ницше башлангыч биргән фәлсәфи сызыкта очратабыз. Барлыкка килүе ягыннан ихтыярны чикләү рәвешендә пәйда булган рухның үзен аның көченнән башка күз алдына китерүе дә кыен. Ихтыярны билгеләү рух эчтәлегендә мөһим роль уйный һәм бу аның асыл табигатендә чагылмый кала алмый.

Рухның төп үзенчәлекләреннән берсе булып аның хәяте матдә яки әйбер хәлендә генә түгел, хәтта процесс яки вакыйга хәлендә дә була алмавы тора. Рух һәрвакыт теге яки бу процессларга һәм матди җирлеккә үрелгән хәлдә, аның бер ягы буларак кына яши. Бу үзенчәлек рухның асыл табигатенә ачкыч хезмәтен башкара. Рух — һәрнәрсәнең бәйсез яшәешкә сәләте ул. Һегель үзенең «Рух фәлсәфәсе» дигән әсәрендә: «Рухның асылы — азатлык ул, ягъни үз-үзенә гайрәдән бәйсез булган мөнәсәбәте», — дип билгели. Ләкин шул ук вакытта рух башка яшәешкә хас үзенчәлекләрдән тыш яши алмый. Шуна күрә бөек философ бик хаклы рәвештә: «Рухның азатлыгы... башкадан бәйсезлектә генә булмыйча, ул башкадан качу аркылы түгел, ә аны җиңеп чыгу аша барлыкка китерелә,»[5] — дип саный. Рухның мондый үзенчәлеген, аның казаныш булуын һәм башка нәрсә аша барлыкка килүен бүтән кайбер фикер ияләре дә басым ясап әйтә.

Бу сызыкта рухның күптөрле күренешләр һәм процессларны җыю сәләте тагын да ачыклана төшә. Нәкъ рух аркасында, мәсәлән, мәдәниятнең бөтенлеге тәэмин ителә дә инде. Чыннан да, идеаль асылның төрле тарафларын тәшкил

---

[1] Ортега-и-Гассет Х. Углубление в себя и обращенность вовне. «Философские науки», 1991, № 5. 164—165 бб.

[2] Карагыз: Гегель Г. Энциклопедия философских наук. Ч. III. Философия духа. М., 1956. 28—32 бб.

[3] Кадыйри З. Куәт һәм рух. Уфа, 1910. 32 б.

[4] Фрагменты ранних греческих философов. Т. I. М., 1989. 241 б.

[5] Гегель Г. Күрсәтелгән әсәре. 41 б.

итеп, җәмгыятьтә фән, дин, әхлак, сәнгать һ. б. яшәеш төрләре рухның һәммә якларын чагылдыручы булып дөньяга килүләрен күрү кыен түгел. Аннан тыш, рухи мәдәниятнең бу өлешләре бер-берсеннән шактый ясалма рәвештә аерылуы хакында фикер йөртергә мөмкин. Матди җирлек белән бәйләнешләрендә һәм кеше тормышында уйнаган рольләре буенча алар төрләнсәләр дә, үзләренең килеп чыгышы, күп гомуми яклары белән бер-берсенә тартылып торалар.

Кешелек мәдәнияте үзенең башлангыч чорында тармакланмаган хәлдә булуы бәхәссез кабул ителә. Ә инде билгеле бер тарихи дәвердә аның төрләре аерымлануы үсешнең үзенә хас бер дәрәҗәсен чагылдыра. Бу гаять мөһим процесс рухи эшчәнлекнең бүленүе шартларында аны биләү буенча аерым бер иҗтимагый төркемнәрнең үз мәнфәгатьләре өчен көрәшеннән дә азат була алмаган. Мәсәлән, тарихта бик еш кына дин белән фән арасындагы көрәшнең мисалы итеп чиркәү инквизициясенең галимнәрне эзәрлекләү, аларны хакыйкатьләреннән ваз кичтерү, хәтта физик юк итү очракларын да күрсәтәләр. Дин, фән һәм сәнгать һ. б. үсешенең билгеле бер баскычында күзәтелгән каршылыкларны мотлак итеп күрсәтү нәтиҗәсендә, әйтик, диннең фән белән бөтенләй капма-каршы юнәлештә булуын исбатларга тырышу әле хәзер дә күзәтелә. Бу каршылыкларның төп нигезе иҗтимагый көчләрнең тәэсире аркасында тууы игътибардан читтә кала.

Хәлбуки мәдәниятнең бөтенлеге һәм бер рухи нигезгә корылган булуы җәмгыять үсешенең тәҗрибәсе белән раслана. Бу уңайдан инглиз философы А. Уайтхед китергән мисал гыйбрәтле. Үз вакытында мәшһүр галим-астроном Г. Галилей Җир — хәрәкәттә, ә Кояш тик тора, дип исбатлаган. Инквизиция исә моңа катгый рәвештә Җир — тикторыш хәлендә, ә Кояш аның тирәсендә хәрәкәт итә, дип раслый, һәм галимгә үлем җәзасы белән яный.[1] И. Ньютон идеяләре нигезендә эшләүче астрономнар исә соңыннан Кояш та, Җир дә — хәрәкәт хәлендә, дигән фикергә киләләр. Хәзер, билгеле булганча, тикторыш һәм хәрәкәтне аңлатудагы нинди концепциягә иярүгә бәйле рәвештә бу өч карашның да дөрес булуы ачылды.[2] Хәер, хәзерге заман дин әһелләре тарафыннан да фән казанышлары тулысы белән танылып килә. Охшаш рәвештә билгеле бер дәвердә ислам дине тарафыннан сәнгатьнең кайбер төрләрен тыю, аңа иркенләп үсәргә ирек бирмәү күренешен дә аңлатып була. Ислам тарихының барлык чорларында да сәнгатькә мондый караш яшәмәгәнлеге билгеле. Ислам өйрәтүләре чынлыкта потка табынуны гына тыя. Үз чиратында сәнгать үсешенә ясалган кире йогынты бер төркем рухани катлавының рухи чикләнгәнлек күрсәтүе аркасында гына мөмкин булган. Моның дәлиле итеп җәдитчелек хәрәкәте тудырган яңарыш процессында бу каршылыкның тәмам хәл кылынуын, сәнгатьнең бөтен төрләренә юл ачылуын китерергә мөмкин.

Икенче яктан мәдәниятнең төрле өлкәләргә бүленүеннән соң да алар арасында даими йогынты сакланып калган. Әдәбият һәм фәлсәфә, дин һәм әхлак бәйләнешләре шундыйлардан. Шулай булмаса, мәдәниятнең төрле яклары арасында арадашчы булып та, мөстәкыйль үзлекләрен озак вакытлар саклаган дини фәлсәфә, яки дини сәнгать, йә булмаса, дидактик әдәбият кебек мәдәни катламнарның яшәвен ничек аңлатырга? Соң чиктә фән, сәнгать, дин, әхлак кебек рухи байлыкларның үсеше үзеннән-үзе яңа баскычта бер-берсе белән бәйләнешләр эзләүгә этәрә һәм бу очракта да берләшүнең рухи ягы ачыклана төшә.

Мәдәниятнең яңа бөтенлегенә ирешү һәрбер рухи эшчәнлек төренең үз табигатеннән һәм үсешенең төп юнәлешеннән килеп чыга. Бу рухи бөтенлекнең өске, асыл ягын тәшкил итә. Моны дин мисалында күзәтеп карыйк. Борынгы община җәмгыятендә дини культ эшчәнлеге матди житештерү һәм иҗтимагый тормышка үрелеп алып барыла. Этнографлар күзәтүенчә, шул чор дәрәҗәсендә торучы Австралиянең җирле халкында да бу нәкъ шулай сакланган. Ләкин тора-бара дини эшләр белән шөгыльләнүче аерым төркемнәр формалаша башлый. Шулар составыннан башта жрецлар төркеме (Борынгы Греция) яки дини каста (Борынгы Һиндстан) аерылып чыга. Ләкин алар әле дәүләт аппаратының бер өлеше буларак яши. Урта гасырларда дин әһелләре аерым оешмалар төзи һәм алар ярдәмендә дин кагыйдәләрен саклауны тәэмин итә. II—V гасырларда Рим империясендә барлыкка килгән христиан чиркәве шундый оешма буларак төзелә. Чиркәү иҗтимагый система буларак ике өлештән тора: берсе дини мәгълүмат

---

[1] Г. Галилейга үлем җәзасы куллануга мөнәсәбәттә хәзерге фәндә башка төрле караш та бар.

[2] Уайтхед А. Н. Религия и наука. «Заблуждающийся разум?: Многообразие вненаучного знания». М., 1990. 448 б.

тарату, дин кагыйдәләренең үтәлешен тикшерү белән шөгыльләнсә, икенчесе дингә ышанучыларның киң катлавын тәшкил итә. Әлбәттә, бу ике өлеш арасында аермалык һәм каршылыклар бар, ләкин алар вульгар социологик әдәбият сурәтләвенчә, мотлак түгелләр. Әгәр мәсьәләгә җитдирәк караш ташласак, бу ике өлешнең аерылгысыз булуын һәм бер-берсе өчен яшәвен күрергә мөмкин. Чөнки дингә ышанучыларның һәрвакыт йола ягыннан гына түгел, рухи яктан да берләшү өчен ихтыяҗлары булса, чиркәү шулай ук дини халыктан башка яши алмас иде. Монда чиркәү һәм дин тарафдарларының дини рух аркасында берләшүе һәм моның теләсә нинди дини мөнәсәбәт һәм эшчәнлек өчен дә үзенчәлекле булуы ачык сиземләнә. Шунысы да бар, әгәр югарыда әйтелгән үзенчәлек аркасында дини рух христианлыкта читләшкән рәвештә яшәсә, ислам динендә исә иҗтимагый институт һәм мөселманнар арасында рәсми бүленеш юк. Ислам гамәлендә дини культ, аң һәм инану , шулай ук дин әһелләре һәм барлык мөселманнар тигез итеп таныла.

Индустриаль җәмгыятьтә чиркәүнең һәм диннең дәүләттән аерылуы нәтиҗәсендә дин әһелләре үзләренең күп кенә иҗтимагый өстенлекләрен югалта. Байтак илләрдә сәяси һәм идеологик төрлелек, вөҗдан иреге өчен хәрәкәтләр киң җәелә. Христианлык үзгәртеп коруы нәтиҗәсендә туган протестантлык кеше һәм илаһият арасында нинди дә булса оешманың булуын күздә тотмый инде. Ислам үзгәртеп коруының җимеше буларак килеп чыккан җәдитчелектә кешенең рухи эшчәнлеген азат итү дин әһеленең хакимлеген түгел, ә дини рухның тантанасын максат итеп куя. Шул рәвешле дин кысаларында кешеләрнең рухи берләшүенә нигез салына. Бу диннең үз асылына кире кайтуы, дөньяны рухи үзләштерүдә яңа адым атлавы итеп каралырга тиеш. Фән-техника казанышлары чәчәк аткан җәмгыятьтә диннең лаеклы урыны булуы шуның белән аңлатыла.

Дини рухның күтәрелүе әхлакның төрле сыйныф һәм милләтләрнең аны үз мәнфәгатьләренә яраштырырга тырышуларының нигезе какшау белән бергә бара. Дөрес, бу әхлакның үз табигатенә ярашлы процесс буларак яши. Билгеле ки, тарихи яктан әхлак хосусый милек һәм дәүләт килеп чыгу нәтиҗәсендә кешеләрнең бер-берсеннән читләшүенә җавап йөзеннән, кешелек ыругының асылын саклауга омтылыш аркасында барлыкка килә. Әхлакый идеянең төбендә кешелек дөньясының берләшү зарурлыгы ята. Бүгенге көндә өскә калкып чыккан гомумкешелек кыйммәтләренең өстенлеге мәсьәләсе дә шуның, ягъни әхлакый чагылышы рәвешендә танылырга хаклы. Ләкин әхлакның иҗтимагый ягы да бар, шуңа күрә югарыда сурәтләнгән процесс тарихи үсешенең югары дәрәҗәсен, иҗтимагый институтларның камилләшүен таләп итә. Мәсәлән, теге яки бу милләтнең яшәеше өчен иң кирәкле шартлар да тудырылмаган бер очракта, аның хәтта алдынгы вәкилләренең дә гомумкешелек кыйммәтләрен алга куюы шактый шөбһәле мәсьәләгә карый.

Бу нисбәттә рухның хисси ягынарак авышкан милли сәнгатьнең үсеше аерым бер үзенчәлекләргә ия. Ул милләтчелек идеясен алга чыгаручы бер өлеш булып гәүдәләнә. Шулай да аның яңарышы, Г. Ибраһимов әйтмешли, «сәнгать — яңа заманның дине» булып әверелү әхлакый идеянең алга барышына иярергә тиешлегенә бәйләнгән.

Шул рәвешчә, бер яктан, хәзерге заман мәдәниятенең берлеге аның рух тарафыннан «өретелүенә» таянса, икенче яктан, төрле мәдәни эшчәнлек өлкәләрендә җәелгән бердәм хәрәкәт аны яңа рухи эчтәлек белән баетуга сәбәпче була.

# БЕР СҮЗ ТАРИХЫННАН

Гап-гади бер татар сүзенең килеп чыгышы, аның җанлы телдә гадәттән тыш тиз үзләшеп һәм табигыйләшеп китүе, тамыр җәюе, хәтта, өр-яңа үсенте-тармаклар җибәрүе турында сөйләргә ниятем.

**«Эшкәртү»** сүзе ул. Без «тире-күн эшкәртү», «беренчел йон эшкәртү фабрикасы», «туфрак эшкәртү кораллары» дип сөйлибез һәм язабыз һәм бу сүзтезмәләр һәркемгә аңлаешлы. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге» «эшкәртү» сүзенең төп биш мәгънәсен ачып бирә:

1) хәзерләү процессында нинди дә булса төскә, тиешле формага кертү, әйбер итеп ясау;

2) чәчү, утырту өчен хәзерләү (сөрү, тырмалау, культивацияләү);

3) киләчәктә куллана, файдалана алырлык хәлгә китерү, нәрсәне дә булса тәгәлләү;

4) кемгә дә булса басым ясап, орышып-тәнкыйтьләп, берәр эшкә мәҗбүр итү;

5) кыйнау, тукмау.

Сүзнең һәр мәгънәсен һәм мәгънә төсмерләрен дәлилләү өчен китерелгән мисаллар Ш. Мөдәррис, К. Нәҗми, Р. Ишморат, Г. Әпсәләмов, М. Җәлил, Б. Рәхмәт кебек әдипләр иҗатыннан алынган.

Телебездә менә шушылай актив кулланылышта йөргән «чеп-чи татарча» сүзнең әле пенсия яшенә дә җитмәгән булуына күбәүләр, бигрәк тә яшьләр ышанып бетми.

Ерактан башлыйк. Менә И. Гигановның 1804 елда Санкт-Петербургта басылган «Словарь российско-татарский» сүзлеге. Монда урысча якта «обработка», «обработать», «переработать» кебек сүзләр теркәлмәгән. Шуңа күрә бу иң элгәрге һәм абруйлы сүзлектә «эш» тамырыннан ясалган сүзләр арасында «эшкәртү» сүзен, әлбәттә, таба алмаячакбыз.

Казан семинариясендә татар теле укытучысы булып эшләгән А. Троянский тарафыннан төзелеп, 1833—1835 елларда Казанда ике томда нәшер ителгән «Словарь татарского языка и некоторых употребительных в нем речений арабских и персидских» сүзлегенә мөрәҗәгать итик. Без анда «эшләмәк», «эшләмәклек», «эшләү», «эшләүчән», «эш итмәк», «эшләтмәк», «эшләтмәклек», «эшләтү», «эшле», «эшләнмәк» сүзләрен генә табабыз. Ягъни А. Троянский сүзлеге дә «эшкәртү» дигән сүзне, гомумән, белми әле.

Каюм Насыйриның 1904 елда Казанда нәшер ителгән (беренче басмасы 1892 елда чыга) «Полный русско-татарский словарь, с дополнениями из иностранных слов, употребляемых в русском языке как научные термины» сүзлегендә «обработанный» — мәгъмүр, абад (җир)», «обрабатывать — иген икмәк, ашламак» сүзләре теркәлгән. Күрәбез, К. Насыйри бүгенге «эшкәртү» сүзенең мәгънәсен фарсы сүзләре белән аңлатырга мәҗбүр булган.

Үзебезнең дәвергә якынрак торган чыганакны актарыйк. Менә С. Рахманкулов һәм Г. Кәрам төзегән «Русча-татарча мөкәммәл сүзлек» (1921). Бу сүзлектә «обработка — эшләү, эшләнү, игү; обрабатывать, обработать — эшләмәк, эшләп эшкә кертмәк, зирагать итмәк (соңгысы игенчелек мәгънәсендә), обрабатывать землю — иген икмәк, обрабатываться — эшләнмәк» дип бирелә.

Игътибар итик, бу сүзлек беренче тапкыр буларак «эшкә кертү (кертмәк)» сүзен тәкъдим итә һәм, гомумән, ул үз элгәрләреннән бер баскыч югары тора торган белешмә санала.

XX гасыр башларында урысча фән һәм техника атамалары инде камилләшкән, әйтик, «обработка» сүзенең бүгенге төп мәгънәләре дә ныклап урнашып, карарлашып өлгергән була. Татарча атамалар исә яралгы хәлендә генә булып, терминнар, гадәттә, гарәби, фарсы яки интернациональ алынмалар рәвешендә яшәп килә. Ул вакытларда татар теленең ни дәрәҗәдә ирексезләнгән, чүпләнгән булуы тел белеме һәм

логика атамаларында аеруча ачык чагыла.

Егерменче елларда татар телен гамәлгә кую бурычы алга сөрелеп, күпсанлы киңәшмә-конференцияләр уздырыла, тиешле карарлар кабул ителә, татарча мәктәп дәреслекләре, төрле фән өлкәләренә караган урысча-татарча терминологик сүзлекләр, инструкцияләр типография ысулы белән дә, гектографта да бастырып чыгарыла һәм таратыла.

Әлеге «обработка», «переработка» төшенчәләрен татарчага тәрҗемә итү мәсьәләсе бу елларда ничегрәк тора соң? Алга китеш, тәрәккыят бармы?

Кулыбызда — «Новый русско-татарский словарь» (1929). Монда, «обрабатывать», «обработать» фигыльләреннән башка, «обрабатывающая промышленность» атамасы да теркәлгән. Беренчеләре «эшләп чыгару», «рәтләп эшләү», «эшләп эшкә кертү» дип тәрҗемә кылына, техник термин исә «эшләп чыгару сәнәгате» дип бирелә, ягъни без монда төшенчәне саф татарча тәрҗемә итәргә омтылыш күрәбез. Ләкин төшенчә үзенең татарча тәңгәлен әле һаман таба алмый, аның татарчасы бик якынча мәгънәгә генә ия һәм ул фәнни-техник әдәбиятта куллану өчен яраксыз. Әлбәттә, шул чордагы популяр мәкаләләрне һәм вак брошюраларны бусы да канәгатьләндергән.

Г. Алпаровның «Татар теленең имля сүзлеге» (Казан, 1927) «эш» тамыры кергән байтак сүзләрне туплаган. Без биредә «эшче-крестьян», «эшчән», «эшхәб» (эшче хәбәрче), «эшсезлек», «эшфак» (эшчеләр факультеты) һ. б. сүзләрне табабыз. Ләкин күренекле тел галименә «эшкәртү» сүзе мәгълүм түгел, чөнки ул сүз «дөньяга килмәгән, тумаган» әле.

Яки менә 1931 елны икенче басма булып чыккан «Татарча-урысча сүзлек» (Төзүчеләре проф. М. Корбангалиев, Р. Газизов, И. Кулиев; беренче басмасы 1927 елда нәшер ителә). Аның фәнни яктан эшләнеше, әлбәттә, күпкә яхшырак һәм ул шул чорның лексикасын тулы чагылдыра. Сүзлектә «эшләп чыгару — производство», «эшләп чыгарыш — производительность», «җир эшләү — обрабатывать землю» терминнары теркәлгән.

«Җир эшләү». Бусы инде җыйнаклык ягыннан атама булып житешкән дә кебек. Ләкин «эшләү» сүзе артык киң һәм күп мәгънәле булганга, терминология ихтыяҗын канәгатьләндерә алмый, чөнки «атама» сүзе үзе үк чикне белдерә, ягъни мәгънәне чикләүне күздә тота.

1938 елда Таттосиздат тарафыннан чыгарылган «Русча-татарча сүзлек»кә күз салыйк. (Мәгълүм ки, ул елны татар язуы әле урыс графикасына күчмәгән.) Сүзлекне төзүчеләрдән Г. Нугайбәк «обрабатывать, обработать» сүзен татарча «эшкә кертү (эшкәртү), эшләп чыгару; жиренә житкереп эшләү» дип тәкъдим итә. «Перерабатывать, переработать» фигылен карасак, шул ук төзүченең бу сүзне татарчага «эшкәртү» дип тәкъдим иткәнлеген күрәбез.

Шушы ук сүзлек ике елдан соң, беркадәр төзәтелеп һәм кириллицага күчерелеп, икенче тапкыр дөнья күрә. Әлеге сүзләр нәкъ беренче басмадагыча калганнар, ягъни «эшкәртү» сүзе әле һаман тулы хокукка ия булып житмичә, төзүчеләр һәм редакторлар нидәндер уңайсызланган, шикләнгән сыманрак, жәя эченә яшереп бирелә.

Әмма шушы ук чорга караган терминологик сүзлек алай консерватив түгел. 1939 елда дөнья күргән «Русча-татарча авыл хуҗалыгы терминнары сүзлеге «эшкәртү» сүзен тулысынча таный: «обработка — эшкәртү; обработка глубокая — тирән эшкәртү; жирне тирән итеп сөрү; обработка мелкая — сай эшкәртү; обработка поверхностная — өстән эшкәртү; обработка предпосевная — чәчү алдыннан эшкәртү». «Переработка» сүзе исә монда «янадан эшкәртү» дип бирелә. Сүзлектә «переработка молока — сөтне эшкәртү (сөттән сыр, май, простокваша һ. б. эшләп чыгару)». Бусы да бер адым алга китеш.

«Политик-экономик терминнар» сүзлеге (1941) «обрабатывающая промышленность — эшкәртү промышленносте» терминын канунлаштыра.

Моннан соң нәшер ителгән татарча-урысча һәм урысча-татарча, шул исәптән, терминологик сүзлекләр дә, «эшкәртү», «эшкәртелү» һ. б. кебек сүзләрне теркәргә онытмыйлар. «Эшкәртү» сүзе кергән кушма атамаларга, әйтик, «Русча-татарча авыл хуҗалыгы терминнары сүзлеге» (1971) аеруча бай.

Мәгълүм ки, бездә орфография сүзлекләре сирәк чыгарыла. Кириллицага күчкәч, мәсәлән, 1941 елда бик ашыгыч тестә (төзүчеләрдән берсенең сөйләвенә караганда, сүзлек төзергә өч-дүрт көн вакыт биргәннәр). «Татар әдәби теленең орфография сүзлеге» басыла. Беркадәр үзгәрешләр кертелеп, шул ук исем белән ул 1948 елда кабат нәшер ителә. Бу сүзлекләр «эшкәртү» сүзен әдәби телгә кертергә жөрьәт итмәгән. Хәлбуки, ул елларда инде вакытлы матбугатта, китап-брошюраларда һәм

радиода «эшкәртү» сүзе тәмам үзләшеп җиткән була. Бу сүзнең Муса Җәлил тарафыннан нәкъ менә «кульязманы әдәби (!) яктан эшкәртү» мәгънәсендә кулланылган булуын искә төшерик. «Эшкәртү» сүзе татар теленең орфография сүзлегенә беренче тапкыр 1983 елда гына теркәлә. Без анда «эшкәртелүчәнлек», «эшкәртелеш» сүзләрен дә таба алабыз.

Тел һәм борынгы әдәбият белгече Ф. Фасеевның «Татар телендә терминология» дигән китабында (1969) «эшкәртү» терминының, «тартылма сүз» булып, «эшкә кертү — эшкәртү» әвереләше нәтиҗәсендә барлыкка килүе һәм бу алымның терминологиядә аңлы рәвештә файдалануы әйтеп кителә. Дөрес! Өлкән яшьтәге белгечләрдән ишетүемчә, «эшкәртү» сүзен телгә кертеп җибәрү мәсьәләсе, утызынчы елларның икенче яртысында, редакцион киңәшмәдә, чыннар да, аңлы рәвештә, фикер алышу юлы белән хәл ителгән. Моны беренче булып кем тәкъдим иткәндер — бусы, гадәттәгечә, билгесез булып кала. Ләкин, минем фикеремчә, бу атама беренче чиратта авыл хуҗалыгы буенча китап-брошюраларда һәм мәкаләләрдә кулланыла башлагандыр, чөнки беренче ихтыяҗ шул өлкәдә («туфрак-җир эшкәртү») булган. Ихтимал, шул ук вакытта бу сүз мәшһүр Казан күнчеләре турында язучылар күңеленә хуш килгәндер («тире-күн эшкәртү»). Һәрхәлдә, төгәл мәгънәле атаманың таралып, табигыйләшеп китүенә аңа булган ихтыяҗ ярдәм иткән.

Мондый ихтыяҗ башка төрки телләрдә дә булган, әлбәттә. Мин шушы чорга караган кыргызча-урысча, урысча-казакъча, казакъча-урысча, урысча-каракалпакча, урысча-карачай-балкарча сүзлекләрне күздән үткәрдем, кырым татар теле, себер татар теле сүзлекчәләре дә, татар теленең диалектологик сүзлеге дә игътибардан читтә калмады. Нәтиҗәдә, мин бу елларда әле «обработка» терминының төгәл эквиваленты табылмаган булуына ышандым.

«Русча-төрекчә сүзлек»тә (Мәскәү, 1972) «обработка» термины, нигездә, «ишлеме», «ишлем» сүзләре аша бирелә. Төрек телендә бу сүзләрнең «возделывание», «вспашка» мәгънәләренә дә ия булуын «Төрекчә-русча сүзлек»тән (1977) күрәбез.

Җыеп кына әйтсәк, без төрки телләрнең күпчелегендә татар теле калыбында ясалган «эшкәртү» сүзен тапмыйбыз. Тугандаш башкорт теле исә татарча әзер атаманы, ягъни «эшкәртү» сүзен тулаем кабул иткән дә куйган.

1954 елгы «Русча-башкортча сүзлек»тә үк «обработать» сүзе «эшкә иңдерү», «эшкәртү, эшләү» дип тәкъдим ителә. Ләкин әле «Обработать землю — җирне эшләү». 1958 елгы «Башкортча-русча сүзлек» исә «эшкәртү» атамасының тәмам үзләшеп җиткәнлеген күрсәтә. Бирелә без «экспедиция материалларын эшкәртү» терминын, «җирне эшкәртү» (эшләү түгел!) кебек сүзләрне очратабыз. Шул рәвешле, татар телендә туган ясалма сүз башкорт теле өчен дә үз булып китә. Бу очракта, билгеле, Башкортстанда татарларның күп булуы, татарча газеталар чыгып килүе зур йогынты ясаган дип уйларга мөмкин. Хәер, ут күршеләренең шулай «лөгать алмашып» яшәве гаҗәпмени?

Менә без бер сүзнең бөтен тарихын, аның кызыклы биографиясен күздән кичердек. Бик гыйбрәтле тарих бу! Ул әдәби телгә катнашы булган һәрберебезне теге яки бу атама-төшенчәнең тәңгәлен беренче нәүбәттә ана теле хәзинәсеннән эзләргә, ана теле мөмкинлекләрен һәм чараларын эшкә җигәргә өйрәтә, шуңа өнди, моның нәтиҗәле алымнарын күрсәтә. Бу исә соңгы вакытларда киръксә-кирәкмәсә дә гарәп һәм фарсы сүзләрен «кыстырып» үтә ватанчы булып кыланган авторлар өчен дә, яңа төшенчәне белдергән сүзне, аны-моны уйлап тормастан, урыс һәм европа телләреннән күчереп кенә куючылар өчен дә файдалы булыр дип уйлыйм.

Сүземне шушында түгәрәкләп, нокта куярга да мөмкин булыр иде. Ләкин... Әйе, тагы бер нәрсә турында әйтмичә ярамастыр. 1991 елда без Гаяз Исхакый әсәрләрен уку бәхетенә ирештек. Аның «Зиндан» исемле җыентыгы — сайланма проза һәм сәхнә әсәрләре басылып чыкты. Укучыларның хәтеренә төшерәм: Исхакыйны Казан зинданыннан чыгарып, туган авылы Яуширмәгә озаталар. Авылына кайтып төшкәч, Гаяз янына бәләкәй кызын алып чыгалар. Гаяз моннан өч-дүрт ай гына элек хатыны белән аерылышкан була. Нарасый, бер дә ятсынмыйча, әтисе кулына килгәч, җыелган карчык-корчык: «Әй бала, атасын таный! Алла эшкәртә, әнисе генә бик кызганыч шул!..» — диешергә тотына.

«Алла эшкәртә» дигән сүзләргә игътибар итегез. Гаяз Исхакыйның «Зиндан» хикәясе, әдипнең үз кулы белән төзелгән библиографиясеннән күренгәнчә, 1906 елда Чистайда, хәбесханәдә язылып, 1907 елда Казанда басылып чыга. Ни дигән сүз була соң инде бу? «Эшкәртү» сүзе халык телендә 1906 елда ук гамәлдә йөргәнме әллә?

Ул чагында без телгә алган сүзлек һәм белешмәләр сукыр һәм чукрак булып чыгамы?

Кызганыч ки, күренекле әдипнең бу мәҗмугасында ялгыш киткән. Төп нөсхәдә, һичшиксез, «алла әскәртә» дип язылган булырга тиеш. «Әскәртә» сүзе исә «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»нә кергән. Аның мәгънәсе — белдерү, хәбәр итү. Китапны чыгару өчен җаваплы кешеләр татар теле этимологиясеннән азмы-күпме хәбәрдар булган булсалар, яисә, һич югында, колакларын «алла эшкәртә» дигән сүзләрнең дорфалыгы, урынсызлыгы, мәгънәсезлеге сагайткан булса, мондый анахронизмга юл куелмыйча калыр иде.

Соңгы вакытларда, иманыбыз яңаргачда, байтак кына иске һәм хаксызга онытылган китаплар кабаттан басыла, әмма шунысы аяныч, аларда хәреф хаталары тулып ята. «Коръән тәфсире», Арча типографиясендә «Ядкәр» исеменнән басылган «Сөен-бикә» китапларын имля шапшаклыгы ягыннан рекорд ияләре дип атап булыр иде. Сагынып, көтеп алынган китапларның дәрәҗәсен болай зәвыксызланып төшермик әле, әфәнде-иптәшләр, оят бит дип әйтәсе килә. Ләкин мин бу өндәвемнең теге мультфильмдагы инсафлы Леопольдның: «Җә инде, егетләр, әйдә, дус кына яшәек әле!» — дигән сүзләре кебек һавада эленеп калачагын да беләм-белүен.

Шушында нокта куярга ашыгам, югыйсә бүтән бер тема башланып китә.

**Адлер ТИМЕРГАЛИН.**

## Мөшәррәф Галиев

НӘНИ ШАЯРУЛАР

### Апас ягы

Апас ягы — тау ягы ул,
Тау өстендә урманнар.
Имәннәре җил-давылга
Бирешмичә торганнар.

Ир-егетләр имән кебек
Төптән үк таза монда.
Апаска мактау әйтелә
Һәр елның азагында.

Шуңа күрә шатлык белән
Аяк басам Апаска.
Инде мине иркәм көтә,
Сөялгән дә лапаска.

Сөялгән дә, күзен алмый
Каратун тарафыннан.
Үзем дә югалып калам
Сөйкемле карашыннан.

Менә шундый миһербанлы
Хатын-кызлар Апаста.
Алар белән танышулар
Ярап куя запаска...

### Аһ, бу нәфес дигәнең...

Хатын алдым Сабадан,
Авызы зур табадан.

Алып бактым Буадан,
Арт саны зур кунадан.

Алып бактым Балтачтан,
Үтерә язды ачтан.

Алганым Актаныштан
Бигрәк тә карышкан.

Алдым хәтта Әтнәдән.
Аердым бер атнадан.

Алып бактым Зәйдән дә.
Аерылмый чәйдән дә,
Аерылмый мәйдән дә...

Инде өмет — Әлмәттә.
Расхуты зур, әлбәттә.

Нияттә бар Туймазы,
Әле нәфес туймады...

## Рәфкать Кәрами

# КУЯН БУЛУ ҖИҢЕЛ ДИСЕҢМЕ...

Шулай да, җәмәгать, элек әле ничек тә очын-очка ялгый идең. Ә хәзер... мунча бәясе ун тапкыр артты, сыра — унбер ярым, тегесе... юк, юк, анысына якын да килерлек түгел минем тиеннәр белән. Ә «кабасы» килә. Бу кыен мәсьәләне ничегрәк чишәргә? Менә юлда экономить итеп булса гына инде. Бер ай бушлай йөрсәң, яртылык булмаса да, бер чөллилек янга калачак. Шәп идея бит бу! Һәм... бүгеннән шулай итәргә булдым да.

Мин үзем бәләкәй генә завод сымак бер әртилдә эшлим. Өйдән шактый ерак — ике транспорт белән барасы. Эше әллә ни түгел инде, шуңа күрә кыяфәт тә неважный. Май чүлмәге тышыннан билгеле, дигәндәй, кем икәнең әллә каян күренеп тора. Контролер бит ул кемнең кем икәнен бер карауда таный. Юньләп кырынмаган да булсаң... Кыскасы, ышаныч юк. Туктале, мин әйтәм, мунчага йөри торган иске портфельне булса да кулга тотыйм. Башка эшләпә дә кидем, муенга аллы-гөлле муенчак, ягъни, галстук астым.

Әнә, килә трамвай. Кердем солидный гына... арткы ишектән. Җыен яшь-җилкәнчәк арасында болай ярыйсы гына сурәттә басып торам. Бер кызый урын да бирде. Ары киттек. Туктадык. Әнә, имансыз арка желегем белән тоям: кереп килә контролер дигәнең.

— Талоннарыгызны әзерләгез! — ди бу.

Булмаган талонны ничек әзерлисең инде аны. Күзне йомдым. Бик арып-йончып төнге сменадан кайтучыга охшарга тырышам инде үземчә. Ике тапкыр кабатлады соравын колак төбемдә. «Уянмадым». Эшче сыйныфны хөрмәт итүеме, чукрак дип уйлавы булдымы — китеп барды. Ярар, ике тәңкә янга калды.

Килеп җиттем үз тукталышыма. Вәкарь белән генә төшеп киләм. Тагын контролер, дөмеккере.

— Ваш талон?

— У жены, — дидем дә артка карамыйча гына шылдым.

Утырдым икенче транспортка. Ярты юлны гына уздым, янә тикшерү:

— Талоныгызны күрсәтегез!

Күзенә туп-туры карадым да:

— Мин сезнең шәһәрдә беренче тапкыр гына, — дидем. — Әле өлгермәдем. Заводка командировкага килдем.

— Кайсы заводка?

Тинтәк. Шундый пүчтәк сорау бирәләрмени, контролер башың белән?! Үзем егерме җиде ел эшләгән әртилнең исемен белмим мени инде мин?! Чатнатып әйтеп бирдем завод-әртилнең исемен.

Монысыннан да җил-яңгыр тимәде. Заводка килеп җиттем. Төшкәндә — тагын контроль. Бу ни хикмәт бу! Үч иткәндәй, инде ничәнчесе бит. Бер көн эчендә. Инде райкомнар да юк бит. Кем куып чыгарган боларны? Монысыннан ничек котылырга? Башта тиз генә күзләремне йомдым, аннары акайттым һәм... тегенең йөзен капшый-капшый төшә башладым

Читкә тайпылды. Сукыр кешедән сорарга намусы җитмәде, ахры. Бик итагатьле кеше икән, рәхмәт төшкере.

Эш беткәч өйгә кайтасы бар бит. Чыктым заводтан, утырдым трамвайга. Чукынып кына китсеннәр инде, трамвайдан төшкәндә — тагын контролер. Гөлмәрфуга әбинең карты, заманында раскулачиваниедән чак котылып калган абзый, болайрак дип җырлый иде: «Колхоз тарала микән? Совхоз кадала микән? Чебен кебек милиция — каян ярала икән?» Контролерлары да милициядән калышмый. Бу юлы, кесә төбеннән иске талон табып алдым да, ике бармак арасына кыстырдым. Контролер каршына җиткәндә генә бармакларны җәеп җибәрдем. Талон җиргә төшеп тә китте. «Күтәр, үскәнем, бик хаҗәт булса. Миңа андый чүп-чарның кирәге юк,— дим эчтән генә.— Өйбәтләп карасам, әле тагын берничәсе кесә төбендә ятадыр.» Юк, иелмәде, контролер, уздырып җибәрде. Уф! Әле тагын бер калтырчага утырасы бар бит. Тирләп чыктым. Эшләпә астындагы пеләшемә хәтле юешләнде. Түзәм. Чөнки өйгә кайтасы бар. Ай ахырына чөллилек акча эшлисем дә бар. Тик, иртә уңмаган — кич уңмас, кич уңмаган — һич уңмас, дигәннәре хак икән. Тагын тикшерүгә юлыктым. Инде хәзер кәтилүк тә, то есть баш шәрифләре дә юньләп эшләми. Берәүдән талон сатып алдым да, тиштермичә ике бармак арасына кыстырдым, җәл бит. Сораса, онытканмын, уйланып киткәнмен, диярмен. Онытмасам да, уйга чумуым хак анысы: күз алдымда һаман шул мөлдерәмә тулы унҗиде кырлы стакан тора. Төшкәндә контролерның борын төбенә йодрыгы-ние белән суздым талонны. Куркып ук калды. Авызын да ачалмады. Ә мин инде кайтып җиттем.

Өйгә кергәч, теге яңа талонны кайнар үтүк белән тигезләдем дә, бик кадерләп, чәй кәгазенә төреп, кесәгә салып куйдым. Кирәге чыгар. Гомер озын, көн күп.

Икенче көнне дә контроль очрагач, гомердә беренче күргән юлдашым белән суверенитет, референдум мәсьәләсендә гәп куертып җибәрдем. Өченче көнне центнер ярымлы бер хатынның сыер түшкәсе хәтле аркасына ышыкланып чыгып ычкындым. Ә дүртенчесендә — бер чибәр хатынның игезәкләр арбасын балалары-ние белән арткы ишектән күтәреп төштем. Утырса, үзен дә алып чыга идем. Абзагызда көч-куәт бар, ни әйтсәң дә — авыл малае бит. Бишенче көнне гел тәрәзәдән күземне алмадым: хәйран матур икән безнең шәһәр. Беренче күрүем... Алтынчы көнне телсез булып кыландым, телсез кешегә бик миһырбанлы икән билет тикшерүчеләр. Үземә дә ошап китте телсез булып кылану. Кем әйтмешли, рольгә кердем. Бер Мәскәү артисты, Сталин ролен уйнагач, атна буе козыреклы фуражка, озын шинель киеп, ясалма мыек тагып, төрепкә тартып йөргән, диләр. Мин дә, кибеткә кергәч, ипи чиратының алдына килеп бастым да, сул кулымның имән бармагын урталай өзгәндәй итеп күрсәттем, янәсе, ярты буханка. Сатучы кыз, әллә мине таныды, миңа түм-түгәрәк күзләрен төбәп, абый, дип җәлләп нидер әйтергә теләгән иде, уң кулымның имән бармагын иренемә тидердем. Шым бул, янәсе, сеңлем, май кап.

Кыскасы, этләшеп җиттем, дөресрәге, эт каешына әйләндем. Эт димәктән, җиденче көнне тукталышта бер сукбай этне трамвайга күтәреп алып мендем һәм күтәреп төштем дә. Хайван ярата торган контролер булды.

— Нинди токым бу? — ди.

— Экстерьербарбос,— дидем күз дә йоммыйча.

Ә ул, мәнсез, авызын ачып калды. Әле шулай өч көн йөргәндер йома алмыйча. Өйрәнегез абзагыздан. Алдасаң, ышандырырлык итеп, тыңлаучының күзе шар булырлык, аскы ирене генә түгел, ияге-ние белән теш казнасы да салынып төшәрлек итеп борчак сибәргә кирәк аны. Акча янга калдырам дип, малай-шалай кебек трамвай артына асылынып йөри алмыйм бит инде мин кырыкка җиткән башым белән. Рәхәтләнеп, тулы хокуклы сәвит гражданы булып, утырып йөрим. Хәер, сәвите бетте бугай

инде. Ә контроле калды. Әнә тагын җиңенә кызыл бәйләгән ике әзмәвер тора... Алар минем төшкә керә инде хәзер. Кичә: «Не смей оскорблять! Минем билетым бар!» — дип кычкырдым һәм үземнең яшелле-зәңгәрле тавышымнан үзем куркып уяндым. Әмма, ничек итсәм итәм, билет алмыйм...

Билет тикшерүчеләрне дә әллә каян таныйм хәзер. Гадәттә, алар эш сөймәүче әзмәвер егетләр булыр. Кайвакытны ялган контролерлар да очрый. Алары белән сүз башка. Моннан унбиш ел элек мәҗбүри бирелгән дружинник билетын түш кесәмнән тартып чыгарам да: «А ну-ка, син үзең кем? — дип сорыйм. — Кая синең значогың, таныклыгың, квитанция кәгазьләрең? Әһә, фальшивый контролермы? Әйдәле...» Шундук ычкына егетем. Суворов абзаң белми әйтмәгән шул, иң яхшы саклану чарасы — үзең башлап һөҗүм итү дип... Теге егетләр икенче мине күрсәләр, танытмас өчен, оялчан кыздай башларын иеп, кооперативный ботинкаларына карап торалар.

Менә, җәмәгать, бер ай йөрдем шулай «куян» булып, дер калтырап. Бүген дә бушлай барып кайтсам, дүрт күз белән көткән, чөллилек була бит.

Бәлки бүген очрамаслар да әле... Юк, имансызлар, әнә торалар. Ничава, дим эчтән генә, бүген мин сезне шаккатырам. Һәм... Башны тилегә салдым да тотлыга торган кеше булып кыландым.

— Ваш талон? — диде контролер.

— Т-талон? С-сейчас...

— Давай быстрее!

— Хо-хо-хорошо...

— Хо-хо, давай күрсәт талоныңны!

— С-с-син нәрсә мине мыскыл итәсең?! М-мин Әфган сугышында к-контузия алган кеше. Ә с-син, кәҗә бәрәне, әле мич алдында күмер ашагансыңдыр ул вакытта. Ә мине Леонид Ильич үзе фатиха биреп кертеп җибәрде. «Бар, энне-к-кәш, дош-ш-маннарны к-кырып кайт», — диде. Ә с-син миннән тал-лон т-таптырасың!

Бик ышандырырлык әйткән сыман идем, югыйсә. Барып чыкмады. Тикшерүчеләрнең берсе үзе Әфганстанда булган икән, каһәр!

— Кайсы юнәлештә сугыштың? — ди.

— Бохарадан бире! — дидем батыр гына.

Якын-тирәдәге мужиклар кычкырып көлделәр. Вәт тинтәк, вәт тинтәк. Үзем, канишны. Кем белгән бит Әфганстанның Бохарадан ары икәнен.

Юк, булмады. Өметләр акланмады. Эләктерделәр... Иртәрәк сөенеп, уяулыкны югалтканмын. Тегеләй иттем, болай иттем, аһ-ваһ килдем, куркытып-өркетеп тә карадым, юк, хәлемә керүче булмады. Тиешле җиргә алып кереп, ыштыраф чәпәделәр. Их, баш эшләмәде! Юкса, ике талон тиштереп, трамвай номерларын хәтерләгән булсам... кирәк чакта, номерына карап, чыгарасың да күрсәтәсең. Гел бер үк трамвайлар йөри бугай бит безнең маршрутларда. Әллә алышыналар микән? Вәйт баш эшләмәде! Ә бу юлы бөтен тырышуларым, ай буена көзге яфрак кебек дер калтырап йөрүләрем бушка китте. Юк, буш түгел шул, алып калдылар, соңгы тиенемә хәтле кырып-себереп талап калдылар! Әле җитмәсә, бөтен кеше алдында мыскыл иттеләр:

— Бер куян аркасында күпме арысланның талонын тикшерергә туры килә бит! — диделәр, мәртәтләр.

— Һе. Бер чүллилек тә акча эшләргә ирек бирмәгәч, сезнең белән куян да, арыслан да булырсың!..







## ФОТОЛАРДА—

## ЗАМАН СУРӘТЕ














**Мидхәт Шакирҗанов — республикада иң өлкән һәм тәҗрибәле фоторәссамнарның берсе. Менә утыз елдан артык инде ул (төрле елларда төрле исем белән чыккан) «Ватаным Татарстан» газетасында фотохәбәрче булып эшли. Шушы гомер эчендә үзәк, республика газеталарында һәм журналларында аның 30 меңгә якын фоторәсеме дөнья күрде. Мидхәт Шакирҗанов — эзләнүчән, тынгысыз репортер: ул һәрвакыт хәрәкәттә, юлда. Республикада ул аяк басмаган, ул булмаган бер генә төбәк тә юктыр. Аның иҗатында хезмәт кешесе — игенчеләр, төзүчеләр, эшчеләр, — кыскасы, замана каһарманнары, заман сурәте үзәк урынны алып тора.**


**Мидхәт Шакирҗанов союз һәм республика күләмендәге фотокүргәзмәләрдә актив катнашып килде һәм призлы урыннарны яулады.**

**Бүген журнал укучыларыбызга Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Мидхәт Шакирҗановның кайбер иҗат үрнәкләрен тәкъдим итәбез.**

# КӘРИМЕВЛАР ЯЗМЫШЫ

Мондый хәлне, мондый фажигане хәтта иҗтимагый-сәяси фикернең бөек шәхесләргә бай тарихында да очратуы бик кыен! Бер кеше гомерендә генә дә бу гаилә әгъзалары Русия вә бөтен дөньяны тетрәткән вакыйгаларның үзәгендә калалар һәм тарихта тирән эз калдыралар. Сүз, барыннан да элек, агай-энеле өч туган Фатыйх, Гариф һәм Камил Кәримевләр турында бара.

Хәер, бу урында аларның әти-әниләрен искә алып узу да кирәктер. Ни дисәң дә, ничә еллар дәвамында без бабаларыбызның чын-чынлап нәсел җебен әйтергә оялып килдек ләбаса. Күптән түгел генә «Казан утлары» журналында бер каләмдәшебез Фатыйх Кәримине җир кешесе, игенче токымыннан дип язып чыгуын ничек аңлатырга мөмкин соң? Нигә соң без хәзер дә дөреслекне әйтүдән оялабыз. Татар халкының күренекле галиме Ибраһим Нуруллин әйтмешли, күз дә йоммый һаман да «миф» тудыруны дәвам итәбез. Бәлкем, менә гаҗәпләнергә кирәк тә түгелдер. Тарихны бозып күрсәтү бүген генә тумаган лабаса. Без хөрмәт иткән күпме галимнәр Тукай белән Насыйрины да «ата атеистлар» дип расларга маташтылар.



Әйе, әйе, менә бу кешеләргә игътибар итегез әле. Бүгенге рәсемдә — Әлмәт төбәгеннән Миңлебай авылы мәчете имамы Гыйльман ахун Кәрими гаять зур гыйлем иясе, Шиһаб Мәрҗанинең иң яраткан шәкертләреннән берсе булган кеше.

Ахун Кәрими шул чорның бөек хатын-кызы, шәрекъ дөньясында Гөлнар ханым исеме белән танылган, көнчыгыш халыклары гореф-гадәтен искиткеч әйбәт белгән, әдәбият өлкәсендәге хезмәтләре өчен христиан хатын-кызлары арасыннан беренче булып Төркиянең «шәфәкать» ордены белән бүләкләнгән Ольга Лебедева белән якыннан таныша һәм аның йогынтысы белән Оренбур каласына күчеп килә. Турыдан-туры үз вазыйфасын үтәү белән бергә, ул җиң сызганып нәширлек эше белән шөгыльләнә. Бу эштә аңа Шакир һәм Закир Рәмиевләр матди ярдәм кулы сузалар. Әмма 1902 елның июнендә Гыйльман ахунның гомере фаҗигале төстә өзелә — аны яшен атып үтерә. Бу хәл исә ахунны шундый эш белән шөгыльләнгән өчен алла сукты дигән уйдырмалар тууга сәбәп була. Хәер, тиз арада гайбәткә юл ябыла. Ахунның хатыны, бик нык ихтыяр көченә ия булган Мәгъсүмә абыстай үзенең абыйсы — атаклы галим, дин белгече һәм әдип Риза Фәхретдиневка мөрәҗәгать итә. Үз чиратында ул, Рәмиевләр белән бергә, Гыйльман ахунның үлеменә һич кенә дә нәширлек эше сәбәп булмавын аңлатып бирә.

Гыйльман ахунның балаларының язмышы да төрлечә языла. Фатыйх Кәрими хакында бездә дә, чит илләрдә дә күп язмалар сакланып калынган. Мәсәлән, аның хакында Мөхәммәт Гайнуллин белән Тамурбәк Дәүләтшин кызыклы мәгълүматлар китерәләр. Гайнуллин әлеге шәхес хакында ачыктан-ачык, ул ахун мулла гаиләсендә туган, дип яза. Бу үзе үк

галимнең һәр эшкә намус белән каравы турында сөйли.



Әмма шунысы аянычлы, күренекле әдип, галим һәм журналист Фатыйх Кәрими дә 1937 елда бик күп татар зыялыларының ачы язмышына дучар була һәм аның гомере канлы террор тарафыннан өзелә. Әлеге фоторәсемгә ул 1898 елда, Станбул каласына килгәч төшкән.

Ә бу фоторәсемдә исә шушы атаклы гаиләнең калган әгъзалары тасвирлана. Алдагы рәттә утыралар: Гасыймә Кәримева һәм аның ире — танылган журналист, нашир Тимерша Соловьев; басып торалар: сулда — танылган юрист һәм милли хәрәкәт эшлеклесе Камил Кәрими. Ул 1949 елда Казанда үлә. Гәрчә репрессия җиле аны читләп узса да, «халык дошманнары» булган туганнары турында гомере буена аның исенә төшереп торалар. Камил белән янәшәдә Гариф Кәрими басып тора. Берничә ел элек кенә бу кеше хакында матбугат битләрендә язып чыгу мөмкин эш түгел иде. Шуңа да, аның турында кинрәк сөйләрбез.

Бер дигән экономист, оештыручы Гариф Кәрими революция алды елларында ук үзенең җәмгыятькә кыю карашы белән киң танылa. Аерата ул Гаяз Исхакый үткәргән фикерләрне хуп күрә. Үзе бер генә фиркада да әгъза булып тормаса да, атаклы публицист Бари Баттал язып калдырганча, «кыргый фиркасыз» дигән дан казана.

«Идел-Урал» идеясе көчәйгән һәм үз эшен «милли мәҗлес» һәм «милли идарә» аркылы уздырган бер вакытта, премьер Садри Максуди белән берлектә, Гариф Кәрими дә бу хөкүмәтнең иң күренекле эшлеклеләреннән берсе буларак танылa. Финанс ведомствосы башлыгы итеп Шәйхулла Алкин сайлана. Шул чорның күренекле җәмәгать эшлеклеләре Сәлимгәрәй Җантурин, Латыйф Яушев, Гали Кормай, Гобәйдулла Буби, Зәйнетдин Агафуров һәм Гариф Кәрими коллегиягә әгъза булып керәләр. Гарифның язмышы да әлеге хөкүмәтнең драматик язмышыннан аерылгысыз. Ул да шушы хөкүмәт вәкилләре белән чит илгә китәргә мәҗбүр була. Егерменче еллар ахырында ул чит илләрдә большевизмга каршы көрәш үзәкләреннән саналган «Идел-Урал» комитетында Гаяз Исхакыйның чын-чынлап урынбасары була. Г. Исхакый Ерак көнчыгышка озак вакытка сәяхәткә киткәндә, Гариф Кәрими асылда үзе генә «Яңа милли юл» журналын нәшер итә. Бу журнал төрле юллар белән, бигрәк тә Польша һәм Алмания илчелекләре аркылы, совет иленә үтеп керә, власть ияләрендә шактый зур шик вә шөбһә тудыра. Анда күпчелек мәкаләләр Г. Кәрими кулы белән язылган. Ләкин ул аларны журналга Осман бай дигән төрек исеме астында бирә. Бер үк вакытта якташыбыз Европаның байтак илләрендә идел-уралчылар эшен җитәкли.

1934 елда татар мөһаҗирият җәмәгатьчелеге кайгылы вакыйга турында



ишетә: Гариф Кәрими үз-үзенә кул сала. Төркиядә моңарчы беркем дә аның серле үлемен тикшермәгән. Ләкин бу иң әүвәле ОГПУ һәм аның агентлары эше дигән сүзләр дә йөри. Әлбәттә, хәзер аның сәяси үтерүме, әллә үз-үзенә кул салу гынамы икәнен әйтү кыен. Шул ук вакытта якын елларда гына разведка архивына үтеп кереп булыр дип тә әйтеп булмый. Ләкин чит илләрдәге сәяси дошманнарны юк итү алымнары тәгаен ачыкланганлыктан, Гариф Кәриминең серле үлемендә ОГПУ кулы уйнамаган дип инкарь итәргә иртәрәк әле. Чөнки совет разведкасының чит илләрдә ниләр кылганлыгын хәзер ачыктан-ачык язалар. Шулай ук Гаяз Исхакый янында да шымчыларның күпләп йөргәне билгеле. Һәрхәлдә, Гариф Кәрими эшчәнлеге совет органнарын һич тынычлыкта калдырмаган. Монысы инде бәхәссез.

Ә хәзер, кадерле укучылар, бу рәсемнәрдәге кешеләрнең йөзенә дикъкать белән тагын бер күз төшерегез әле. Аларның һәркайсы киләчәккә ышаныч белән карый. Гыйльман ахун да, аның уллары да үзләренең фаҗигале язмышлары хакында уйларына да китермәгәннәрдер...

Фоторәсемнәр матбугатта беренче тапкыр басыла.

**Булат СОЛТАНБӘК.**

### Безнең календарь

## Мөхәммәт Гайнуллин

**(1903—1985)**

1903 елның 18 августында хәзерге Татарстанның Апас районы Кызыл Тау (Коллар) авылында игенче гаиләсендә туа. Шунда җиде сыйныфлы җәдит мәктәбен тәмамлый. Тәтеш укытучылык курсларыннан соң, мәктәптә балалар укыта.

1928 елда ул Казанга килә һәм Көнчыгыш педагогия институтының башта филология факультетында, аннары аспирантурасында белем ала. Шул дәвердә әүвәлге фәнни тикшеренүләрен башлап җибәрә, аспирантура чорында институтның татар теле-әдәбияты бүлегендә лекцияләр сөйләргә керешә. Шушы шөгыль аны татар әдәбияты тарихы буенча җитди эзләнүләргә этәрә. Утызынчы елларда Г. Камал, Г. Тукай, Ш. Камал һ. б. язучыларыбызның иҗатын яктырткан хезмәтләре вакытлы матбугатта дөнья күрә. XX йөз татар әдәбияты буенча төзи башлаган дәреслек-хрестоматиясе 1947 елда тәмамланып, аерым китап булып басылып чыга һәм озак вакыт югары уку йортлары студентлары өчен кыйммәтле чыганак хезмәтен үти.

Кырыгынчы елларда М. Гайнуллин Казан педагогия институтында укыта, Татарстан дәүләт нәшрияты идарәчесе, СССР ФА Тел, әдәбият һәм тарих институты директоры вазифаларын башкара. Бер үк вакытта фәнни тикшеренүләрен дә дәвам итә — «Горький һәм татар әдәбияты», «Каюм Насыйри» китапларын бастыра. 1946 елда «XIX йөз азагы һәм XX йөз башы татар әдәбияты» дигән темага диссертация яклап, филология фәннәре кандидаты исемен ала.

Илленче-алтмышынчы елларда галим XIX йөз — XX гасыр башы татар әдәбияты тарихын тагын да тирәнрәк өйрәнергә керешә — К. Насыйри, З.Һади, З. Бигиев, М. Акъегетзадә, Дәрдмәнд, С. Рәмиев, Ш. Мөхәммәдев кебек язучы-

ларның тормышы һәм иҗаты турында материалларны барлый, шул шәхесләрнең туганнары, якыннары кулында саклаган кульязмаларны, документларны архивка җыя һәм аларны фәнни әйләнешкә кертеп җибәрә. Татар әдәбият белемен вульгар социология кысымыннан арындыруда адым арты адым ясап, әдәби мирасыбызны мөмкин кадәр тулырак күләмдә укучыларга кайтару өлкәсендә җиң сызганып эшли. Шуның нәтиҗәсендә Риза Фәхретдинев, Фатыйх Кәрими, Галиәсгар Гафуров-Чыгтай кебек әдипләребезнең әсәрләре тикшерелә, аларның әдәбиятыбыз һәм иҗтимагый аңыбыз үсешендәге урыннары билгеләнә, исемнәре онытыла башлаган Газизә Сәмитова, Мәһруй Мозаффария, Зәйнәп Сәгыйдә, Заһидә Борнашева, Мәхүпҗамал Акчуриналар да җәмәгатьчелек игътибарына тәкъдим ителә.

Эзләнүләрен киңәйтә барып, М. Гайнуллин милли матбугатыбыз, әдәби тәнкыйтебез үсешен тикшерүгә дә күп көчен куя. Шул эшчәнлеге нәтиҗәсендә ул 1958 елда «Беренче урыс революциясе чорында татар әдәбияты һәм публицистикасы» дигән темага докторлык диссертациясе яклый. Аның бу хезмәте урыс телендә аерым китап булып басылып та чыга. Аннары бер-бер артлы «XIX йөз татар әдәбияты», «XX йөз татар әдәбияты», «Татар мәгърифәтчелек әдәбияты» дәреслек-хрестоматияләре, «Дуслыкта көч», «Татар әдипләре» җыентыклары, урыс телендә «Татарская литература XIX века» монографиясе дөнья күрә, вакытлы матбугатта галимнең йөзләрчә мәкаләләре нәшер ителә.

Галим шул ук вакытта югары уку йортларында укытуын да дәвам кыла, фәнни белгечләр әзерли, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты директоры вазифаларын башкарганда (1945—1953, 1959—1961) татар филологиясен һәм тарихын, иҗтимагый фикерен өйрәнү юнәлешендә оештыру эшләрен алып бара. Заманында репрессияләнгән язучылар һәм галимнәребезнең, җөмләдән, Гаяз Исхакыйның мирасын өйрәнүне башлап җибәрә, аларны аклау буенча мөгълүм тырышлык куя.

М. Гайнуллинның мәктәп дәреслекләре язу, әдипләребезнең һәм шагыйрьләребезнең җыентыкларын төзү, аларны матбугатка әзерләү, кереш сүз белән тәэмин итү һәм редакцияләү, Мәскәү чыгарган «Краткая литературная энциклопедия»гә татар әдәбияты турында мәкаләләр язу, шушы басманың бер киңәшчесе һәм редакторы булу кебек хезмәтләре дә ихтирамга лаек.

Татарстанның һәм РСФСРның атказанган фән эшлеклесе, Язучылар берлеге әгъзасы (1957) Мөхәммәт Хәйрулла улы Гайнуллин безгә бай мирас калдырды — аның хезмәтләре бүген дә меңләгән укучыларның кулыннан төшми, туксан еллыгы уңаеннан, без аны бүген дә тирән хөрмәт белән сагынып искә алабыз.

*Латин әлифбасы нигезендә*

*татарча уку күнекмәләре*

MӨXƏMMƏDSALIX ÇӨNƏJ

MƏSÇIDKƏ

Əj, mөkətdəs Təꞑreneꞑ nurlь qaderle paq өe,
cьn kyꞑeldən hər mөselmannьꞑ sөjgən ap-paq өe!
Kykkə suzьlƣan manaraꞑ ilgə jaqtьlьq birə,
kyreneşe cittən də mөəmingə anьꞑ şatlьq bire.
Janƣьrap andan azan ujƣata mөəmin bəndəne,
iꞑ sөjekle izge tavьşdьr azan əjtkəndəge.
Sineꞑ izge mixrabьꞑ izge imamnarƣa urьn,
cəcəder uqьp imam andan ajatlarnьꞑ nurьn.
Өjrətelə mөnbərdən tuƣrь, izge, jaqtь jul,
kem aꞑa kersə ijərep tuƣrь, izge, jaxşь ul.
Kөtə mөəmin şatlanьp çomƣa namazlar soltanьn,
paqladь ul siꞑa kilep şul kөndə tənen və çanьn.
Kilə mөəminlər siꞑa, qalmьj namaz vaqtь saen,
itələr qollьq Xodajƣa, əjtələr həm aj-vajen.
Sində mөəmin ber bere ilə kyreşə, sində beregəder,
aşra mөəminne siꞑa kily - julƣa kertəder.

1925

---

Башы журналыбызның 7 нче санында.

## XAN MƏCETE

Hər binadan beek bulьp, kyklərgə cьqmьş başьŋ,
min beləm belderməsəŋ də, aƣadьr qanlь jəşeŋ.
Bu xəleŋdən şiqajət qьldь sineŋ hər ber taşьŋ,

Qalbemne meŋ pare qьldь şul gyzəl Xan Məcete.

Ber zamanlar sində namaz uqьƣanlar xan ide,
qavme Tatar həm Terekneŋ məkəne Kazan ide.
Ul vaqьtnь təsvir itsək, ne gyzəl zaman ide,

Qalbemne meŋ pare qьldь şul gyzəl Xan Məcete.

Hər kilisə urtasьnda jalƣьzьŋ qaldьŋ nicen?
Iltifatьŋ bez Tatardan, sin bina, aldьŋ nicen?
Əhle Islam qalbenə sin xəsrətne saldьŋ nicen?

Qalbemne meŋ pare qьldь şul gyzəl Xam Məcete.

Ber vaqьtta sində tordь əhle Islam gəskəre,
şefkəteŋ bette bygen də, qalmadь meŋdə bere.
Başqalarnьŋ çire buldь, uşbu ken Islam çire,

## ЧИРАТТАГЫ СЕССИЯ

12—15 июльдә Татарстан Югары Советының XVII сессиясе эшләде. Анда республикабызның бәйсезлеген ныгыту буенча байтак адымнар ясалды — яңа законнар һәм карарлар кабул ителде. Ә шулай да бу сессия эшендәге иң истә кала торган яңалык — Татарстанның гимнын кабул итү булды. Шулай итеп хәзер республикабызның үз флагы, үз гербы һәм үз гимны бар!

## ВЕНГРИЯ ПРЕЗИДЕНТЫ КИЛДЕ

1993 елның 3 июленнән 4 июлена кадәр Венгрия Республикасы Президенты А. Генц Татарстан Республикасында визит белән булды.

Визит барышында А. Генц Татарстан Республикасы Президенты М. Шәймиев, Югары Совет Рәисе Ф. Мөхәммәтшин, Премьер-министр М. Сабиров, республиканың башка җитәкчеләре белән сөйләшүләр алып барды.

Венгрия Республикасы Президенты Татарстан Республикасы башкаласының истәлекле урыннары белән танышты, фән һәм мәдәният хезмәткәрләре, эшлекле даирәләр вәкилләре белән очрашты.

Үзара аңлашу һәм татулык шартларында узган сөйләшүләр барышында ике якны да кызыксындырган күптөрле мәсьәләләр тикшерелде.

Яклар Венгрия һәм Татарстанның уртак тарихи тамырлары, шулай ук икътисад, мәдәният һәм фән даирәсендә бүгенге көнгә урнашкан элемтәләр барлык өлкәләрдә мөнәсәбәтләрне камилләштерү өчен ышанычлы нигез, дигән уртак фикердә торалар.

Яклар 1992 елның 4 ноябрендәге сәүдә-икътисади һәм фәнни-техник хезмәттәшлек турында килешүнең һәм 1993 елның 11 маенда төзелгән Венгрия Республикасы һәм Татарстан Республикасы арасында 1993—1998 елларда сәүдә-икътисади хезмәттәшлегенең төп юнәлешләре хакында килешү положениеләрен уңышлы рәвештә тормышка ашыру халыкларыбыз арасында дуслыкны һәм хезмәттәшлекне сыйфат ягыннан тагын да югарырак дәрәҗәдә үстерү өчен объектив алшартлар тудырачак, дигән ышаныч белдерделәр.

Фән, мәдәният, мәгариф, сәламәтлек саклау, спорт һәм туризм өлкәләрендә үзара мөнәсәбәтләрне ике якның да үстерергә омтылуы хакында әйтелде.

Эшлекле һәм файдалы бу визит Венгрия һәм Татарстан арасындагы элемтәләрне ныгытуга зур өлеш кертер, үзара файдалы хезмәттәшлекнең активлашуына ярдәм итәр.

## «АК КАЛФАК» ҖЫЕЛДЫ

25 июньдә «Ак калфак» бөтентатар хатын-кызлар ассоциациясенең пленумы булды.

Пленумга Санкт-Петербург, Кишинев, Рига, Пермь, Самара, Уфа шәһәрләреннән, Себер, Казахстан, Үзбәксан якларыннан, Финляндия һәм АКШтан, хәтта Шри-Ланкадан делегат хатын-кызлар җыелган иде.

Пленум әлеге ассоциациянең Казандагы һәм Хельсинкидагы үзәкләре тырышлыгы белән уздырылды. Алдагы елны ЮНЕСКО гаилә елы дип игълан итте. Шуңа күрә пленумда татар гаиләсенең ныклыгы, йолаларның дәвамлылыгы, гореф-гадәтләргә тугрылык хакында уртага салып сөйләшенде.

Ассоциациянең президенты, «Сөембикә» журналының баш редакторы Р. Р. Туфитуллованың чыгышын тыңлаганнан соң төрле төбәкләрдән килгән хатын-кызлар эш тәҗрибәсен уртаклаштылар, максатка ирешүдә нинди алымнар отышлы булу хакында фикерләштеләр.

Эшләнгән һәм эшләнәсе эшләр турында зур сөйләшү соңында пленум Татарстан Министрлар кабинетына мөрәҗәгать кабул итте. Анда хөкүмәт органнарында хатын-кызлар мәсьәләләре белән шөгыльләнүче махсус структура төзү зарурлыгы турында әйтелә.

## ИҖАТ БЕРЛЕКЛӘРЕНӘ ӨСТЕНЛЕКЛӘР

Татарстан Министрлар Кабинеты Мәдәният министрлыгын, язучылар, композиторлар, рәссамнар, театр эшлеклеләре, кинематографистлар, журналистлар, архитекторлар берлекләрен, музыка җәмгыятен һәм алар тарафыннан оештырылган предприятиеләрне табыштан салым түләүдән азат итү турында карар чыгарды. Республика энергетика комиссиясенә, Элемтә министрлыгына, «Водоканал», «Таткоммунэнерго», «Татэнерго» берләшмәләренә югарыда күрсәтелгән иҗат берлекләренә һәм аларның предприятиеләренә хезмәт күрсәтү өчен түләүләрне бюджеттагы мәдәният-агарту учреждениеләре тарифлары буенча оештырырга кушылды.

## САЛИХ СӘЙДӘШЕВ МУЗЕЕ АЧЫЛДЫ

Казанның М. Горький урамындагы 13 нче йортта татар халкының сөекле композиторы Салих Сәйдәшев музее ачылды. Мәшһүр композиторыбызь 25 елга якын гомерен шушы йортта үткәргән.

Тантананы Татарстан Республикасы мәдәният министры урынбасары М. Низамиев кереш сүз белән башлады.

Аннары Татарстан Фәннәр Академиясе Президенты М. Хәсәнов, Композиторлар берлеге рәисе Р. Кәлимуллин, композитор Ә. Бакиров, язучы Г. Ахунов, композиторның улы Альфред Сәйдәшев чыгыш ясады.

Музейны ачуда Татарстан Республикасы Югары Советы Рәисенең беренче урынбасары З. Вәлиева катнашты.

Салих Сәйдәшев музее директоры Я. Шәмсетдинов бу истәлек йортының киләчәктә ничек эшләячәге турында сөйләде.

Аннары Татарстанның сәнгать осталары, Уфа «Нур» татар дәүләт театры артистлары Салих Сәйдәшев әсәрләреннән зур концерт куйдылар.

## САРА САДЫЙКОВА ФОНДЫ ОЕШТЫ

Татар дөньясында мәдәниятне үстерүгә хезмәт итүче тагын бер фонд оешты. Бусы сөекле композиторыбыз, республиканың Г. Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты Сара Садыйкованың исемен мәңгеләштерү һәм иҗатын пропагандалауны күз уңында тота.

Шул уңай белән үткәрелгән җыелышта Татарстан иҗат берлекләре вәкилләре, журналистлар, Апас районы администрациясе башлыгы урынбасары Рәмис Ногманов, Сара Садыйкованың кызы Әлфия Айдарская, танылган җырчыларыбыз, шагыйрьләр катнашты. Алар яңа фондның Устав проектын тикшерделәр, яраткан композиторыбызның 90 еллык юбилеена әзерлек эшләрен бүгеннән үк башлап җибәрү, аерым алганда, Апас районының Тутай авылындагы кебек, Казанда да аның музеен булдыру, бай мирасын халыкка җиткерү һәм башкалабызның бер мәйданында зур һәйкәлен ачу турындагы фикерләре белән уртаклаштылар.

Фондны оештыру җыелышында 9 кешедән торган идарә составы һәм аның рәисе итеп «Казан» милли-мәдәни үзәге директоры урынбасары, Сара Садыйкованың бай мирасын туплау буенча күп хезмәт куйган Әзһәр Хәсәенов сайланды.

## ЮЛЛАР ТАТАРСТАНГА ИЛТӘ

Тугандаш Башкортстанда яшәүче милләттәшләребез Җөмһүриятебезгә су юлы белән — махсус теплоходта килделәр. Уфа кунаклары арасында татар теле һәм әдәбияты укытучылары, мәгариф министрлыгы хезмәткәрләре, педагогия институты һәм университет укытучылары, галимнәр белән бергә Башкортстанның халык артистлары Илсәяр Газетдинова һәм язучылардан Башкортстанның халык шагыйре Нажар Нәҗми, Габдулла Байбурин, Суфиян Сафуанов, Рәшит Гатауллин, Марис Нәзиров h. б. бар иде. 18—20 июнь көннәрендә алар Шәһре Болгарда булырга, Казан белән танышырга, Татарстанның халык язучысы Әмирхан Еники белән очрашырга, «Укытучылар йортында үткәрелгән семинар-киңәшмәдә катнашып, татар телен һәм әдәбиятын Башкортстанда укыту, гамәлгә кертү турында сөйләшүдә катнашырга да өлгерделәр.

Болгарда кунаклар белән очрашуга шагыйрьләребез Г. Зәйнашева, Р. Гаташ, Р. Миңнуллин, Г. Садә һәм җырчы, Татарстанның халык артисты З. Сәхабиевалар килделәр — теплоход салонында әдәби-музыкаль кичә уздырылды.

## «СИРАТ КҮПЕРЕ» — ТӨРЕК ТЕЛЕНДӘ

Соңгы вакытта Татарстан белән Төркия арасындагы күпкырлы бәйләнешләр әдәбият-сәнгать хезмәткәрләре арасында иҗади дуслыкка да ярдәм итә. Күптән түгел төрек дөньясын өйрәнү фонды нәшриятында татар язучысы Ринат Мөхәммәдиевнең Г. Тукай исемендәге дәүләт бүләгенә лаек булган «Сират күпере» романы төрек телендә басылып чыкты.

Мирсәет Солтангалиев турындагы бу китапны татарчадан төрекчәгә Измир университеты доценты язучы Мостафа Өнәр тәрҗемә иткән.

Китап Истанбул университеты профессоры, доктор, мәшһүр җәмәгать эшлеклесе Туран Язганның кереш сүзе белән ачыла.

Китапта Мирсәетнең һәм аның туганнарының фоторәсемнәре һәм күп кенә документлар беренче тапкыр дөнья күрә. 450 битлек бу хезмәт Төркиядә зур кызыксыну уятты.

Бу китапның Төркиядә дөнья күрүе яңа мәдәни бәйләнешләргә юл ача. Хәзер Татарстан Язучылар берлеге төрек телендә чыгару өчен татар хикәяләре һәм татар шигърияте антологияләрен төзеп бирде. Алар Әнкара шәһәрендә якын арада дөньяга чыгару өчен әзерләнә.

## МӘСКӘҮДӘ САБАН ТУЕ

Татарларның иң гүзәл милли бәйрәмнәренең берсе — Сабан туйлары Татарстанда һәм БДБ илләрендә матур итеп үткәрелде. Ул Мәскәүдә дә булып узды.

Милләттәшләребез генә түгел, башкортлар, казах, үзбәк, руслар да агылды бу бәйрәмгә. Измайлово паркы дәртле җыр-биюләрдән, чүлмәк вату, аркан тартышу, гер күтәрү, кул көрәштерү, баганага менү кебек уеннардан, кибетләр тирәсендәге ыгы-зыгыдан гөр килеп торды. Гадәттәгечә, халыкның күпчелеге зур мәйдан тирәли утырып, пәһлеваннар көрәшен карады. Җитезләр, кыюлар, шаяннар өйләренә Сабан туе бүләкләре алып таралыштылар.

Бәйрәмне оештыруда «Туган тел» җәмгыяте һәм Мәскәү мәчете имам-Хатибы Равил хәзрәт Гайнетдин башлап йөрде.

## МОРЗАЛАР ҖЫЕЛЫШЫНДА

2 майда Уфада «Татар морзалары мәҗлесе»нең чираттагы җыелышы булып үтте. Анда, махсус чакыру буенча, Казаннан Татарстанның халык язучысы Әмирхан ага Еники һәм аның хәләл җефете — күренекле галим Ш. Мәрҗани оныгының кызы Нәҗия Таһир кызы катнашты.

# РӘССАМНЫҢ УРЫНЫ ТҮРДӘН

Табигать күренешләрен төшермәгән рәссам юктыр ул дөньяда. Яшь татар рәссамы Илдар Бикбулатов та бу жанрга еш мөрәҗәгать итә. Әмма аның иҗатында шәһәр пейзажы, дөресрәге — Уфа каласы күренешләре өстенлек алып тора. Гәрчә ул үзе 1953 елда Белорет шәһәрендә туып үссә дә, 70 нче еллардан бирле Уфада яши. Сәнгать училищесында укый, аннары үзенең осталыгын Сәнгать институтында чарлый. Республика, зона һәм илкүләм күргәзмәләрдә катнаша.

1990 елда Санкт-Петербургта ТАТАРТ исеме белән узган күргәзмәдә Илдар тамашачы ихтирамын казана. Татар сәнгатендә легендага әверелгән «Чыңгызхан» оешмасы әгъзасы булган бу яшь автор үзенә генә хас сәләткә ия авангардчы рәссам буларак шөһрәт казана.

Аның укучылар игътибарына тәкъдим ителгән бу әсәре «Комач төсендәге мәчет» дип атала. Уфада булган кеше, әлбәттә, аны шунда ук танып ала. Хәлбуки, автор һич кенә дә бу мәчетнең фотокүчермәсен төшерүне максат итеп куймый, әмма үзенең эчке кичереше ярдәмендә аның образын, үзгә-үзенчәлекле эмоциональ төзелешен тулы канлы итеп тасвирлый. Монда күпмедер дәрәҗәдә француз импрессионистларының нинди дә булса образны билгеле бер вакыт мизгелендә ачып бирү традициясе чагыла. Рәссам мәчетне комач төсендә итеп кичке шәфәкъ нурында күрә. Гомумән, аның иҗатында бу алым төрле төсләр яссылыгында кабатлана: рәссамның бер рәсемендә мәчет күгелҗем-зәңгәрсу нур эчендә, икенчесендә ул ап-ак төстә. Һәр юлы мәчет манарасы, ярымай яңа ягы белән ачыла, һәр юлы кабатланмас һәм үзгә. Шәһәрдә бүгенгәчә сакланып калган бердәнбер бу мәчет образы бер картинадан икенчесенә күчеп килә. Шунысын да әйтик, ул архитектура корылмасы булудан бигрәк — символ. Шәһәрнең, татар мәдәнияте традицияләренең яңадан туууын аңлауга бер ачкыч. Шул ук вакытта халык хәтере ул. Анда халыкның узганы һәм киләчәге чагыла.

Картинаның композициясе төс тажлары тәэсиренә корылган. Зәңгәр, ак, кызыл төсләр бәйләмен куллану — гомумән шәрекъ мәдәниятенә хас традиция. Моның өчен мисалны ерактан эзләп йөрисе дә түгел, борынгы сөлгеләрне генә күз алдына китерегез. Ал-кызыл төсләр фонындагы нәкыш-чәчәкләр кемнәр күңеленә генә канат куймаган икән? Ә зәңгәр һәм ак төсләр бәйләнеше һәр авыл йортына таныш. Димәк, рәссам да тикмәгә генә бу алымны искә төшермәгән. Шул рәвешчә, ул, мәчет образыннан файдаланып, бүгенгене болгар-татарның ерак гасырлардан килгән традицияләренә илтеп бәйли. Шәрекъ белән бәйләнеш, барыннан да әүвәле, әсәрнең тематикасына, бөтен деталь-образларның орнамент-бизәк аша ачып бирелүенә килеп тоташа. Монда һәммәсе туры сызыклар, гомумиләштерелгән формалар аркылы ачып бирелә.

Әлбәттә, И. Бикбулатов пейзажларында беренче карашка милли хәрәкәт сизелми кебек. Әмма шунысы ачык, алар тиз арада, бер карауда гына туган образлар түгел. Аларда — рәссамның тирәнтен уйлануы, безнең тарих, безнең мирас.

Илдар Бикбулатов әсәрләрендә шулай ук сүзләргә урын юк. Кешеләр дә, башка персонажлар да тасвир ителми аларда. Рәссам үз фикерен архитектура, йортлар, урамнар — кыскасы, шәһәр күренеше аша җиткерә. Кыскасы, бу рәсемнәрдә — чор сулышы, ерак тарих эзе... Рәссам безне рухи дөньяда үз урыныңны ачык тоярга һәм милли хисеңне кадерләп сакларга чакыра.

**Гүзәл ВӘЛИЕВА-СӨЛӘЙМӘНОВА.**

**Юрий ФИЛИМОНОВ** фотосурәте

Тышлыкның дүртенче битендә: язучы һәм публицист Рахмай Хисмәтуллин.

**Дмитрий БУНТУКОВ** фотосурәте.

# ЯҢА КИТАПЛАР




**Равил ФӘЙЗУЛЛИН. Сайланма әсәрләр. Ике томда. I том. Шигырьләр, поэмалар, миниатюралар. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1992.**

*Китапханәләргә кергәч бөрешеп калам*
*Китап киштәләре алдында.*

Равил Фәйзуллин Китап дигән изге затка мәдхия җырлап, заманында шулай дип язган иде. Гомумән ул китапка, «ташка басылган» сүзгә, туган телгә ихтирам белән карый торган шагыйрь. Аның күп кенә әсәрләре шушы темага багышланганнар да. Бу гаҗәп тә түгел, чөнки аның язмышы — китапларда; китаплар — аның гомер сәхифәләренең елъязмачысы. Туган телендә шагыйрьнең ике дистәгә якын китабы дөнья күрде. Татарстан китап нәшрияты шигырь сөючеләргә тагын бер олы бүләк әзерләде — шагыйрьнең 2 томлык сайланма әсәрләрен бастырып чыгарды. Беренче томга 1958—1971 елларда иҗат ителгән шигырьләр тупланган. Китап «Үсмерчак дәфтәреннән», «Яшьлек дәфтәреннән», «Солдат дәфтәреннән», «Әмәт дәфтәреннән», «Әлмәт дәфтәреннән» һәм «Кыска шигырьләр» дигән бүлекләрдән тора.

Равил ФӘЙЗУЛЛИН. Сайланма әсәрләр. Ике томда. 2 том. Шигырьләр, поэмалар, миниатюралар. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1993.




Сүз дә юк, Равил Фәйзуллинның ике томлык «Сайланма әсәрләр» җыентыгы басылып чыгу, шагыйрьнең үзе өчен генә түгел, бөтен татар әдәби хәрәкәтендә шатлыклы вә билгеләп үтәрлек вакыйга, һәр яктан тәкъдир итәрлек күренеш булды. Шулай итеп, ниһаять, танылган шагыйрь, җәмәгать эшлеклесе, Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Равил Фәйзуллинның киң колачлы, тирән эчтәлекле, гуманистик рух белән сугарылган иҗатын бердәм күзалларга мөмкинлек туды. «Сайланма әсәрләр»нең икенче китабына 1972—1982 елларда иҗат ителгән шигырьләре, балалар өчен язылган әсәрләре һәм поэмалар тупланган.

Һәр ике том да зур зәвык белән бизәлгән, әсәрләр хронологик тәртиптә урнаштырылган. Болар барсы да шагыйрьнең эволюцион үсешен ачыграк күзалларга ярдәм итәр, дип ышанасы килә.

Якындагы кибетләрдән таба алмасагыз, бу китапларны түбәндәге адрес белән соратып алдырырга мөмкин:

**420084, Казан шәһәре, Куйбышев урамы, 3. 13 иче китап кибете, «Китап-почта» бүлеге.**

Бәясе 30 сум

Индекс 73210



КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)

Журнал включен в центральный каталог